ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

6.2007



# Татарстан Республикасы Президенты
# УКАЗЫ

## 2007 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында



*Р. Вәлиев*



*Р. Кәлимуллин*



*Р. Нигъмәтуллина, И. Рогожина, М. Нигъмәтуллина*

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре комиссиясе тәкъдимен карагач, карар бирәм:

2007 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1. Язучы, шагыйрь **Вәлиев Разил Исмәгыйль улына**—«Иске сәгать дөрес йөри» дигән проза әсәрләре җыентыгы өчен, Татарстан китап нәшрияты, 2004 ел, һәм «Ядкарь» җырлар китабы өчен, «Рухият» нәшрияты, 2005 ел.

2. Композитор **Кәлимуллин Рәшит Фәһим улына**—соңгы елларда иҗат ителгән симфонияләре өчен: кыллы уен кораллары өчен «Тукай моңнары» симфониясе (1997 ел), хор һәм симфоник оркестр өчен «Казанны сагыну» концерт-поэмасы (2004 ел), симфоник оркестр өчен музыка «Урман авазлары» (2003 ел).

3. **Нигъмәтуллина Рада Хөсәен кызы, Рогожина Изабелла Викторовна, Нигъмәтуллина Марина Викторовна** составындагы авторлар төркеменә – «Тукайга мәхәббәт белән» дигән скульптор эшләр сериясе өчен.

**Татарстан Республикасы Президенты** **М. Ш. ШӘЙМИЕВ**

*Казан, Кремль*
*2007 ел, 24 апрель № ПУ–210*

# Казан утлары
# Qazan utları

2007

**6**

**(1016)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*«Татмедиа» массакүләм коммуникацияләр буенча Татарстан Республикасы агентлыгы һәм Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Раиф Мәрданов, Рашат Низами, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Гәрәй РӘХИМ. Дусларым аңлар минем бу халәтне... *Шигырьләр.* ........ 5
Камил КӘРИМОВ. Уен. *Роман.* ........ 8
Фарсель ЗЫЯТДИНОВ. Кошлар теле дәшә яхшыга. *Шигырьләр.* ........ 60
Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА. Гомер – үтәр, гөлләр – калырлар... *Шигырьләр.* ........ 64
Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН. Балачакта калачак. *Парчалар.* ........ 68
Әмир МӘХМҮДОВ. Дим буеның шагыйрьләре. *Шигырьләр.* ........ 75
Лилия ГАЗИЗОВА. Татарчамы, урысчамы – гамем. *Шигырьләр.* ........ 79

**ӘДӘБИ МИРАС**

Гөлчәчәк ГАЛИЕВА. Атылган йолдыз кеби... ........ 82
Тәбриз МӨБАРӘКОВ. Гөл әби. *Хикәя.* ........ 84

**ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ**

Илфак ИБРАҺИМОВ. Әдәбият һәм сәнгать елы. ........ 90
Ләбиб ЛЕРОН. Хәлең ничек, татар прозасы? ........ 96
Әхмәт РӘШИТ. Шигъри хәзинәдә ниләр бар? ........ 102
Гали АРСЛАНОВ. Еллык драматургия. ........ 108
Газинур МОРАТ. Караңгылыкны сүккәнче, шәм кабыз. ........ 112
Равил РАХМАНИ. Милләт үсешенең көзгесе. ........ 115
Азат ӘХМӘДУЛЛИН. Боз кузгалырга итә. ........ 121

**ХӘТЕР**

Г. ГАЗИЗ. Татар телендәме, рус телендәме? ........ 125

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. ........ 128
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ........ 132

**АККОШ КҮЛЕ – ИЛҺАМ АЛАНЫ**

Мөдәррис ВӘЛИЕВ. «Аккош күле»ндә әдипләр чуагы. ........ 137
Зөфәр БӘШИРОВ. Сурәтләрдә тарих «күзе» ........ 138
Ләбибә ИХСАНОВА. Истәлекле җәй. ........ 145
Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Әдипләрнең гамь бишеге. ........ 149

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Нәгыйм МӨХИБУЛЛИН. «Сөлчә буенда» язылмый калды. ........ 161

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Рашат НИЗАМИ. Тәнкыйть тә – тирән дәрьядыр ........ 169

**АК ҖИЛКӘН**

Алия ГАБДЕЛХАКОВА. Тарту көче. Хикәя. ........ 179

«Казан утлары» архивыннан ........ 185
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 187

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман К. КАРИМОВА «Игра» (начало); рассказы-миниатюры Г. МУХАМЕТШИНА; стихи Г. РАХИМА, Ф. ЗИЯТДИНОВА, Э. ШАРИФУЛЛИНОЙ, А. МАХМУДОВА, Л. ГАЗИЗОВОЙ.
«Литературное наследие»: рассказ Т. МУБАРАКОВА «Гюль эби» (с предисловием Г. Галиевой).
«Итоги литературного года»: доклады И. ИБРАГИМОВА, Л. ЛЕРОНА, А. РАШИТА, Г. АРСЛАНОВА, Г. МУРАТА, Р. РАХМАНИ, А. АХМАДУЛЛИНА.
«Наука»: А. ТИМЕРГАЛИН. «Словарь нации» (продолжение); Ф. ГАРИПОВА.
«История наших деревень» (продолжение).
«Лебяжье»—поляна вдохновения»: воспоминания М. ВАЛИЕВА, З. БАШИРОВА, Л. ИХСАНОВОЙ, Р. ФАЙЗУЛЛИНА о доме творчества писателей «Лебяжье».
«Рассказы из жизни»: Н. МУХИБУЛЛИН. «На берегу «Сульчи» остался ненаписанным...»
«Книжное обозрение»: рецензия Р. НИЗАМИ на книгу И. Валиуллина «Душа поэта—море».
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Юмор-сатира»: эпиграммы Л. ЛЕРОНА, шаржы З. ХАЙРУЛЛИНА; юмористический рассказ Р. ГАЛИУЛЛИНА.
«Белый парус»: рассказ А. ГАБДУЛХАКОВОЙ «Сила притяжения».
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Республика моя; писатель Альберт ХАСАНОВ.

## IN THIS ISSUE:

Prose and poetry: novel by K. KARIMOV "Games" (beginning); stories-miniatures by G. MUHAMETSHIN; verses by G. RAHIM, F. ZIYATDINOV, E. SHARIFULLINA, A. MAHMUDOV, L. GAZIZOVA.
Literary heritage: story by T. MUBARAKOVA "Granny Gul" (with foreword by G. Galieva).
Results of literary year: reports by I. IBRAGIMOV, L. LERON, A. RASHIT, G. ARSLANOV, G. MURAT, R. RAHMANI, A. AHMADULLIN.
Science: A. TIMERGALIN. Dictionary of nation (continuation); F. GARIPOVA. History of our villages (continuation).
Swan glade of inspiration: memoirs of M. VALIEV, Z. BASHIROV, L. IHSANOVA, R. FAYZULLIN about writers creativity house of Lebyagie.
Stories from life: N. MUHIBULLIN.
On coast Sulchi left unwritten.
Book review: review by R. NIZAMI on book by I.Valiullin "Soul sings about sea".
Pages from Tatar encyclopedia.
Humour-satire: epigrams by L. LERON, caricatures by Z. HAYRULLIN; comic story.
White sail: story by A. GABDULHAKOVA 'Force of attraction'.
From photoarchive of magazine.
Diary of social-cultural life. On our covers: My Republic; writer Albert HASANOV.

*The magazine edits monthly*

* Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
* Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
* Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 25.05.2007 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С–632 Тираж 6451.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2007 ел.

Гәрәй
Рәхим



# ДУСЛАРЫМ АҢЛАР МИНЕМ БУ ХАЛӘТНЕ...

## Илкәем

Яз язлаган... Җәй җәйләгән...
Көз көзләгән ИЛКӘЕМ!
Кыш кышлаган... Кышын туңгач,
Син җылыткан ИЛКӘЕМ!

Таңым аткан... Көнем туган...
Шәфакъ баткан ИЛКӘЕМ!
Төне буе синең уйны
Уйлап яткан ИЛКӘЕМ!

Сәгатьләрем, минутларым,
Мизгелләрем - синеке...
«Син кемнеке?..» - дип сорама...
... Мин - тик туган ИЛНЕКЕ!..

## Кышкы җыр

Кышның матур кичендә
Сиңа учлап ак кар аттым.
Син дә мине яраттың,
Мин дә сине яраттым.

Әгәр чын-чынлап яратсаң,
Кардан киртәләр корма да.
Яратуны ап-ачык әйт —
Ялынма да, ялындырма да.

Йөрәгемнең кайнарлыгы
Кар киртәләрне эретер.
Көртләр өстенә тезелгән
Эзләреңнән тайпылмый йөретер.

Кар өстендәге пар эзләр
Безнең сөю эзе булыр.
Ай яктысында яңгырап
Боз сөңгеләрне чыңлатыр кышкы җыр.

*Гәрәй РӘХИМ (1941) — шагыйрь, прозаик; егермедән артык китап («Вәгъдә», «Зирекләрнең кара бөдрәләре», «Үз җиремдә — үз җырым», ике томлык «Сайланма әсәрләр» һ. б.) авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Безнең сөю сүзләреннән
Кышкы бозлар кайнарланыр.
Тәрәзәләрдә ут яныр,
Чыршыларга кабыныр.

Шул чагында сине миңа
Бүләк итәр кышкы буран.
Урап-урап кар явар,
Бурап-бурап кар явар.

Кышкы кичтә без бергә-бергә
Төшенербез иң татлы сергә.
Икәүдән-икәү генә,
Икәүдән-икәү генә.

Ике күзе тәрәзәдә
Ике күзе тәрәзәдә,
Тәрәзәдә ике күзе —
Мине көтәдер инде.
Йөрәгемдә ялкын гына,
Ялкын гына йөрәгемдә —
Янып бетәдер инде.

Тәрәзәдән кояш карый,
Кояш карый тәрәзәдән —
Туп-туры карый аңа.
«Сөйгәнең инде юлда, — дип —,
Юлда, - дип, - инде сөйгәнең» —
Ул хәбәр сала аңа.

Көтә-көтә аргансындыр,
Аргансыңдыр көтә-көтә -
Тик өмет өзмә генә.
Мәхәббәттә дөрлә, әйдә,
Әйдә, дөрлә мәхәббәттә -
Тик янып бетмә генә.

## Кистемгә килгәч

*2002 елның кара көзендә без Туфан Миңнуллин белән Удмурт Республикасында яшәүче татарлар янына сәяхәт кылдык. Сәяхәтне оештыручылардан безне республиканың иң аулак төбәгендә урнашкан берәр татар авылына алып баруларын сорадык. Безне удмурт урманнары уртасында борынгыдан килгән гореф-гадәтләрне саклап яшәүче Кистем дигән авылга алып килделәр.*

Дөнья буйлап йөри торгач
Килеп җиттек Кистемгә.
Бу җырымны багышлыймын
Дуслар, сезнең исемгә.
Кистемнәр кемнәр икән дип
Йөргән идем, сез икән.
Монда матур тормыш корып
Гөрләп яшисез икән.
Бәхетегез киселмәгән.
Кемнәр әйткән кистем, дип...
Сез әйтәсез, илем шушы,
Монда туып-үстем дип.
Чал тарихта эз калдыру
Булмыйдыр ул корбансыз.
Авырлыкка баш бирмичә
Таза тормыш кормагансыз.
Юк сездә мескенләнү дә,
Юк зарлану, пошаман.
Татлы, моңлы зарларыгыз
Үзегезгә охшаган.
Кистем көен җырлыйсыз сез
Йөрәкләрне җилкетеп.
Сез мәңге яшәрсез монда
Дөньясын дер селкетеп...
Туфан белән, җил-җил итеп,
Килеп җиттек Кистемгә...
Бу җырымны багышладым
Дуслар, сезнең исемгә.

## Алтын читлекле «төрмә»

Син мине күрмә генә,
Янымда йөрмә генә.
Өемә керә күрмә —
Син мине күрә күрмә.
Яныңа да китермә,
Төшләреңә дә кертмә.
Мин якын килә башласам:
«Шөкәтсез!» — диген, үртә.

Минем чиксез мәхәббәттән
Гашыйк булырсың үзең —
Алланып китәр йөзең,
Моңланып калыр күзең.
Әгәр миңа гашыйк булсаң
Гамьсез гомерең үтәр,
Кайгысыз көнең бетәр,
Җаныңны сагыш тетәр.

Мине күрсәң дә күрмә,
Минем тирәдә йөрмә.
«Мәхәббәт ул, наз гына!» - дип,
Татлы хыяллар үрмә.

Минем чиксез мәхәббәтем
Вак хыялың җимертер,
Үрле-кырлы сикертер –
Башкаеңны тилертер.

Берүк мине мактама...
... Бар, гашыйк бул башкага.
Сылу, яшь бер каен идем –
Әверелдем тактага.

Эшеңә дә, уеңа да
Якын китермә, кертмә.
Мине үзеңдәй итмә -
Шүрәледәй үкертмә.

Әгәр миңа гашыйк булсаң,
«Җаным, үптер, - диярсең,
Тик синеке генә булыйм,
Элеп киптер!» - диярсең.

Йом күзең, мине күрмә,
Төшләремә дә кермә.
Син бит минем йөрәгемә
Алтын читлекле «төрмә».

Мин йөргән җирдә йөрмә,
Ялгышып үбә күрмә.
Миңа булган сөюеңә
Чыдамый... үлә күрмә...

Нишлим соң синең белән?!,
Син миңа - рухи йөгән.
Әйдә, лутчы синең өчен
Үзем егылып үләм.

* * *

*(Билгесез көн алдыннан)*

Картлык килә хыялларымны сындырып...
Аларның күпмесе инде ләхеттә.
Өр-яңа кабер казып куелган
«Гомер» дигән иң-иң татлы бәхеткә.

Бу гомер сыйды бары дүрт фасылга:
Балачагым - язым, Егетлегем - җәем,
Олпатлыгым - көзем, Картлыгым - кышым...
... Менә шул...
Инде кәфенем җәйдем.

Дусларым аңлар минем бу халәтне...
Дошманнар: «Ниһаять!..» - дип куаныручлар.
Шигырьләрем генә,моңсу итеп:
«Син китәсең, без калабыз.. .» - диеп юаныручлар.



Камил
Кәримов

# УЕН

РОМАН

## Үҗәт күзгеләр каршында

Кемдер аңа ике сәгать буе залдан комсызланып текәлеп утырды. Мең кеше арасыннан аерылып торган явыз, хөсетле, хәлне алырдай караш иде бу. Концертның икенче бүлеген көчкә ерып чыкты Сөмбелә. Саубуллашып, сәхнә алдына баш ияргә килгәндә, алып баручы яшь егетне култыклап өлгерде, мактаныр өченгә түгел, алай-болай сөрлегеп китмәгәем диде…

Менә хәзер ул кеше бизәнү бүлмәсенең ишеген шакыр. Керә-керешкә үк концертка мәдхия укыр, иң яраткан җырчым—Сез, дип кулын үбәр. Өченче звонокка чак өлгердем, сонга калмас өчен сәгатенә йөз егерме миль беләи кудым, чәчәк кибетенә сугылырга вакыт калмады, дияр. Күкрәк кесәсенә ашык-пошык тыгылып, симез бумажнигын чыгарыр, кабаланып чылбырын аерыр һәм җыр китабы калынлыгы яшел акчалар арасыннан алтынлы-гөлле визиткасын алып бирер. Төннең теләсә кайсы вакытында мобильнигыма шылтырат, концертларыңны оештырырга ярдәм итәрмен. Главалар арасында дусларым бик күп, аларга минем бер сызгыруым җитә, дияр… Тагын ниндидер мактанулар, алдагы планнар турында сорашулар, очрашуга өметләр… Сөмбелә, әлеге визиткага күз йөгертеп чыккач, күнегелгән миһербанлык белән: «Oho! Сез бик зур кеше икәнсез!»—дип сокландагандай итәр.

Соңгы вакытларда җырчыбыз грим бүлмәсенең ишекләрен бикләп утыра башлады. Концерт алдыннан бизәнсә дә, соңыннан юынса да—янына иптәшләрен кертми торганга әверелде… Кермәсеннәр, күрмәсеннәр, көлмәсеннәр, кызганмасыннар…

Бизәнер өчен аңа ким дигәндә ике сәгать вакыт кирәк. Ак вертолет белән сабантуй аланына алып китәләрме, теплоходка төялеп чит илгә чыгамы, әллә автобус белән Сургут каласына барып җитәме—барыбер, Сөмбелә әнә шул ике сәгать вакытны алдан ук исәпләп куярга тиеш. Аппаратураларны

---

Камил КӘРИМОВ (1950)—*прозаик; дистәләп китап, шул исәптән «Ком сәгате» һәм «Сакау куке» романнары авторы. Казанда яши.*

бушатып, микрофоннарны көйләр өчен ярты сәгать китә. Ә калганы жырчыга бизәнер өчен китә.

Сөмбелә бизәнгән арада төркем эшсезлектән интегеп тик йөри. Баянчы пыяла кружкага чыбык батырып чәй кайната, биючеләр туктаусыз тәмәке тарта, музыкантлар кыланчык шешәләрдән сыра имә, антураж дип алынган икенче жырчы арзанлы күлмәген тигезләргә үтүк эзли. Артык иртә алып килгәне өчен төркем Сөмбеләнең үзенә ишеттермичә генә зарлана, әрли, әрәм үткән шушы ике сәгать эчендә Казанда эшләнергә мөмкин булган, ләкин бүленеп калган файдалы эшләрне саный. Гадәттәгечә…

Күнел ачу учаклары базарга авышканнан бирле концерт заллары, сәхнәләр эреләнде. Хәзер инде авыл клубларында чыгыш ясау артистлар өчен чынга ашмастай хыялга әверелеп бара. Зур залларның сәхнә арты да иркен—бер яктан икенче якка күчкәндә сөртенмисең, бәрелешмисең, тырпаеп торган калакларга эләгеп ертылмыйсың… Грим бүлмәләре дә күбәү. Сөмбелә үз янына һичкемне кертми, бикләнеп бизәнә.

Сөмбеләнең тамашачысы концерттан соң бик тиз тарала. Шушы Чаллы, шушы ук зал бит инде югыйсә… Әле ун ел элек кенә… тәнәфес игълан итәр хәлең юк—сәхнә артына тамашачы тула. Фотога төшик, дип «крутойлар» ыгы-зыгы килә, әби-апалар кассета сатып алырга тели, мәктәп балалары автограф сорый. Кайбер кылтым егетләр, иренегездәге иннекнең эзе битемә төшсен әле дигән булып туганнарча гына үбешүгә өметләнә… Концерт ахырында пәрдәне ябып өлгермисең—ярты зал сәхнәгә менеп баса, кием алыштырырга ашыккан жырчыны жибәрми тора, микрофон чыбыкларын жыярга ирек бирми, «Газель» йөртүченең кайтырга дип юлга ашыктыруын колакка да элми. Тамашачы һаман тантана итә… Әйе, һәрхәлдә элек шулайрак иде.

Жыр сәнгате—бик авыр эшкә әверелеп бара.

Данлыклы «Мэрия» залы Сөмбеләгә дә суынды. Залның жан жылысын кайтарыр өчен сыналган, йә сыналмаган яңа ысуллар уйлап табарга кирәк. Әлбәттә, элек тә концерт залының кеше күзе төшәрдәй һәр почмагында бер-ике буш урын була торган иде, тик бүгенгечә күпләп түгел…

Сөмбеләнең бүген, никтер, ишекне бикләргә кулы бармады. Биек көзгеле өстәлләрнең уртадагысына терәлеп утырды. Үтә күренмәле лавсан букчаның астын өскә китереп чәчәкле салфетка табып алды. Косметика сөтенә манылган мамык чеметемен бизәнгән килеш нурланып торган битенә тидерергә ашыкмады. Бүлмәнең өч як стенасына тигезләп эленгән көзгеләрдән кимчелек эзләде. Күпне күргән алдавыч көзгеләр Сөмбеләнең барлыгын төрле яклап күзәтеп тора. Бу бүлмәдә күпне күтәргән урындыкның шөрепле буыннарын шыгырдатып һәр көзгегә борыла-борыла карый торгач аның үзеннән гайрәте чигеп куйды… Айның жиргә күренми торган салкын ягы булган кебек, артистның да тамашачы гына күрә торган ягы бар. Дөрес, сәхнә кануннары кушканча, залга арт белән басу тыела. Эстрада жырчысы сәхнәдә бөтерелеп тормаса, халык аны ветераннарга тиңли башлый. «Тиз арада жиде-сигез килога ябыгырга кирәк,—дип уйлап куйды Сөмбелә,—элек мин жәй көне коелып бетә торган идем…»

Грим бүлмәсендәге һәр көзге, аның чамадан чак кына артып киткән килбәтен аеруча күрсәтеп, бәхәскә керергә тели иде сыман. Сул стенадагы көзгеләр: «Син бу күлмәгеңне Зилә Сөнгатуллина үрнәгеннән күчердең, нечкә билле, чатыр итәкле күлмәк сиңа килешми. Безгә ышанмасаң, әнә, ишеккә кагылган арткы көзгедән сора. Синең кулбаш сөякләрең өрелде, торыгын кыскарды, табаның жәелде»,—диләр. Аллагы көзгеләрдә: «Өске өлеше иңенә сыланып тормаса күлмәгеңне хет өрфиядән тектер—барыбер килешмәс»,—дигән чагылыш бар. Грим бүлмәсе белән бүленеп калган озын

идәннең теге ягында егетләр аппаратура жыялардыр, дөп-дөп атлаулардан уң стенадагы көзгеләр тыпырдый. Тыпырдап, дерелдәп үчеклиләр кебек: «Бенифисына утыз җиделе башмагынны капларлык озын күлмәк тектер. Итәгеннең бер ягыннан ерык ач. Ерыгы зуррак булган саен артист яшьрәк күренә. Сина инде минле ботынны төбенә чаклы күрсәтсәң дә таман булыр...»

Ишекне шакучы юк... Сөмбелә, ниһаять, каршысында күзенә терәлеп торган көзге тоткынлыгында калды. Муенына көмеш чылбыр белән эленгән тугыз ташлы кулонын сөяк пеналга салды. Алкалары юк аның, гомергә алка такмады, хәтта колагын да тиштермәде. Ясалма керфекләрен куптарып алды. Чылбыры вак-вак боҗралардан торган көмеш сәгатен ычкындырды. Пеналда һәммәсенең аерым бүлеме бар иде. Һәм үз чыраена үзе каты бәгырьле карар чыгаргандай, кулындагы юеш мамык кисәге белән әле маңгаена, әле битенә аркылы-торкылы эзләр төшерде. Майлы кершән белән алсуланган мамык чеметемнәре, өстәлгә өелгәч, көзгедәгесе белән ике күч булып күренде. Күз читендәге ерганаклар тирәнәйде, маңгай чәче астында яшеренеп яткан сызыклар башны югары чөйгәч бераз әзәйгән кебек булды. Иреннең чия кызылын кәгазь киптергечкә күчереп бетергәч ул янадан кызгылт көрән иннек ягып куйды. Йөзендәге җинеллектән хәтта кәефе күтәрелгәндәй булды. Көзгедән калын соры кашлы, киң маңгайлы, коңгырт күзле, жыры бүленеп калган бөрмә иренле, Казанга качып килмәсә Акъярда менә дигән авыл укытучысы була алырдай Сөмбелә апа карап тора иде... Бик озак киелеп, озак салына торган купшы яшел күлмәк эченнән чыгып спорт костюмын да киеп өлгерсә, артист үзен яртылаш кайтып җиттем дип исәпли ала.

Сөмбелә, ике кулы белән үрелеп, күлмәк артындагы чылбырны аермакчы иде, ишекне бикләргә онытканын исенә төшереп сискәнеп куйды. Кырыкмаса-кырык тапкыр алышынган чыбык элгечкә килеп кагылган гына иде, кемдер ишек шакыды. Әгәр шушы мизгелдә ул: «Керегез, ишек ачык!» дип дәшсә оятка каласы иде. Ник дигәндә, янына керәсе кешене, әллә кайчаннан бирле, ишек төбендә көтеп торган кебегрәк килеп чыга бит бу.

Сөмбелә, аяк очларында гына йөгереп дигәндәй, көзге янына килеп басты:

—Керегез, кер, мин киенгән!—диде ул, өстәлдәге мамык өемен учына йомарлап.

Ишек ачылмады, әмма, кабат шакыдылар.

—Керегез! Әйтәм ич, ишек бикле түгел!—Бу юлысы Сөмбелә, каршы алырга килүен сиздерергә теләп үкчәсенә катырак басып атлады.

Теге якта сап-сары розалар бәйләме басып тора иде. Чәчәкләрне үрелеп күтәргәнгә генә күренмәгән, алты яшьләр чамасындагы бер кыз, бүләкне жырчы апасына тапшыргач йөгереп китеп барды. Әгәр концерт күлмәген алыштырып өлгергән булса Сөмбелә ул баланы куып тотар, шап-шап итеп сөяр, ягымлы сүзләрен кызганмас, исемен сорар, кем кызы икәнен әйттермичә калмас, һичьюгы бүлмәгә алып кереп сумка төбендәге хәзинәдән берәр конфет тоттырып тоткарлар, сары розаларны үз куллары белән тапшырырга оялган абзагызны: әйе, әйе, һичшиксез абзагызны, бүлмәгә керергә мәҗбүр итәр иде.

Ут сүнеп алды—монысы инде зал хуҗалары телендә: «Ашыгыгыз, вакытыгыз бетте!»—дигәнне анлата. Хәзер исә эчтән бикләнгән грим бүлмәләрен каерып ачардай Әүхәт белән вахтер килеп житә. «Ачкычларны тапшырыгыз!»—дигән әмере ишетелә дә инде. Вахтерның кырыс тавышыннан шунысы аңлашыла ки: димәк, аренда түләве тиешенчә жыелмаган, зал төбендә бәйдә торган контролерга, рубильникны күтәреп торган электрикка, швабрасын залдагы жылы торбага киптерергә элгән идән юучыга, пыяла канатлы урам ишегеннән «Хуш килдегезме?» дип каршы алып, «Барыгыз инде, бар, озак маташасыз!» дип озатып калучы вахтерга, оешмаларга билет

таратучы әбиләргә, урам ягына белдерү ябыштыручы исерек рәссамга, ак пәрдәнең соры ягын әйләндереп, сәхнә түренә кәрҗинле ясалма чәчәк чыгарып куйган ике эшчегә, авторлар хокукын сакларга теләгән оешманың вәкиленә—кыскасы, Казаннан артистлар килгәнне кул сузып көтеп торган Мәдәният сараеның барлык тамагына, мәхәр азрак эләкте дигән сүз... Вахтерның тел төбендә әнә шул тамаклар исеменнән җыйналган өметсезлек. Ниһаять, ул кырыс тавышлы маржаның түгәрәк гәүдәсе Сөмбелә каршындагы көзгедә пәйда булды.

—Господи! Битлеген салган, кабыгын һаман салмаган! Утны сүндергәч кармаланып чишенерсең, бел шуны!

—Чабата! Син бу түткәйне бәхилләттеңме әле?!—Сөмбеләнең ялварулы тавышы грим бүлмәсе ишегенә капланган вахтер аша сәхнә ягына таралды. Ләкин җавап әйләнеп кайтмады.

«Чабата» бу минутта әле һаман касса бүлмәсендә, язулы саннары ышкылып беткән кесә калькуляторына баскалап, бүгенге концертның матди хәлен исбат итеп азаплана иде. Утның сүнеп алуыннан каушап ул кат-кат санады.

Вахтер түткәй, Сөмбеләнең киткәнен көтеп алырга теләгәндәй, сөялгән урыныннан кыймшанмады.

—Узган атнада Уразаева концерты булды. Вәт, халык ташкын булып килде ичмасам. Рәт арасында идәнгә чүгәләгән кешеләрне пожарниклар да куып чыгара алмады.

—Берәр круг биреп карасын әле. Икенче килүендә халык ничегрәк җыелыр икән, әйтерсез.—Сөмбелә үз тавышына мөмкин кадәр ясалма ягымлылык кертергә тырышты, ике арадагы сүз ыргытыш берүк әрләшүгә күчмәсен, концерт белән керердәй заллар санаулы гына, бу түткәй каршына әллә ничә килерсең әле.

Чишенә башласам бәлки ишек төбеннән китеп торыр бу дип, Сөмбелә күлмәгенең чылбырына үрелергә иткән иде, тик көзгедә сыланып калган киң форматлы чырайга тагын бер кат сыный карагач кире уйлады, каршысында Илфирәтне чишендерсән дә исе китмәс бу түткән күзле бүкән кебек...

Профессиянң артист булсын да, аптырап утыр имеш... Сөмбелә көзге каршында ике бәйләм булып чәчәк аткан сап-сары розаларны пөхтәләп алды да вахтерга таба борылды. Көзге өстәле белән ишек арасында биш алты гына адым булса да, ул бер тирән сулыш белән һәр чәчкәне иснәп өлгерде. Яшьлек хатирәләрен яңартып, югалтуларны барлап, сөелү минутларын күзаллап, туган якның көзге болыннарына әйләнеп кайткандай, канатланып сөенерлек халәт иде бу...

—Сез минем әниемә охшагансыз, бик матур кеше, мәгез әле, шушы чәчәкләрне өегезгә алып кайтыгыз.—Сөмбеләнең чәчәк бәйләме сузган кулы кинәт тартышкандай, сискәнеп куйды... Ә бит урамдагы алтын көзнең үрнәгедәй сап-сары чәчәкләр арасында яшел сөенечләр булырга мөмкин. Бәлки ул үзенең визиткасын, йә булмаса куен дәфтәреннән кача-поса гына ертылган кәгазь кисәгенә телефон номерын язып җибәргәндер. Таныш бизнесменнар кулыннан алганда чәчәкләр сабагында хәтта «У. Е.»лар да ияреп килә иде.

—Кая әле, сынык башлы розалар эләкмәдме микән,—дигән булып, ул бәйләмне аска таба каратып селкегән булды.

Юк, бәйләм арасыннан бер хәбәр дә коелмады, чәчәкләре дә исән-сау, әле тәнәфес вакытында гына Голландиядән кайтып төшкән кебек...—Тик төнлә белән ваннага чылатырга салыгыз, яме, көндез шиңмәс алар. Сары розалар төнлә шиңә.

—Беләм, беләм, мин инде концерт саен чәчәк ташыйм. Бүген чәчәксез калам икән дип торам. Розаларны төнлә йөздерергә кирәген дә, көндез вазага

ике сәдәф аспирин саласын да беләм. И, рәхмәт, бердәнбер букетыгызны мина бирәсез. Тавышыгыз матур сезнең. Жырларыгыз йөрәктән чыга. Татар булмасам да кемнең тавышы кайдан чыкканны чамалыйм. Дворецта унбиш ел эшлим инде мин...—Аның тавышы әкренләп кырыслыгын югалтты һәм ниһаять, якын киношчегә әверелде.—Еш киләсез шул. Афиша өстенә афиша ябыштырабыз. Артистлар үзара кинәшеп, чират саклап килсәгез безгә дә күнелле булыр иде... Элек рәхәт иде, бөтен концертларны филармония билгели, айга бер генә бригада килә. Тамашачы гел шул ук кешеләр, концертка дигән акчалары жыелып өлгерми хәзер.

—Апа, сез мина булышыгыз әле.

Вахтер түткәй, утлы күмергә орынгандай ише генә кагылып, Сөмбеләнең күлмәк чылбырын ычкындырды да ашыгып китеп барды.

—Тынычлап, иркенләп чишенегез, мин ашыкмыйм, иртәнгә чаклы утырасы әле,—дигән сүзләре мышный-мышный чәчәк иснәве белән өзек-өзек бүленде.

Килеп життек, дисәләр киенә, бетте, дигәнгә чишенә, киттек, дисәң күзен йомамы—жырчы инде ул! Мотор тавышын жиңеп, башкаларны уздырырга теләп сөйләшә һәм юл буе акырып жырлап кайта торганы музыканттыр, йә тел бистәсе, рәсми телдә әйтсәк—алып баручыдыр ул кеше. Үз тавышын үзе хөрмәт иткән жырчы юлда һич жырламас һәм дә сөйләшмәскә тырышыр, кабинадагы катнаш һаваны турыдан-туры суламас өчен муенын борынына тиклем яка эченә батырыр. Йокымсырап барганда тамак төбендәге жырчы жепселләр ял итә, көч жыя.

Сөмбелә, арткы утыргычта колачын жәеп, берүзе барды. «Алтылы» дип халык теленә кергән бу машина гадилегенә күрә бик йомшак, олы юлның шадраларын жинелчә капшап кына үтә, арткы утыргычы офислардагы күн диван кебек сыгылып тора, баш астына берәр букча салсаң йоклар өчен жайлы. Ләкин йокы дигәнең ике көнсез әйләнеп кайтмаслык итеп качты. Ян тәрәзәләрдән баксаң язны көтеп кара шәүлә булып калган өнсез урман ишарәсе, арткы тәрәзәгә борылсаң «Газель» уты күзгә төшә, алга карап барсаң соры юлда фара нурларының туктаусыз эзләнүе машинаны агымга каршы ашкынган моторлы көймә кебек итә, башка каба. Көпчәкләрнең шыбырдавында су тавышы бар. Төннең тирән чагы. Әгәр шушы минутта таң ата алса яз башланыр иде кебек. Кышның монысы да ялыктырды. Язның шулкадәр тансык чагы. Бу кадәр зарыгып, өметләнеп, хыялланып көткән мәлдә яз дигәнең кинәт килсәме—йөрәген сөенечтән шартлар иде.

Чаллы юлы гүя алкын елга кебек, аның инде һәр борылышы, һәр күпере, якын-тирәдәге һәр уты таныш... Гомер дигәнең агымсуларга караганда тизрәк ага. Соңгы егерме ел эчендә Сөмбеләнең күргәннәрен елгалар куып тотарлык түгел...

Казанга кайтып житкәнче үз башыннан кичкәннәрне тәфсилләп искә алырга, ялыктыргыч вакытны онытылып үткәрергә була иде әле. Дүрт сәгатьлек хатирәләргә язмышның ничә вакыйгасы сыяр иде икән?.. Тик «алтылы»ның хужасы—Чабата тынлыкны харап итте. Ана берәүнең дә исеме белән эндәшкәне юк. Жинел сөякле, чандыр гәүдәле, какча чырайлы бу кеше абый да түгел, энекәш тә түгел, яшь аермасының ничек булуына карамастан бөтенесе дә аны «Чабата» дип кенә атап йөртә. Ул егерме ел буе жыр һәм бию ансамблендә биеп, кырык яшеннән пенсиягә чыккан. Чигүле түбәтәй, яшел атлас камзул, эленке генә бәйләнгән, туры төпле, озын балаклы буй-буй ыштан киеп биегәнен телевизордан еш күрсәтәләр. Бию уртасында, шома табанлы читек кәвешен салып чабата киеп куя да шунын сөенеченнән егылганчы бии. «Чабата» биюенең исеме үзенә кушамат булып тагылыр дип кем уйлаган?! Чабата—Сөмбелә төркеменең администраторы, дөрес, визитка кәгазенә ул үзен эре-калын хәрефләр белән Продюсер дип яздырган.

Концертларны оештыру, билет тарату, жыелган акчаны кассадан алу—анын өстендә.

«Газель» микроавтобусын Сөмбеләгә сайлау уенында катнашканга бүләк иттеләр, ә радиоаппаратураны үзенеке итәр өчен бәйрәм көннәрендә химия заводына өч ел буе бушлай җырлыйсы бар әле.

—Бая кассирша безне үртәп маташа, Уразаева афишасын күргәч, Сөмбелә концертына дип алынган билетларның күбесен кире китереп тапшырдылар, ди.

—Җавабыңны бирә белдеңме соң?!

—Әйе менә, әрләшеп утырдым ди кассирша белән!

—Ничәнче тапкыр бит инде!.. Концертыбызга бер атна кала дигәндә генә афишасын китерә дә элә. Мин җырлап киткәнне көтеп торса ярамаганмы?! Юри, үчегеп эшли бит ул аны.

—Усаллык белән түгелдер, бик самими кыз әле ул.

—Юри эшли, юри! Ни өчен икәнен дә беләм. «Ягымлы яз» конкурсында мин аңа каршы сүз әйткән идем, сәхнәдә үзенә-үзе артык ышанып, чамасыз эре кыланганы өчен. Бу жюриларда йөреп күпме дошман җыйдым.

—Һәр нәрсәнең үз вакыты: берәүләр сәхнәгә менеп килә, икенчеләр жюрига төшеп утыра... Уразаеваның тавышына сүз әйтерлек түгел! Ул—тембр дисеңме, ул—дикциясе; үзе нәфис, үзе сөйкемле, моңлы, һичбер музыкасыз-нисез җырлый ала, яшьлегенә күрә горурлыгы да килешә.

—Яклама шуларны! Сәхнәдә яшьлек кенә җитми, тәҗрибә дә кирәк.

—Тәҗрибәнең поты бер тиен хәзер. Тамашачы дигәнең концертка җыр тыңларга дип түгел, артистның үзен күрергә килә. Тыңлыйм дигән кеше өчен җыр белән кибетләр тулы. Аудио дисеңме, видеосы кирәкме—җылы өеңнән чыкмыйча, төнге транспортларда интекмичә, сөтле чәеңне йоткалап, диванына җилкә терәп—рәхәтләнеп тыңла... Юк, шул, әгәр берәр җырчыны яратса—меломан дигәнең барыбер өеннән чыгып китә. Яшьләрне яраталар шул.

—Яшьлек үтә, тәҗрибә кала.

—Ие, бер яшьлек үтә, аның урынына икенче Уразаевалар килә. Тәҗрибәле җырчылар юбилейларда, бенифисларда мактаныр өчен генә кирәк. Тамашачы карт җырчыны эзләми.

—Илһам абый белән Әлфия апаларны кая куясың? Заллары гел тулы, чәчәккә күмәләр, сәхнәдән төшермиләр...

—Оештыра белмәсәң аларга да кеше килми.

—Менә, күрдеңме, үз гаебеңне үзең таныдың?!—дип канатланды Сөмбелә, әлеге бәхәснең шулаерак тәгәлләнүен көтә иде инде ул.—Оештыруың шуның хәтлек кенә! Афишаны элеп кайтасың да—вәссәлам!

—Җ-ж-җук, телефон аркылы кассадагы хәлне гел сорашып торам...

Чабатаның мин-минлегенә тисәң, тартык авазларда тереләп кала торган гадәте бар, Сөмбелә моны бик яхшы белә. «Жигули» эчендәге кысанлыкта кабынып киткән котылгысыз бәхәснең гел яшьләрне мактауга корылуы аны рәнҗеткән иде, шуна күрәдер, ул администраторның каушавыннан канәгатьлек хисе кичерде. Абзагыз дорфаланып кырыс хөкем карарын укып бара. Үзенең артык борчылганы сизелми, җырчы әйтергә мөмкин булган соңгы сүздән курыкмый, димәк аны чакырып торган башка җырчы бар, димәк, аны тагын да ныграк үртәп, ул исемне әйттерергә кирәк.

—Ялкауландың син, Чабата, акчаны җиңел эшләргә өйрәндең. Башкаларны кара: «Күңел» радиосына реклама биргәннәр, Чаллы телевидениесе көн саен клипларын күрсәтеп тора, баерак оешмаларга барып билетлар таратып йөрү дисеңме?..

—Рекламага түләсәк, ярты заллы концертларыңнан нәрсә калыр? Синең белән аншлаг күргән юкка инде...

—Оныттыңмы? Күп булды инде минем дә аншлаглар.

—Ну, Сөмбелә, элек дип күпме шапырынсаң да аннан тамак туймый.

—Аның каравы җыелган акчаның унбиш процентын биреп барам мин сина.

—Әйе, Зәлияләр унны гына түли. Ну, тулы залдан шактый чыга ул.

Алай... Зәлияләр төркеменә кучәргә икән моның исәбе дип кызулык белән нәтиҗә ясап өлгерде Сөмбелә, исәп-хисапларын өйрәнгән, нәтиҗә ясалган. Инде китәсе көнен генә сорыйсы калды.

—Әйт, Чабата, ничәсенә чакырдылар, ераккамы?

—Октябрь бәйрәме тирәсендә Нижгар—Мәскәү—Питерга бер атналык маршрутлары бар. Татар диаспоралары гарантияли.

—Әйтәм җирле баядан бирле алар җырын җырлап барасың!.. «Эльруш» дуэтына ияреп китеп миңа кире кайтканыңны онытма!

—«Эльруш» дуэты таркалды бит. Юкса мин аларны Җир шары буйлап йөртеп чыга идем.

—Син таркаттың аларны, Чабата!

—Ж-ж-ж-жук! Нишләп мин булыйм?! Раушания кияүгә чыгып кына х-х-х-хәрәп булды алар.

—Син, син!—Чабатаның каушавыннан Сөмбелә тагын да ныграк комарланды.—Зәлия белән Зөфәрне дә таркатачаксың! Әйткән иде диярсең!

—Ж-ж-ж-жук! З-зәлия ж-җырлаганда ззалдагылар ж-җ... елап утыра! Мин аларны рәхәтләнеп тыңлый алам. Ә синең ж-җырлаганны тыңламас өчен фойега ч-чыгып китәм.

—Туктат, туктат машинаны! Мин «Газель»гә күчеп утырам. Бар, яраткан җырчыларыңны бүген үк куып тота аласың!

«Алтылы»ның багажнигыннан сәхнә күлмәкләре кидерелгән кофр белән озын каешлы сәяхәт сумкасын алган арада «Газель» куып җитте. Чабата кузгалып китәргә ашыкмады, ул әле Сөмбеләнең дулап саубуллашуына һаман да ышанып җитми иде, күрәсең. Уңышсыз концертлардан соң җырчы кызыйның холыксызлануы гадәти хәл, көзге төн аны тиз суытыр, авыз эченнән мыгырдап гафу үтенер дә янадан килеп утырыр дип көтте... Килүен кире килде Сөмбелә. Ләкин гафу үтенер өчен түгел, бүгенге сүз көрәшендә җиңүче булып калыр өчен генә.

Ул сәхнә артыннан кабат баш иягә чыккандай мактаулы халәттә иягэн чөйде, гәүдәсен турайтты, вак, әмма ышанычлы адымнар белән фара нурларын кисеп Чабата ягындагы ян тәрәзәгә иелде:

—Мин сина әйтеп өлгермәгән идем, бүген миңа бер кочак роза керттеләр, зур гына компаниянең генераль директоры иде. Ул шәп проект тәкъдим итә... Синең китеп баруың әйбәт булды әле.—Һәм Сөмбелә, үз ялганына үзе куанып, әзер елмаюын яшерә алмады. Фара яктысы—зал түреннән сузылган прожектор нурлары сыман иде, ә олы юлда тыз-быз үткән йөк машиналарының көпчәк чыжлавы көчле алкышларны хәтерләтте...

Унике урынлы «Газель» сигез кеше белән шыгрым тулган. Арткы рәтләрне сүтеп алып, аппаратураларны тәярлек мәйданчык ясагач, бәләкәй автобус эче кучәнергә әзерләнгән бүлмә эчен хәтерләтә иде. Кеше саен берәр сумка, биючеләрнең түбәгә инсә белән эленгән озын күлмәкләре, Наилнең тез өстендә йоклап кайткан ак тышлы баяны, Тимурның ау мылтыгы кебек саклап барган гитарасы, бернинди геометрик фигурага да охшамаган кул сандыгы эчендәге саксофон белән Алып батырның кыска туныннан коелган төймә кебек аяк астында комачаулап яткан запас көпчәкне дә исәпкә алсан—суларлык һава күләме бик чамалы монда. Шулай да ут сүнгәч салонда иркенәйгән кебек булып китте.

—Чабата бабай безнең көйгә кайта алмый, мин аны җибәрдем,—дип

акланып өлгерде Сөмбелә, ник дисән, йомшак кәнәфидән каты сәкегә күчеп утыруның сәбәбен сорамый калмаслар иде. Аллан ук җавап биреп, эшне җиңеләйтте.

Араларына солистка кереп утыргач тынып калдылар исә—монарчы бу җиле кешенең кем турында сөйләшеп барганын күз алдына китерүе кыен түгел. Шуңа күрә Сөмбелә тынлыкны үз кулына алырга булды.

—«Карамай»га җиткәч туктарсың, Илфирәт, сыйлыйм үзегезне!

—Банкет!—дип төзәтте Фаил, исән микән дигәндәй, тез өстендәге баянын капшап.

Чаллыга барган саен ач кайтабыз дип көрсенеп арган тавышлар янәдан уянып, «Банкет» сүзенә әллә ничә төрле бизәк өстәделәр:

—На шару!.. Халявый... Үзе сыйлый... Бер атнадан бирле банкет күргән юк... «Карамайга» чаклы тагын туксан чакрым кайтасы, әллә «Кыстыбый»га туктыйкмы?.. Юк, «Карамай»—супер! Андагы кебек итеп беркайда да пешерә белмиләр... Сиңа инде йөз илле грамм салып бирсәләр, урамдагы көйгән шашлыкны да мактыйсың...

Банкет дигәч, Илфирәт тәмәке кабызды. Сөмбелә, башын кыегайтып кына, шырпы очында биеп алган мескен ялкынга күз салды, тик каршы дәшмәде. Йокы ачылсын дип тырышуларыдыр инде, күрәсең, төнге юлда шоферлар аеруча еш тарта. Тартасы килгән саен урамга чыгам дип машина туктата башласаң Чаллы белән Казан арасын тәүлек буе кайтырсың. Шоферга беркем каршы сүз әйтә алмый. Юлга чыккач иң кадерле кеше ул. Исән-сау йөртү өчен генәме? Казанга кайтып җиткәндә сәгать инде төнге икеләр тирәсе булыр. Шушы сигез кешенең һәркайсысын фатир ишегенә тиклем кайтарып, таратып чыгасы бар. Кемне алдан, кемне иң соныннан илтсәсен шофер үзе хәл итә. Йокының иң тәмле чагында, ашамаган-эчмәгән, юынмаган килеш тагын бер сәгать буе шәһәр эчендә каңгырап йөрисең килмәсә—рульдәге кешегә каршы дәшмә.

Банкет тукталышын йокы аралаш үтеп китмәс өчен егетләр бер-бер артлы мәзәк сөйли башлады.

Сөмбелә көзге пәлтәсенең йомшак якасына ышыкланып сулышка ияргән төтен исен сөзде. Ул мәзәкләрнең беренче рәтеннән үк теманы аңлап ала да ишетмәмешкә сабыша. Сөйләүчегә кысылмый, кычкырып көлми... Караңгыга ышыкланып тик елмаеп бара. Әгәр онытылып китеп сүзгә кушылсаң, шунда ук мәзәк персонажына әвереләсең, кеше ышанмаслык көлкеле мажараларга синең дә катышың бар кебек һәм аларның һәммәсе дә синең баштан узгандыр кебек килеп чыга.

«...Яңа татар үзенең хатынын диңгез буена ял итәргә җибәрә...»—дип башланып киткән мәзәкләр Сөмбеләнең игътибарын җәлеп итмәде. Аның баш миендә кайнаган уйлары егетләрнең тел очында уйнаган көрлектән көчлерәк иде...

Кемнән килде соң бу розалар? Бүләкме, шаяртумы, онытылган мөһим бер вакыйганы искә төшерү дип аңларгамы моны? Кеше кулы белән бүләк тапшыруның сәбәпләре бардыр ич: авыруы күзгә күренеп торган гарипме ул, әти-әнисенең рөхсәтеннән башка гына акча туздырырга җөрьәт иткән меломан малай-шалаймы, әллә үз яшеннән үзе оялырлык чамасыз өлкән агаймы?!

Яз—ирләрнең актив чагы... Түтәлдәге яшелчәләр—өстәлдә, бакчадагы җиләк-җимешләр карынында, кыш буе карлы саф һавада сихәт җыйган, мут телевизор каршында диван колачлап гайрәт туплаган ирләрдә куәт ташый, «малайлар чуагы» башлана...

Чабата да чын ир кеше. Алмагачлар чәчәк атканга сөенеп, шомырт чәчәкләре коелганга көенеп язны еламсырап үткәрә торган ир уртасы, быелгы кышның

кире кайтмаслыгына ышанып, әнә ничек батырайган! Моң белән акча эшләп анын гаиләсен күтәрергә булышкан Сөмбеләгә каршы дәшә, үрти, чагыштыра, күрәләтә хыянәт итә. Бер Чабата гына түгел, туксан чакрым буе анекдот сөйләп барырдай жиде кешенен һәркайсысы да шулай. Алар ике-өч сәгать буе концертында туганнарча, дустанә елмаеп-көлеп синең өчен сөенгән булып торыр да, пәрдә ябылгач янә дошманына әверелер.

Пәрдә ябылганнан соң башланган ыгы-зыгысы, жыеп төяү, вак-төякне югалту, башкарылган жырларны бәяләү, бүгенге хаталарны эзләү, банкетларда юанулар һәм ниһаять, кайтып житүләр, кыскасы, үз өеңнең бусагасын атлап кергәнче кылынганнарның барысы-барысы бергә сәхнә арты дип атала. Сәхнә арты хыянәт белән тулы. Алып килгән чәчәк бәйләмен концерт беткәнче саклап, соныннан, пәрдә ябылгач кына сәхнә артына кереп, жырчыны эзләп йөрүчеләр бармы—алар әнә шул хыянәт дигән нәрсәне үз күзләре белән күрергә, башкаларга бәйнә-бәйнә сөйләргә теләүчеләр. Әле өенә кергәч, жан исең сенгән иске мендәрең өстендә дә сине хыянәт көтеп ятарга мөмкин, чөнки уңышсыз юлга чыксаң, сәфәреңне кыскартып, төннең теләсә кайсы михнәтендә көтмәгәндә кайтып керәсен. Әгәр өметләнмәгән уңышка очрасаң гастрольләреңне озайтып, өйдәгеләр борчылып көтсә дә кайта алмыйсың. Һаман саен кабатлана торгач, билгесезлекнең нәтиҗәсе булып, сине пәрдәнең ике ягында да хыянәт сагалап тора башлый. Бер хыянәт, ике хыянәт... өч... биш... Ахыр чиктә син ул хыянәтләргә күнегәсең...

Хыянәтләр артистны чыныктыра, яшәргә, жиңәргә өйрәтә.

Жыр уен кебек ул—яңа чагында гына кызык. Яраткан «шлягерларыңны» ун-унбиш тапкыр рәттән тыңласаң—туясың. Аннан соң тагын яналары кирәк. Күпме патефон тәлинкәсе, аудиокассета, компакт дисклар ярылып, сүтелеп, кырылып өелеп ята, чүплеккә чыга. Күпме жырчы тамашачыны күрүдән мәхрүм булып өендә—ябылуда яши... Чабатага һәйкәл куярлык—ул Сөмбеләне биш ел буе рәттән тыңлады. Әйбәтрәк түләсән тагын да тыңлый ала иде әле. Үзгәртергә, үзгәрергә, нәрсәдер эшләргә, яңарырга кирәк! Төркемне бер «Жигули»га сыярлык итеп биш кенә кешегә калдырыргамы? Ул чагында ваграк район үзәкләренә, эрерәк авылларга рәттән кереп йөрергә була. Соңгы ун елда бөтенләй концерт күрмәгән авыллар бик күп. Ләкин билет бәяләрен шәһәрдәгедән сигез-ун тапкырга киметергә туры килә. Кулыңа калган акчаң сынар туфли алырга житәрме? Икенче сынарын алыр өчен тагын бер авылга керәсе була. Бичарага—ничара... Сөмбелә авыл буйлап хәер сорашып китте, дип и сөйләнер иде артистлар.

Нишләргә?! Үзең кебек тагын берәр жырчы алып төркемнең шавын арттырыргамы? Ул чагында: «Син дә мулла, мин дә мулла, сәдаканы кем бүлә?» Концерт Сөмбеләнеке дигән тамга төшеп калырга тиеш буламы? Антураж булып килгән яшь жырчылар да тиз үсә. Бер-ике ел ияреп йөриләр дә телевидениенең йолдызлар фабрикасына шомарырга дип ашыга-ашыга китеп тә баралар.

Популярлык казану бик авыр, ләкин әнә шул танылган жырчы дигән исемне елдан-елга саклап калуы тагын да авырырак... Иртәгә үк... Юк, бүген үк, кайтып бераз ял итү белән—яңа күлмәк тектерергә, яңа плакат ясатырга, синнән отып алып табын артында жырланырлык яңа жыр эзләргә кирәк. Яңа жырга лаек булыр өчен үзең дә яңарырга кирәк...

Чын сәхнә түгәрәк мәйдан ул—анын кыйбласы бихисап, пәрдәләре ялтыр-йолтыр, утлары көлтә-көлтә, яшел, кызыл, зәңгәр төсләре катлы-катлы. Ак белән сорыны, кара белән коңгыртны бутамасаң гына, кызыллыктан алсулыкны, зәңгәрлектән шәмәхәләнүне аера алсаң гына синеке ул сәхнә...

Банкет булмаса, артистлар арка терәвенә кыек-мыек сөялгән килеш кайтып житәселәр иде. Сөмбелә «газельне кафе янында туктаткач, төнге сәгать икедә

көн янадан башланды. Күнел ачу йокыдан көчлерәк иде бүген.

Чәчүләр бетеп, җыеп алынасы байлыкны алдан ук санап, югарыдагыларга рапорт биргәч, шәһәрнен базарлы мәйданнарына ярминкәләр килә, авылларда язгы бәйрәмнәр башлана. Хисләргә туенган яшьләр никах хәстәрен күрә, юбилейлар, туйлар, өмәләр китә... Кыскасы, елнын җырлы-уенлы чоры бу. Җим сибәр сәгатьне көткән күл балыгы кебек, артистлар арасында да ыгы-зыгы арта. Сөмбелә хәзер җитәкчеләрнен кунакка чакырганнарын кул кушырып көтеп ятмый, бәйрәмнәрне үзе эзли, исләренә төшереп шылтыраткалап тора. Кайсы гына җырчынын өенә кермә—районнардан, шәһәрләрдән ялынып алып кайткан телефон кенәгәләре журнал өстәлендә өелеп торыр. Эш югында көннәр буе хәбәрләшеп тә сынар концерт оештыра алмаган чаклар була. «Зәйтүнәгә ныклап әйтергә кирәк, «уныш»лы вакытны кулдан ычкындырмасын, әнисе югында телефоннан китмәсен, җырлап акча эшләүнен җинел түгеллеген белеп үссен. Юкса, өйдә үзе генә калгач, әнисенен күлмәкләрен киеп артист булып уйнарга ярата ул. «Ходаем, кызымны җырчы язмышыннан ераграк тот...»—дип, юлдагы уйлары белән пыран-заран килеп, подъездга кергәч, Сөмбелә почта әрҗәсенә ачкыч эзләп джинсы кесәсенә тыгылды. Чәчәкле кәрҗинне идәнгә куймаска тырышты. Сөмбеләләрнен «егерме дүртенче»ләре лифт каршысында ук.

Сөмбелә әрҗәдән төшкән яналыкларны актара башлады. Һәр реклама кәгазен, бушлай таратыла торган гәҗитләрне җентекләп караштырды. Күнелендәге кысыр өметне юатырга теләп ниндидер билгесезлектән хат эзләде бугай ул. Роза чәчәкләре арасында ияреп килергә тиешле язу почта аша әйләнеп кайтыр кебек иде ана. Кызына күренгәнче көтелмәгән яналыкларны сөзеп алуын хәерлерәк. Зәйтүнә хәзер урта мәктәптә соңгы елларын укый, аттестат алганчы ук өлгереп җиткән зур кыз инде ул, әнисенә кагылышлы һәр яналыктан зур сер эзләргә ярата, сораулары күбәя.

Почта әрҗәсеннән алай искитмәле яналык чыкмады, бәлки телефоннан берәр хәбәр бардыр әле дигән уй Сөмбеләне өйгә ашыктырды.

—Абау, розалар!!!—Зәйтүнә әнисенен хәлен сорарга да онытты.—Әллә спонсорлар бар идеме, бүген минем туган көнем дип шаярткансындыр әле?!.

—Чәчәксез кайткан көннәрем сирәк инде, кызым.

—Анысы шулай, әни. Мондый чәчәкләрне, телевизордан күренер өчен, культура министры гына бүләк иткәли иде бугай. Розалар... бер кәрҗин!

—Сары розалармы?

—Бүләк ителгән чәчәкләрнен сарысы-кызылы юк, әни!..

—Минем төсләр аера торган чагым шул, кызым. Синен яшьтә булсам бәлкем үрле-кырлы сикерер идем дә...

—Әни, кем бүләк итте? Главамы, «КамАЗ» директорымы?! Әллә... джентельменмы?..—Зәйтүнә бик мөһим кешенен исемен ишетергә теләп, сурәттәй катып калды.

—Белмим, кызым. Кәрҗин үз аягы белән керде, җентельменын күрмәдем.

—Әни! Әйтәм ич, сина әле шундый шәп кеше гашыйк булачак! Менә күрерсен... Бөтен гәҗит, радио-телевидениеләрне шаулатып туй итәрбез. Бөтен кеше сине—бәхетле Сөмбеләне янадан күрер өчен концертларына ябырылып килер... Ә мин ана әти дип дәшәрмен...

—Монарчы бер дә кияүгә бирәсен килмәде...

—Җүләр, бала-чага булганмын.

—Бүген үстенме?

—Үстем. Мин синен кебек ялгыз яшәмәм.

—Бирсен Ходай!

—Кияүгә китсәм үзен генә каласын.

—Бүген үк китмисендер ич?

—Юк. Таныштык кына әле.

—Кем белән? Кайчан? Иртән мин юлга чыкканда өйдә бала-чага булып, «Марс» шоколады алып кайт», дип, еламсырап озатып калган иден.

—Мәктәптән соң өйгә кайтмыйча, туп-туры университетка барып килдем, укырга керүчеләр өчен программа кирәк иде. Менә шунда таныштым.

—Мин сиңа бүген шоколад алып кайтмадым. Кәрҗин күтәреп йөреп бөтенләй онытып җибәргәнмен.

—Ярар. Бүгенгә түзәрмен. Яңа егетем Мөхәммәт тә шоколадлы. Алжирдан.

—Негрмы?!! Йә, Хода... Африкадан кода белән кодагый килеп төшсә... Балантау халкының коты алыныр.

—Озаграк карап торсаң күзияләшә аңа. Әле беренче курста гына укый ул. Син дә ияләшерсең.

—Йә булды, кызым. Бүген болай да башым чатный. Шаяртуларыңны иртәгесе көнгә калдыр.

—Әни...

Зәйтүнәсенең тавышында ниндидер гозер бар кебек тоелды Сөмбеләгә.

—Нәрсә, кызым, әллә бүген үк Африкадан илчеләр киләме?

—Юк, әни. Минем бүген университеттан кайтканда мобильнигымны чәлдерделәр. Маршруткада бик тыгын иде.

—Әрләрлек тә хәлем юк. Акча эшлисең килсә әнә районнарга, колхозларга шалтыратып чык. Белешеп кара, концертлар кирәкми микән. Белмәгән эшең түгел, теленнән килә.

—Белештем, әни. Байлангарга багышлап җыр язганнар, авылда кичәсен үткәрәселәр ди. Сиңа композитор белән элемтәгә керергә куштылар... Кармыш авылына Чишмә бәйрәменә чакырдылар. Теләчедә районның унбиш еллыгына багышлап Культура сарае ачыла диделәр, килергә куштылар. Аланда уңыш бәйрәме, көнен-сәгатен билгеләп үзенә элемтәгә керәсе булыр. Шулай итеп, дүрт концерт сиңа! Минем гонорар бер телефонлык.

—Әйе. Эшләп кайтыйм әле башта ул авылларда. Аннан булыр сиңа кесә телефоны.

—Әни, иртәгә үк кирәк шул. Юкса Африка белән элемтәм өзелә.

—Әйтәм аны бик тыпырчынасын... Ярар, таң атканчы гына түз инде алайса. Акча кулга кереп өлгермәде... инде чыгып та бара...

Чиләкле суга аспирин салып, розаларны шунда күчергәч, өй эченә шоколадлы конфет исе таралгандай булды. Йокы бүлмәсендә караватлары янәшә торса да аларның юрган-мендәрләре аерым. Бүген Зәйтүнә әнисенең юрган астына шуышып керде, куенына сыярга тырышып бөгәрләнде.

—И, әнием, әле дә ярый син бар бу дөньяда!

Конфетлы чәчәк исе куенга да кереп тулган иде инде. Алар тәмләп йокыга киттеләр.

## Яңа ел күбәләкләре

—Мин!..

Калканлы ишек артындагы кешенең кемлеген белер өчен шушы бер сүз җитте. Сөмбелә аның тавышын «Ә?» дигәннән дә таный ала.

Дүрт бармаклы йозак ачылгач, тимер тупса өстендә Чабата пәйда булды. Чаңгычыларныкы кебек чуклы калфагын каш астына тиклем батырып кигән, мамыклы курткасыннан чыгып торган калын свитер муенчагын борынына терәлгәнче күтәргән. Чыраенда салкын күзе белән, агарып ялтыраган борыны гына калган. Кулларын күн бияләй кигән килеш кесәсенә тыккан.

—Син нәрсә, Чабата, җәяү килдең мәллә? Шушындый суыкта!

—Машинам кабынмады. Телефоннан аңлата торган сүз түгел. Ашыктым.

Сөйләшә торгач, Чабатаның күкшегән иреннәре жылына башлады.

—Иртәгә кабыныр иде әле. Тамагына жил бәрсә... Хәер, синең жырлыйсың юк ла.

—Заказчик барында тизрәк хәл итик. Башкалар сизеп алганчы.

—Алар чынлап та минеме—Сөмбелә килсен дип сорыйлармы? Әллә кем булса да ярыймы? Дөресен әйт, сырлап-мырлап торма, мин инде көйсез кәләш түгел.

—Точно, сине чакыралар.

Сорау өстенә сорау яудырып тинтерәтүе Чабатага ышанмаудан түгел, ул инде сыналган администратор, әйткәнен хәленнән килгәнчә төгәл үти, чакырган жырчысына тамашачы жыя белә, акча бүлгәндә хәрәмләшми. Сөмбеләне эшсез калдырып еш кына башка жырчыларны алып чыгып киткәләгән икән, монда берни эшләр хәлең юк, халык кемне сагына, шуны чакыра. Соңгы елларда Чабата жинелрәк эшкә күчте, ул хәзер Зәлия белән Зөфәргә иярде. Бу жырчыларның ин йолдызлы чагы, концертларын тәмамлап янадан башласалар да үзе жыелган зал таралышмас, таң атканчы тынларга әзерләр. Әлмәттә бер көндә рәттән ике аншлаг жыелган диделәр. Шуна күрә дә Чабатаның һич уйламаган жирдән Сөмбеләне Әлмәткә чакырып килүе бераз икеләнергә мәжбүр итте. Тамашачыны кулга иялләштергән Драма театры бинасында булса бер хәл... йөз илле менле шәһәрдә Сөмбеләне сагынырдай биш йөз тамашачыны өй саен чакырып та жыяр иде әле Чабата. Ә ул мең урынлы Техниклар йортына афиша илтергә жыена.

—Нәрсәдән куркасың? Синең инде Әлмәттә жырламаганың юкка биш былтыр.

—Өч кенә ел әле...—Башка артистлар арасында гайбәт булып таралмасын өчен юри төгәллек кертте Сөмбелә, Әлмәткә юлы ябык дип уйламасыннар.

—Өч ел күрмәгән жырчыны мин дә сагынам,—дип үзенчә сөендерергә тырышты Чабата.—Сөмбеләне алып килсәң, аншлаг гарантируем, диделәр.

—Ник алайса турыдан-туры үземә чыкмаганнар, синең аркылы эзлиләр?

Монысына Чабатаның бераз чырае сытылды. Суыктан агарып кергән бит алмасында кызыллык тибеп алды.

—Безне гел бергә эшлиләр дип белгәннәрдер. Монарчы администраторлар аша эш иттеләр ич. Ну, теләсәң әйтермен аларга, сина шалтыратырлар. Бәлки миннән башка гына барасың киләдер?

—Кырык градуслы салкында бригада сөйрәп зыянга эшләп кайтсан... Буш залга жырласам кәефемә салкын тия минем.

—Бүген—кырык, иртәгә—ноль... Яздан курыкма, килеп терәлгән. Гарантия диделәр. Барырга тек барырга!

Татар эстрадасында жиләкле аланнар тарая Сөмбелә өчен. Югары Ослан, Тәтеш, Бөгелмә, Лениногорск кебек татарча ишетми торган төбәкләрне генә түгел, Минзәлә, Актаныш, Әтнә, Баулы кебек әлифбалы кала-салаларның юлларын да онытып бара инде ул. Әлмәткә дә өмете өзелгән иде. Ник дигәндә, сәбәбе бар...

Соңгы тапкыр чыгыш ясаганны искә төшерсәң... Ул көннәрдән бирле инде өч тапкыр календарь алышынды. Әле дә төшкә кереп йөдәтә торган әкияти көннәр иде ул. Һәр әкиятнең үзенә генә хас чоры, батырлары, кагыйдәләре була...

...Борын-борын заманда жирнең кыл уртасында, Девон ханлыгы дан тоткан ди. Ханлыкның халкы ерак бабаларыннан мирас булып калган коелардан жир мае чыгарып, шуның белән сәүдә кылып кәсеп иткән, казна туплаган ди. Девонның эш сөючән халкы күңел ачарга, кәеф-сафа кылырга бик яраткан ди. Мәжлесле йолаларны, урам бәйрәмнәрен, кызыл көннәрнең берсен-бер буш калдырмаганнар, яналарын уйлап таба торганнар. Мактама дигән кечкенә

генә инеш ярында күнел ачу сарайлары булган боларның. Җәй көне ул Яшел сарай, ә кыш көннәрендә Ак сарай дип йөртелгән. Яңа ел килергә өч көн кала девонлылар мал бүләләр икән: җир маена катышы булган һәр инсанга затлы мал, күчемсез мөлкәт, зиннәтле уенчыклар, талир тәңкәләр өләшкәннәр болар. Өч көн буе Ак сарайда уен-көлке, җыр-бию тынмаган, мәҗлес сүрелмәгән.

Менә тагын Яңа ел якынлашкан. Ак сарайга күрше мәмләкәтләрдән, кенәзләрдән һәм олыслардан мөхтәрәм кунаклар җыелган. Ике йөз дисәтинәле ишегалды диңгез аръягыннан кайтартылган симез көпчәкле, дегетләнгән тәрәзәле, җир мае төсендәге бихисап а р а б а белән тулган ди. Кунакларның күңелен ачсын өчен Пайтәхеттән гөсләчеләр, кубызчылар, чичәннәр, җыручылар, шамакайларны һәм хәтта кендек сикертүче малайларны да чакырткannar. Өч көн вә өч төн дәвам иткән бәйрәм. Менә, ниһаять, мөнәҗәтче Сөмбеләнең нәүбәте җиткән. Җиде йөз кунак каршысындагы түгәрәк келәмне мәйдан итеп чыгып баскан ди ул. Ни күрсен—түрдә ханның генераллары, бирерәк—яраннары, алар артында карачылары, алайлары һәм малайлары тезелешеп утыра ди. Ә өстәлләрдә... какланган, ысланган, томаланган, кыздырылган итләрнең биш төре, пешергәннән соң сүтеп җыелган балыкларның җиде төре, салават күперендә нинди төсләр булса—шундаен җимешләр һәм дә ки бер-бер дию пәриен үзенә сыйдырырлык бәллүр шешәләр, кыскасы, чичәннәр тел белән, җыручылар мөнәҗәт белән әйтеп бирә алмаслык нигъмәт ди. Ә Кар сарае эчендә җиде диңгез аръягыннан һава шарына төяп кайтарылган аллы-гөлле күбәләкләр, кыш уртасында уянып, генераллар өстендә чәчәкле канатларын җилпи икән.

Девонлыларның чыршы бәйрәменә Хан үзе бик йөрми ди инде. Соңгы елларда ул аяк-куллары өшү белән интегеп, раштуа суыклары алдыннан, ханбикәсен ияртмичә генә Урта диңгез буендагы Анталия кояшына кызынырга иялəнгән ди. Хан югында девонлыларга генераллар хуҗа булып кала ди.

Баш генерал көмеш чәнечкеле кулын изәп кенә мөнәҗәтче кызга җырurlарга кушкан. Ә Сөмбелә келәмгә баскач берәр кызык уйлап табарга маһир икән: йә ул ике-өч табышмак әйтеп тыңлаучының тапкырлыгын сыный, йә чигүле кульяулык бүләк итеп хуҗаның күңелен күрә белә, йә мөнәҗәтләр китабы өләшә ди. Бүген дә ул, Чыршы бәйрәменең йоласына туры китереп, Кырык тартмачыларда сатыла торган битлекләр алып килгән.

Сөмбелә мөнәҗәтне бии-бии башкарган ди. Табын артына ябышкан кунакларны түгәрәк келәмгә чакырып биергә мәҗбүр иткән. Уен арасында һәммәсенә битлек өләшкән. Кемгәдер бүре, аю, куян, кемгәдер маймыл, чучка, шамакай чырае эләккән. Ә Сөмбелә үзе төлке битлеге кигән. Әлбәттә, җир маеннан симергән генералларның гәүдәләре селкенмәгән, куллары гына биегән. Мәгәр, көлешә-көлешә күңел ачып, бер гаилә булып уйнаганнар ди болар.

Ярый хуш. Мөнәҗәт тәмам. Инде янә табын артына утырышканнар ди. Менә киткән ыгы-зыгы... Бер генә генерал да үз битлегенә риза түгел: бу синеке, монысы миңа тиеш, дип бер-берсенең битлеген йолыккалый башлаганнар, аю битлеге өчен көрәшеп кул сугышы чыккан хәтта. Алайлары, кучерлары ярдәмгә өлгереп, көч-хәл белән аерган тегеләрне.

Бәйрәм дәвам иткән үзе. Әнә шул көннән башлап мөнәҗәтче Сөмбеләне тамашаларга чакырмаска булганнар ди...

***

Реклама ярдәмен тоя башлагач синоптикларның да аллан юраганы юш килә башлады, ялганлаудан туктадылар: йә ява, йә юк; юнәлешсез җил, мөмкин, ихтимал, кәтелә, үзгәрүчән дигән икеле-микеле сүзләрне сирәк ишетәбез хәзер. Сынап карарсыз. Һава торышының спонсоры энергетиклар

дисәләр коры һәм кызу көннәр килергә мөмкин, нефтьчеләр вәгъдә иткән көнне аяк астын дегеткә батырып яңгыр явар иде, ә инде «Газпром» ярдәме тисә җөмһүриятне томан капларга мөмкин…

Инде атна буе бүгенге һава торышының спонсоры—ОАО «Холод», ягъни тәмле-туклыклы тундырмалар житештерә торган комбинат бугай… Сөмбелә иягенә тиклем жылы суга чумып ваннада ята, ә урамда—яз башына хас булмаган утыз биш градус суык.

Су өсте күбекләнмәгән иде, юыну бүлмәсенең стенасына ябыштырылган көзге өлгеләрендә төрле ракурсларда чагылган гәүдә сурәтен күреп сөенде әле ул. Шөкер, буй-сыны әнисеннән… Гөлчәчәк пенсия яшенә житсә дә гел жинел сөякле, әгәр кызының концерт күлмәкләрен кидерсән таман гына булыр… Шунысы үкенечле, Сөмбеләнең жырчы булып эшләвенә тиздән егерме ел була, ә Гөлчәчәк белән Харисның кызлары жырлаганны Казанга килеп тынлый алганнары юк… Әллә бенифисны туган авылда гына үткәрәсе микән дип тә уйлаган иде ул. Тик бу уеннан кире кайтты, ижат кичәләрен зурдан кубып оештырыйм дисән зур житәкчеләрне, олы шәхесләрне, хәбәрчеләрне күпләп чакырырга кирәк. Ә алар бәйрәм-мәжлесләрдә буш сүзләр сөйләп алжыган халык, Казаннан чыгарга бик яратмыйлар. Авылдан туган-тумачаны төяп килүең күпкә җайлы.

Сөмбелә торып басты, ванна суы тубыктан гына калды. Кайнар тәненә бәлзәмле крем сылады, кулы сыйпап торган һәр урынны жентекләп, гаебен эзләп күзәтеп барды. Юк, юк… Тәнендә сөялләр, тамыр төеннәре дә, тәкле шадралар да күренми. Кызыгалар әле ана, барыбер кызыгалар. Сынныйлар, күзәтәләр, качышлы уйнап сары розалар китерәләр. Болар берсе дә тикмәгә генә түгел… Байлары күбәйгән саен тамашачылары кимегән Әлмәтнен меңкешелек залында Сөмбелә концертына билетлар сатылып беткән! Бу бит—триумфаль аншлаг! Әллә икенче сулышы ачылды микән? Әлмәттән кайткач, кочагы белән афишаларын тоттырып Чабатаны башка шәһәрләргә дә жибәреп карыйсы булыр.

Иртәгә Әлмәттә зур концерт. Һәм бу мөмкинлекне шоуга әверелдереп исемне яңартырга кирәк. Сөмбелә программаны ныгытыр өчен Уразаеваны да чакырды. Кыз, вак-төяк студияләргә баш имичә, эстраданың олы юлыннан бара. Ул киләчәктә зур жырчы булып үсәр, шулвакытта Сөмбеләне дә үз төркеменә ияртер… Эстрада дөньясында кылынган бик күп гамәлләр әжәткә эшләнә: яхшысы да, яманы да… Күптән инде конферансье дип атала торган һөнәри мәзәкчеләрне дә чакырганы юк иде. Алар бездә унбишләп кеше, Сөмбелә инде барысының да репертуарын яттан белә. Шуна күрә үз концертларын үзе алып барырга күнегеп килә иде. Ләкин Әлмәтнең укалы тамашачысы Шәрәфине ярата—сәхнәгә чыгып бер сүз әйтмичә басып торса да халык ана ярты сәгать буе кул чабачак.

Шулай итеп, Сөмбелә концертының алып баручысы Шәрәфи булса, алып кайтучысы «Газель»ле Илфирәт.

—Чаллы аша барабызмы, әллә яңа күперданме?—дип сорады ул, артистларны төяп бетергәч.

Сөмбелә чак кына җавап биралмичәрәк торды. Чаллы юлы кин, төзәтелгән, туктап-туктап чәй эчәрдәй, хәжәт кылырдай жылы корылмалар бик күп, әмма ераграк чыга, салкында болай да бензин күп бетә. Житмәсә тукталыш ышыкларында, урман почмакларында, үзәнлек чокырлары саен «дзот»ларда гаишниклар сагалап тора… Ә Саескан күпереннән китсән юл йөз чакрымга кими. Чамасыз тар, сикәлтәле, кыек-мыек ул, әлегә кайнар чәйле куышлары, заправка тукталышлары да ике-өч урында гына, аның каравы юлчылар белән качышлы уйнарга ярата торган инспекторлары азрак…

—Мин ишетми калдыммы, әллә син әйтми торасыңмы?—дип кабатлап

сорады Илфирәт.

—Әйдә КамАЗ юлыннан.

—Ә штрафларны кем түли?

—Алайса, Саескан күпереннән.

—Мондый суыкта сүнеп калсак, машиналар әз йөри.

—Ярар, трассага чык.

—Барырга-кайтырга утыз литр бензин әрәм китә.

—Ну, сон, Саесканнан дим ич!..

—Артык куып булмый. Вакыт ягыннан санасаң, шул ук.

—Син нәрсә, Илфирәт, суыктан курыксаң рульгә үзем утырам. Кирәксә, Ульян каласы аркылы өченче юл бар.

Илфирәт тавыш-тын чыгармыйча рәхәтләнеп көлә белә, андый чакта аның грузиннарга охшаган чырае күп җыерчыклы татарга охшап кала.

—Артистлар ягына өрдерә торган мич җылынсын өчен генә сөйләндереп торам. Алтышар сәгать паром көткән чакларга үч итеп яңа күперләрдән йөрик әле! Бабайлар: «Әйләнгечтән юл туры...»—дип яшәгәннәр. Ә җитәкчеләребез нәрсә ди—«Юлның кыскасы...»

—Сүзнең остасы!..—дип түгәрәкләде Шәрәфи.

Соңгы елларда Шәрәфинең тагын бер сәләте ачылды. Ул җинел машина сәхнәсендә генә сөйләргә ярый торган такмакларның русчасын татарчага, татарныкыларын русчага тәрҗемә итәргә ярата. Кыска-кыска такмакларын кабатлатып, ютәл купканчы көлә торгач ялыктыргыч сәфәр тиз үтә, ерак юллар да кыскара.

Март суыгы, мәрхәмәтлек күрсәтергә теләгәндәй, олы юл читендәге талтирәкнең һәр ялангач ботагын мамыклы бәскә төргән. «Газель»нең тизлеге арткач, ян тәрәзәләрдә дә шул ботакларның сурәте беленә башлады. Кайры тунның мехлы ягы күлмәкләргә чытырдап ябыша, кемгәдер орынсаң, йә кулдан-кулга нидер күчерсәң, ток суккандай итә. Коры суыкларда моңын өшетмәс өчен, Сөмбелә сулышны җылыдан алырга тырыша, авыз-борынын тун эченә яшерә. Шәрәфи мәзәкләреннән дә тун эчендә көлеп барды.

Артистның үз концертына соңга калып килүе гадәттән тыш хәл түгел, бәлки гадәти хәл. Аны «йолдыз авыруы»ның бер төре дип атасаң да ярый. Популяр шәхесләргә хас вакыт җитмәү синдромы да ул. Соңга калу вак-вак тоткарлыклардан, әрәм-шәрәм иткән минутлардан, техник сәбәпләрдән җыела. Еракта яшәгән кеше эшенә гел башкаларга караганда алданрак килә, ә балкон тәрәзәсеннән эш урыны күренеп торган кеше һәрвакыт соңга кала.

Кыска юлга артык ышанып куаламадылар, туктальшларда эленке-салынкы маташтылар, кичтән эчкән сыраларны бушату, тәмәке тартулар күбәйде... Һәм баскыч төбендәге реклама коймасына сыланган Сөмбелә портретына фара яктысы килеп төшкәндә концерт башланырга нибарысы бер сәгать вакыт калган иде. Соңга калу инде бу! Әле аппаратураларны бушатып урнаштырасы, микрофоннарны көйлисе, сәхнәне бизисе, күлмәкләрне үтүклисе, чәй эчәсе һәм ин четереклесе—Сөмбеләнең бизәнәсе бар. Ул арада әле егетләрнең берәрсе кибеткә китеп өлгерә.

Машинадан төшүгә Сөмбеләне тамашачылар сырып алды. Эчтә каршыласалар соңга калып килгән өчен борчылалар дияр иден, ә болар Мәдәният сараенын ишеге төбендә үк. «Ник ике көн рәттән куймыйсыз? Без барыбыз да билетсыз калдык!»—дип өзгәләнүләре җанга рәхәт. Күптән, бик күптән ишеткәне юк инде Сөмбеләнең шушы ягымлы сүзләрне. Ул: «Белмим шул... Исәнмесез?!. Тагын килербез бик чакырсагыз... Керерсез, басып торып булса да тынларсыз, пожарниклар рөхсәт итсә...»—дип сөйләнүдән гайре аклану сүзләре таба алмады.

Тагын биш минуттан башларга дигәндә, бөтенесе дә әзер иде, хәтта

чыбыклы стаканнарда кайнатып чәй дә эчеп өлгерделәр. Шунда гына Сөмбелә, нидер сизенеп, сагаеп калды: юлдан килгән шәпкә репетиция ясыйсызмы, әллә халыкны залга кертә башлыйбызмы дип, тенкәгә тиюче юк. Сәер, бик сәер хәл бу. Фойеда өченче звонок янгырады. Чабата да каядыр олакты. Сәхнә белән зал арасында авыр дивар булып шәмәхәдән коелган калын пәрдәне каерып, теге якка карагач, Сөмбеләнең йөрәге куырылды—өч тамашачы утыра, ә керү ишеге ябык—чаршавына чаклы корылган.

Ул, бәрелеп-сугылып дигәндәй, грим бүлмәсенә керде. Кесә телефоныннан Чабатаны эзләп тапты.

—Син кайда?

—Кассада.

—Ник халыкны кертмиләр?

—Башлый торыгыз.

—Ничек инде башлый торыйк?! Ике минут калды, ә залда өч кеше утыра. Тугыз йөз туксан җидесе кая? Ишеккә берьюлы ябырылсалар җимерәләр ич.

—Башлагыз, Сөмбелә, башла!

—Минем белән киңәшмичә нинди этлек эшлисең анда? Ну-ка, Чабата, хәзер үк монда кил!

Чабата каушады, тартык авазларны сайлап:

—С-с-с,—дип нидер аңлатмакчы иде ул, тик Сөмбелә, «монда кил!» дигән әмерен соңгы сүз итеп, телефонын шапылдатып япты.

Алар грим бүлмәсеннән башкаларны куып чыгардылар да бикләнеп сөйләшмәк булдылар. Концертант белән администраторның кычкырып сөйләшүен йозакка бикләп буламы—артистлар ишек артына сөялеп тыңлап тордылар.

Ч а б а т а. Менә аренда кәгазе. Менә ДК персоналына түләгән ведомость. Ә менә чиста выручка!

С ө м б е л ә. Ә билетлар?

Ч а б а т а. Мең билет залдагы өч егет кулында.

С ө м б е л ә. Тышта йөзләгән кеше калды. Кертик алайса.

Ч а б а т а. Әйттем. Егетләр риза түгел.

С ө м б е л ә. Нәрсә, әллә мине картага оттырганнармы?

Ч а б а т а. Ва-банкта унсигез яшьлек җырчылар хәзер. Бәлки гашыйклардыр. Крутойлар арасында фанатлар беткәнме?

С ө м б е л ә. Мина табынырга, үзен әйтмешли, әллә унсигез яшьлек чагыммы?

Ч а б а т а. Алай димә. Әлфия апа синнән ике тапкыр... Ну аның да фанатлары бар. Башла концертны.

С ө м б е л ә. Бригада белән киңәшәм, алар ни дияр.

Киңәшеп торасы булмады. Ишек аркылы тыңлап торган иптәшләр исеменнән Шәрәфи җавап бирде:

—Спектакльләр әзерләгәндә репетицияләрне без гел буш залда үткәрәбез... Главное—бушлай түгел. Калганына исең китмәсен. Син алгарак чыгып җырла, прожекторлар утыннан күзең әлҗе-мөлҗе килер дә өч кеше тулы зал булып күренер.

—Программаны кыскартмыйбыз,—диде Сөмбелә.—Сындырдык дип сөенмәсеннәр.

—Ә тәнәфес ясыйбызмы соң?

Шәрәфи шушы сүзе белән, шартларга җиткән киеренкелекне җимереп ташлады, Сөмбелә пырхылдап көлеп җибәрде хәтта.

—Тәнәфес юк. Интегеп утырсыннар!

Сөмбелә өч тапкыр күлмәк алыштырып чыкты. Соңгысында бенефис

өчен язылган яңа җырларны сынап карады. Җырдан-җырга күчкәндә әйтелә торган сүзләрне дә үзгәртмәде. «Рәхмәт халкым, сез барында мин үсәм әле. Җылы өйләрегезне, матур сериалларыгызны ташлап килгәнегез өчен, көчле алкышларыгыз өчен рәхмәт!»—дигәндә залдагы өч пар кул озакка сузылган алкышлар белән җавап бирде.

Соңгы җырны гына алыштырды Сөмбелә. Дәртле музыкага күмелеп саубуллашырга тиешле төркем «Кыр казы» җырына тезелешеп чыгып басты.

Кыр казы
Иделләр читендә
Ялгыз башым миңа читен лә...

«Кыр казы»ның соңгы кушымтасында Сөмбеләнең яшьле күзләрен шәмәхә пәрдә каплады. Ул грим бүлмәсенә ашыкмады (анда артык якты, житмәсә хәзер кеше кереп тулачак), сәхнә артындагы иске декорацияләр арасына посып, сабыйларча үкереп җылады. Күз яшенең һәр бөртеге, һәр сулкылдау-ыңгырашуы җырдан-җырга җыела килеп тулган иде инде. Әгәр бушанмасаң бүгенге хурлыктан йөрәгең шартлап ярылырга мөмкин иде.

Яшьләр ашык-пошык кием алыштырды, тавыш операторы сәхнә идәннәрен дөбердәтеп аппаратураларны җыйды. Һәркайсы үз эше белән мәшгуль. Аның нинди хәлдә икәнен күпне күргән Шәрәфи генә сизеп алды, бушансын бераз дип якын килми торды. Аннан соң, чәйнекнең кайнарлыгын белергә теләгәндәй итеп кенә, имән бармак сырты белән Сөмбеләнең иңбашына орынды.

—Сеңлем, мин синең сөлгеңне алып килдем, җебегән кершәннәреңне шушында гына сөрт. Күзләреңне яхшылап корыт, яшьләр күрмәсен. Күз яшеңне—сүз яше диярләр.

—Рәхмәт...

Сөмбелә, сөлге канатларын җәеп, чишмә улагыннан юынгандай сөртенде.

—Тирләп-пешеп җылап алдың, ә?! Сихәте булыр. Күз яшьләреңне кемгә багышладың?

—Рәнҗедем.

—Рәнҗедем?!. Вәт җүләр, мин бит тиңсез мәхәббәтең укшыта, әй лә, үксетә дип торам.

—Өч кешенең күңелен күрер өчен өч сәгать буе шамакайландык.

—Начальство банкетларга чакырса йөгерә-йөгерә киләбез лә.

—Андый чакыруларга шартын алдан ук белеп, әзер булып барасың. Ә монда... мең урындыкка өч капиталист утыра. Рәнҗедем.

—Рәнҗедем дигәннән, минем Комаргужада шәп председателем бар. Дояркалар янына чәйгә чакырды бу мине. Бер сәгать чамасы кәефләрен күтәрдем мин боларның. Саубуллашканда бухгалтер кыз:—рәнҗемәсәгез менә шушыларны гына алыгыз инде, зинһар,—дип миңа акча сузды.

—Рәнҗетүегез өчен рәхмәт! Башка вакытта тагын да күбрәк рәнҗетегез, яме, минәйтәм... Ә син мең билет сатылган өчен рәнҗеп торасың.

—Ул күзле бүкәннәр сәхнәгә менеп рәхмәт тә әйтә белмәделәр.

—Ник әйтмәсеннәр, бүлмәңә чәчәк керттеләр.

—Розалармы?

—Әйе, күргән иденме?

—Юк. Болай да беләм.

—Димәк, кемнән икәнен дә беләсең, шуңа җылыйсың.

—Белмим шул... Бер кәрҗинме?.. Сап-сары розалармы?

—Раштуадай суыкта кәрҗинләп чәчәк китерергә син әкияттәге үги кыз түгел лә... Сарысын сары—анысы факт, ну зур бәйләмне чытырдавык

бәйләүгә төреп биленнән кызыл пута белән бугаННАР. Кагыйдәне исенә төшерәсе юктыр инде—аншлаг булган көнне солист хисабына банкет. Әйдә, киен тизрәк. Әлмәтне чыккан чакта бер шәп кафе бар, ул төнге уникедә ябыла.

—Юк, юк. Әлмәттә түгел. Үзебезнен Чаллы аша кайтабыз. Анда да шәп урыннар бар. Алар тәүлек буе эшли.

—Баш өсте, Сөмбелә—Ханбикә!.. Роза, роза—от Дедушки Мороза!—диде дә Шәрәфи, үзенен нинди изге эш эшләгәнен дә абайламыйча китеп барды.

Шушы кеше сәхнәдәге тәҗрибәсен өләшеп йөри: әрсезләрне туктата, китек күнелләрләрне юата, мохтаҗларга җор сүзен садака итеп өләшә. Булган хәлләрне мәзәкчегә тәрҗемә итеп чынбарлыкнын ун ягын әйләндерә. Авыр сүзләрне рифмалаштырып ул ике-өч минут эчендә кызнын күз яшен киптерде, болытлы дөньясына кояш чыгарып куйды. Һәм бая гына нурлары сүнгән Сөмбелә янадан эстрада йолдызына әверелде: «Нишләп торам әле мин бу чытырманда?!»—дип, кемнәрдер ташлаган иске декорацияләр арасыннан елмаеп килеп чыкты.

Өч кешегә җырлап, Әлмәттән бер кочак сары гөләп гөлләре күтәреп кайткач, Зәйтүнә дә уйга калды. Өй эче бер кат тынычланып, инде көндәлек мәшәкатьләр белән юана-юана искечә яшәп торабыз дигәндә генә өй эченә сагышлы кояш булып тагын сары розалар бәйләме килеп керде. Хәзер әнилекызлы чәй эчәргә теләсәләр дә, вакыт табып икәүләшеп телевизор карасалар да үзара сөйләшеп утырулары элеккечә серләшү-чөкердәшү түгел, ә ниндидер тикшеренү эшләренә охшап кала. Һәр сорау ачыктан-ачык әйтелмәс: кинаяле, ишарәле, икеле-микеле булыр, һәр җавап аклануны таләп итә сыман, ә җавапсыз калган сораулар астыртын нияткә бәрабәр.

—Әни, син яшь чагында берәр егетне елатып калдырмадынмы?

—Безнен Балантауда чәчәкләр теленДә сөйләшердәй малайлар юк иде.

—Бәлки курсташларын арасыннан «текә» бизнесменнар чыккандыр. Араларында сагынучылары бардыр...

—Яна байларнын сагыну стилен беләм мин. Аларнын мәхәббәте саунага, ресторанга, табигать кочагына чакырудан башлана. Текә байлар кызыгырлык яшьтән уздым инде.

—Бәлки синен җырларына гашыйк булып яшәгән берәр министрнын хатыны үлгәндер?

—Матбугатта некролог чыгар иде. Бәлки-бәлки дип миннән сорау алырга бик оста син. Ә бәлки негр кияүнен шаяртуыдыр? Аларнын бай малайлары гына укый ала бит.

—Әни, син кәрҗин күтәреп кайтып кергәндә Мөхәммәт белән танышмаган идек әле без.

—Әйе шул. Аптырагач кына әйтүем.

—Әни, әйдә залда ремонт ясыйбыз. Стенага алтын сарылы обой ябыштырабыз. Өйгә кояш кергән кебек булыр. Сары розаларны биек аяклы подставкаларга куябыз.

—Әгәр бүтән бүләк итмәсәләр?..

—Ясалма чәчәкләр алырбыз, алар матуррак та, озын гомерле дә... Ә бу «Мистер Икс» таныш кешеңдер, оныткансындыр гына, исенә төшерерсен әле, менә күрерсен, кызым әйткән иде аны, диярсен.

Әйе, искә төшсен өчен белсән иде әвәл, яхшылык телиме ул Сөмбеләгә, әллә үч аласы киләме? Күзгә күренмичә, тавышын ишеттермичә, хат-фәлән җибәрмичә генә сагалап йөрүенен сәбәбе рәнҗүме, әллә соклануымы?! Бу күзгә күренмәс кеше гел янәшәдә кебек, Сөмбеләнен кая барып җырлыйсын алдан ук көтеп тора, кемнәр аркылы чакырасын да белә. Тагын нинди сынаулар оештырыр икән әле ул? Монарчы кыланганнарын кабатламасмы? Ахыры ничек бетәр? Үзен сиздермәве белән җырчыны чыгырыннан чыгарып,

соңгы чиктә сәхнәдән этеп төшерергә телиме? Конкуренция дигәннәре сәнәгатьтә генә түгел, сәнгатьтә дә бар лабаса! Ләкин Сөмбелә берәүнең дә ярын тартып алмады—ул бөтенләй кияүгә чыкмады, «җырдан туган кызы»на да унҗиде тулды, минем кызым ул дип эзләп килердәй кеше күптән инде гүр иясе... Сәхнәгә ашкынып килеп кергән кендекле, ботлы, биеп торган күкрәкле, әмма тавышсыз җырчыларның спонсорларын үзенә каратмады, хөсетлеләрне яуга күтәрерлек мактаулы исеме дә, абруйлылар хисабыннан алынган фатиры да юк. Маньяклар, фанатлар эзәрлекләп борчымады, автограф сораучылар да имза куелган җирдә калды, ияреп йөрмәделәр.

Чәнечкеле гөлләр белән бимазаларга алынган әлеге күзгә күренмәс кешене бик ерактан, яшьлекнең үзеннән эзли башларга кирәктер. Әгәр анда табылмаса язмыш йомгагын бөтенләй сүтеп, өр-яңадан урап куярга туры килер.

## Аю табаны

Октябрь бәйрәмнәре җиткәч, Балантау авылы кар күбегенә күмелгән көзле фасылы белән борылып басты. Көз дип әйтер өчен артык кырыс, кыш өчен шактый йомшак көннәр иде бу.

Армиягә повестка килгән өйләрдә озату мәҗлесләренә әзерлек башланды. Җир шарының үз күчәре тирәсендә зыр-зыр әйләнүенә инану өчен кырлы стаканны тутырып, артыннан конфет кәгазе иснәп кую җитә. Тик, хикмәти Хода, Идрис солдат хезмәтенә китә дигән елны май аенда ук коммунистлар партиясе аракыга каршы сәясәт башлап җибәрде: спиртлы эчемлекләрне ачу чикләнде, исерткечсез мәҗлесләр үткәрү макталды, киң таралган шәрабларны бетерү йөзеннән, җылы якларда җәйрәп яткан сортлы йөзем плантацияләрен туракладылар. Ул законга бик тиз арада «Сухой» дигән кушамат тагылды.

Кабинетына бикләнеп эчсәң, өстәлгә җәелгән гәҗиттә «Сухой закон»ның татарчага тәрҗемәсе туры килә. Өенә кайтып пәрдәңне корсаң, идән астындагы хәзинәнә үрелгәненне телевизор экраныннан генераль секретарь күзәтеп тора. Инде яманатлы эчемлекне лимонад шешәсенә күчереп салсаң, өч борынның берсе барыбер өстеннән җалу язып җибәрә. Качып эчә алу мәртәбәгә әверелде, «аек туй» кунаклары чоланнан чыкмады, кинәшмәләргә керәсе кызыл чырайлар кершән белән акшарланды, тыйнак сөйләшүләрдә лавр яфрагы, әнис, тмин, канәфер кебек тәмләткечләр авыздан төшмәде.

Закиулла Шакирович, Армиягә китәсе егетләрнең ата-аналарын парткомга җыеп, Горбачев портреты астында әңгәмә үткәреп алды.

—Сөйләшү шушы булсын, малайларны озатканда өстәлгә аракы куймыйсыз! Юлга кыстырып җибәрүләр дә ни-ни!.. Татвоенкомга салмыш килгән призывникларны туп-туры айныткычка озатачаклар, штрафын үзегезгә түлисе. Ишетсен колагың!

—Закун игълан ителгән көнне генә усал була. Яз көне чыккан указ өчен ул хәтлек борчылмасак та ярыйдыр,—дип, җыелган халык парторг белән сүз көрәштерә башлады.

Зәкиулла Шакирович, җыелган халыкның кәефен-фикерен ныграк белер өченме, ачыктан-ачык сөйләшергә мөмкинлек бирде. Соңгы фикерен кадаклап куйганчы башкалар ни уйлаганны белү бик кирәк иде. Дөрес, әниләр авызларына шым кабып утырдылар, житәкчеләр әйткәнчә эшләгәндә озату мәҗлесләренең мәшәкате, җәнҗалы азрак булачак. Шуңа күрә, берсен-берсе бүлдереп, гел ирләр генә гәпләште.

—Житмеш ел буе әйләнгән башны кисәк туктатсаң—халык ычкына бит соң! Делянкадан утын кайтартсаң да, печәнгә төшсәң, өмә белән өй күтәрсәң дә гел эш башында әвәлгечә ярты йөри. Бакча сукалатсаң да акча биреп кенә котылып булмый.

—Чаллыдагы малай янына иркенләп кунакка барганыем. Яшьләр эштә чакта көндез вакытым иркен дип йөз дә бишенче номерлы кибетләренә чиратка басканыем. Түбәгә, тимерче кадагы белән кадаклап, калай радио беркеткәннәр: «Гражданнар! Минздрав кисәтә! Спиртлы эчемлекләр сәламәтлек өчен зыянлы!»—дип һәр минут саен такылдап тора. Ике сәгать тордым чиратта. Йөз егерме минут дигән сүз бит ул! Әгәр, йөз егерме тапкыр «ярамый!» дип тукып, газиз башкаеңны миңгерәтсәләр, шуңа ачу итеп гел киресен эшли башлыйсың. Ике шешәне эчке кесәмә яшердем дә янадан чират койрыгына барып бастым.

—Әйтәм аны җиңги эзләп бармыйча кайта белмәдең Чаллыдан. Күңелле яшәгәнсез икән.

—Сиңа көлке. Тыелган әйберне гел комарланып җыясы килә бит ул. Кирәкме-юкмы, запаста кытаклап торсын. Гозерлеләр арасында бөеренә таянып йөрүе рәхәт.

—Тыелмаганы да җитәрлек. Стакан төбенә унбиш грамм корвалол, егерме тамчы вәлириән, егермене сукыр кычыткан, аю камыры төнәтмәсе саласың да су кушып йөз граммга чаклы җиткерәсең. Аш алдыннан түнтәреп куйсаң—бик җиткән. Әгәренки шул минутта ишек шакысалар, сәкегә җәелгән намазлыкка сикереп менәсең дә «әссәләгаләйкем рәхмәтулла»ны әйтеп башыңны читкә борасың… Эчүчелек авыру бит ул, авыруны указ белән дә, әрләп тә дәвалап булмый. Аны дару белән дәваларга кирәк.

—Тәк, агайлар, җитте! Сез монда,—дип имән бармагы белән Горбачев портретына таба төртеп кисәтте парторг,—антисоветская пропаганда белән шөгыльләнмәгез. Балантау Һинд океанындагы утрау түгел. Сез үзегезнең СССРда яшәгәнегезне онытмагыз. «Сухой закон» көннән-көн корылана бара. Хәзер райком кешеләре дә ГАИ инспекторы кебек—өрдереп карыйлар. Җитәкчеләргә эш җиңеләйде, кемнедер урыныннан куарга теләсәләр, берәр рюмка җибәргәнен сагалап кына торалар. Кемнең кем булуына карамастан җәза көтә.

—Ну, алайга китсә партком секретарьларын исни алмаслар инде,—дип шаяртмакчы булды Идриснең әтисе.

—Парткомны—райком иснәр, райкомны—обком! Обкомны иснәүчеләр Мәскәүдә утыра! Так што, тыныч булыгыз, аекка сабышып исереп йөрергә ирек бирмәсләр. Ишетсен колагын—Армиягә озатканда өстәлгә хәмер куймыйсыз!

—Повестка килмәгән ич әле, Зәкиулла!—дип, сөйләшүнең азагын йомшартырга иде агайларның исәбе.

—Кемнәр китәсе однозначно билгеле. Малайларыгыз район хәрби комиссариатының карарын телдән ишетте. Повестка юл билеты бит инде ул. Ә мин сезне беләм, хәзер әче бал куя торган чагыгыз. Сөйләшкәнчә ни-ни!.. Ишетсен колагын!

Булачак солдатларның газиз туганнары парткомнан таралышканда Гөлчәчәк капка төбендәге сукмакның кырпак карын себереп маташа иде. Идриснең әнисе Халидә Сөмбеләнең әнисе белән күршеләр генә түгел, бер тәрәз төбендә үскән гөлләр кеби генә дә түгел, яшьтәшләр дә, бер чорда укып, клубка бергәләшеп йөреп, бер-бер артлы килен булып төшкән ахирәтләр. Шуңа күрә ул туп-туры Гөлчәчәк янына килеп басты.

—Сөмбелән кая? Капка төбен өйалды идәне кебек итеп сөртеп тора иде бит.—Халидә елмаерга тырыша, тик кырылган кәефен яшерә алмый.

—Кыз клубта әле. Тәрәзә ярыкларын ябыштыралар. Кыш бик тузынып килергә уйлый ди быел. Галанка мич белән ат абзары чаклы клубны ничек җылытмак кирәк?! Капка төбенә аптыраганнан гына чыгуым, әллә берәр кизү йөри инде, Ходаем, бу араларда гел башым авыртып тора…

«Синең башың ындыр табагына Казан кунаклары килгән көннән бирле авырта түгелме соң?!»—дип чак әйтеп куймады Халидә. «Ул төнне безнең өйнең дә уты сүнмәде, игътибар иткәнсездер, шуннан бирле Идриснең сөмсере коелды»,—дип тә өстәсә капка төбендәге хәл белешү ике гаилә арасындагы сәясәткә әверелгәсе иде.

Халидә якты чырайлы хатын. Авылда аны башка Халидәләр белән бутамас өчен «сары чәчле» дип йөртәләр. Хәтта: «Халидә чәче сыман сап-сары» дигән чагыштырулар да ишетелгәли. Тик аны сары төс белән генә тасвирлап әйтеп булмый. Ашы тулган кукуруз чәкәненең яңа гына бөркелеп чыккан пумаласы төсле, кыргый болынлыкта елкылдап яткан күзгә сусән уты сыман ул чәч Халидәнең йөзенә нур бөркеп тора. Егетләр сөяр яшькә җиткәч, ул «марҗа кызы» дип гел үртәмәсеннәр өчен, ефәк толымнарын төенләп, яшел косынка белән каплап йөртә иде. Килен булып төшкәннән бирле кеше сүзенә ияләнде, үртәүләргә исе китми, хәтта яшел яулыгын күзләре төсендәге зәңгәргә алыштырды.

Җиденче класста укыганда микән, Сөмбелә балан тәлгәшләре күтәреп кергән иде. Әнисе ел саен балан җыя, бер өлешеннән как коя, калганын тәлгәшле килеш чормага чыгарып элә. Язга чаклы исән-имин тора, бозылмый. Балан бәлеше пешерәм дисәң чормадан кергәнчә алып төшәсең дә бөрчисең… Халидәнең яшенә күрә кан басымы уйнаклап тора иде. Чи баланны сытып, кайнар чәйдә пешекләп эчәргә кирәк иде… Сөмбелә Халидәнең җыелган урын өстендә ял итеп яткан чагына туры килде: шәмәхә фланель халат кигән, яулык бәйләмәгән, толымнары ап-ак мендәр өстендә, зәңгәр күзләре җемелди… уенчык караватка салган Казан курчагы диярсең… Идрис тач әнисенә охшаган. Күләгәсез чәченең һәр бөртеге нурланып тора. Зәңгәр күзле. Атналап кырынмый йөрсә дә ияк очында кабарган төкләре бик сизелми. Икесе тиң какча буйлы, җинел сөякле. Әнисенә ияреп чыкса Идрис кыз балага охшап кала. Сөмбелә аны егет итеп күрергә теләми, күбрәк иптәш кыз урынына йөртә. Хикмәте менә шунда…

Гөлчәчәк, себерке сабына таянып, Халидәнең моң-зарларын тыңлады, бүлдермәде, каршы төшмәде, «әйе, әйе» дигәндәй ым кагып торды.

—Нужаланып үстерәсең, үстерәсең малайны, Хөкүмәткә илтеп тапшырасың. Инде кешечә бәйрәм ясап озатырга да ярамый икән. Киткән чакта, ачык машина кузовында нечекләр итеп урам әйләнмәк кирәк?! Шушындый җилдә җырлыйлар бит әле алар. Районда җыелып, Татвоенкомга илтеп япканчы күпме туңасылары булыр. Әтиләре әйтмешли, сөяк-санакларын җылытырга җае чыкмаса салкын тиеп лазаретка егылышып бетәрләр…

—Теге ике чиләкле имән мичкән исәнме?

—Исәнен исән. Тик партком Зәкиулла әче бал куймаска кушып бик каты сөйләште бит.

—Ә без чүлмәк утыртабыз, коры сырага чүпрә катышмый. Сосласын үзем әзерлим, балан җыйганда очраштырган колмагым исән…

—Авыз иткәнем бар барын, ну әвәрәсе кулымнан килмәс.

—Өйрәтермен, Халидә. Безнең әни мәрхүм, авыр туфрагы җинел булсын, гел чүлмәк утырта торганые. Әткәй мәрхүм коры сыра ятты, хәмер белән мавыкмады…

Кич житеп, урамга таралган майлы таба, елкы шулпасы, сызыкта кыздырылган бәрәңге, кәбестә бөккәне исләрен күшеккән җилләр исни башлагач, авылга җан керде. Гөлчәчәк мичтәге кисәү башларын, утлы күмерләрне Казан астындагы учакка тартты, каз шулпасы куәтлерәк кайный башлады. Яна кышның салкыны көндезләрен кояш җылысына каршы тора алмыйча килеп-китеп йөри. Зуррак мал суйсаң сүле агып бетәр дип сугымлыкларга тотынырга тәвәккәллек житми. Ишлерәк оялы өйләр дә каз

өмәсенә ашыкмый. Ит кирәксә, инде күптән симереп туктаган казларны берәм-берәм чалып юана халык. Елкы-каз ите озаграк кайнарга тиешле...

Якты көннәр кыскарып бетеп бара. Эш кешесе бер караңгыда чыгып китә, дөм караңгыда кайтып керә, керә дә аш пешкәнне көтеп утыра. Харис диван-караватка авышып телевизор карый, Сөмбелә, көзге каршында үзенә-үзе иптәш булып, әле бүген генә хат ташучы кулыннан алган «Агитатор блокноты»н актара.

Гөлчәчәк, аш кайнаган арада тик утырмас өчен, чоланга чыгып ярты чиләк арыш алып керде. Мич каршындагы сәкегә суккан палас җәеп салкын арышны шунда таратты, уч төбе белән сыйпап тигезләде. Чүмечтәге салкын суны самавыр астында таманлап, вак-вак йотымлап бөркеде дә арышны калын җәймә белән каплап куйды. Баштарак хатыны ватылган электр үтүгенә үч итеп күмер үтүге белән нәрсәдер үтүкли дип уйлады, ахрысы, өйгә көек исе таралмагач, Харис соныннан сорап куясы итте:

—Нишлисең син анда?

—Салат оныңа арыш үрдерәм,—диде хатын, тавышын горур гөрелдәтеп.

—Кызым, әниең язгы чәчүгә әзерләнә бугай.

—Әни, чынлап та, нәрсәгә ул?

—Чүлмәк утыртабыз, кызым. Коры сыра булыр.

—Сөмбеләне Армиягә алалармы әллә?—дип янадан телевизорынаябырылды әти кеше.

—Идрисне кешечә озатырга кирәк,—диде Халидә. Коры сырага статья юк икән. Мин сосла ясап бирәм, калганын күршеләргә тапшырам.

—Салат оны, сосла, коры сыра дигән булып... Гомердә чүлмәк утыртканың юк ич синең!

—Әйе шул. Сезнең өйгә килен булып төшкәннән бирле тотынган кәсебем түгел. Синең коры сыра сораганың юк ич, яратмыйсың бугай.

—Кемне? Синеме?

—Коры сыраны.

— Ә син чынлап та чүлмәк утырта беләсеңме?

— Беләм.

— Вәт, хикмәти Хода! Кайчан өйрәндең?

—Әнидән күрдем... Әни әбидән өйрәнгән... Әбием, бабакай тиешле кешебездән яшь килеш тол калгач, Габдулла муллага бала караучы булып яллангган, шунда кул арасына кергән.

—Да, кызым. Әниеңнең чыбык очы муллалар нәселенә барып тоташа икән... Син дә өйрәнеп кал. Кооператив ачарбыз. Җырлый-җырлый сыра сатарсың...

Ачның ачуы яман дигәндәй, шаяртып Сөмбеләнең кәефен күтәрергә теләгән иде Харис, киресенчә килеп чыкты, кыз әтисенә шундый итеп карап куйды, телевизор экранында калын-калын ак сызыклар йөгерешеп алды хәтта.

Яшерен-батырын түгел, өйдәгеләр Сөмбеләгә хәзер никтер кияүдән кайткан кыз кебегрәк итеп карыйлар. Була бит шулай, клубтан кайтышлый ат җигеп сагалап торалар да толып каплап билгесез тарафтагы аулак өйгә алып кайтып ябалар... Үзен мәҗбүр итә алганы язмышка баш иеп яшәп кала, ә теләмәгәне бер атнадан булса да барыбер качып кайта. Тешләнгән, йә корт төшкән алма ише кипшеп, сулыгып ятасың. Андыйларга авыр сүз әйтергә ярамый, серкәләре су күтәрми; шук егетләр, җилдән бала тапкан яшь бичәләр хакында мәзәкләр сөйләсән—мыскыл итү кебек килеп чыга. Ә инде үгет-нәсихәт биреп, яучылар чакырту, кодалау, әти-әниләр аркылы таныштыру кебек юллар белән колагына чалынсаң—кем булуына карамастан, өй эчендә генә түгел, авылда бер җан дошманга әвереләсең. Димәк, баланың китек күңелен сыйпап, холкына ятып, кыланышларына түзеп яшәргә туры килә. Әгәр көннәрдән бер көнне: «Мин Казанга китәм!»—дип

кырт кистереп әйтә калса, Сөмбеләгә һичкем каршы төшмәс, киресенчә, сөенерләр генә иде. Казан каласы—зур кала, мул дөнья, кин дәрья... Миллионлаган кеше арасында китек күңелле, сынык сөякле, яраланган йөрәклеләре дә аз түгелдер. Сөмбелә китеп урнашса анда һичшиксез насыйбын-тиңен табар, бер бәхетсезне бәхетле итеп булса да үзе бәхетле була алыр иде. Мәгәр кызый авылдан китү турында сүз кузгатмый, артистлык хыялы турында кат-кат искәртеп өйдәгеләрнең тенкәсенә тими. Сөмбелә берәүне көтә. Ул көткән кеше авылның чокыр-чакырлы урамнарыннан олы юлга чаклы ат белән алып чыгачак, ә Казан юлында алар һичшиксез сап-сары «Москвич» машинасына күчеп утырачак. Көткән кешесе киткәннән бирле җәй белән кыш алышынды, хыялы алышынмады, бары тик теге ат кына кыңгыраулы тарантастан тугарылып, төрле чанага жигелде. Кыз өч ай эчендә үзенә йомылды. Эчтән сызды, тик ашаудан калмады, тумышыннан килгән елмаюын югалтса да клуб ачкычын авыл советына илтеп ыргытмады, сөйләшеп утырасы урында авыз эченнән көйләде. Ошамаган сүз ишетсә «ярамыйга карамый»ны жырларга тотынды... Август төнендә гармунчы янында калып ике араданиләр булганын Сөмбелә бары тик үзе генә белә. Һәм өйдәгеләрнең аның турында начар уйлап, хафалануы белән ирексездән килеште ул. Ин мөһиме, шушы борчулы көннәр бәрабәренә төпчек кыз әти-әнисеннән ирек яулады...

Сәке өстенә жәелгән арыш көяз кәләшкә әверелде. Гөлчәчәк күрмәгәндә Харис үзе дә килеп җәймәне ачып карый, кулы белән сыйпап тигезли, су бөрки, орлыклар тылсымын бик сакланып кына кире каплап куя.

Бишенче көнне арышның шытымы бөртек буена житте. Гөлчәчәк үрентеләрне табаларга җәеп сүрән мичкә тыкты. Иртәнгә алар үргән килеш әвәл пешә, аннан шытырдап кипкән була.

Келәттәге лар артында кырык еллык тузан эченнән кул тегермәнен эзләп алып керделәр. Аның ике ташы да исән-сау иде, мунчала белән юып корыткач чатнаган, кителгән урыннары күренмәде.

Кул тегермәне белән салат оны тарттыру курчак уенына әверелде, Сөмбелә әйләндерде, әнисе ташка арыш коеп торды. Харис кызлар уйнаганны карап көлеп утырмакчы иде, йомыш куштылар үзенә, заманында мич казнасы янында хезмәт иткән, ә хәзер исә көрпә салудан арыга тотылмаган күмер чүлмәген чоланнан алып кереп, чәй содасы белән эчеп-тышын ышкып юасы бар иде. Ир кешенең кул көченнән корым катламы кырылып, чүлмәк кызыл кирпеч төсенә керде.

—Гөлчәчәк, тишек ләбаса бу, кадак эшләпәсе сыярлык.

—Төбеннән мәллә?

—Юк, төптән чиртеш буе өстәрәк.

—Шулай тиеш. Әйтәм ич, әбиләрдән калган хәзинә ул. Син аны агач бөке белән томала.

—Ну хатын! Ул-бу була калса, өр-яңадан борынгы заманча яши башларга әзер икән без...

—Тәүбә, диген, ниткән «ул-бу» ди сиңа! Шөкер, әнә, Горбачевыгыз Әфгандагы сугышны туктатырга уйлый ди, солдат улкайларыбызны кире кайтарачак ди.

—Ә Идрисләр ник китә алайса?

—Идрисләр алар Кызыл Мәйданда Жиңү парадларында мактаныр өчен генә барып кайтасылар!—диде Харис, кызының күрше егете турындагы сүзгә кушылуына сөенеп.

Кичкә тагын мич ягылды. Усак утыннары шарт-шорт янган арада Гөлчәчәк, бик эшем кешесе чыраен чыгарып: «Тегене бир, моны китер!..»—дип, өйдәгеләрне тыпырдатты. Харис бер култык арыш саламы алып кереп аны салкын суда юып бирде. Сөмбелә ипи камыры изә торган күәсне алып керде. Калганын Гөлчәчәк үз кулына алды.

Ярты чиләк иләнгән арыш оны өстенә теге салат онын салгач, ипи куәсе тула язды. Башта Гөлчәчәк бу ике онны коры килеш болгатты, аннан кайнатылган суны жылымсалатып әз-әзләп салып торырга кушты. Куәс эчендәге боламык сыек камырга әверелде. Гөлчәчәкнең кулына күз иярми. Атна саен чүлмәк утыртып шомарып беткән диярсең! Ул арыш саламын чүлмәк эченә тыгызлап тутырды да сыек камырны шунда бушатты.

—Салам белән камырны бергә кушкач сыерларга башак болгату була түгелме соң инде бу, Чәчәк?—дип аптырап калды Харис. Тик Гөлчәчәк жавап кайтармады. Эшендә булды.

Ипи салганда, сулы пумала белән үрелеп, мич көймәсенең көлен ашыкмыйча сыпырып алалар иде. Ә бүген исә утлы күмерләрне бөртекләп тарткач, кызуны әрәм итмичә, тиз арада чүлмәкне таш өстенә шудырдылар. Мич капкачын иртәнгә чаклы ачарга ярамый иде...

Төн уртасында өй эченә таралган куе ис йокыдан уятты. Серкәләнгән арыш, төче күмәч, әче көлчә, яна киселгән ипи кыерчыгы, кыздырылган сохари катыш шоколад тәме килә иде әлеге истән.

—Сосла исе инде бу, жанашларым!—диде Гөлчәчәк мактанып.

—Кызым, син анда ничек түзәсең, әле бу якта да чыдар хәл юк,—диде Харис, чүлмәкле мич ягын үз куышы иткән Сөмбеләне үртәп.

—Агач кашык белән үрелеп авыз итимме соң, әни?!

—Шаярма кызым! Өлгермәде әле ул.

Чүлмәк чыкканны көтеп иртүк торып бассалар да Гөлчәчәк мич капкачына берсен-бер якын жибәрмәде.

Мал-туарларга печән салып, сыерны савып, исән калган казларны ишегалдына чыгарып жим сипкәч, капка биген ачмыйча гына, ниһаять, чүлмәкне мичтән кисәү белән шудырып чыгардылар. Колач буе имән улакны сәке белән урындыкка таяндырдылар. Улакның аскы ягына туры китереп, идәнгә биш литрлы бидон куйдылар. Ике кирпечне янәшә тезеп сәкедәге чүлмәкне улак авызына куйдылар.

Гөлчәчәк агач бөкене тартып алгач, чүлмәктән кызгылт-көрән сосла бәреп чыкты. Ул көнбагыш мае кебек тавышсыз акты. Бидон төбенә күбрәк жыелган саен кызыл төсе куерды, көрән булып күренә барды. Улактагы гөрләвек тынгач, бүгенге муллыкка сөенгәндәй жырлап утырган самавырдан ике чүмеч су алып өстәделәр. Кайнар су чүлмәк эчендәге саламнарга качып калган куе сосланы юып алып чыкты.

—Ялап карар өчен бөтенебезгә дә шушысы житә,—диде Гөлчәчәк, тулыр-тулмас бидоннан агач кашык белән чумырып алгач,—сосла салкын килеш тәмле була. Бар, кызым, өстен яп та чоланга чыгарып куй.

Яшьләр кичке уенга киткәч, Гөлчәчәк нигез күршеләре Халидәгә күтәренеп керде: бер кулында бидонлы сосла, икенчесендә колмаклы төенчек.

Булган сосланы жылымса су белән болгатып ике чиләкле имән мичкәгә тутырасың. Эчемлек әзерләгәндә бары тик кайнаган су гына яраганын авыл жирендә артык аңлатып торасы юк... Мич башында бер тәүлек уйнагач, эчемлекнең колмагын сөзеп салкынча урынга—идән астына төшереп куясың. Менә шушы була инде коры сыра, шушы инде ул «чүлмәк утырту»ның сихәтле бәлзәме!

Балантауның яз көне киткән егетләре һәркайсысы аерым-аерым мәжлес үткәргән иде, алар «Сухой закон»га эләкмәде. Ә менә хәзер, өч егет повестка алгач, жыелып кинәштеләр-кинәштеләр дә өйдән-өйгә йөреп лимонад шешәсенә карап утырганчы Идрисләрдә генә саубуллашыйк диделәр. Халидә апаларының чүлмәк утыртканын Идрис аркылы ишеткән иде инде яшьләр. Бөтенесенең коры сыра татып карыйсы килде. Яшьләрнең генә түгел, Гөлчәчәк, Сөмбелә, Харисның да авыз иткәне юк иде әле борынгылардан

калган яна эчемлекне. Күршеләргә керер алдыннан Сөмбеләгә нәсихәт тукып алдылар.

—Кызым, Идрис алдында турсаеп утырма, авылдан боегып китмәсен.

—Өмет белән китсенме, әйт әле, әни?

—Бу дөньяда бик күп нәрсәне кеше күнеле булсын өчен генә эшлисең. Сездән көнләшеп җәнҗал чыгарырдай егетләр калмады. Идрис янында дустанә утырсаң укаң коелмас. Илгә солдат үстергән Халидә апаң да сөенер...

Халидә мәҗлес алдыннан кибеткә барып, жиде тиенлек кырлы стаканнар алып кайтты. Егетләр ягыннан кем паштет, кем гөбәдия, кайсыдыр каз бәлеше пешереп китерде. Табында ипи куярлык та урын калмады. Нигъмәт арасында гөнаһ шомлыгы булып качып утырган кырлы стаканнарга, кояшта көйгән колмак чәчәкләре төсендәге эчемлек салынгач, кунаклар бер мәлгә шым калды.

Колхоз председателе отчет-сайлау җыелышлары башланганчы дип өч атналык путевка белән ял йортына киткән. Авыл советы рәисенең мунча кереп йөргәнен күргәннәр, баш бухгалтер Шәмәрдән ит комбинатыннан кайтып житмәгән диделәр. Юл кирәк-яраклары тутырылган өч рюкзак, хезмәт итү урынына барып житкәнче юл чыгымнарын капларлык өч конверт, председатель исеменнән бер ай алдан кул куелган өч мактау грамотасы—һәммәсе дә партком секретаре кулында иде.

Бүләкләрне тапшырып: «Исән-сау әйләнеп кайтыгыз, сез колхозга бик кирәк!»—дигән теләкләрне горурлык хисе белән ике кат кабатлагач, Зәкиулла Шакирович кул астына туры килгән стаканлы эчемлеккә үрелде. «Нүжәли эчә инде бу, шушы хәтлек кеше арасында» дигән сынаулы, хәйләле, өметле карашлар ана текәлде. Парторг Франциядәге Шампань провинциясенең атаклы дегустаторы кебек, бер йотым эчемлекне ике ирен арасында чәпелдәтеп матчага бакты. Бөтен кеше алдында маңгаеннан иягенә таба йөзе агарды... Тагын берне йоткач, иягеннән маңгаена таба кан йөгерде... Һәм ул, мәҗлестәгеләрне сөендереп, кырлы стаканны илле граммлы йотымнар белән дүрт селтәнүдә бушатты.

—Куаска охшаган!—диде парторг, ялтыратып кырылган мыек урынын сыпырып.—Рөхсәт!

Кунаклар чиллә сусавы белән стаканнарга ябышты.

«Коры сыра» куас түгел шул ул...

Өч егет исәнлегенә өч стакан түнтәреп куйгач, яшьләр җыр эзли башлады.

—Егетләр, кагыйдәне беләсез! Хор белән берне җырлагыз да мин китәрмен, җан көеге булып утырмам,—диде парторг саубуллашырга теләп.

Дан сина, дан, Совет солдаты!<br>
Дан сина, дан, Совет солдаты!

Әлеге җырның соңгы кушымтасын кәефле җырчылар шулхәтлек күп кабатладылар ки, Зәкиулла Шакирович өенә батыр солдат булып кайтып китте.

Вак-вак йотымнар белән авыз итә торгач, Сөмбелә дә бер стаканны бушатты. Аның елмаюын янында утырган Идрискә багышладылар. Ләкин кызый, тәрәзәләр өстендәге кашаганың чигүле пар күгәрченнәренә текәлгән дә күз алдына китергән берәүгә елмаеп утыра иде.

Сөмбеләнең бергә укыган дуслары авылда берәү-икәү генә. Күбесе йә укырга кереп, йә эшкә урнашып Казанда калды. Алар ял көннәренә кунакка кайтып клубка чыгалар, бииләр, уйныйлар, студент тормышы белән мактанышып, укырга керә алмаганнар алдында масаялар да тагын китеп баралар. Повесткалар атна уртасына килгән. Казаннан кайтучылар юк иде.

Бер-ике яшькә булса да үзеннән кечерәк мәктәп балалары белән күмәк жыр жырлап утыруны бик өнәмәде Сөмбелә һәм кинәт торып басты. Бу анын үзем генә жырлыйм дигән сүзе иде.

Йә «Резидәкәй»не, йә «Озату»ны жырлап егетне елата бу хәзер дигәндәй, кәефле кунаклар мажара көтеп Идрискә таба борылды.

Ә Сөмбелә мажара көткәннәрнең өметен акламады, елар хәлгә житешеп күзләренә яшь тыгылган теләсә кайсы жан иясен елмайтырлык жыр башлады. Кушымтасы бигрәкләр дә күнелле:

Син сөймәсән миндә сөймәм—
Гөл үсмәгән битенә...

Жырнын мәгънәсен тигез мәхәббәткә юрап, Идрис өчен сөенделәр. Егет, каушавыннан үзен кая куярга белмичә, Ильич лампасы астында жемелдәп торган житен чәчен ике кулы белән каплап, өстәл читенә таянды. Ояла-ояла куануы ул анын... Арткы өйдә аерым табын корып утырган туганнар арасындагы Гөлчәчәк белән Харисның гына күнеленә шом керде...

Сонгы өч ай эчендә артык күп янгырады инде бу жыр, чамасы югалды. Һәм ул жыр азатлык яуларга теләгән Сөмбеләнең эчке бер фетнәсенә, каршы дәшүенә, көрәшкә чакыру авазына әверелде кебек. Кыз Идриснен Армиягә китүеннән тәм табып тантана итте. Пионер яшеннән бирле «иярчек тай» булып тагылган, «чал чәчле», «әнисе кебек», «тумас борын картайган», иптәш кыз урынына калган күрше малаеннан котыла, ниһаять... Шул ук вакытта Сөмбелә үзенең тәмам аяныч ялгызлыкта калганын белә. Әти-әниләр, кичке уеннардан кайткан яшьләргә рәхәтләнеп серләшергә дә ярамый бит сон ул. Алар бер яклы вәгазь, кинәш, нәсихәт кенә. Унсигез яшьлек кызлар, күп очракта, якын туганнары арасында да үзләрен ялгыз хис итә... Һәм ялгызлык аны бер мәл һич көтмәгән кискен чаралаpга этәрә.

Парторгның: «Исән-сау әйләнеп кайтыгыз!»—дигән изге теләге бер атнадан ук кабул булыр дип кем уйлаган?!.

Кар ява башлаганны төн уртасында Идрисләрдән жырлашып таралышкан кунаклар гына күргән иде. Ә инде иртән бөтен авыл ак сөенеч белән сөенде. Тәүге кар соры мохитне акшарлап куйгач, Балантауның исеме жисеменә тач туры килде, авылдагы һәр куак, тал-тирәк балан агачына әверелеп чәчәк атты, диярсен...

Кар бөртекләре әле ябышкак түгел—бөтерчек жилләр искәндә алар бизәкләрен саклап кына тәрәзә йөзеннән капка өстенә куна, рәшәткә баганасыннан аяк астына килеп төшә.

Бар тынлыкка бер үзе калганмы—Идрисләр түбәсендә сынар ала карга зарланып утыра.

Идрисләр капка төбенә «ГАЗ—52» килеп туктады. Машинанын әржәсенә сыер савучыларны жәйләүгә илтә торган озын урындыклар беркетелгән иде. Каршы искән юл жиле йөзгә туры бәрелмәсен өчен әржәнең алгы өлешенә брезент ышык куелган.

Кичәге коры сыраны өчәр стакан каплап өлгергәч, егетләргә тагын байлар чырае керде. Инде районга чаклы ачык машинада жырлап барырлык куәт бар иде. Колхоз идарәсе йортында озак тоткарланмадылар. Озата килгән туганнарнын кинәш-нәсихәтләре өч егеткә дә бертөрлерәк яуды:

«Бүрек колакчынын төшереп бәйлә, колактан кергән жил кире чыкмый.»

«Рюкзагын аяк астында калмасын, ризыклар сытылыр.»

«Документларын онытылмады микән инде, Ходаем?..»

«Теге акчаларынны барып житкәнче тотасы түгел!»

«Өчпочмакларны ашый-ашый барыгыз, суынгач тәме калмый анын...»

«Барып житүгә хат язып сал. Иренеп ятма анда...»

Әгәр, машина кузгалып китмәсә, үгет-теләкләрнең бетәсе юк иде әле.

«Алмагачы» көенә көне буе җырларга була. Өч урамны янгыратып әйләнгәндә дә куплетлар кабатланмады. Ниһаять, район борылышына чыгып, күмәк җырны көчәйтер өчен генә әрҗәгә төялгән жилкенчәкләр коелгач, машина Армиягә китте... Яше житеп килгәннәр сагышланып кул болгады, ә тизрәк үсеп солдатка китү турында хыялланган үсмерләр кызыгып, көнләшеп калды...

Ә бер атнадан Идрис кайтып төште. Сәлперәйгән рюкзагын бер иңенә элгән килеш, юл унаенда очрардай авыл машиналарына күренмәс өчен карлы сукмаклардан кача-поса, язмышына рәнжеп кайтып төште... Ул атна буе урамга чыкмады, кеше күзеннән качып ятты. Халидә парторг бүләк иткән рюкзакны эчендәге вак-төяк бүләкләрен барлап кире илткән иде—алмадылар. Бүләк ителгән, акт төзеп гамәлдән чыгарылган, кул куелган, өегездә калсын, диделәр. Әнисе рюкзакны тагын алып кайтып тоттыргач, Идрис үзен каты сугышта фронтовик дусларын ташлап кирегә йөгергән дезертир кебек, антыннан ваз кичкән сатлык җан кебек хис итте... Әнисенең юатырга теләп: «И улым, әйбәт булган ич, ил-җирләр тыныч түгел. Ике ел буе ут йотып яшәгәнче, сөенергә генә кирәк...»—дигән сүзләрен урамда очраган беренче егет үк сызып ташлаячак:

—Нихәл, негодный, борып кайтардылар мыни?!.

Балантауда Армия хезмәтеннән «ак билет» белән калган егетләр бар барын. Тик аларның берсенең дә кушаматы «негодник» түгел. Идрискә дә кушмадылар андый сүзне. Ә менә, Татвоенком комиссиясе куеп кайтарган диагноз кушамат булып бик тиз ябышты. «Әй, Аю табаны!»—дип дәшсәләр, Идрис ирексездән борылып карый хәзер...

Сөмбелә житен чәчле күрше егетенең кире кайтуына сөенмәде дә, көенмәде дә. Кыз инде, август киченнән бирле, мин сине авылдан коткарам дип, алмалар тешләп ант иткән назлы гармунчыны көтә...

## Назлы гармунчы

Кибет күләгәсеннән тагын берәү пәйда булды. Монысы чынлап та көткән кунакка охшаган: ыспай, пөхтә, җыйнаклыгы олагаем гәүдәсенә күрә түгел, тузан кунмаган күн чабатасының ачык челтәреннән ап-ак юка оекбашы балкый—Балантауга килеп төшкәннән бирле урамнарны җәяү гизмәгәне әллә каян күренеп тора. Тыгыз тәнендәге ак теннискасы бер үлчәмгә кечерәк кебек сыланган. Зөлфеннән алып маңгаена чаклы капланган куе кара чәченең һәр бөртегеен кызган бишнәгә урап бөдрәләткән кебек. Мыек чолымнары ияк читендә елкылдый. Кысык күзләренең елтырына, калын кара кашларының кыйгачлыгына да игътибар итсән бу абзыйның ерак бабалары, кояшка якынрак тарафларда яшәп, сонрак безнең якларга күчеп килгәнне чамалавы кыен түгел.

Сөмбелә каушамады түгел, каушады—исәнләшергә дә онытып телсез калды. Хәер, тиз арада өненә килеп, кулындагы көшел көрәген мылтык урынына күкрәгенә терәде дә парторг ягына борылып үрә катты:

—Зәкиулла Шакирович, ни боерасыз?!

—Боерык алганчы, менә, кунаклар белән таныша тор: «Наз» ансамбле җитәкчесе Марат Гомәр абыең бу!

—Абау!—Агач көрәк, Сөмбеләнең кулыннан шуып китеп, сай чүәк эченнән күренеп торган аяк йөзенә калагы белән килеп төште.—«Наз»ны бик яратам мин, сезне дә бик яхшы беләбез. Күргәнем генә юк иде. Менә нинди кеше икәнсез?!

—Нинди кеше?—Марат Гомәр мыек чолымнарын сикертеп елмаеп куйды.

Каршы килмәсәгез күрешер идем, дигәндәй, сак кына кулын сузды, аннан нигәдер кызның кулын җибәрмичәрәк торды.

—Нинди кеше мин?—дип кабатлап сорады ул тагын, һәм әлбәттә юри, вакытны сузар өчен генә.

—Матур артист.

—Син дә чибәр кыз. Артист булырга теләсәң бик тиз хыялыңа ирешә алыр идең. Булышырбыз!..

Сүзгә парторг катышты.

—Берүк күңеленә коткы сала күрмәгез, Марат туган, көч-хәл белән генә тыеп торабыз без аны. Кечкенәдән коеп куйган җырчы ул. Быел укырга керәлмичә кире кайтты.

Артист уч төбендә утлы күмер тотып йөри мәллә—Сөмбеләнең бармаклары пеште, кулын көчкә тартып алды.

—Медицина институтына барып карады,—дип дәвам итте парторг. Кызны һушына китерергә теләгәндәй, аның тавышы кисәк кырысланды.—Бер чибәр кыз авылда төпләнеп калса, аңа өметләнеп ким дигәндә җиде егет кала. Ә колхозга яшь көчләр һай бик кирәк! Китер әле, Сөмбелә, шул күрәгеңне, казыкка бәйләнгән кебек торма. Үзем күтәрим лутчы.

—Зәкиулла Шакирович, икмәк калагы ул, ташлама!

—Үрәтмә, кызый, беләбез! Ә менә теге кунагыбыз—шагыйрә! Гөлҗиһан апа, килегез әле. Койма тирәсендә бик чиста түгелләр. Дару үләннәре җыясыгыз килсә, мин сезне Спасс якларына—Такталга алып кайтырмын. Әйдәгез, клубны карап чыгыйк, кичен чыгыш ясыйсы булыр...

Киң балталы ачкычның юан көпшәсе йозак кендегенә туры килəлмичә интектерде. Тере шагыйрәне күргәч коелып төште Сөмбелә. Аның җырлары модада бит хәзер. Концерт куйсаң да, мәҗлескә җыелсаң да, савымчылар машинага төялеп җәйләүгә китсә дә гел Гөлҗиһан апаның җырлары яңгырап торыр.

Монарчы Сөмбелә шагыйрьләрне райком секретарьлары кебегрәк итеп күз алдына китерә иде. Күреп сөйләшәсең килсә ишек төбендәге сакчыга паспортыңны күрсәтеп керәсең, чират торып үз сәгатеңне көтәсең, кабул итеп кәгазенә автограф куйган арада ул әллә ничә начальник белән телефоннан сөйләшеп өлгерә. Рәхмәтеңне әйтеп, вакытын әрәм иткәнгә гафу үтенеп, чыгып китәсең. Ә ул, мәгърур гына баш изәп саубуллаша да тагын шигырьләренә чума...

Бактың исә сукыр кычыткан, кара әрем, меңъяфрак, бака үләне кебек аяк астында түшәлеп яткан чүпне дару үләннәре дип хөрмәтләп җыеп йөри торган башка авыл апасы Гөлҗиһан Зәйнашева үзе икән! Сөмбеләнең аңа Дәү апа дип, якын итеп эндәшәсе килде. Шагыйрә шултиклем гади иде ки—аның чүәге Сөмбеләнеке кебек, өстендәге ябык изүле, озын җиңле чуар чәчәкле ситсы күлмәге күрше апасыныкы шикелле, юл тузаны кунмасын өченгә бөркәнгән күгәрчен тамагы төсендәге сатин халаты әнисенекедәй таныш. Августның урып-җыюга ярардай кызу торуына карамастан, баганалы көрән оек киеп килүе белән карилəрчә самими ханымга әверелә иде. Шагыйрә икәнен белгәч, Сөмбелә аны фотога төшергәндәй текәлеп, кызларга гына хас җентекле һәм дә ки көнләшүле караш белән күзәтте.

Куна тактасы өстендә озаклап он иләгән хуҗабикәләрнеке төсле генә итеп йөзенә кершән тузаны өргәннәр. Беренче карашка ук игътибарны үзенә җәлеп итә торган үзенчәлекле борыны да табак битенә килешле генә. Җәенке иреннәре кызгылт иннек белән бөрелгәч, иягендәге тыгыз җыерчыклары да өзлексез елмаю өстәп тора. Кечкенәдән михнәттә үсеп, моң-зарларын кешегә сиздермәскә өйрәнгәнгә охшый бу апа.

Шагыйрә клуб тирәсендәге гарасатта үсә алган әрсез үләннәрне туй чәчәге

кебек иркәләп беләгенә салды.

—Авыл халкы аптекада яши. Үз кадерен үзе белми генә.—Һәм шагыйрә килә килешкә үк үләннәрне парторгка сузды.—Менә боларын машинага илтеп куегыз әле, Зәкиулла, бераз кипши торсын. Исән кеше дулаган җирдә зәхмәт юк, завод-фабрика тирәсеннән генә җыярга ярамый. Мин бит өемдә кибет чәен эчмим, сукыр кычыткан төнәтеп эчәм, давлениием югары минем. Миннурдан аерылгач гипертоникка әйләндем.

Парторг, шагыйрә кочагыннан алган үләннәргә әлләни исе китмичә генә, янә рәшәткә төбенә илтеп куймакчы иде, ләкин кунак апаның чын күңелдән ачылып китүен күреп, ул уйдан кире кайтты, машинага таба юнәлде.

—Исемең ничек соң, кызым?

Сөмбелә, йозакка иелгән җиреннән тураеп басты. Инде шагыйрә дә аңа бик текәлеп сыный карады һәм үз соравына үзе җавап эзли башлады:

—Тукта, исемеңне әйтми тор... Күпчелек кызларның исеме—Алсу, Ләйсән, Гөлназ, Гөлнара хәзер. Туры китердемме?

—Юк. Сөмбелә мин... Әнием Гөлчәчәк, апам Резедә, Казандагы туган апам—Лилия...

—Тәрәз төбендәге гөлләр кебек икәнсез... Сөмбелә... Гиацинт дигән бик матур чәчәк исеме.

—Дару үләне мәллә, Гөлҗиһан апа?!

—Белмим шул, балакаем. Җирдә күпме чир булса—шулхәтле дару үләне үсә, тик кеше үзе яшәгән җирдәге үләннәрне генә файдаланырга тиеш. Сөмбелә чәчәге безгә бик ерактан күчеп кергән ул. Исемең үзеңә бик килешә. Минем дә синең кебек чакларым бар иде.

—И, Гөлҗиһан апа, сез әле дә бик чибәр ич!

—Рәхмәт, балакаем, мактауны ялган булса да тыңлавы рәхәт аны. Мине дә чибәр дип әйтә белгәч... синең фантазияң бик көчледер...

—Кем белгән инде, Гөлҗиһан апа.

—Клуб тирәсендә ни житте кеше эшләмәс. Җырлыйсыңмы, биисеңме, әллә нәфис сүз остасымы син?

—Бәйрәм кичәләрендә бөтенесенә тотынабыз инде.

—Зәкиулла, Марат!—дип янына дәште шагыйрә.—Алыгыз әле Сөмбелә кулыннан шушы ачкычны, ат башы хәтлек йозак белән сугышканын читтән карап тормагыз.

—Кунаклар алдында юри генә иркәләнә ул!—Парторг шелтәләгән рәвеш китереп сөйләнсә дә чынында исә тимер аркау белән аркылыга бикләнгән калын ишекне бик теләп ачты. Клуб эчендәге тәртипне күздән кичергәч, алар ишекне янә бикләп, ындыр табагына очрашуга ашыктылар.

Ындыр табагына менеп житкәнче шактый таушалган өстәлне кызыл постау белән каплап, янына өч урындык куйгач, көшел каршында җыйнак президиум барлыкка килде. Өлкәнрәкләр мәкинә чүмәләсе өстенә брезент җәеп утырды, яшьләр көрәкләргә таянып артка басты. Утны өзделәр—тигез гөрелдәү белән эшләп торган барлык двигательләр берьюлы сүнде, амбар түбәләрендәге тук күгәрченнәр генә, партиянең урып-җыю идеологиясенә үзләренчә өлеш кертергә теләгәндәй, өзлексез гөрлиләр иде.

—Ярты гына сәгатькә!—дип башлады парторг. Әлбәттә, тамашачыларга карап әйтелсә дә вакыт чамасын сиздерүе килгән кунакларга алдан ук искәртеп кую өчен кирәк иде.—Сезнең алдыгызда җырчы шагыйрә Гөлҗиһан Зәйнашева һәм баянчы композитор, «Наз» ансамбленең житәкчесе—Марат Гомәр.—Ике кунак өчен берьюлы кул чапкач, көчле алкышлардан теге күгәрченнәр шым булды.

Шагыйрә кай арада сатин халатын салып яшергәндер, анысын Сөмбелә сизми калды, ул хәзер яңгыраган һәр шигырьне отып калырга әзер, чөнки

алар кайчан да булса барыбер көйгә салыначак, иртәме-соңмы аны җырларга туры киләчәк иде.

—Шигырь язу—елауның бер төре ул, шуна күрә мин сезгә сагышлы шигырьләремне укымый торам, аларны, боерган булса, бүген кич иркенләп очрашканда тынларсыз...

Ике кунак вакытны урталай тигезләп бүлешкәннәр иде ахрысы, шаян шигырьләр төп-төгәл унбиш минут яңгырады.

Баянчы исә бераз уйнаган саен бер кавым акланып ала. Районга килгәч бригадаларын бүлеп авылларга ваклап таратканнар икән. Гөлҗиһан Зәйнашева белән Марат Гомәр Балантауга эләккән кебек, яшь җырчы Кларалы, баянчысыз гына язучы Самат Шакирга ияртеп, күрше авылга җибәргәннәр ди. Районны тизрәк йөреп чыксыннар өчен.

Ындыр табагында үзенең җырлары яңгырый алмагач, шагыйрәнең кәефе төште—йөзендәге елмаюы сүнеп-сүнеп алды. Шаян шигырьләрдән иләсләнгән халык мәкинә өстеннән төшәргә ашыкмады. Авыл җирендә йоласы шундый—гармун уйнаганда җыр кушылырга тиеш.

—Гөлҗиһан апа үзегез җырлагыз инде, моңыгыз бардыр, юкса бу хәтле җыр яза алмас идегез!—дип ялынды яшьләр.

—И, балакайларым, Җир йөзендә нинди һөнәр бар—бөтенесен эшли алам, түлке җыр белән бию генә сорамагыз.

—Алайса, әнә, Сөмбелә җырласын, «Сәяхәтче»не!

—«Үз илемдә»не!

—«Күңелле ял итегез» дә шәп җыр.

Бәлкем бу минутта Сөмбеләгә бераз ялындырырга да кирәк булгандыр, ләкин ул, алдан ук сүз куешкандай, исемен ишетүгә Марат Гомәр янына килеп басты. Чын гармунчыга ияреп җырлыйсы бик килә иде аның. Алай да каушавы хак—ул ялгыш баянның бакалары ягында калган иде. Анысын гармунчы үзе төзәтте, кызның сул кул ягына күчеп басты. Артистларча гына пышылдашып алдылар.

—Нинди тональностьта уйныйм?

—Белмим мин. Башлап җырлыйм, ә сез иярегез.

Юлга чыккан һәр кеше җырлый алырдай гади сүзләр, Сөмбеләнең ләззәтле моңы белән баянның аһәңле иҗекләренә килеп кушылгач, тынлаучылар гына түгел, хәтта ындыр табагында өелеп яткан август киче дә өнсез калды.

Сөмбелә яна җырларны тиз отып кала. «Сәяхәтче» җырын ул инде кырыкмаса-кырык башкаргандыр, кирәксә патефон тәлинкәсе кебек, көннен-төннен кайсы вакытында кушсаң шунда җырлый ала. Менә хәзер дә үзен иркен тотты, шигъри юлларга уйлары да иярде хәтта... Күр әле син... бөтен яшьлеге авылның мактанчык уенчыларына ялынып үткән икән! Балантау гармунчыларына иң әвәл, җырны исләренә төшерер өчен, авыз эчендә генә көйләп аласың, аннары кушымталарда сине куып житкәнен көтеп торасың. Кайберләре исә тик бер генә тирәдә уйный ала—өйрәнчекләрдән өйрәнгән «До-мажор»дан ни аска, ни өскә күчә белми. Калынрактан уйна, нечкәрәк кирәк дип терсәгең белән төрткәләүдән һич файда юк, йә чәрелдәп, йә ыңгырашып дәвам итәргә туры килә... Ә чын гармунчы сине кирәксә югарыга тартып менә, тавышыңа тәңгәл китереп кушыла, моң борылышларында сабый баланы көйләгән кебек итеп житәкләп бара икән...

Гармунчы белән җырчы арасында һөнәр күрсәтү бәйгесе башланды кебек: берсе, Казан артындагы авылда, музыкаль әзерлеге булмаган килеш, сокландыгыч тавышлы яна яшь җырчы очратырмын дип һич уйламаган иде, шуңамы бик сөенеп уйнады; икенчесе маэстро янында җырчы исеме алыр өчен ике-өч минут эчендә бөтен тавыш байлыгын күрсәтеп өлгерергә тырышты.

Төгәл ярты сәгать үтүгә кунаклар алдында гафу үтенмичә генә утны

куштылар. Тынлаучылар берсе-берсе ун кешегә торырлык итеп кул чапты. Кинәт кабынган моторлар гүелтесеннән өркеп күтәрелгән күгәрченнәрнең канат кагышлары алкышларга кушылды.

Парторг Сөмбеләне читкәрәк дәшеп алды.

—Син кунакларга авылны күрсәтеп ал. Нәкъ бер сәгатьтән ашханәгә алып килерсең. Ишетсен колагың, төгәл бер сәгать!

—Ярар, Зәкиулла Шакирович, бер сәгатьтән һава сулатып, бит-кулларын юдырып китереп куярмын.

—Әй, әй... канатлы кырмыска! Үз ишләрен күргәч ничек талпына! Матри, кызый, үрсәләнмә! Быел ни-ни-ни! Беркая да китмисең. Киләсе җәйгә, имтиханнарыңны уңышлы тапшыра алсаң, Казаныңа үзем илтеп куям. Пока тынычлап эшлә! Ишетсен колагың! Так, онытмадыңмы, төгәл илле биш минуттан ашханәгә!

—Бая бер сәгатьтән дигән идегез ич, Зәкиулла Шакирович.

—Биш минуты сиңа вәгазь сөйләп үтте, ну әрәмгә китмәде. Шылдымы?!

Сәяси лозунглар өләшкән елларда, ике идел кичеп, Татарстанның көньягыннан төньягына күчеп килгән парторгны Балантау халкы бик тиз туганый итте. Елы-елы белән аны колхоз рәисе итеп тә сайлыйлар. Ләкин туры сүзле мишәр егете эш урыны белән исәпләшми, районлагы кимчелекләрне күңеленә бик якын алып, райком пленумнарында чәчрәп сөйли дә... икенче көнне үк аны йә парторг итеп куялар, йә авыл советында калдыралар. Көзге хисап җыелышларында колхозчылар аны тагын рәис итеп сайлый. Нинди генә эшкә куйсалар да кешедән калган урын дип кимсенми, җиң сызганып тотына үзе. Саратовтагы Партия мәктәбеннән җитәкләшеп кайткан хатыны белән, артык бәхәскә кермичә генә, Балантауда бөтенләйгә төпләнеп калдылар. Бүген дисә бүген теләсә кайсы министрлыкны җитәкли алырдай егеткә «Ике башлы Зәкиулла» дип йөзенә бәреп әйтәләр. Мактау гына түгел, кинаясе дә бар—парторгның баш түбәсендәге аркылы буразна аның акыл оясын зур-зур ике ярымшарга аерган. Ул урында хәтта тыгыз чәче дә киртләчләнеп тора. Баштагы мәлләрдә ул, урта звено җитәкчеләре кияргә тиешле ак кепканы кайсы ярымшарына кияргә белмичә, кулына тотып йөри торган иде, хәзер болай гына, гел яланбаш.

Алар авыл артындагы тар урман буйлап атладылар. Ындыр гөрелтесе ерагайган саен, җәйнең икенче ягында сайрар кош булып берүзе калган тургайларның куанышып сайравы ныграк ишетелә башлады. Кайсы яктан килсәң дә жил үҗәтләнеп агачлар ягына юнәлә кебек. Алтыннары авырайган каен яфраклары көзне ашыктырып җилгә иярә.

Ике яктан култыклап алырлар дип өметләнгән иде Сөмбелә. Әмма, «УАЗ»икның алгы утыргычына уникe килолы баянын бәйләп озаткач, Марат Гомәр җинеллек тоеп, тар урманның күрше рәт арасына күчте. Аның сөйләшеп баруы күбрәк сәхнә монологына охшаган иде.

—Көн сап-сары бүген, ә?! Минем болай алтын-көмешкә бик исем китми. Ну, Алтын көзне яратам инде. Ятимлектә үссәм дә минем яшьлек мул иген кырлары тирәсендә үтте. Безнең Чирмешән буйларында туфрак көчле. Көлтәләрен кочаклап алсаң хуш исеннән дә тамагың туя, башаклары—сары розалар хәтле!

—Җыр язар вакыты җиткән инде моның! Әйдә, комачауламыйк, арттарак калыйк.

—Гөлҗиһан апа, җыр ничек языла соң ул? Шагыйрь белән композитор бергә утырып язалармы? Әллә аерым-аерым язып бергә кушалармы?

—Кем ничектер, балакаем, аның кагыйдәсе юк инде. Менә без Миннур абыең белән бергә яшәп иҗат иттек.

Шагыйрә, Балантау кызын самими дус итеп, ана эч серләрен бушатырга

теләдеме, әллә артист булырга сукырларча хыялланган менләгән баланың берсе итеп алдан ук кисәтергә, сәхнә тирәсендә сагалап торган тигезсез көрәшле, татлы һәм төче, алкышлы һәм күз яшьле, газаплы һәм ялтыравык язмышны күз алдына китереп карарга ярдәм итмәкче идеме—белмәссен. Бактын исә, шагыйрәнең башыннан кичкәннәре сәхнәдәгеләр өчен сер түгел. Пәрдә ярыгыннан борын тыгып залны күзәтүләрен, гармунчы белән айрылышкан чакта гаилә шаһиты Әлфия Афзалованың судта ясаган чыгышын, концертлар белән чыкканда самолет багажнигына капчык-капчык дару үләннәре төяп кайтуын, хәтта, китап акчасына сатып алган яна «Запорожец»ны йөртергә өйрәнгәндә, барган көйгә куркудан ике кулы белән күзен каплап: «Абау!»лап чүерташ өеменә барып кергәнен дә яна мажараларга өстәп, теллән-телгә сөйли торалар. Гайбәткә кергән кешенең гөнаһысы кими дигәннәре хак булса шагыйрә инде ошбу якты дөньяда ук изге кеше... Ә бүгенге кыз пәрдәнең икенче ягыннан—Казан артистлары белән чагыштырганда ул әле тамашачы гына. Ләкин затлы һәвәскәр тамашачы. Шагыйрә дөрес яшәде, ялгышлары—теләп алынмаган, хөсетлеләр, әрсезләр, тотнаксызлар дучар иткән җәза гына. Бүген дә, иртәгә дә Сөмбелә каршында оялырлыгы юк. Ул хәтта, кызыйның тел очында эленеп калган соравын да сизеп тора.

—Әйе, сенлем, композитор Миннур минем ирем иде.

—Чынлапмы, Гөлҗиһан апа?!—Кызый өчен бу бик зур яналык иде һәм бу серне Балантауда әлегә бары тик Сөмбелә генә белә!

—Сер түгел инде ул. Без Илһам абыен, Әлфия апаннар белән концерт куеп йөргәндә син әле мөгаен тумагансындыр да. Мин концертны алып баручы, Миннур—гармунчы. Ул баянда уйнарга яратмады, гомер буе германский аккордеонын күтәреп йөрде. Шәп иде тавышы, Миннур өйдә юк чагында да моң бөркелеп тора иде аннан. Артистларның, язучыларның бәйрәм кичәсенә иң беренче кунак итеп Миннурны чакыралар иде. Уйнаганда гармунына якын килер хәл юк—күрек жиленнән гел мәҗлес табыны исе килә иде. Гармун сулышы иснәгәнең бармы әле синең?

—Ник булмасын инде, Гөлҗиһан апа! Бездәгеләрнең бөтенесе шундый. Сабан туена бишәр гармун җыела. Берсе исән кайтса рәхмәт, калганнары мәйдан читендә батырларча ятып кала. Халык таралгач хатыннары эзләп таба.

—Гармунчының язмышына шулай язылган. Дуслары күп була, бөтенесе сыйларга тели. Мәҗлестән-мәҗлескә йөрсән ул арыш маеның исеннән дә исерәсендер... Хәер, сәхнә үзе дә исерткеч хәмер шикелле—бер тәмен татысаң шундук иярәнәсең. Гел-гел ашкынып торасың, кул чабулардан башларың әйләнә, гәүдән авырлыгын тоймыйсың, таныш дәшсәләр масаясың. Ә берзаман картаеп, йә популярлыгыңны югалтып сәхнәдән төшсән—авыруга сабышасың. Һич көтмәгән чирләрең кузгала, кимсенү хисе биләп ала, алкышларга сусау башлана... Менә шулай, сенлем, алкыш белән алкаш тугандаш сүзләр алар!..

Шагыйрә, әлеге сөйләшүне шаярту белән түгәрәкләп, күнеллерәк әңгәмәгә күчәргә теләгән иде ахрысы да, тик үзе куерткан сагыштан тиз генә котыла алмады.

—Өйдән гармун чыгып китсә—аннан да авыр кайгы юк икән, сенлем!

—Гафу итегез, ул исәнме соң?

—Исән! Аллага шөкер! Яшьрәкләр тартып алды. Бик чибәр нәмәстә тапкан. Тагын мәхәббәт белән исереп йөри.

—Айнытач кайтыр әле, Гөлҗиһан апа!

—Кайтса бер сүзем юк, гафу итәм... Артистның айрылышуы да үзе бер концерт бит ул... Әлфия Афзалова авылыгызга килсә фатирга алып кайт, сөйләттер әле бер. Гөлҗиһан апа рөхсәт итте диярсең, иренми ул, бәйнә-бәйнә сөйләп бирер.

—Гөлҗиһан апа, үкенмисезме?

—Нинди үкенү ди ул! Күр әле син—күпме җыр туды!.. Менә шулай, Сөмбелә кызым, һәр җырда кеше язмышы...

—Ә Марат Гомәрнең шагыйрәсе бармы?

—Үткәне турында ялган сөйләр хәлем юк. Ну бүгенгесе көндә тулай торакта ялгыз яшәгәнен беләм. Шагыйрә белән гармунчы гына кавышырга тиеш димәгән: әнә, Әзәл Яһудин—алып баручы, Зәйтүнәсе—җырчы; Фәрит Хатыйпов—композитор, Рәбыйгасы—җырчы, шигырь язмый; Хәйдәр белән Зөһрә—икесе дә җырчылар... Саный китсән, татар сәхнәсендә күп инде андыйлар...

Сөмбелә парторгның кисәтүен исенә төшереп беләзекле сәгатенә күз салган иде, шайтан таягына баскан баладай чәрелдәп куйды:

—Беттем! Зәкиулла Шакирыч үтерә мине! Кунакларны чәйгә алырга вакыт ич. Әле кире кайтасыбыз бар...

Кичке очрашудан соң шагыйрәне өенә алып кайтып төне буе сөйләшеп чыгарбыз дигән иде Сөмбелә. Ләкин кичке уйлар гамәлгә ашмады, төн хыялларга аркылы төште.

Чәй эчкәндә үк парторг Сөмбеләнең кәефен бозып өлгерде. Иҗат кешеләре тынычлык ярата, дип, ашханә белән бер түбә астына салынган ике бүлмәле «Колхоз йорты»н ачтырган. Кай арада урын-җирен алыштырып өлгергәннәр... Яңгырлы-карлы көннәрдә төрле тарафтан килгән вәкилләр кунгалый торган иде бу йортта. Монда шагыйрә белән гармунчыга күңелсез булмасмы? Төн уртасында уянып чәй эчәргә теләсәләр кадер-хөрмәт кем күрсәтер?..

Казаннан килгән артистларның бушлай концертын карарга дип җыелган иде Балантауныкылар. Сәхнә уртасына ачык партия җыелышындагыча кызыл постаулы озын өстәл бизәп куйгач, тәмәке тартырга дип урамга чыгып качучылар күбәйде. Тыңлаучы булып күпчелек хатын-кызлар гына калды. Пәрдәне бөтенләй ябып тормадылар. Бу хәл тамаша алдыннан көтелә торган серлелекне бөтенләй югалтты.

Артистлар кием алыштыра торган шакмаклы кысан бүлмәнең кайчандыр мулла намазлыгы җәелгән мөнбәр икәнен абайлап алды шагыйрә. Искереп беткән агач клубларның эчтәлеген, төзелешен, язмышын яхшы белгәнгә күрә ул бүгенге кичәне оештырып йөрүчеләрне артык сораулар белән йөдәтмәскә теләгән иде... Төбеннән үк кисеп алган манараның эзен яшерер өчен, түбәне төзәтеп, Казан калае белән яңа баштан ябып чыкканнар. Кирпечтәй кызыл төскә буяп кына тарихны каплап куялмассың... Манара кисүченең язмышы, гадәттәгечә, фаҗига белән беткәндер әле... Шагыйрәнә кызыксыну барыбер үзенекен итте, клубка әверелгән мәчетнең бәетен Сөмбеләгә сөйләп бирергә туры килде. Илле ел элек, Себер урманнарыннан хат рәвешендә кайтарып, Балантау халкының хәтерендә телдән-телгә күчеп сакланган әлеге бәет шактый кыскарып, эчтәлегендә фаҗигале күренешләре генә исән калган иде.

Утызынчы елларда кулаклар колхозлашу хәрәкәтенә янаган иң зур куркыныч булып исәпләнде. Тора-бара, колхоз һәм совхозларның саны күбрәк арткан саен, көрәш кискенләшә барды. Инде мулла-мөәзиннәрне дә сыйнфый дошманнар исәбенә кертеп сөргенгә озатырга керештеләр. Дини руханиларны мәхәллә саен чүпли торгач, ниһаять, Балантауның Габдулла мулласына да чират җитә. Хуҗасы кулга алынган мәчетнең манарасы киселергә тиешлекне бик яхшы белә Габдулла мулла. Аның үзен, яшь абыстае белән бер таң алдыннан чем-кара тарантаска утыртып, Малмыжга алып китәләр, мәхәллә диндарлары белән бәхилләшергә ирек бирмиләр. Малмыж пристанена, якын-тирә авыллардан арестантлар җыелганны көтеп, ул бер баржа трюмында өч көн ята. Шунда кәгазь белән хәрәндәш сыныгы табып, үзенең васыятен язып өлгерә. Аларны Полянда Әгерҗе ягына баручы тауар поездының бер

вагонына кучерәләр. Халыкта артык нәфрәт уятмас өчен изге колларны Казанга да кертеп тормыйлар, хөкем карарын баржада гына укып, туп-туры Себергә олактыралар. Яшерен сакларга жайлы булсын дип бөгәрле торгач имән чикләвеге хәтлек кенә калган васыять кәгазе чуен юлларны, Нократ суларын, атлы сукмакларны кичеп Балантауга килеп төшә. Язу кисәген кем алып кайтканы билгеле түгел, һәм аны күргән кеше дә юк. Шымчыларга килеп житкән хәбәрнен ни икәне генә билгеле. Мәчет манарасын кискән кешегә ачы каһәр төшәр, якты дөньяда килеш тәмугъ утында янар, бөтен нәселе корыр, дигән Габдулла мулла.

Активистлар бәддога чыгарган манарага кул күтәрердәй кеше табылмый. Ниһаять, партячейка утырышында Алкин дигән берәүгә мәжбүри йөкләмә бирәләр. Көннәрдән бер көнне, авылнын карт-корысы ахшам намазына керешкән жиреннән, намазлыктан төшеп, мәчет янына килә. Бала-чага, яшь-жилкенчәк, абый-апалар күптән монда икән инде.

Алкин мәчет түбәсенә менгән дә каланча төбендәге калайны куптарып, айлы манараны күтәргән түбәтәй юанлыгы сигез жепсәнен берсенә пычкы терәгән.

Бәддога Алкин башына кинәт төшәргә тиеш дипме, жыелган халык фажига көтә. Манара ауганчы, әвәл ярымайны алып төшәргә кушалар. Ләкин Алкин жирдәгеләрнең бердәм каргышын тоямы, текә биеклеккә менгәч, кеше күзалдында егылып төшеп жан-тәслим кылудан шүрли.

Алкин кулындагы пычкы сигезенче баганаы чәйнәп өзгәч, азанын югалткан манара халык уртасына гөрселдәп аугач, фажигале тамаша күрергә дип килгән халык «аһ!» итеп ике колагын каплый, әйтерсен, бу авырлык һәркемнең үз башына ишелеп төшкән кебек була.

Төне буе янгыр явып чыга. Иртән халык ни күрсен—мәчет нигезенә айлы башын куеп яткан манарадан жилләр искән, яшел чирәм өстендә егылган эзе дә калмаган хәтта... Кем алып кайтып яшергәндер, кара тарантас хужаларын анысы әлләни кызыксындырмый, чөнки Нократ буенда манаралы авыллар әле бихисап була.

Балантау шым калып Алкин башына төшәсе бәддоганы көтә. Язгы ташулар да хәвефсез генә тына, рамазан чилләсендә өен яшен дә сукмый, күзгә карангы төннәрдә ишегалды тәрәзәсен каерып кулак кавемнәре дә керми... Ә раштуа суыкларыннан сон, көннәрне сындыргач, Алкин Иске Йөрек урманына буралык агач белешергә дип чыгып китә. Өйләдән сон күтәрелгән өч көнлек буран тынгач акбүз айгыр әйләнеп кайта. Жигуле атнын һичбер жиренә зыян тимәгән, Алкин үзе генә юк. Бүреләр ботарлаган толыбын язгы чәчүгә чыккан агайлар эскерт төбеннән табып алалар.

Себергә сөрелгән Габдулла мулланын бер улы әле дә булса исән-сау килеш Төмәннән йөз чакрымдагы Киндерле авылында яшәп ята ди. Хрущев тәхеттә утырган елларда батыраеп, Балантауга кайтып күренгән. Туган авылынын бер як капкасыннан керә дә икенче як капкасыннан чыгып китә. Манара язмышын бик нык сорашкан диләр... Ул Төмән тирәсендәге урман эчендә гел татар авыллары гына ди. Казан тирәсеннән сөрелгән алпавытлар, үз авылларынын исемнәрен кушып, яңа салалар тергезгәннәр ди. Габдулла мулла малае: «Сөргендәге тормыш сезнекеннән жинелерәк. Анда урман ишелеп тора, балыклары жимсез кармакка да эләгә, киек-жәнлекләре бихисап, мал-туар өчен печән ишегалдына кереп үсә. Авыл исемнәре дә—Киндерле, Айшә, Янтык, Казан, Яркәй, Шыкча—гел сездәгечә»—дип әйткән ди.

Шул кайтуыннан бүтән күренмәгән үзе...

Сөмбелә «Манара бәете»нен язылу сәбәбен сөйләп биргәч, шагыйрәнен кәефе кырылды.

—И, Ходаем, гыйбрәт йортларын күнел ачу оясы итеп күпме гөнаһ

жыйгандыр инде безнең буын!—диде ул, бәеткә кучкән гаеп өчен җавап тоткандай.—Әйдә, балакаем, очрашу кичәсен урамга гына күчерик.

Моны ишетеп алган парторг башын кыңгыр салып каршы чыкты:

—Гөлҗиһан апа, алай ук килешеп бетмәс! Хөрмәтле шагыйрәбезне урамга куып чыгарган кебек...

—И, Зәкиулла Шакирович, мин гап-гади бер авыл хатыны лабаса. Шигырь язу да шул ук һөнәр инде ул—сыер савучы, йә, әнә, комбайнер кебек!—Һәм шагыйрә югалып калмады, парторг уң кулында йомарланган ак кепкасы белән маңгай сырларыннан тир бөртекләрен сыпырган арада сәхнәгә чыгып та басты.

—Җәмәгать! Шушындый бөркүдә, ахшам намазына җыелган кебек, мүкәләп утырмыйк әле. Әйдәгез, урамга күченәбез. Урындыклар идәнгә кадакланмаган. Яшьләргә дә тәмәке тартасыбыз бар дип кереп-чыгып йөрисе булмас. Шигырь тыңлый-тыңлый тартсыннар, черки килмәс.

Сабантуйларда чыгыш ясаганы бар Сөмбеләнең—урамдагы халыкны тыңлатуы, ай-һай, кыен. Урам—ул тәнәфес урыны, саф һавада һәркем иркле, бәхәскә керәсе, узып-узып яңалык сөйлисе, җырлыйсы, хәтта, җаен табып сүгенәсе дә килә. Ничегрәк итеп төркемне тамашачы итә алыр икән шагыйрә апасы?..

Ул Балантау халкының чибәрлегенә шигъри юллар белән соклanudан башлады. Чибәрлекләренә бик үк ышанып житмәгәннәрне уңганлыкта мактады. Шул минутта төркем икегә бүленеп горур тынлыкка чумды.

Шагыйрә сәгать буе шаян шигырь укыды, дөресрәге яттан сөйләде. Ялгышкан-онытылган урыннарда туктал͏ып гафу үтенде дә кабат башлады. Берәр сүзен ишетми калсак мәзәге аңлашылып бетмәс дипме, тамашачылар сөйләшмичә, сораулар бирмичә, арлы-бирле йөренмичә тыңлады.

Ындыр табагындагы чыгыш кабатланмагач, Сөмбелә дә шагыйрәгә ияреп яңа җырлар сайлады, алдан ук әйтеп куймасалар да ул үзен җырлатачакларын белә иде...

Клуб эчендә сабыр гына тыңлый белгән тамашачы да концерт беткән минуттан йөгәнсез төркемгә әверелеп ишеккә ябырыла. Ә урамда черкиләр талавына бирешмичә, анда-санда машина-тракторлар үтеп киткәндә сискәнмичә, уты сүнгән өйләрдә этләр өрүен ишетмичә түзеп утырган тамашачы «Шушының белән әдәби-музыкаль кичәбез тәмам!»—дигәннән соң ниләр кыланыр икән?.. Шагыйрә бу очракны да алдан күреп куйган иде.

—Дусларым, ә беләсезме, моннан ярты гасырлар элек, нәкъ менә сез утырган җиргә, клубка әверелгән шушы мәчетнең киселгән манарасы авып төшкән... Бу йортның изге урын икәнен онытмагыз. Без киткәч тә бүгенгечә тәүфыйклы авыл булып яшәгез!..

Балантау, бөтен тавыш-тынын томалап, кинәт өнсез калды... Ә аннан соң, язгы ташкын шарлавыгы кебек көчле алкышлар шавы авылга таралды.

Мәктәп бакчасыннан уталган бер бәйләм календуланы кочагына алгач, шагыйрә тагын сөенде:

—Балакайларым, бу бит искиткеч шифалы чәчәк. Аракыда берәр атна тотсаң салкын тигәннән иң шәп даруга әверелә...

Парторг халык алдына чыгып кунакларга рәхмәт әйтте дә китте. Казан мәдәниятының кичке язмышы мәктәпне быел гына бетергән Сөмбелә кулына калды.

Ана теле укытучысы шагыйрәне үз өенә алып кайтырга күндерә алгач, Сөмбелә бик сөенде, укытучы апасының дәрес аңлаткан чакларда бүленеп-бүленеп шигъри юллар язарга һәвәслеге барлыгын белә бит ул.

Чемоданлы баянын күтәреп, Сөмбелә каршына килеп баскач, Марат Гомәр

юлаучысын югалткан юлчыга охшап калды.

—Гостиницага кайтып китсәм адашмам микән?

—Марат абый, хәзер кызлар сезне вечерга чакырыр. Чын гармунчы белән күнел ачасыбыз килә диләр. Таң атканчы биетсәгез, гостиницага кайтып торасы да калмый.

—Гармун уйнау авыр хезмәт ул, Сөмбелә. Пот ярымлы әргәнне көне буе сөйрәп йөргәч бер дә күңел ачасы килми. Казаннан чыкканга бер атна бит инде.

—Алайса, кызлар күргәнче югалырга кирәк.

—Ярый, Балантау Сарытау түгел, ничек тә юлны табармын әле.

—Мин хәзер, Марат абый, клубтагыларга магнитофонны кабызып калдырыйм да чыгармын. Бик тиз, яме!

Мәрхәмәтле августның бөтен йолдызлары да кабынган. «Киек каз юлы»на текәлгән авылның ак төннәре, җинел кырлар өстеннән килеп кергән камыл исе алҗыган гәүдәләрне канатландыра, йокысыз Шушма куенында кунып калган йорт үрдәкләренең мактанчык бакылдаулары су буена дәшә, таушалган урам юлы, бәхетлеләрне яшерергә теләгәндәй, дистәләрчә сукмакларга таркалып читкә кыя, ымсындырып чакыра.

—Марат абый, чемоданыңны күтәримме?

—Мә!—диде гармунчы, кызның тәкъдимен уенга алып.

Шунысы кызык, баянны урыныннан кузгата алмаска да тиешле Сөмбелә, һич сер бирмичә, адымнарын тигез саклап, гәүдәсен төз тотып атлый.

—Бир, бир, бир монда!—диде гармунчы куркуыннан чемодан тоткасына ябышып.—Йә биленне сындырырсың.

—Сынды ди, хәзер! Сөмбелә апаңның амбарда симәнә тутырган капчыкларны ничек ташыганын күрсәң әле син...

Гармунчы Сөмбеләнең гадилегенә сокланды. Нибарысы бер-ике сәгать күргән килеш туганнарча якын итә белүе, сөйләшкәндә тел яшермичә ачылуы һәм ниһаять олы музыкантка—бөтен Советлар Союзында шөһрәт казанган, хәтта Мәскәү Кремленең съездлар сараенда Леонид Брежнев каршында чыгыш ясый алган «Наз» ансамбленең җитәкчесе, газета-журналларда макталган, атказанган педагог Марат Гомәргә сүз уаеннан гына «Син» дип эндәшә алуы гаҗәпләндерде, якынайтты, яраттырды, сөендерде. Әгәр шушы урында хәзер башка музыкант булсамы—беркатлы кызыйга кисәтү ясар, оялтыр һәм гафу үтенергә мәҗбүр итәр иде. Ә Марат Гомәр сөенде генә, димәк кызый инде иртәгесе көннән зур сәнгать дөньясына сәяхәткә чыгачагына бүген үк ышана, музыкант абыйсын гармуны кебек үз итә.

Баян әрҗәсенең кечкенә тоткасына ике кул ничек сыйгандыр—Сөмбелә һаман тотынып барды, үҗәтләнүе түгел, чын күңелдән тантана итүе аның... Шушы ышанычлы кулларны ычкындырмыйча, илаһи канат астында йолдызлар яңгырыннан ышыкланып, Казан каласының илһамиятле балкышына таба барасы да барасы иде...

Балантауда мондый төннәр бәлки һәр август саен кабатлана торгандыр, ләкин бүгенгесе ниндидер серле вакыт үлчәменә алып кереп өметне азындыра, хыялларны ашыктыра, язмышка ашкындыра, сөйләшәсене китереп тора.

—Киләсе елга җәй башлангач, Сабан туена килегез, Марат абый. Безнең Балантау табигатьнең колагы бит ул... Шомырт чәчәк аткач, авыл читенә чыгып бассаң, бөтен әйләнә-тирәдәге авазны тыңларга була. Өй түрендәге куак саен оя корган Пижмара сандугачлары дисеңме, атаклы Шалкан тавында батып калган машина ыңгырашуларымы, Карадуганның сыек тал питомнигында котырып яткан бакалар хоры, Каракүлдә тәкърарлек елавы—барысы да ишетелә.

—Ә бәлки, боларны син генә ишетәсеңдер, Сөмбелә?! Иҗат кешесе өчен

бик гадәти халәт бу. Мин үзем дә, илһам килеп ялгызым баян уйнап утырганда, колак төбемдә бер кыз бала жырлавын ишетәм. Шул кыз тавышын нотага төшергәч, яңа җыр туа. Мин ул тавышка «Илһамия» дип исем куштым.

—Кызык... Бик кызык... Сез бәлки Илһамиягезне ишетәсездер дә, тик мин бит әле иҗат кешесе түгел.

—Жае чыккач әйтим инде, алайса... Синдә табигый колоритлы тавыш материалы бар. Музыкаль белем биреп, дөрес итеп җырлау техникасына өйрәтсән—синнән менә дигән эстрада җырчысы ясап була.

—Кызык, бик кызык. Сез җырчыны җиһаз ясагандай итеп чагыштырасыз.

—Җиһаз түгел, скульптура дияр идем мин, Сөмбелә. Материалын бар, образ бар, каркасын әйбәт... Остаз кулы гына кирәк.

—Гафу итегез, Марат абый, баян футлярынын тоткасында мине кысып тотканы остаз кулы түгелме сон?

Гармунчы, барыр сукмагыннан адашып, көтелмәгән упкын алдына юлыккан төнге мосафир кебек кинәт туктап калды.

—Сөмбелә, мин бит кызлар ансамблен житәклим.

—Анысын бик яхшы беләм, Марат абый. «Наз» кассетасы белән дөнья тулган.

—Белмисен шул. Хор белән ансамбль профиле ялгыз җырчы әзерләүдән бөтенләй аерыла. Сина консерваториягә керергә кирәк.

—Барып карадым инде быел. Медицина институтына керәм дип алдалап киттем дә консерваториягә барып ике җыр җырлап кайттым.

—Музыкаль грамотан юк, дип, махсус мәктәпләренең тугызынчы классына укырга керергә куштылармы?

—Әйе. Күчми калган мәктәп баласы кебек тагын тугызынчыдан башларгамы? Ә сез моны каян беләсез, Марат абый, әллә имтихан комиссиясендә утыра идегезме?!

—Юк. Нәжип Жиһанов безнең кебекләрне комиссиягә якын җибәрми.

—Кем инде ул сезнең кебекләр?

—«Народниклар», «Наз»—Халык ансамбле исемен йөртә бит...

—Артист булырга хыялланган кеше өчен башкача юл юкмыни?

—Сиңа сигезне бетергәч тә музыка училищесына керергә кирәк булган. Авылыгызның җыр укытучысы киңәш итә алмадымы шуны?

—Киңәш бирүчеләр күп анысы... Тик әтинең мине артист итәсе килми. Казаннан концертлар килгән саен берәр артист апа безгә фатирга керә. Аларның язмышларын сөйләттереп кызык таба. Артист тормышын газиз кызыма түгел дошманыма да теләмим, ди. Үзе артистларны үлеп ярата ул, бер концертны да калдырмый. Тик мине җырчы итүгә теше-тырнагы белән каршы. Авылда гына җырларга куша, гомер буе тыңларга риза ди үзе... Бик кыен хәл—өйдәгеләр әрли, урамдагылар мактый...

—Мондый тавышны өйдә бикләп асрау, кем дигәндә, мәрхәмәтсезлек, кәнишне.

—Марат абый, син чынлап әйтәсеңме соң бу сүзләреңне? Әллә, мине бала-чагага санап, үртәвең генәме?—диде Сөмбелә, тагын «Сез»не югалтып.

—Үртәмим дә, юмаламыйм да, минем кызлар язмышы белән шаярып йөрер чагым үткән инде.

Көтмәгәндә хәвефка калса, чын гармунчы иң әвәл үзенең гармунына ябышыр, аннан соң гына җанын саклау турында уйлар. Үтелгән юлда фара яктысын абайлап алгач Марат Гомәр моны әлләни житди нәрсәгә юрамаган иде. Ләкин яктылыкның кечкенә «СШ—20» тракторыннан икәне беленгәч тә ул никтер Сөмбелә белән гармунчыны урап узып китмәде, киресенчә, этеп йөртелә торган арбасын терәп тукталды.

—Курыкмагыз, Марат абый,—дип юатырга ашыкты Сөмбелә,—Идрис кенә

ул. Беренче класстан бирле артымнан тагылып йөри. Колхоз ана өр-яна трактор бирде. Төнлә йөргәне өчен житәкчеләр әрләсәләр авылдан китәм дип кенә куркыта. Шуна сүз әйтмиләр.

—Житәкчеләрегез курыксын. Ну мин авыл жирендә курыкмыйм...

Ул арада, Идрис, тракторны сүндермичә генә, жиргә сикереп төште. Яктылык эченә кереп, гармунчыга кул биреп күрешкән уңайдан, Сөмбеләгә эндәште:

—Парлашып кына Фатих Кәрим әкиятеннән кайтып килешегез түгелдер ич? Мин сезгә көчтәнәч китердем.

Фарага бик якын басканга гына Идриснең сусән чәче кабарып, гәүдәсе олгаеп күренгән икән, читкә чыгып кабинасына үрмәләгәндә ул бөтенләй кечерәеп, нәни малай булып калган иде. Аның көзге кыланышларын белгәнгә күрә, нәрсә эшләргә жыенганын сизенде Сөмбелә. Тик:

—Идрис, кирәкмәс, әрәм итмә!—дип кычкыруы арбаның гүелдәп күтәрелүен жинә алмады.

Текә тау кебек күтәрелгән арбаның алгы борты ачылып китте дә Сөмбелә белән гармунчының аяк очына күп, бихисап күп алма тәгәрәп төште. Трактор китеп баргач та Марат Гомәр тораташтай басып калган урыныннан кузгалырга батырчылык итмәде, кайсы якка атласаң да алмага басарга туры килер иде. Искә төшкәндә бер, авыл эченә барып керә торган жил, камыл исен югалтып бүгенге төн өчен ашыгып өлгергән сары алмалар исен тузгытып алды.

Ә Сөмбеләнең ашыгасы юк, инде Колхоз йортының шыксыз шәүләсе күренеп тора, гармунчы кереп китсә аның белән бергә бүгенге төннең серлелеге дә ияреп китәчәк һәм кыз кичәге авылда тагын япа-ялгызы калачак.

—Марат абый, үпкәләмәгез инде Идрискә, бигрәкләр дә бала-чага бит әле ул.

—Киресенчә, малай чакларыма әйләнеп кайткан кебек булдым.

—Фатих Кәрим әкиятеннәнме дигәне дә яратып кына.

—«Гармунчы аю белән жырчы маймыл»ны Фәйзи агай Йосыповка ияреп концерт саен тынлагач, яттан беләм инде мин. Ияләнелгән.

—Ә без ул әкиятне Идрис белән икәү сәхнәләштерә идек.

—Идрис гармун уйный белә мени?

—Уйный дип, әкият сөйләр өчен ярый инде шунда. Күрше авылларга концерт белән чыкканда, миннән калмас өчен, юри артистлана. Бүген бөтенләй таныррлык түгел ул. Жиргә коелган алмаларны ашамаганымны белә, ачуымны чыгарыр өчен юри кыланды.

—Кем бакчасын ботарлады икән?

—Колхозның Хрущев заманыннан калган ташландык бакчасы бар. Халык бик жыймый аны, һәркемнең өй түрендәгесе дә житәрлек. Ә Идрис юри шул агачларга тракторы белән килеп бәрелә, күпме кирәк—арбасына шул чаклы коела.

—Бүген мин сине бәхетсез итәм, ахрысы. Яраткан егетең юктан көнләшеп берәр мажара китереп чыгармасын тагын.

—Нинди яраткан егетем булсын инде ул! Күпме әйтәм мин аңа, иярчек тай урынына йөрмә артымнан, дим. Ә ул һаман-һаман сагыз кебек сылануын белә. Армиягә китсә хәер бирер идем ичмасам. Авылдан китмичә котыла алмам инде мин аннан.

—Котылу жинел лә ул.

—Марат абый, коткар син мине бу авылдан. Әгәр теләсәң син мине алып китә аласың бит, әйеме?!

—Кирәксә, кырык төрле сәбәп таба алам. Ярамас шул.

—Ярамый, дигән сүздән өйдә дә гарык инде мин. Сезнең кебек танылган, көчле, мөстәкыйль кеше «Ярый!» дип әйтә аладыр ич. Әллә хатыныгыз бик

көнчеме, шуна сагаясызмы?

—Мин гаиләмне ансамбльгә алыштырдым. Композитор Александр Ключарев әйтә, Марат, син «Наз»ны оештырдың, ләкин шушы ук «Наз» синең үзенне харап итәчәк, ди. Минем бөтен куанычым—ансамбль, мин алар белән генә яшим.

—Бөтенесе белән берьюлымы, Марат абый?..

—Һәй, Сөмбелә! Бер карасаң син шундый самими, ә ныклабрак карасаң—бик акыллы. Килештек, алайса, «ярамый!»га карамыйча коткарам мин сине моннан. Бүген үк түгел, язга таба, имтиханнар алдыннан.

—Чынлапмы, Марат абый?! Вәт рәхмәт!

Гармунчы рәхмәтле Сөмбеләне ике куллап күтәреп алды, аның бөтен сизгерлеге кулларына күчте. Баян сәдәфләрендә биеп, җиде йөз төрле моң чыгара ала торган йөгерек бармаклары яна көй эзләгәндәй тыпырдап куйды, тик җилкә чокырында сәдәф тапмады, ике алма яшереп йөрткәндәй кабарып күренгән кукрәгеп тәненә сылашкан юка ак күлмәктән гайре берни капламаган иде. Гомере буе ялгыз тимерче кебек күрек тарткан сул кулы тагын да бәхетлерәк икән. Кисәк күтәрүдән итәге җыерылып менгәч куркынып калган аяклары күрек тарта торган кул өстендә иде. Бары тик Шушма тугаенда кызынып ятканда иптәш кызлары гына көнләшеп күз төшерә алган ботлары, кабыгы каезланган сөян агачы кебек елкылдап, йолдызлар яктысында балкый.

—Син бит инде арыдым диден, Марат абый, тузанга егып төшерә күрмә!

—Каешы өзелгәндә дә баянымны кулымнан төшергәнем юк.

—Мине гармун итеп уйнарга җыенасынмы әллә?

—Синнән шәп җыр туар иде бүген, Сөмбелә.

—Җыр гына туса ярый ла...

—Иң әвәл җыр тусын әле. Гармуннан да җинелерәк бит син!

Һәм Марат Гомәр, кызның авырлыгын үлчәргә теләгәндәй, һавага чөеп алды. Әллә ялгыш, әллә уй-теләге шул иде—Сөмбелә талпынган арада гармунчы аның кызлар күзе генә төшәрдәй җиренә иреннәрен тидереп алды.

—«Илһамия»нең үзе икәнсең син, Сөмбелә. Ник мин сине ике генә ел элегрәк очратмадым икән?!

—Ярамый, Марат абый, егетләр үбә торган урын түгел ул. Төшерегез мине җиргә. Болай ярамый, дим ич.

Ни өчендер, гармунчы кыз алдында гафу үтенергә теләмәде. Киресенчә, ул әле уенны дәвам итеп Сөмбеләне алмалар әсирлегеннән коткаргандай юл читенә чыгарып бастырды. Баянын алырга дип кире килгәндә аяк астында тагын күпме алма сытылды. Ә үзе монарчы Балантау яшьләренә ишетелмәгән яна җыр такмаклады.

Марат Гомәр вакытны сузарга булды, туфлиенә сыланган алма сутын чирәмлеккә бик озаклап сөртте. Август аенын төн озынлыгына өстәлгән сәгать ярым вакыты шушындый очракларда кирәк икән. Хәтта декабрьнең соңгы төннәре дә бик кыска булып тоелыр иде мондый чакта. Кача-поса гына килгән, дөресрәге, бөтенләй өмет итмәгән сөенеч вакыйгаларны ашыктыра, тыелып калырлык хәл юк, буйсынырлык акыл, кире чигенерлек чара юк. Рәхәттән исереп ялгышуы шундый җинел икән ул. Күр әле, нинди кабатланмас, гыйшыклы һәм бик кыска төн бу—үкенеп тә өлгермәссең.

—Мескен чирәм... Бу хәтлек ышкуга туфлиегез тишелеп чыгар! Марат абый, «ярамыйга карамый»ны өйрәтегез әле миңа.

—Урамда җыр өйрәтмиләр.

—Һи, без урамда, фермада, ындырда дип тормыйбыз, кайда ишетәбез шунда отып калырга тырышабыз.

Тагын бераз гына чирәм таптарга исәбе бар иде әле гармунчының, тик

клуб ягыннан янә теге трактор килеп чыкты. Бу юлысы, арбага төялгән исерекләр жыры анын гөрелтесеннән көчлерәк иде.

—Ут яктысына кергәнче качып торыйк, Марат абый! Малай-шалайлары да табыла бит анын шундый чакта. Ну, иртәгә иманын өшкерәм мин анын. Күрше малае гына ул Идрис, егетем дип уйламагыз тагын...

—Бала-чага шикелле качып калыиммыни инде шулардан?

—Бәйләнешмик, Марат абый, юкса соңыннан сүзе күп була анын, күрше хакы бар бит әле... Райком да урып-жыю өстендә хулиганлыкны бик якламый. Әнә теге бура артына сыеныйк. Эзләп арыгач айнырлар.

Исерекләр хоры үтеп киткәч, Сөмбелә кабаланып, гармунчыны ашыктырды.

—Колхоз йортына кереп бикләнерсез,—дип әйтеп бетерүе булды, трактор кире борылды.

Кунакханә тәрәзәсен яктыртып тукталгач, Идрис арбадагы исерекләрне жиргә бушатты. Арбанын күтәрелүе чыр-чу, сүгенү, ыгы-зыгыны көчәйтте, төшкән бере тәрәзәгә ябырылды, алкалы йозакны тоткалап ишеккә типкәләде.

Эчтә кеше юклыкка ышангач, тагын авыл буйлап китеп бардылар. Инде кунакны озатып куймыйча чаран юк. Күнеленә шом кергәч, кызый өенә ялгызы кайтырга яхшысынмады.

Эзләп-эзләп таба алмагач, исерекләр Колхоз йортына еш сугылырлар. Сөмбелә гармунчы кулыннан ачкычны алып өйгә керде. Ут яндырырга ярамагач, кунакнын эчке ишекләрне табарлыгына шикләнде. Мангаен бәреп кара яндырса, иртәгә халык алдына ничек чыгар? Өй эченә күз тиз ияләште, трактор ерагайган арада, вакытны әрәм итмичә, жәһәт кенә тәрәзәне ачып, урам ягына пышылдады:

—Марат абый, мә, йозакны ал. Баянынны эчтә калдырып ишекне тыштан биклә. Син тәрәзәдән керерсен.

Тәрәзәне ябып икәүләшеп бикләнеп калгач, бүлмә эченә әкренләп күз ияләнде. Кыл уртада хан заманыннан калган түгәрәк өстәл икән, тирәсендә ике урындык бар. Киң ашъяулык астыннан чәйнеккә һәм дә шикәр савытына, чынаяк-чокырларга охшаш нәрсәләр төртеп тора. Ә инде стенанын тәрәзә уелмаган ягында, урын жирләре пөхтәләп жәелгән агач караватны күргәч, Сөмбеләнен йөрәге «Жу!» итеп куйды. Халык телендә аны «полуторка» тахта дип йөртәләр. Ләкин бүрәнә читлеккә үзе очып кергән ак күлмәкле кыз бер мендәрле караватка бер ярым кешенен ничекләр итеп ятарга мөмкин икәнлеген күз алдына китерә алмый иде әле...

***

Көтү куар алдыннан гына кайткан кызларын ничек каршы алачакларын бик яхшы белә Сөмбелә. Ә шулай да кайтып күренергә кирәк. Өйдәгеләрне әле жинелеп кайткан килеш жинәсе бар. Әйтеләсе битәрләү-әрләүләренә, рәнжешле нәсихәтләренә, өркетү-кисәтүләренә алдан ук жавап әзерләп, әти-әнисе алдында әхлак имтиханы тотасы бар.

Авылга өй саен тотылган утны саный торган аерым счетчиклар керткәннән бирле һәр лампочканы бәрәкәт белән генә яндырырга өйрәнгән Харис арткы өйдә утны сүндермәгән. Әти кешенен: «Без сине төне буе йокламыйча көттек!»—дигән беренче сүзе инде бу. Апасы читкә китеп, өйдә олы кыз урынына калган төпчекләренә монарчы каты бәрелгәннәре булмады. Хәер, мәктәпне тәмамлап, үзенә күрә күнел ачу ирегә яулаганына ике генә ай үтте ләбаса һәм монарчы кызнын әле тан яктысына кушылганчы ут яндырып көтәрлек фигыльләре шәйләнмәде.

Балантаунын бөтен жан иясе изрәп йоклый. Кояш офыктан кубып килә. Тынлыкнын шундый сизгер чагы, әгәр Сөмбелә капка келәсенә ялгыш ныграк

орынса—абзардагы ишле каз: «Как? Как?»—дип русчалатып сорау алыр, казлар авазына сагаеп күрше Жамалыйларның мыжый эте «Ah! Ah!»—дип өреп куяр. Шуны гына көтеп яткан күрше урам сарбайлары җавап кайтарыр. Алар «Һау»гасына сыерлар уяныр, уянган берсе янында чиләк тоткасы шалтырар, урман каравылчысы Рәхмәтулла, мотоциклын пырылдатып, делянка егылган тарафка ашыгыр, хуҗалыктан сөт җыючы Раузалар каршына Идриснең тракторы килеп туктар һәм көтү җыела торган тыкрыкта урын өчен, таш ваткан тавыш чыгарып, кәҗә текәләре сөзешә башлар... Авылны уятыр өчен капка келәсенә кагылу җитә...

Гөлчәчәк болдыр ишеген урам ягыннан ачканнарын көтеп торган, ахрысы—кулына сөт чиләге, беләгенә чүпләмле сөлге элеп каршыга ук килеп чыкты. Ул көндәгечә коңгырт сатин халатын кигән, тик ни хикмәттер, ак яулыкка төренгән, шуның өстенә, чәчәкле-чуклы тагын бер яулыкны эзәр итеп, киң маңгаен каплап будырган. Мунчада кызу тиеп, йә челләдә кояш сугып башы авыртса Гөлчәчәк гел шулай кысып бәйләп куя торган иде. Әни кеше буш сөт чиләгенә бәрелеп калган кызны бөтенләй күрмәмешкә сабышты. Гүя Сөмбелә аның өчен бөтенләй юк ул хәзер... Каладан килгән артистка ышанып үз өен онытткан һәм көтү куганда гына куып кайтарылган газиз кыз бала өчен ягымлы сүзләр кинәт беткән, елмаюы ике каш арасындагы җыерчыкларга кереп качкан, төне буе еламсырап чыккан күзләрнең исән кайткан баланың йөзенә сыный карарлык та хәле юк, бусага аша атлап кереп баручы унсигез яшьлек җан көеге ак күлмәк кенә бары.

Әти кеше күлмәк җиңенең сәдәфен каптыра алмыйча идән уртасында катып калган. Сөмбелә аны үтеп китә алмады һәм ирексездән абажур астында калды. Йөз илле ваттлы лампа яктысы кызның бөгәрләнгән күлмәк итәге белән таралмаган чәч арасына тузганакланып ябышкан мендәр мамыкларын фаш итте. Чирәм яшеле йокмаган, кабина дегете тимәгән, кан табы юк—күлмәгенең ак килеш исән калуы әти кешенең кырау төшкән бәгыренә аз гына өмет җылысы бөркеп куйды: бәлки рәнҗетмәгәннәрдер әле. Куеныңда төн уздырса да куркытмыйча, елатмыйча, кул сузмыйча иркәләгәндер генә. Харис белән Гөлчәчәкнең аулак өйләрдә күпме кич утырганы, кочаклашып кунып калганы бар иде. Таң аттырабыз, дип, әйләнеп-тулганып, бөгәрләнеп-кармаланып ничәмә-ничә төннәр бергә үткәндә күпме ястык мамыгы ияреп кайткандыр. Тик Гөлчәчәкнең әти-әни кыйный дип зарланганы булмады. Орышып, әрләп, кул күтәреп кенә Ходай биргән яшьлекне биш почмаклы бүрәнә читлектә бикләп яшәтеп буламы? Дөрес, Гөлчәчәк белән Харис беренче төнгә тугры калдылар. Аулак өйләрдә аркылы җәелгән түшәк өстендә тезелешеп яткан тынгысыз төннәрдә Харисның гыйшыклы кулы куенындагы Гөлчәчәкне үтеп китеп, янәшәләрендәге күрше кызының күкрәгенә үрелмәде. Таң атканда сандугач йокысыннан изрәгән кулы саташып озаймасын өчен ул Сөмбеләнең булачак әнисен беленнән урап кочаклый торган иде. Зөфәф ширбәтен татыгач, аулак өйләр тагын да күбәйде. Ләкин никахка чаклы шаярулар араны суытмады, киресенчә, бер-берсеннән башка яши алмый торган гомерлек ярга әверелделәр. Яучы җибәргәндә Гөлчәчәкнең тәне кайнарланган иде инде... Олы кызлары Резидәне, никтер, җиде айдан туды дип хафаланган булдылар. Аның ничә айдан туганын Харис белән Гөлчәчәк үзләре генә белә... Әйе, борынгыдан килгән йолалар никахка чаклы якынаймаска куша. Ни кызганыч, шәҗәрәбезнең өске ботаклары югарырак үрмәләгән саен, затлы йолаларыбыз искергән кануннарга әверелеп, бездән ерагая бара. Хәзер инде никах туена чаклы кәләшен саф килеш саклап кала алган кияүләр ай-һай сирәк. Ләкин Харис әлеге уйлары белән Сөмбеләне һич акларга теләми, үз балана—сөекле кызына килеп кагылгач, тотнаксызлык дигән шуклык җаннарны тетрәндерерлек аянычка әверелә икән. Ник дигәндә, әти кеше

кыз баланы яратып кына түгел, сокланып үстерә һәм Харисның жаны Сөмбелә жанында. Әгәр Казаннан килгән гармунчы кызның жанын яралаган булса, димәк, әти кешенең дә жаны яралы. Кызны рәнжетү—әтине рәнжетү, кызны мыскыллау—әтине мыскыллау дигән сүз.

Харис хурлыклы уйлар белән үзен-үзе кыздырды. Сабырлыгы үртәлүдән соңгы чиккә життеме—үч алу нияте белән нииндидер кискен карарга килеп, кием шкафын ачты. Өстендәге абзар киемнәрен сала торды, жыенда, мәжлесләрдә, сайлау көннәрендә кияселәрен ала торды. Сөмбелә аны ике тәрәзә арасындагы кыска эргәгә терәлгән ике канатлы озын көзгедән күзәтте. Йокысы туймагангамы—әтисенең тәк томалдан кием алыштыруын нәрсәгә дә булса юрап өлгерә алмады. Бары тик ике-өч ел буе шкаф шүрлегеннән чыкмаган кин читле салам эшләпәне кулына тоткач кына, әтисенең дөреслек эзләргә дип казыйлыкка жыенганын аңлап алды. Сөмбелә көзге каршысында тагын бераз гына оеп торса Харис гармунчы янына ыргыласы иде.

—Әти!—Кыз үз тавышыннан үзе сискәнеп куйды, ләкин ярсыган тәрбиячене туктатырлык башка катгый сүзләр ялгап әйтә алмады. Әгәр, төнлә туган яңа жыр тел очына килеп кунмаса, иртә таңнан бөтен татар дөньясын шаулатырлык гауга чыгасы иде бүген:

Ә мәхәббәт, ә мәхәббәт дәвам итә
Ярамыйга карамый, карамый...

Харисның ачуы сүнде. Төпчек кыз иртә диме, кич диме, жырлап уяна, жырлап эшкә чыгып китә, авыз эченнән көйләп караңгы өйгә кайтып керә. Жыр аның яшәү рәвеше, жырлый икән—димәк яшьлеге дә ул дигәнчә уза. Һәм әлеге «Ярамыйга карамый»ның ачу китергеч, инәнне елатырлык жан ачысы белән янрый алмастай күңелле жыр булуы сабырлык бөркеп тора. Ул тынгысызлык эшләпәсен янадан шүрлек түренә—нафталин, лимон-әфлисун кабыклары арасына томырды.

Почмактагы караватка барып аугач, Сөмбелә чаршауны корды. Чишенергә ашыкмады, ак күлмәген салмаганда кичәге төн һаман дәвам итә кебек иде әле. Янарак кына сизеп алды кызый—күлмәк изүеннән «Шипр» хушбуе катыш тәмәке исе килә, әйтерсең лә шул искә гармунчының жаны ияреп кайткан. Һәм чишенсәң ул сине шук күзләре белән эзәрлекләр, гел өстеңә карап торыр кебек. Сөмбелә әнә шул серле халәткә жавап итеп елмаеп куйды. Ак жирлеккә табигатьтә булмастай эре-эре умырзаялар төшкән чаршау, ябык пәрдәгә әверелеп, кызны яшерде. Пәрдә әти белән сөекле кызы арасында беренче таш коймага әверелде. Дәшми калсам көн саен шулай соңарып кайтырга өйрәнер дип кенә әйтелгән нәсихәтләр умырзаялы койма аркылы бик сүрән вәгазь булып үтеп керә һәм төн хисабына сыегайган йокыны куерта...

—Ансамбльгә бөтен кызларны да шулай жыя торгандыр ул... Жырлар өчен генә булса синең ише һәвәскәрләрне Казаннан да табар иде... Авылда килеш кунарга кайтмадың, сине читкә жибәрсәң бер атнада әрәм итәрләр... Төн кызлар башыннан йөри... Жылыга кергәч нарат күркәсе орлык коя... Гармунчы халкы гомергә алкаш булды, шуңа ышанып йөрсәң...

Чаршау артыннан каршы дәшеп үчекләүче булмагач, Харис бер яклы сөйләшүнең кызыгын тапмады. Шкаф каршына өелгән эш киемнәрен кабат киеп ишегалдына ашыкты. «Ярамыйга карамый»дан сагаеп, Гөлчәчәк тә кереп килә иде инде. Кулындагы чиләк төбендә ярты литр чамасы сөт.

—Бар, савып бетер сыерыңны! Буш чиләк белән каршыма килмә.

—И Ходаем, кул күтәрдең мәллә, атасы?

—Әллә син мине ул хәтлек... Кыз балага кул күтәрергә... Әрләдем генә.

—Такмаклап жылый түгелме?
—Жырлый ул.
—Шушындый чакта жырлап торырга... ычкынганмы әллә?!
—Төнлә ычкынган булса ычкыныр да, ычкынганмы-ычкынмаганмы, барыбер—бөтенләй кулдан ычкынганчы Идрискә ычкындырырга кирәк аны, Казанга бергәләп чыгып ычкынырлар.
—Идрисен көзгә повестка көтә әле анда...
Биш почмаклы, алты матчалы, сигез тәрәзәле, өч кешеле өйнең чаршау чатырлы бер почмагында Сөмбелә исемле яна дөнья пәйда булды. Пәрдәнең ике ягында гүя хәзер капма-каршы ике телдә сөйләшәләр, берсен-берсе аңламыйлар: эшкә ашыктырмыйлар, йомыш кушмыйлар, артык сораулар бирмиләр, «яме» дигәндә «ярар» дип жөпләмиләр, кара-каршы сүз көрәштермиләр, кайбер ошамаган сорауларны ишетмәмешкә сабышалар. Көндәлек мәшәкатьләр Казан кунаклары килгәнче ничек үткән булса, гармунчы киткәч тә шулай дәвам итте. Һәркем өй эчендә бүленгән вазифаны гадәттәгечә үзе башкарды, вакытында эшенә йөрде, көтү каршылады, юан-юан дүрт агач аякка бастырылган «Беларусь» телевизорының куна тактасы чаклы экранына ябырылып «Семнадцать мгновений весны» сериалын карады, бер өстәл артына табын көйләнде. Әмма Сөмбелә колхоз өендә кунып кайткан көннән башлап гаиләдәге иминлек икегә бүленеп элек һәм хәзер дигән бәяләмә белән үлчәнде. Мактаулы, сөенүле һәм хуплаулы, мәрхәмәтле һәм яклаулы көннәр вакыт үлчәменең теге ягында калды, ә сагышлы минутлар, офтану һәм көрсенүләр, тынгысыз кичләр бу якка күчте.
Яңа көн тугач, Казанныкылар Балантау кунаклары түгел иде инде. Аларны парторг күрше Субаш авылына илтеп куячак. Сөмбелә клуб ачкычын Идрис аркылы биреп жибәрде. Сөенә-сөенә китте егет. Кызның гармунчыны озата бармавын, аның белән хәтта саубуллашырга да теләмәвен үзенең зур жиңүе итеп тойды ул. Сөмбелә уйлап эшләде моны. Йокысы туймаганга күрә генә йомышчы малай итмәде ул аны. Тагын бер кат күрсен Идрис чын гармунчыны, көпә-көндез, кояш астында күрсен, олы шәхескә карата булган хөрмәтне тойсын, тинсез көндәше алдында чигенсен, иртәгә дигән ачы хакыйкатькә буйсынсын...
Сөмбелә күрше авылның үзешчәннәрен күз алдыннан кичерде: Субашның гөсләче әбиләре бар, скетчлар куярдай егетләре, биючеләр ансамбле бар. Ә монә гармунчыны жәлеп итәрдәй жырчы кызлары юк... Юк!

## Кар өстендә

Авыл баласы шәһәргә ачкыч эзләп килә. Эшли-эшли, яши-яши жыя ул аларны. Килеп урнашу белән һөнәри училищенең тулай торагыннан дүрт караватлы бүлмә бирәләр. Пыялага төрелгән оясында черем итеп утыручы вахтерша әбине гел ырылдатмас өчен һәр егетнең кесәсендә үз ачкычы йөрергә тиеш. Бу синең шәһәр кешесе буларак иң беренче ачкычың! Караватъ янындагы тумбочканың йозагы болай да ачыла...
Эш урыныннан сейфлы кабинет ачкычы алыр өчен алга таба да укып, күп ачкычлы агайларга ярарга тырышып, шактый үсәсе бар. Кабинетлы кеше ачкычларны тизрәк жыя: фатир ала, машиналы була, гараж сала, дача төзи...
Сиксәненче еллар уртасында, портфель белән почта әрҗәсен санамаганда, дүрт йозак ачардай ачкыч бәйләмең булса син инде түгәрәк бәхетле «городской» иден. Трамвай тукталышында чиләкле эремчек күтәреп калган авылдашларыңа, машина тәрәзәсен төшереп, куллар болгап китә аласың.
Дөрес, кайсыдыр ки ирләрнең кесәсендәге бәйләмдә өендәгеләргә түгел, хәтта чит кешеләргә дә әйтергә ярамаган серле йозак ачкычы була. Кулына

эләксә, хатынын ул ачкыч белән шәһәрдәге бөтен йозакларны кытыклап чыгар һәм серенне гәүдән белән каплап ятканда өстенә килеп керер.

Гармунчы әнә шул серле йозак аркасында бөтен ачкычларын бәйләме белән югалтты. Урлатмады, төшереп калдырмады, үз ирегe белән югалтты. Һәм янадан ачкыч җыяр өчен ана заводның тулай торагыннан урын бирделәр. «Наз» ансамбле, җиде ел элек, завод клубы каршында оешкан иде. Монарчы җитештергән тауарлары белән әлләни мактана алмаган заводның даны кызларга ияреп үсте: «Наз» чит илләргә чыгып, телевизорлардан күренеп, газета-журналларда макталып, ана мәдхия өләште. Шуңа күрә, ачкычлары белән бергә үзен дә югалтмасын өчен, гармунчыны ике караватлы бүлмәгә ялгызын гына керттеләр.

* * *

Клуб ачкычын әнисенә калдырып, Сөмбелә берәр атнага Казанга китте. Туганнан туган апасы Лилиянең сирәк-мирәк булса да хатлары килә иде, шул хатларны кат-кат укый торгач, Сөмбелә шәһәрдәге хәлләрне бик шәп күз алдына китерде. Күчтәнәчкә ниләр алып барасы икән дип баш ватасы юк... Анда ите, мае, шикәре—гел талонга гына. Тамак саен бүлә калсаң бер айга ике кило шикәр, бер кадак май, кило ике йөз грамм ит, әгәр ит алмасаң ул талонга сигез йөз грамм колбаса тия. Эремчек белән каймакны молкомбинаттан китергәндә кибет янында чиратка басып каршы алсаң гына өлгерәсең. Ә сыйр кебек нәрсәне кайчан сорасаң да: «Әле генә бетте!»—дип кырт кисәләр. Их, бер сары гына «Москвич»ын булсын иде дә, Лилия апага кыш чыгарга җитәрлек күчтәнәч алып килсәң иде... Ә болай: ике кулына ит күтәрсәң йомырка сыймый, бәрәңге янына сөт алып булмый, суган алсаң эремчек кала...

Юлга чыкканда бер кулың буш йөрергә тиеш дип, кара дерматин сумканы шыплап тутырдылар: бүтәкәсен, башын-аякларын аерым төреп бөтен каз салдылар, биш кадак атланмай, ике дистә йомырка сыйды. Чылбырлы йозагын тарттырганда сумка эчендә бушлык калганны күргәч, Гөлчәчәк чоланга чыгып ике сәке балан кагы алып керде. «Толчок» базарына барып җитә калсаң диген булып, егерме биш сумлык сигез акчаны Сөмбеләнең кытыгы килә торган иң сизгер төшенә—култык астындагы кесә төбенә булавка белән эләктереп куйды. Юл чыгымнарына диелгән вак-төякләр косметичка белән бергә инбашына асылган бәйрәм сумкасына бикләнде. Кирәк-ярак документларны үзе белән алырга әзерләнгәнен сизеп, әни кеше кызының бөтенләйгә китәргә диган ниятен чамалады.

—Ярар, ерак ара түгел, кирәк нәрсәң булса сорап хат язарсың, кеше аркылы җибәрербез,—диде Гөлчәчәк һәм ниндидер бик мөһим эшне капылт исенә төшереп, караватастындагы чемоданнан бер кассета алып бирде.—Онытa язганмын, менә мин магнитофонга хат яздырдым. Шушы кассетаны сакла, телдән әйтә алмаганнарым шушында. Атаң-анаң кинәшеннән чыкмасаң Ходай ярдәменнән ташламас сине...

—Син нәрсә инде, әнием...

Сөмбелә бөтенләйгә китәм, дип кырт кисәргә дә, йә бер атнадан кайтам, дип акланырга да теләмәде, унайсызланып әнисенең муенына сарылды. Җиденче сыйныфны бетергәннең каникулында ата каз чукыганнан бирле елаганы юк иде кызның. Күз яшьләре өч ел буе җыелып, дәү үскән баланың әни куенына кергәнен генә көтеп торган икән. Әгәр газиз гомереннең санаулы елларын башкаларга бүләк итәргә яраса, әниләр иң кыска гомерле кеше булырлар иде...

Икәүләшеп рәхәтләнеп балавыз сыгып алгач, күчтәнәчле сумка җиңеләйгәндәй булды. Хәер, әтисе ишегалдында көтеп тора иде, олы юлга

чаклы ул төпчек кызына авыр йөк күтәртмәде.

Чепья автобусы сонармады. Харис сумканы ишек саңакларына бәрмичә генә эчкә кертеп куйды. Сөмбеләгә тәрәзә кырыенда ялгыз буш урын бар иде.

«Атна уртасында юлда йөрүче азрак шул. Анысы шәп булды әле...»—дип куанып куйды ул, автобус кузгалып киткәч. Ләкин әче төтен таралып, ак «ПАЗ»ик күз алдыннан югалгач, әлеге куаныч бөтенләй мескен булып калды. Харис, хәер-фатиха биреп, үзенең иң изге, бүтән бер нәрсә белән дә алыштырып булмастай юанычын, яшереп үстергән чәчәктәй төпчек кызын бөтенләйгә озатты түгелме?!

Әти кешене көнозыны күз төбендәге төтен ачысы җәфалады.

Автобус, юл өстендәге авыл тукталышларында кеше булмаса да туктап-туктап ял иттерде, гүя Казандагы язмышына Сөмбеләне төп-төгәл график буенча алып керергә тиеш иде ул. Һәркемнең үз вакыты, үз юлы, сәгатен белеп кенә көтеп торган үз бәхете бар бу фани дөньяда.

Авылларны үтеп, кырдагы юлга чыккач, күз аллары яктырып кала. Гомердә авыл табигате күрмәгәндәй, тәрәзәгә ябырылды Сөмбелә. Йотлыгып-йотлыгып күзәтте, күңел түрендә ак кәгазьле яңа альбом ачып, туган як манзарасын рәсемләп күчереп барды, ахрысы.

Кыш аклык булып үсә. Туңга сөрелгән басуларның эре-эре түмгәкләре дә кар белән күмелгән инде. Хәлсез тракторлар бер-бер артлы тезелеп салам тарта. Карлы түмгәкләргә аяк терәп карышып-тартышып кына шуышкан эскерткә ферма песиләре ияргән. Аларга тере уенчык булып кыр тычканнары кайта.

Каршы яктан да автобуслар очрый. Кемнәрдер исә, Сөмбелә ашкынган Казан белән саубуллашып, кире кайтып килә. Юлның икенче ягына чыгып, кайтучылар арбасына күчеп утыра аласың. Сине өеннән беркем куып чыгармады. Җимеш бакчасы уртасында балкып торган таш нигезле, сигез тәрәзәле нарат өйдә әти-әниеңнең кадер-хөрмәтенә, хәләл мөлкәтенә тиенеп яшәргә хакың бар кана. Бәлки төпчек малайларны үгетләп, кирәксә ялварып, бурыч, йола дия-дия төп нигездә калдыру мөмкин хәлдер. Мәгәр үсеп буйга житкән, җиләге пешкән, ялтыравык хыялларына табынган кыз баланы тышаулардык көч юк. Табигать моң иңдергән икән, ул аңа өстәп үҗәтлек, кырыслык, эзләнү, мактауга сусау да бирә. Моңарчы рәсемнәрдә генә күргән, ишетеп кенә белгән шагыйранә сихри дөньяның эченә барып керәсе килә. Һәм бала ләззәтле хаталары белән мөлдерәмә тулы язмышка ашкына, яңа җыр эзләп чыгып китә. Ул инде Шушма буендагы тал-тирәкле сандугач оясын ташлап, катлы-катлы итеп өелгән шау-шулы ташлар арасында яшәргә дә риза... Сандугач балаларын очарга гына өйрәтә, ояда җырларга өйрәтми. Җырлар өчен үзенә аерым оя корырга кирәк...

Биектау авылын үткәч, кар керләнде, тора-бара шикәрлеген югалтып бөтенләй көл төсенә керде. «Казанга җитәбез бугай»,—дип уйлап куйды Сөмбелә.

Кат-кат әйткәнне көтмәде, автобус Дәрвишләр бистәсен чыгып барганда кирәкле урында үзе белеп туктады. Лилия апасы эштән кайтырга иртәрәк иде әле. Тукталышта кычыткан капчык авызын кочаклап утырган әбидән бер стакан көнбагыш алмакчы иде Сөмбелә, сәгатенә күз салгач, көрсенеп, ике стакан сорады. Өй түбәсе юлдан күренеп торса да ашыгып атлады ул, гадәте шулай—әкрен йөрергә яратмый, тиз булсын, житез булсын аңа. Барасы җирендә көтеп торсаң тор, әмма җәһәт йөр!

Авылда булсаң, капка төбендә нәүмиз утырган кунакны күреп җиде күршең чәйгә дәшер иде. Кесә төбендә ачкыч булмаса шәһәр өчен син кунак түгел, ятим килмешәк кенә икәнсең. Подъезд төбендәге рәшәткә урындыкта утырган

кызга беркемнен исе китми. Дөрес, кыздырылган көнбагыш ярганын күреп, түбәдәге күгәрченнәр Сөмбеләнең аяк астына күчте.

Урталарына бер уч көнбагыш килеп төшкәч, жим исен сизеп, тыныч кына миһербанлык көтеп йөргән кук күгәрченнәр гаиләсендә, этеш-төртеш башланды, әтәчләре чукышырга тотынды. Ул арада, табыш бүлүчеләрне ерактан күреп алып, хужаларыннан качкан ак күгәрченнәр төркем өстенә килеп төште. Авызына ризык кергәне туеп китә белми, читтә калганнары баш төртергә куркып ач йөри. Сөмбелә тагын бер уч тутырып алды. Бу юлысы ул көнбагышларны чәчеп сипте, шунда гына һәркайсысы өлешенә туры килгәнне тынычлап чүпләде. «Жимне тигез сибәргә кирәк шул»—дип үзенчә фәлсәфи нәтижә ясап куйды кызый... Чүпләп бетергәч, аклы-күкле төркем ызгышны шундук онытты, гөрләшеп әйләнә-тирәдән юкны эзләргә кереште.

Сөмбелә кошлар белән серләшеп алды:

«Алай ук күнелсез түгел икән шәһәрегездә. Сез авылга кайтыгыз. Колхоз күгәрченнәре бик тату яши анда. Ындыр табагы жәен-кышын көрпә тагарагы кебек...»

Лилия апасы Сөмбелә белән сөенечен тыеп кына күрешге.

—Бөтенләйгә килденме?—диде Лилия өйгә кергәч. Ул Сөмбеләнең жавабын ишетмичә торып түргә үтәргә ашыкмады.

Кыз бармак очында әйләндергәләп йон береткасын кабартты. Аннан, ашыкмыйча гына, күгәрчен тамагы төсендәге плащ белән тышланган төлке якалы пәлтәсенең путасын ычкындырды.

—Белмим әле апа. Авыл советыннан расчет алмадым. Берәр атна отпускы хисабына булыр, дидем. Клуб ачкычы әнидә калды. Әти белән икәүләшеп танцыга йөрсеннәр бераз.

Ял, әни, әти, танцы сүзләрен бергә жөпләп әйткәч, Лилиянең кәефе күтәрелде, авыл күчтәнәчләрен мактарга керешге, төп нигездә калганнарның хәл-әхвәлен сорашты.

—Килгән көнне кунак бик кадерле була ул,—дип, кухнядагы өстәлне тарсынып, ике кеше өчен зал уртасына жыелма өстәлне жәеп куйды.

—Жәйгә имтиханнар тапшырып карыйсы булыр. Керү шартларын белешеп, сайлаштырып кайтыйм дидем.

—Бәлкем читтән торып кына укырсың. Авылда эшең яхшы иде, чиста, дәрәжәле, күнелле...

—Сандугач белән чыпчыкның аермасын беләсең ич инде син, апа.

—Беләм, беләм! Чыпчык консерваторияне читтән торып бетергән, сандугач көндезгедә укыган...—Әле һаман артист булырга хыялланасынмы, сеңлем?

—Үҗәтлегемне дә беләсең инде, апа!

Казан жылысыннан куркып кына кыш кереп килә. Чын кар тукталышлардагы калай куыш түбәләрендә, телефон будкалары, трамвай билетлары сата торган киоск өсләрендә генә. Кин урамда таш юллар тузланып шулпаланган. Башкалабызны туйганчы күрим әле дип иртүк чыккан иде Сөмбелә. «Кольцо»да кибеткә-кибет терәлеп торгач, шәһәрнең үзәгенә ишек саен чират үсеп чыккан. Жентеклэбрәк карап торсаң, алжыган чырайлы әбиләр, әле сөт, әле колбаса, яшелчә, ипи чиратлары алып, кибеттән кибеткә күчә тора. Шөкер, икмәк талонга түгел әле, бер кулга ике бөтен алырга рөхсәт ителә. Казан күмәчен сагынып килгән зур сумкалы апалар, ипи чиратын түгәрәкләп, кереп-чыгып, кереп-чыгып йөриләр.

Көнне бушка уздырмас өчен Сөмбелә әвәл музыка училищесына, аннан консерваториягә барып килде—аралары ерак түгел икән. Марат Гомәр әйткән культура институтын да эзләп тапты. Барган бер жирдә кабул итү шартларын,

кызыктыргыч бүлекләрнең төгәл исемнәрен күчереп алды. Ниһаять, бүгенгә житәр дип, яңадан «Кольцо»га төшсә—үзәктәге чиратлар тагын да зурайган, бүселгән, тынгысызланган. Дәрвишләр бистәсенә йөри торган автобуска да чират бик зур иде. Кулында артык биштәре булмагач, баһадир чират аны әләктереп алды да арткы ишектән төеп кертте.

Төне буе урын өстендә боргаланып чыкты Сөмбелә. Чөнки иртәгә бик борчулы көн. Казанга килүенең төп сәбәбе, яшерен уйлары йокы бирми: «Танырмы ул мине, «Наз» кызлары алдында ничек акланырмын? Әрсезләнеп йөри, мескен димәсләрме? Икәүдән-икәү калган очракта сүзне нидән башларга?!.

Клуб дигәч, Балантауның манарасыз иске мәчетен күз алдына китергән иде Сөмбелә, ләкин завод клубы йөз ел элек байлар салдырган өч катлы мәһабәт бина булып чыкты. Бүлмәләр саны бихисап икән үзе, тик «НАЗ» халык ансамбле дип язылган ишекләре икәү генә иде. Ул ишекләргә якынайган саен Сөмбеләнең адымнары акрынайды, адымнар акрынайган саен йөрәге күкрәк читлегенең кысанлыгына үртәлгәндәй усалланып типте... Менә хәзер ишек жилкәннәре киерелеп ачылыр, аннан колачын җәеп Марат Гомәр үзе килеп чыгар да: «Нихәл, Сөмбелә?! Каршы алырга килүең әйбәт булды, Балантауга концерт белән кайтырга әзерләнә идек әле»—дияр.

Ә ишек артында һаман тынлык. Эчке якта җан иясе юк дияр идең, бер өйрәнчеге имән бармагы белән клавишларны санагандай пианинода «Әпипә» көен эзли. Ишекне ачык калдырып коридорга йөгереп чыгучы кеше дә әнә шул дүрт-биш яшьләрдәге малай булды. Сөмбелә өнсез калды, уйлары өсте-өстенә өелде.

«Ходаем, гармунчының малае ахрысы бу. Әллә хатыны да шушында микән? Хәер, булса ни, мин ир эзләп килмәдем лә, җырларга теләүчеләр бер мин генәме... Әнисе: «Улым, ерак китмә, хәзер кайтабыз» дип ишек тоткасына килеп тотынганда Сөмбеләне күреп алды.

—Син кемне көтәсең?—диде ул малае белән сөйләшкәндәй.

—«Наз»ны... «Наз»га!..—дип каушап калды Сөмбелә, чөнки ул җырчы кызлар алдында җавап тотарга бөтенләй әзер түгел иде.

—Кер әле монда, кер. Син ансамбльгә язылырга килденме?

—Әйе. Белмим шул...—дип, башлаган җөмләсен ерып чыгарга өлгермәде Сөмбелә, пионер сәхнәсе чаклы бүлмәнең уртасында басып тора иде инде.

—Исемең ничек?

—Сөмбелә.

—Тавышың нинди?

—Ул лирик сопрано диде.

—Лирик сопрано—бик интернациональ тавыш ул. Җырлап күрсәт!

—Аның тыңлап караганы бар,—диде Сөмбелә, бертуктаусыз сорау яудыручы яшь әнидән котылырга теләп.

«Аның» дигән сүзенә «кем ул?» дип бәйләнмәгәч, сөенде әле кызый.

—Оялма. Әллә ялындырасыңмы? Җырла, давай!

Аркылы-торкылы урындыкларда аптырап утырган тагын биш кыз Сөмбеләгә йөзләре белән борылды. Алар никтер урамнан кергән килеш, өс киемнәрен салмаганнар, төймәләре генә чишелгән иде.

Җырларга тек җырларга, җырчы кая басса—шунда сәхнә дигәндәй, кыз береткасы белән пәлтәсен салып буш урындык аркасына элде дә август төнендәге ак күлмәген төзәткәләде.

—Oho!!!—дип, тел шартлатты «Наз»лылар. Алар, алдан ук ятлап сүз куешкандай кумәкләшеп янә сокландылар.—Oh-oho!!!

—Мондый материал белән җырламыйча да артист булырга була... Җырлыйсыңмы, юкмы инде?!—Яшь әни дә Сөмбелә кебек үҗәт иде.

—Гармунчыгыз кая? Уйнасын...

—Гармунчыбыз юк бүген.

Сөмбелә, кире киенергә теләп, береткасын кулына алды, тик ашыкмады.

—Алайса иртәгә килермен.

—Иртәгә дә килмәс ул, кичә дә юк, узган айдан бирле...

Һәм яшь әни, жан тамырына жинелчә генә чиертеп куйды. Үнәченә чиертсә—тамагына салкын тигән дип уйлар иден. Жан тамырына чиертүнең нәрсә икәнен телевизордан «Что, где, когда» уенында ишеткән иде инде кызый. Петр-I заманында «сухой закон»ны бозган кешеләрнең жан тамыры өстенә мөһер кыздырып басканнар. Шул көннән бирле, инде ике йөз елдан артык вакыт үтсә дә «мөһергә чиертү» сәрхүшләр әлифбасы булып сакланган.

Барыбер, гармунсыз-такмаксыз гына, «Резедәкәй»не жырлап күрсәтергә туры килде. Шуннан соң алты кыз уникe кеше өчен кул чапты.

—Инде танышыйк,—диде яшь әни, ант иткәндәй кулын күкрәгенә куеп,—мин Әлфия, менә Люция, Илсөя, Фәния, Зәйнәп, Резедә... Безнең монда ярты ансамбль дә юк. Әнә теге фотода, жырчы егетләребез: Алмаз, Зөфәр, Фаят...

Әлфия бүген репетициягә килмәгән кызларның исемнәрен стенадагы плакатлардан санарга керешге... Ләкин бер күрүдә егермегә якын жырчының исемен хәтерләп була мыни?..

Кайтырга жыенганда, малаена киенергә ярдәм иткән булып кына Әлфияне сөйләндереп өлгерде Сөмбелә.

—Кайда соң ул Марат абый? Өйдәме, бүлнистәме, Казандамы, берәр авылда качып ятамы?

—Аны белмәссең. Йә телевидение тирәсендә, йә филармониядә, йә язучыларның яңа бинасында... Радиога барсаң, анда да очрый. Кайда күбрәк таныйлар—шунда инде ул.

Уйланырлык хәлләр күбәя Сөмбелә өчен. Әгәр үзен танып белүчеләрне эзләп йөри икән, ник соң әле гармунчыбыз янәшәдә түгел?! Аны Сөмбеләдән дә ныграк танып белгән, көткән, кирәксенгән һәм югалтудан куркып эзләп чыккан башка берәү бармы тамашалар Казанында?!

Ике көн эчендә Сөмбелә шәһәрнең бөтен ижат оешмаларын, театрларны, концерт залларын, радио белән телевидение бинасын эзләп тапты. Эзләп табып кына калмады, дежур торучы абый-апалардан сорашты, күзенә чалынган афишаларны жентекләп укыды, сәгать унбер тулганны көтеп якын-тирәдәге гастрономнардан бүселеп чыккан чиратларны күздән кичерде... Ләкин гармунчы табылмады. Шунысы сәер, аның югалуы беркемне дә борчуга салмый кебек. «Күренгәне юк», «күптән килгәне юк», «безнең тирәдә бик йөрми ул хәзер», «югала торган кеше түгел, китереп куярлар әле...» дип юатыбрак жавап биргән жавапсыз кешеләр Марат Гомәрнең еш югалып йөрүенә ияләшкәннәрдер кебек. Сөмбеләнең бәргәләнеп эзләп йөрүе читтән күзәтеп торучыларга гайбәт куертырлык артык сәбәп кебек кенә иде бугай.

Өченче көнне, Химиклар мәдәният сарае янында белдерүләр карап йөргәндә, Сөмбелә кызыл исемнәр белән тыгызлап тутырылган бер афишаны күреп алды. Жырлары патефон тәлинкәсендә чатнаган биш-алты жырчыны санаганнан соң, уртага зур хәрефләр белән: «Наз» халык ансамбле дип өстәгәннәр. Билетлар соңгы рәттән генә калган иде инде. Сөмбелә, бер сум илле тиеннән сынар билет алып, тагын уйга калды. Ул Лилия апасын чакырырга уйламады да, ник дисәң, «Наз» ансамбле катнашмаган мәлдә Сөмбелә үзе дә концертны ташлап кайтып китәчәк. Туган апасы кызның кайбер серләрен белмичәрәк торсын.

Башланырга ике сәгатьләп вакыт бар иде әле. Кыска көннәрнең эңгере куерганны көтмичә, багана башларына бәйләм-бәйләм эленгән неон лампалар

кабынгач, концерт бинасы мәһабәт наратлар арасына салынган әкияти сарайга охшап калды. Электр утын кызганмасаң карурманнарны да яктыртырга була икән... Алдан килгәннәрне ымсындырып торган ешлыкта һәр куак, һәр үлән нурга коенган, рәт араларындагы сукмакларның кары көрәлгән, чүп савытлары тезелгән, куе чытырманнарның шомы качкан. Сөмбелә башта бер рәттән үтте, аннан икенчесенә күчте, сукмаклар белән телгәләнгән ешлыкның эченә кергән саен серлелек артты.

«Әй бер наратны кисканнәр!»—дип, көрсенде кызый кар астыннан күренеп калган кара төпне ерактан ук шәйләп. Тик, якынайгач, ул төпнең кондыз бүрек кигән башы да бар булып чыкты. Икенче рәткә сикереп трамвай юлына таба йөгерергәме, әллә ярдәм сорап кычкырыргамы дип аптырап атлый торгач, Сөмбелә әлеге бүрекле төпнең янәшәсенә үк килеп җитте. Кызый, капчыклы бодайларны арбага ыргытырлык беләкләрен киереп, горур рәвештә үтеп китәргә теләгән иде.

—Сөмбелә, нихәл?—дигән мыгырдау аны кинәт туктатты.

—Исәнмесез?..

Казанның танып дәшәрдәй кешеләрен без дә танырбыз, дигәндәй, кисәк борылып караса—гармунчы! Кар өемен кәнәфи итеп утырган, кулларын ике якка җәеп арка терәвен колачлаган, тезен тезгә чалыштырып бүрекле башын артка чөйгән, чыраен сакал баскангамы—мыегы бөтен иягенә җәелгән кебек...

—Балантауга барыбер кайтам дип әйттемме мин сиңа? Менә бит, кайттым!

—Юк инде, Марат абый, мин үзем Казанга килдем. Сине көттем-көттем дә.

—Көн саен сезгә кайтам дип чыгып китәм, юлым борылып-сырылып бетә.

—Аугa чыктың мәллә, Марат абый, куак арасында качып ятасың?

—Бик образлы итеп әйттең... Мин чынлап та сунарчы. Бераз көтеп торырга иренмәсәң үз күзләрең белән күрерсең—ак колагыннан тотып куян баласын китерәчәкләр.

Исерек кешенең тел төбенә төшенер өчен әйткән сүзләрен икешәр кат кабатлатырга кирәктер. Шаяртамы гармунчы, фикер тирәнлеге белән өстен булып күренергә телиме, анламассың... Тик шунысы аермачык—ул кемнедер көтә. Һәм ак колакчыннарын салындырып куян бүрек кигән сәрхүш килеп басамы хәзер, әллә куян мамыгыннан эрләнгән кыеклы шәлгә төренгән һәвәскәр кызыймы, барыбер, Сөмбелә аны, гармунчы әйткәнчә, үз күзләре белән күрергә тиеш.

—Тор, Марат абый, ояна салкын тидерерсең.

—Минем пәлтәм калын! Мондый салкыннарны күргәне бар! Узган көзне, ансамбль белән Имәнкискә авылына бардык. Концерттан соң колхоз автобус белән кайтарып куярга тиеш иде. Килмәде автобус. Шоферы төнлә Казан юлына чыкмас өчен махсус исергән диделәр. Урамда тездән кар, клубка ягылмаган. Кем сәхнәгә, кем бильярд өстәленә бөгәрләнеп яттык. Тамашачылар сулышыннан бәс сырган сәхнәдә ике сәгать буе кулмәкчән җырлап күшеккән кызларны жылытыр өчен клуб эчендә төнлә учак ягасым килде... Түздек. Кайткач бөтен ансамбль температура белән аяктан егылды. Ә минем менә шушы пәлтә канатына сыенган ике кыз исән-имин калды... Бүтән Имәнискә сәхнәсенә аяк басмабыз, дип ант иттек.

—Пәлтәм жылы дип кар өстендә төн кунарга җыенмыйсыңдыр ич? Кемне көтәсең соң син?

—«Офицерлар кибете»нен грузчигын көтәм. Мин аңа ун сумлык кызыл акча тоттырып калдырдым. Талонсыз-нисез генә бер ярты таба алам диде.

—И, Марат абый! Бигрәкләр дә беркатлы кеше икәнсең син! Кулына ун сум акча тоткан грузчикны көтеп кыш чыгарсың әле шушында.

—Син нәрсә, кызый, минем дусларга ышанмыйсынмы?! Женя грузчик кына түгел, Женя заманында Вафирә төркемендә соло-гитара уйнап дан казанган кеше! Әнә! Әнә, килә ул! Маэстро, тизрәк атла! Окопта салкын!

Каеш табанлы киез ботинкасын лаштор-лоштыр сөйрәп, бер кат күлмәк өстеннән баллон куртка бөркәнеп, яланбашын жилдән саклапмы—бөкшәеп килеп баскан бу грузчикның кайчандыр зур жырчылар янәшәсендә чыгыш ясый алганына ышануы да кыен. Ул ин әвәл Сөмбеләгә шикләнеп карады, гармунчының «кызый үзебезнең кеше» дигән ым-шымын сизгәч кенә куенындагы хәзинәсен чыгарып, ватылган ун сумлыкны хисаплап тапшырды.

—Нәкъ син әйткәнчә, бөкесе колаклы. Биш сум утыз тиенлеге. Ундүрт тиенгә ике сыйр, ун тиенгә алты карамель. Калган дүрт сумы вагы белән,—дип, Женя сдачаны йомарлап гармунчының кулына тоттырды.

Балантауда, бәйрәм саен диярлек, мондый гына сәрхүшләрне күргәне бар инде кызыйның.

«Болар гурласыннан гына чөмерергә жыеналар ахрысы» дип уйлап өлгерде микән Сөмбелә, юкмы, ул арада Женя курткасының күкрәк кесәсеннән майонездан бушаган банка чыгарып бүлә башлады. Савыт тулган арада кул калтыравыннан баллон курткасының жине өзлексез кыштырдап торды. Женяның күптән баш төзәтер вакыты житкән иде бугай инде, тик шулай да ул сәхнә интеллигенцияләренә хас горурлык белән, салкыннан поскан муенын яка эченнән чыгарып, махмырлы башын артка чөйде һәм мөлдерәмә бокалны Сөмбеләгә сузды.

—Мадам! Беренчесе сезгә!

Гармунчы «Мадам» дигәне өчен Женяны сүгәргә онытып Сөмбеләгә текәлде, чөнки кызый, тәжрибәле сәрхүшләрне үртәгәндәй, әвәл сул кулы белән борын астын пыршылдатып, уң кулы белән кисәк майонез банкасына үрелде.

Мондый гына скетчларны уйнаганы бар инде Сөмбеләнең. Их, шешәләрен тартып алып ярты литрлы юанычларын кар астына агызасы иде! Гитарачы абзагызның кыллары зынлап өзелер иде, мөгаен, югалту кайгысыннан үз-үзен белештермичә, шешә белән мангаена менеп төшәргә дә күп сорамас, Алла сакласын! Ә гармунчы нишләр иде икән? Яклап сүз әйтерме, әллә икәүләшеп дөмбәсләп көрткә күмеп китәрләрме?.. Күрәләтә хәвеф оештыру булыр иде бу...

—Урамда эчә алмыйм. Минем өлешне шешәсендә калдырыгыз,—диде Сөмбелә, һәм жирәнүен артык сиздермәскә тырышып, хәмерле савытны кире Женяга тоттырды.—Әтием әйтмешли, кичен эчкән аракы—агу белән бер.

—Мәктәп баласы әле ул!—дип яклашты гармунчы.

—Нинди бала?! Мәктәпне жәй көне үк бетердем инде.

—Сездән сон әлегә аттестат өләшкәннәре юк. Димәк, мәктәп баласы син... Жәй житкән саен, чыгарылыш имтиханнары үткән саен олгаерсын...

Гармунчы конфетларны Сөмбеләгә бирде.

—Мин эчмим!—дип баш тартты гармунчы, мөлдерәмә банкага чират житкәч кенә.—Концертка кереп үземне тынлыйсым бар. Афишага язганнар!

—Блин! Шешәне бушатыгыз! «Русская водка» өстенә автографынны куйдырып алып кайтмасам... хатын ышанмый мина бүген...

—Ә без анын этикеткасын куптарып алабыз!—дип тотынган иде гармунчы, тик «Русская водка» бик һәйбәт ябыштырылган булып чыкты, ертылып бетте.

Женя югалып калмады, чалбар кесәсеннән сары бер сумлык чыгарып, гармунчыга сузды. Тегесе бөгәрләнеп беткән акчаны шырпы кабы өстендә тигезләп автограф куеп бирде.

—Имзаңны бик арзанга өләшәсең!—диде Сөмбелә үртәлүен тавышына чыгарып.—Һич югы унлык булса да ярар иде, кирәксә миндә егерме биш сумлыгы бар.

—Һе, юк, кызый! Син мине әллә исерек дип беләсеңме ул чаклы?! Беренчедән, унлык белән егерме бишлектә Ленин бабай башы бар. «Перестройка» белән «гластность»ка ышанып сәяси хата ясар хәлем юк. Икенчедән, Женя бер сумлыкны вакламыйча түзәргә мөмкин, ә зур акча нәфесне гел кытыклап тора ул.

Әллә терелеп хәл керде үзенә, әллә салкынга бүтән чыдар чамасы калмады—Женя килгән сукмагыннан кире йөгерде. Гармунчы утырган җиреннән җәһәт торып пәлтә итәгенә ияргән карларны какты да үз урынына эчелеп бетмәгән шешәне батырып калдырды.

—Монда тагын киләсең мәллә, Марат абый?

—Кем белгән?! Күмеп куям әле. Бозыла торган нәрсә түгел. Концертларны карап чыккач килеп китәрбез.

—Шушы хәлдә залга керәсеңме? Анда кеше күп булачак бүген.

—Беләм. «Наз» ансамбле катнаша дигәч халык җыелмый ни... Ә безне афишага кертергә рөхсәт сораучы булдымы—юк!

—Сон, Марат абый, исемегез зал тутырырга ярдәм иткәч әйбәт ич инде.

—Кемгә әйбәт? Аларгамы?! Ике язарлар, өч язарлар... Ә без катнашмыйбыз. «Наз»лар ялганчы, дип бер сүз китсәме... Үзеңә кирәк чакта ялынып та җыя алмассың тамашачыны.

—Димәк, исемең язылган җиргә алдан ук әзерләнеп килергә кирәк... Мондый хәлдә түгел инде... Без авылда да хәтта, сәхнәгә эчеп чыккан артистларны сөймәдек... Ә монда, Казан уртасында... Обком шушында, бөтен министрлар, начальниклар, студентлар, газета-журнал корреспондентлары шушында.

—Син нәрсә, кызый, мине тәрбияләргә килдеңме?

—Юк, Марат абый, мин сиңа ышанып килдем.

—Әйе бит әле, синең артистка буласың килә. Синең яшьтә бөтен кызларның да артист буласы килә.

—Алайса, мин буш хыял куып йөрим инде, шулаймы, Марат абый? Әйт миңа хәзер, күземә карап әйт! Балантауында яшә шунда, шәһәрдә синең ишеләр буа буарлык дип әйт. Кайтам да китәм.

—Бик сагынгач... кайтып кил соң...

—Сагынмадым әле.

—Алайса кайтма! Синең тавышың Оркыя Ибраһимованың баяны кебек моңлы. Минем баян синең янда мескен генә.

—Баян сайларга дип килмәдем, Марат абый. Әйдә, өеңә илтеп куям.

—Ә син әле Казанда йөри белмисең...

—Ияреп кайтам. Өеңне тапмаслык ук исермәгәнсең лә.

Җәяүлеләр өчен тап-такыр итеп көрәп куелган кин сукмакка чыккач, гармунчы сумалага ябышкандай, адымын атлап бетермичә тукталып калды.

—Минем өем юк.

—Бөтен кешенең көтеп тора торган өе бар, Марат абый.

—Юк, дидем. Мин калдырам да китәм, калдырам да китәм...

—Бигрәк юмарт икәнсең... Урамда яшәмисеңдер ич инде?

—Кунактан кунакка йөрим. Бүген миңа синә кайтабыз.

—Мин әле Казан кызы түгел... Сине бу хәлдә Лилия апама күрсәтәсем килми дә. Балантауга дисән—бер хәл, әти-әни алдында аклануы җиңелрәк. Хет иртәгә үк кайтып төшик.

—Бүген үк!—Гармунчы күкрәк кесәсеннән чылбырлы сәгатен алып ут яктысына ачты да уйнап башланган сүзне чынга борып куйды.—Кичке биш.

Жәй көне бу вакытта әле көтү дә кайтмаган була. Хәзер такси туктатабыз, теләсән ожмахка илтеп куя.

—Түлке, Марат абый, авылда аракы юк. Туй өчен дигәндә район рөхсәте белән ике ящик бирәләр бирүен... Ә болай кибетләрдә корылык.

—Бетте. Күз алдында ташладым ич. Кар өстендә калган шешә соңгысы иде. Мин гел шулай, бер-ике атна шаярып алам, сәбәпләре житди булганда. Бүтән эчмим. Коръән булса кулыма тотып ант итәр идем. Юк бит. Кесәмдә Шәүкәт Галиевнең шигырь китабы бар. Телисеңме, шуның белән ант итәм.

Һәм гармунчы жырлап та жибәрде:

Күпме күзләр күреп онытылган,
Күпме күзләр чыккан хәтердән...

Жыр бик тиз бүленде. Урам уртасын сәхнә итәргә жыенган Марат Гомәр янына ике милиционер килеп басты.

—Гражданин, ваши документы?—дигәне чын урыс иде.

Сөмбелә гармунчының беләгенә чытырдап ябышты:

—Марат Гомәр же это, абый жанашым. Ансамбль «Наз»!

Әле дә ярый фуражкалыларның икенчесе татар егете булып чыкты. Ул юри генә эндәшмичә елмаеп торган икән.

—Беләм, сеңлем. Өйдә кассеталары бар. Ә бу кеше,—диде ул иптәш егетенә төртеп,—Рауза Рымбаева белән Суфия Ротарудан гайре жырчыны белми. Марат абый, всё же урамда кычкырып йөрмә инде син, сәхнәдә генә жырла. Давайте, тыныч кына, яме!

Милиционер егетләр киткәч, гармунчының беркавым кәефе кырылып торды. Аннан, кыз алдында уңайсызланыпмы, акланган сыман өстәп куйды:

—Әйтәм ич, безнең илдә һәр урыска берәр татар ияреп йөрергә тиеш. Юкса паспортсыз-нисез урамга чыгам димә.

—Авылда рәхәт ичмасам. Анда участковый һәркемне танып белә.

—Киттек, Сөмбелә, сезнең участковый янына.

•••

Сөмбелә гармунчыны ияртеп кайткач, Гөлчәчәк белән Харис телдән яздылар. Парторг озатып кермәде, шагыйрә дуслары иярмәгән—кызларына алма корты булып төшкәне аңлашыла ласа!

Һәрхәлдә, өй эчендә, абзар-курада йорт мәшәкатьләре көндәгечә бер көйгә дәвам итте. Һәркем, үзе белеп дигәндәй, капка төбендәге сукмакны себерде, ишегалдындагы карны көрәде, мичкә якты, мал-туарны карады. Бер өстәл артына дүртәүләшеп табын кордылар. Аерым-аерым урын җәйделәр. Гармунчыны коры сырадан да өзмәделәр, якты йөз, кунакчыллык сүзсез генә дәвам итте. Дөресрәге, барысы өчен дә Сөмбелә сөйләште: кирәк нәрсәне сорап алды, кыстый-кыстый сыйлады, яңалыкларны сорашкан булды һәм үз сорауларына үзе үк җавап та биргәләде.

Өч көннән соң, колхоз белән араны бөтенләй өзеп, Сөмбеләнең инде гармунчыга тагылып китәсенә ышангач, әни кеше нәсихәтен әйтерлек көч тапты:

—Анда итәгеңне җыеп йөре, кызым!

*Ахыры киләсе санда*



Фарсель
Зыятдинов

# КОШЛАР ТЕЛЕ ДӘШӘ ЯХШЫГА

## Тагын килде язлар...

Тагын килде язлар.
Илләр гизеп,
Сайрар кошлар кире кайттылар.
Сайрый берсе, сайрый талга кунып,
Кемнән безгә сәлам тапшыра?
И шатлана, сайрый, канатлана,
Кайткангамы туган ягына?
Ә сәламен меңнәр кабул итә,
Моңы меңнәр өчен агыла...
Дәртләнеп, ул канатланып шулай
Илләр аша сәлам тапшыра.
Кошларыбыз теле кешелекле,
Кошлар теле дәшә яхшыга.

## Курай

Әй, курай,
курай,
курай,
Бабам уйнаган курай.
Әткәм уйнаган курай.
Еллар үткәч, ник соң әле
Китеп югалдың болай?
Артык моңлы булгангамы?
Урау булды юлларың...
Еллар томаны артына,
Еллар томаны артына
Китеп күздән югалдың...
Күп нәрсәләр күңелләрдән
Вакытлы китеп тора.
Кайтырсың, дим,
Синнән башка
Ил күңеле китек тора.

Фарсель ЗЫЯТДИНОВ (1937) — *язучы һәм галим; «Яшәү мәгънәсе», «Тагын язлар килде», «Безнең гомер» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

* * *

Иделгә таянма, дисең,
Соң, кайларга таяныйм?
Кемнәр белән серләшим дә,
Кемгә карап юаныйм?

Идел бит ул үткәнебез,
Ул бит безнең киләчәк!
Оныкларга моңыбызны
Чал Идел җиткерәчәк.

Иделгә таянма, дисең,
Уеңны һич аңламыйм.
Иделгә дә таянмагач,
Кайларга соң таяныйм?!

* * *

Салынды сер бирмәс канатлар,
Зур төен төйнәлде күңелдә.
Давылмы, яңгырмы—ни булыр?
Болытлар куера күгемдә.
Куерсын...
Куерсын, ни булган?
Йөрәктә битараф көн туган.
Яшьнәгән, дөрләгән күңел гел
Бер мизгел эчендә булды көл.
Шул көлдән оешып авыр таш
Гәүдәмне каядыр сөйри күк.
Атлыймын гүя мин зираттан,
Каберләр риваять сөйли күк...
Чардуган.
Күрми ул кояшны,
Каплаган усакның башлары.
Сукмагым буена тезелгән
Хисләрнең чатнаган ташлары.
Чү! Аргы ягында зиратның
Чын тормыш гөр килә түгелме?
Чыгыгыз, әй, үлмәс хисләрем,
Калдырып көлләнгән күңелне.
Чыгыгыз, әй, олы хисләрем,
Кабызып сүрелгән күңелне!

## Ак вә кара

Күккә баксаң, ак болытлар
агып бара,
Җиргә баксаң - күз җиткәнме?—
бар җир кара.
Ак вә кара, ак вә кара.
Тәрәзәмдә тулган айның
ак шәүләсе,
Ә шәүләдә—Кушбаш кошның
күләгәсе.
Ак вә кара, ак вә кара.
Кайда соң сез, яклаучылар—
изге җаннар?
Дүрт ягында баш калкыта
хамелеоннар.
Ак вә кара, ак вә кара.
Төн үтәр дә таң атар дип
көтә халык.
Галактика йолдызлары
сибә аклык.

Ак вә кара, ак вә кара.
Йолдызлардан очкын ал да
яктырт Җирне,
Яндыр утта коллык дигән
яман чирне.
Ак вә кара, ак вә кара.
Ак вә кара...

* * *

Сулкылдап тибә йөрәгең синең—
Хокуксыз иркен төбәгем минем.
Сыкранып яши ник соң бар халык?
Баксаң, үзеңдә күпме бар байлык.
Әйләнеп кара—үткәнең анда:
Гасырлар йөзә кайгы һәм канда.

Күз яшьләренә ышанмый беркем—
Күпме яшәргә бил бөгеп, өркеп?
Үз байлыгыңа үзең бул хуҗа—
Тик шунда гына бетәр бу нужа.
Әйләнеп кара—үткәнең анда:
Гасырлар йөзә кайгы һәм канда.

* * *

Татар башы күргәннәрне
кай телдә дә
Килештереп, җайлап кына
әйтә алмам.
Әмма шуны әйтә алам:
һәр телдә дә—
Татар башын ашый бүген
хәйлә-ялган.

## Бүленмәс бербөтен

Бүленмәс бербөтен без, дисең,
Барысын үзеңчә сөйлисең.
Табигать ул, дисең, көйләнгән,
Нәкъ бербөтен булып төйнәлгән.
Үрмәкүч тоткан бөҗәкләр дә,
Мәче эләктергән үҗәтләр дә,
Чуртан тоткан вак балыклар да,
Аксак кәҗә йоткан ак гөлләр дә,
Иркле һәм ирексез көннәр дә—
Барысы бүленмәс бербөтен,
Менә шулай, татар Бөркетем...

Алдыйсың, ышанмый күңел,
Юк, болар һич бербөтен түгел.
Бар нәрсә бүленә Галәмдә,
Керәләр төрле гамәлгә.
Белсәң икән син барсын да:
Бүленә хәтта атом да.
Кирәк чакта, әйе, бүленә,
Тели икән, кабат берегә...
Менә шулай, урыс Бөркетем,—
Юк җирдә бүленмәс бербөтен.

## Сак бул, ди ак кышлар...

Сузылды ул куллар җилләрдә уйнаган
ак карга...
Яшь булып эреде кулында—әйләнде
ак парга.
Кызыгып чәчәген өзде ул алманың—
ай Алла!
Көз җиткәч, бакчада ким иде, җитмәде
бер алма...
Маймычка кызыгып, тотты да ташлады
комлыкка.
Мескенем буылып-буылып талпынды
сулыкка...

Ә бүген сиңа бит, сиңа бит үрелә
шул куллар.
Сак бул, ди бакчалар, ак карлар,
дулкыннар...

## Кыяташлар булып...

Вәхшилектән ничек туйганымны
Белсәң иде әгәр син, белсәң...
Кыяташлар булып калкыр идем,
Менәреңне әгәр мин белсәм.

Туйдым, дускай, туйдым вәхшилектән,
Җаным туйды талау, алдаудан.
Телен, денен сатып алданганнар
Котыла алмый бүген ялганнан.

Учларымда учак ягар идем,
Кызганмыйча әгәр син түзсәң.
Мәңгелеккә китеп барыр идем,
Килереңне әгәр мин белсәм.

Тере килеш йотар кебек бары,
Сыгыла калсаң әгәр, бил бөксәң.
Кыя ташы булып калкыр идем,
Менәреңне әгәр мин белсәм,
Менәреңне әгәр мин белсәм...

* * *

Еракта, еракта
кабынды бер йолдыз.
Тартыла күңелем шуңарга,
белмисез.
Бәлки, ул минем йолдыздыр,
ә бәлки, түгелдер.
Кем белә:
әлегә билгесез.
Тартыла күңелем...
җылысын тоймыймын.
Еракта алар соң
ник сүрән яналар?
Күңелне тартырлык
гаҗәеп балкышны,
Нурларны
йолдызлар каян соң алалар?
Минем күк...
Төн ярып,
утларга талпына күбәләк.
Карасаң,
янганы, көйгәне азмы соң?
Ашкынам...
Ярый ла, көтмәсә мине дә
Утларга талпынган күбәләк
язмышы...

**Редакциядән:**
*Бу айда Фарсель Зыятдиновка 70 яшь тула. Әдипне журнал укучыларыбыз исеменнән ихлас котлап, аңа сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары телибез.*



Эльмира
Шәрифуллина

## ГОМЕР—ҮТӘР, ГӨЛЛӘР—КАЛЫРЛАР...

### Тормыш яме

Бисмилламны әйтеп, токмач кисәм,—
Ак яулыгым ябып башыма,—
Тел өстендә генә тотарлык ул,
Туганнарым килсен ашыма.

Билләремдә чиккән ак алъяпкыч,
Кош телләре кисәм, кыйгачлап:
Күпереп пешсен сары майда йөзеп,
Күзегез кызсын, үзегез туйгач та.

Бәлеш салам, белгәнемне укып,
Каз итеннән—кайнар, шулпалы...
Чөкердәшеп чәйләп утырыйк соң,
Күршеләрем дәшим, туктале.

Бер сөйләрлек булсын:
Аш-суының
Тел төбендә калды тәме, дип.
Кардәш-ыру,
Дус-иш белән яшәү—
Дөньябызның яме,
Гаме бит!

### Әткәем йөргән җирләрдә

Әткәем узган юллардан
Йөрим, йөрим уйланып.
Кан-яшь тамган җирдә үскән
Кылгандай дулкынланып.

Бу күзләрем ник елмая?—
Елыймын бит эчемнән.
Көйрәп китмәсме даласы
Дөрләгән уй-хисемнән?

Җил әз генә хәбәр бирсә,
Тере җандай кылганнар
Ташланалар уңга-сулга:
«Исәнме,—дип,—туганнар?»

Ары чабып, бире килеп,
Әйтә кебек кылганнар:
«Белегез тыныч тормышның
Кадерләрен, оланнар!»

Әткәм сугышкан җирләргә
Килдем, йөрим уйланып.
Кан-тир тамган җирдә үскән
Кылгандай дулкынланып.

---

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА—*шагыйрә, прозаик; «Яңгыр җиле», «Мизгел», «Сөюемнән мин бер чибәр идем...» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Чиккән сөлге

Чиккән сөлге—яшьлек истәлегем:
Яз гөлләре, моңлы гөрләвек.
Чиккән сөлге—минем гомер юлым:
Кышкы буран, җәйге күлләвек.

Чиккән сөлге—яшел урман юлы:
Күзгә сагыш, кышкы бозлавык.
Чиккән төсләремә карыймын да
Эндәшәлмый торам беравык.

Чиккән сөлге—бүләк балаларга,—
Күзләремнән күчкән нурларым.
Ничәмә төс, ничәмә җыр анда—
Һәр төсендә минем кулларым.

Чиккән сөлге—әниләре төсе,
Сагынганда искә алырлар.
Янып торган яз бизәге чиктем,
Гомер үтәр,
Гөлләр калырлар!

## Галиҗәнап әнкәй

Алиһә дә, ханбикә дә түгел,
Син гап-гади татар килене.
Гомер иткән йорт-җиреңә әллә
Күңелеңнән нурлар иңдеме?

...Бала булып яшәгәнсең башта,
Тапкан, баккан газиз әнкәңә.
Сабый булып барып сарылгансың
Ирек яулап кайткан әткәңә.

Зифа булып үсеп җиткәнсең дә,
Килен булып, килеп иңгәнсең.
Ярсу җанлы, дәртле, мәхәббәтле
Иргә хатын була белгәнсең.

Таңнан торып казан аскансың син,
Иген чәчеп, урак ургансың.
Әмма җирнең һәрчак уртасында
Син булгансың һәм нык торгансың.

...Итәк тулы уллар, кызлар әнә—
Ничә җанга ана син хәзер.
Син алиһә—безнең дөньябызда,
Тезләнергә әзер, бир әмер.

Син—патшасы безнең яшәешнең,
Күпме йөрәк сиңа тоташа.
Синең сөю көчле иткән илне,
Алып чыккан янган ут аша.

Син—гап-гади татар килене бер,
Син—гап-гади татар хатыны.
Син—иң бөек яшәү чыганагы,
Галиҗәнап әнкәй, алтыным!..

## Әрәмә

Бала чакта аз чаптыкмы
Зөбәер кырларыннан?
Эссе көндә су эчкән чак
Тәгәрмәч юлларыннан
Истә әле, һаман истә
Чыклы чирәм, чокырлар.
Җимешенә җибәрмәскә
Тарткалашса чытырман,
Шуып астан керә идек—
Безме аннан буш кайткан?
Әмәлен тапсаң, әрәмә
Бар байлыгын
Чиләгеңә бушата...

## Нурчишмәм

Карап торам, хәйран калам,
Суларыңа таңкә салам,
Таңкәле су—сучишмәм.
Көмеш суда чагыла нур,
Көмеш суда агыла җыр—
Җырчишмәм син, җырчишмәм.

Салкын суын кулга алам
Тып-тып тамчың телгә тама—
Балчишмәм син, балчишмәм.
Тәннәргә сихәтең сеңә,
Җаннарга җылың йөгерә—
Җанчишмәм син, җанчишмәм.

Җирнең җәйге кочагында,
Кызның моңсу курчагыдай,
Чүгәлим, тик җир ишмәм.
Моңлансам да синең кебек,
Горур калам дәртең күреп,
Сүз тишсәм дә, сер чишмәм.

Көч-гайрәтең, күрче, нинди,
Миндә дә ут, ялкын көйри—
Туган чишмәм, җирчишмәм.
Тибеп, бәреп чыгасың ич,
Тынычлангач тонасың ич—
Сафчишмәм син, сафчишмәм.

Уйлап торам, хәйран калам,
Суларыңа таңкә салам,
Таңкәле су—сучишмәм.
Көмеш суда агыла җыр,
Көмеш суда чагыла нур—
Нурчишмәм син, җырчишмәм!

## Кемнәре юк бу дөньяның?..

Бар икән бәхетле җаннар,
Рәхәтенә тиенгән,
Тәнендәге һәр күзәнәк
Мәхәббәттән киенгән.

...Ләззәтләргә чыдый алмый
Бар микән үлүчеләр?
Акылдан ничек шашмаган
Сине тәү белүчеләр?

Кемнәре юк бу дөньяның,
Без генә белмәгәч тә,
Эрер өчен кочагына
Атылып кермәгәч тә.

Насыйбым түгел, шулай да
Мин сине беләм икән.
Төшләремдә күрәм дә бер,
Өнемдә көләм икән.

Төшләр дә ярап куя шул
Бәхете чамалыга.
Күпсенмәгез шул бәхетне—
Күңеле яралыга...

## Көтә-көтә

Көннәр ага берсен-берсе этә-төртә,
Төннәр ага күз яшьләрен сөртә-сөртә.
Шул көннәргә, шул төннәргә чат ябышып,
Үтә гомер, юньле тормыш көтә-көтә.

...Җәмәгатең тик эш аты булды, җаным,
Сине көтеп алалмыйча атты таңым.
Гомер әзрәк калган саен артты аңым,
Тыелдым гел, сабыр итим диеп тагын.

Урау, озын булса да юл—юл бит әле,
Борчыса да, көтеп алган шул бит әле.
Тирә-юньдә хисапсыз күп тол бит әле,
Ятка түгел, үз иремә кол бит әле...

Көннәр акты—берсен-берсе этә-төртә,
Төннәр акты—күз яшьләрен сөртә-сөртә.
Элке-салкы дәвер үтә менә, үтә—
Көзгә кердек анык тормыш көтә-көтә.

## Кайгыларны мин берүзем эчәм

Болын-болын гомер калды җирдә,
Чишмә-чишмә эчәр таң суы.
Уемда син һаман минем белән,
Ә өнемдә инде—тансыгым!

Кабат-кабат кайтып сагынуларым,
Телеп-телеп ала үзәкне.
Ялгызларга һәрчак шулай микән?
Бирә генә дөнья кирәкне.

Бураным да, ләйсән яңгырым да
Син булгансың,
Һәм син—бүген дә.
Кайгыларны мин берүзем эчәм,
Кирәксең син шатлык көнемдә!

## Сыный алмас идем

Күкләр күрмәсә дә, гөлләр белә:
Йөзем якты, керсез вөҗданым.
Гайбәтләргә урын калдырсам да,
Явызлыклар җирдә кылмадым.

Дусларымның әйткән киңәшләрен
Догам итеп йөртәм җанымда.
Кемгә ошый, кемгә ошамыйдыр—
Апа да без, сеңел, ханым да...

«Хыялый ул» диеп ялгыштылар,
Эндәшмәүне артык күргәнгә.
Барсын белеп, барсын сизеп тордым—
Кытыклары килде түзгәнгә...

Хәсрәтләр килде—саргаймадым,
Авырлыклар килде—сынмадым.
Үземне дә, дусны-дошманны да,
Дөньяны да шулай сынадым.

Сынган булсам, сыный алмас идем!



Гарифҗан Мөхәммәтшин

# БАЛАЧАКТА КАЛАЧАК

ПАРЧАЛАР

## Гадил дустым

Мин хыялымда еш кына үткәннәргә—бала чагыма, үсмер чагыма кайтам. Олыгайган саен ешрак кайтам. Гомер фасыллары алышынып, балачактан ераграк киткән саен әнә шул чаклар якыная бара. Күрәсең, яшәешнең кануннары шундыйдыр... Кайтам. Анда мине беренче булып шул ерак балачакта калган дустым Гадил каршылый.

Гадил! Түм-түгәрәк каракучкыл йөзле, тәбәнәк гәүдәле, әмма нык бәдәнле иде ул. Ә иң тәэсирлесе—аның күзләре. Куе кара кашлар астыннан елтырап карап торган, мөлдерәмә ниндидер серле бер моң тулы шомырт кара күзләр.

Әле яңа гына кар сулары китеп, үлән төртә башлаган болында яланаяк йөгерешкәндә дә, сабан туйлары алдыннан яшел чирәм өстендә бил алышканда да, әле яңа гына йөгәнгә күнегеп килүче ярсу яшь тайларга атланып узышканда да еш кына ул алда, җиңүче була. Хәер, җиңелгәндә дә кәефсезләнми, «Д-а-а малай!»—дип аркаңнан кагып җиңүче өчен шатлануын, соклануын белдерә.

Гадилнең әтисе сугыш кырыннан кайтмады, үсә төшкәч белдем—Ленинград янындагы Пулково биеклекләре өчен барган авыр сугышларда башын салган ул. Берсеннән-берсе кечкенә дүрт баласын сугыш елларында да ач үлемгә бирмичә саклап үстергән әнисен, инде уңышы күптән җыелган, кышкы йокыга талып баручы басудан башак җыеп кайтканда тотып, биш елга хөкем иттеләр. Инде бусагага баскан салкын кыш алдыннан балалар тома ятим калдылар. Балалар йортына да аларны соңлап кына, кыш урталары үткәч алып киттеләр. Гаиләдә иң кечкенәсе булган Гадил өч туганы белән ач-ялангач килеш күршедән-күршегә күчеп йөреп үпкә авыруы алды. «Мыеклы үрмәкүч» үлеп, әнисе котылып чыккач кына кайтты ул туган авылга. Әмма теге мәкерле авыру үзенекен итте. Ундүрт яшендә, алмагачлар чәчәк аткан ямьле май аенда вафат булды ул. Гомеремдәге иң беренче онытылмас авыр югалтуым...

Ул көннәрдә әтиемнең берсе артыннан берсе тәмәкесен кабызып, үзен-үзе кая куярга белмичә уфтанып, сугышта бармакларын югалткан кулы белән ара-тирә өстәлгә йә скәмьягә суккалап йөргәнен хәтерлим. Ниндидер әйтеп булмый торган бер ачу бар иде аның күңелендә. Алар Гадилнең әтисе белән

---

Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН (1941)—*шагыйрь; «Уеннан уймак», «Серләвек», «Бәхет» һ.б. китаплар авторы. Балтачта яши.*

яшьлектән дуслар булганнар, сугышка да бергә киткәннәр.

Хыялый малай иде Гадил. Әллә ниләр уйлап чыгара шунда—әле йолдызларга «оча», әле йөзеп барган ак болытларга «утырып китә», әле күз күрмәгән, колак ишетмәгән ерак илләр турында мавыгып сөйли башлый. Ни генә сөйләмәсен, тавышында бер сихерле торган уйчанлык, ихласлык була анын—авызынны ачып, ышанып тыңлыйсың. Ә көлеп җибәрсә!

Менә без тыкрык башындагы яшел үләндә чемченүче каз бәбкәләрен саклап төпсез зәңгәр күккә карап гәп корып ятабыз. Язгы җылы матур көн. Әмма әллә кайлардан суырып-сулкылдап эч бора. Ул елларда иң тенкәгә тигәне шул мәрхәмәтсез ачлык иде. Бигрәк тә яз көннәрендә...

Гадил гадәттәге уйчан тавышы белән сүз башлый:

—Эх малай, менә хәзер туйганчы бер ипи ашасан иде, ә!

Ул әнә шул тинсез янгыравыклы сабый тавышы белән көлеп җибәрә. Мин дә ана кушылам. Без икәүләп яшел чирәмдә тәгәрәшеп көләбез. Чүгә-чүгә чирәм чүпләгән каз бәбкәләре дә башларын күтәреп, гаҗәпләнеп-аптырап безгә текәләләр. Нәрсә булды боларга, янәсе.

Нидән көлдек икән без ул вакытта? Ипи кебек аннарны чуалтырлык хуш исле, вак-вак күзәнәкле, күпереп пешкән тәмле ризыкны туйганчы ашау мөмкинме соң инде, дип үзебезнең беркатлылыгыбызданмы? Әллә чыннан да, килер әле шундый бәхетле бер заман, дип сабыйларча ышануыбызданмы? Белмим. Әмма көлеп туктаганда безгә ничектер әле генә туйганчы икмәк ашаган кебек бик тә рәхәт булып китте. Менә нинди тылсымлы көчкә ия икән ул көлү!

Еллар үткән саен көлү-елмаюның менә шушы тылсымына минем иманым ныгый-тирәнәя барды. Тормышымда ниндидер киртә-авырлыклар очраса да, башыма кайгы-хәсрәт килсә дә, гаделсезлекләргә тап булсам да, мин яшь аралаш булса да елмаерга-көләргә тырыштым. Авырлыклар җиңеләеп, кайгыларым тонықланып кала, дөньям кинәеп, ямьләнеп китә. Андый вакытларда минем күз алдыма гел ерак балачагымда калган Гадил дустым, аның белән бергәләп яшел чирәмдә тәгәрәшеп көлүебез килеп баса. Һәм күнелемдә үземә шундый тылсымлы ачыш ясарга ярдәм иткән балачак дустым Гадилгә рәхмәт хисе уяна. Рәхмәт сиңа, уйчан шомырт кара күзле дустым Гадил!

## Самолет

Үсмерлеккә авышып барган чорыбыз. Инде сабыйлыгыбыз үткән, күп нәрсәне зурларча аңлый беләбез.

Беркөн кичен, инде көтүләр кайткач, авыл өстеннән Мещан урманына таба түбәннән генә, тавышы белән авыл халкын өркетеп, ике катлы канатлы самолет очып узды. Ул чорда бу чикерткә кебек нәмәрсә инде безнең өчен гайре табигый хәл. Бөтен кеше урамда, капка төбендә, шушы вакыйганы «тикшерә».

Берничә минуттан урам башыннан тузан туздырып бер төркем малайлар йөгереп чыкты. Иң алдан җан-фәрманга бездән өч-дүрт яшькә олы Навил җилдерә. Ул авылның иң оста алдакчысы. Навил алдаса, төп башына утырып калганыңны абайлармын димә. Аның «Мине алдый алмыйсың» дип бәхәсләшкән авылның иң зирәк акыллы агаен да җиңел генә шул халдә калдырганын гыйбрәт итеп сөйлиләр иде өлкәннәр.

—Мещан урманы кырыендагы каланча янына самолет төшкән!—дип кычкырды бу безнең янга җитәрәк.

Малайлар өеренә без дә кушылдык. Егермеләп малай-шалай җан-фәрманга чабабыз. Алай да Навил ашыктыра:

—Тизрәк, малайлар! Самолет безне көтеп тормас. Очып китсә күрми каласыз!

Ниһаять, без каланча янында. Әмма самолет та, аның эзе дә юк. Нәүмиз карашлар белән Навилгә борылабыз.

—Эх, өлгермәдек, киткән икән... Самолет шул инде ул, йөгереп кая аның артыннан өлгерәсен, тю-тю-ю...—ди бу уфтанып-сызгырып. Әмма шундук көр тавышка күчеп кабынып та китә:

—Ничава, егетләр, икенче төшкәндә өлгербез әле, борыныгызны салындырмагыз!

Без әкренләп аңга киләбез, үкенечләрдән айныйбыз, берәм-берәм кайту ягына борылабыз. Тик... кабат Навилнең көр тавышы яңгырый. Ул бармагы белән урман читенә күрсәтеп:

—Егетләр, буш кайтканчы берәр-икешәр көлтә менә шушыларны күтәреп кайтыйк инде. Ике көлтәнең нәрсә авырлыгы бар инде аның!—ди бу ярым үтенечле, ярым әмерле тавыш белән.

Без бераз икеләнеп бер-беребезгә карашып торганнан соң, көлтәләргә бәйләнгән усак, юкә яфракларына үреләбез.

Эшнең асылын иртәгесен генә аңлап алдык. Көндез Навил энесе белән бергәләп сарыкларга кышка яфрак әзерләгән икән. Аларның уфалла арбасы юк. Аны алып кайту өчен урманга ничә мәртәбә өстерәлеп барырга туры килер иде! Самолет вакыйгасы ана мәсьәләне җинел генә хәл итәргә ярдәм иткән. Әмма инде безнең Навилгә булган үпкәләр тоныкланган, аның хәйләсенә соклану-гаҗәплəнү тойгылары гына калган иде. Әйтеп кара син шушыннан соң Навилне оста алдар түгел, дип!

## Кино

Авылга кино килү зур вакыйга иде. Кино буласы көнне авылда сүз шул турыда гына—нинди кино, нәрсә турында, кайсы механик килә икән, Әхмәт килсә шәп булыр иде, ул киноны бер дә өзмичә күрсәтә...

Ә без—малайларның башында башка фикер—ничек кенә итеп кинога әләгергә? Үтә чаялар юлын табып, качып яки тәрәзәдән шуып керә. Киномеханикны йокларга үзләренә алып кайту ысулын файдаланучылар да бар. Әмма иң нәтиҗәлесе механикка фуражкаңны биреп, аппарат әйләндерүгә килешү. Ул чорларда кино күрсәтүче механик киноаппаратның генераторын кечкенә генә ручкасыннан әйләндереп торып күрсәтә, «телсез» киноларның эчтәлеген дә сөйләп бара әле. Әмма кемнең соң ике сәгать буе генератор әйләндерәсе килсен! Гадәттә механик моның өчен өч- дүрт малайны бушка кинога кертә, клубка шыгрым тулган халык арасына кереп качмасыннар өчен аларның фуражкаларын җыеп ала. Тегеләр исә, кино карый-карый, чиратлашып ручка әйләндерәләр. Механик та канәгать, малайлар да шат.

Әлеге дә баягы Навилнең дә кино карыйсы килә. Тик билет алырга акча, «залог»ка салырга фуражкасы юк.

Беркөнне бу үтә гозерләнеп күршесе Габделхәйгә керә:

—Малай, бер генә кичкә фуражканны биреп тор, кеше шикелле бер кичке уенга чыгып керим,—ди.

Ничек инде мондый гозерне тыңламыйсың—Навил олырак, берәр җитди сәбәбе бардыр дип, бирә Габделхәй фуражкасын.

Иртәгесен кардан арчыла башлаган тау битенә сарыклар көтәргә чыккан малайлар бергә җыела. Кәрт сугу, мәзәк сөйләү китә. Ә Навил исә, гадәтенчә мактанып, кичә кино каравы турында сөйли башлый.

—Шыттырасың, синең кинога керергә акчаң юк!—дип тегенең ялганын фаш итә Габделхәй әле генә Навил кайтарып биргән фуражкасын бер кулы белән арткарак этеп.

—Ә мин фуражка биреп карадым,—ди Навил тыныч кына.

—Ялганлама, синен фуражкан юк!—дип ярып сала Габделхәй.

—Менә тагын, фуражканы синнән алып тордым ич!—ди Навил бер дә исе китмичә.

Авызын ачып калган Габделхәй инде күпне күреп таушалган фуражкасын жиргә атып бәрә һәм Навилгә:

—Ну-у-у мин сине, малай!—дип яный.

Билгеле инде, эш шуннан тирәнгә китми, барыбызның бергәләп көлешүе белән тәмамлана. Әмма Навилгә үзеннән ниләрдер куша-куша әлеге кинонын эчтәлеген сөйләргә туры килә.

Без киноларны исемнәре белән белмибез. Безнен өчен алар дүрт төрле була: «Сугыш турында», «Партизаннар турында». «Шпионнар турында», «Мәхәббәт турында». Табигый ки, малай-шалайны беренче өчесе кызыксындыра, соңгысы турында әле хәбәрдарлыгыбыз бик такыр.

Бу җәһәттән яшьләр арасында шушындый бер вакыйганы еш искә алалар иде.

Йомыкыйрак табигатьле Зөбәер беркөнне чордашлары арасында үзенен сугыш турындагы киногa барачагын әйтеп сала. Навилгә исә шушы житә кала. Менә авылга инде ничәмә-ничә күрсәтелгән, чираттагы бишьеллыкнын бөек бер төзелешендәге вакыйгаларны сурәтләгән эчпошыргыч кино килә. «Производство темасы» була инде. Навил нindидер юллар белән Зөбәернен колагына сугыш турында кино килгән, дигән хәбәрне ирештерә.

Бара Зөбәер кинога. Сеанс башлана. Ә экранда тимер-томыр, машина-трактор, кешеләр йөгерешә, нидер күтәрәләр-төшерәләр, сөйләшәләр, үбешәләр. Әмма сугыш юк. Озак түзә Зөбәер. Ниһаять, түземлеге беткәч бөтен зал ишетерлек итеп:

—Кайчан сугышалар соң инде болар?—дип кычкырып җибәргәнен сизми дә кала.

...Балачак, анын беркатлы гөнаһсыз вакыйгалары инде еракта, бик еракта. Киноларны да без өйдә, кәнәфигә кырын ятып, кнопкага гына басып үзебез теләгәнен тәүлекнен теләсә кайсы вакытында карыйбыз. Карыйбыз да онытабыз. Ә менә балачак кинолары никтер онытылмый.

## Тәмәке

Без малай чакларда балалар, үсмерләр арасында тәмәке тарту бик модада иде. Язын авыл каршындагы тау битендә кардан арчылган җирләр күренә башлау белән кышкы ачлыктан үзенне тотып ашарга әзер булган сарыкларны чемченергә алып чыгабыз. Анда инде кәрт сугу, йөгереш-чабыш, бил сынашу китә. Чебиләүдән канап-кутырлап беткән аяклар гына үзәккә үтә. Әй аларнын әрнеп сызлаулары...

Тәмәке тартунын беренче күнекмәләре менә шунда үзләштерелә. Эш уч төбендә шәпләп уылган коры печәнне төреп тартудан башлана. Аннан инде коры мүкне уып тарту китә. Ә инде үсә төшкәч «мәхрә» тарта башлыйсын. Өйрәнеп житкәннәр аны бик тә мәртәбәле итеп тарталар: бер аяк үзенчә читкә табарак авыша, сынар кул билгә таяна, икенче кулнын ике урта бармагы арасына төрелгән тәмәке кыстырыла. Ара-тирә, авыздан төтенне өреп чыгарганнан сон, әллә кая барып житәрлек итеп чертләтеп төкерелә һәм чәнти бармак белән тәмәкенен көле коеп төшерелә. Эффект бәхәссез. Ин остарып житкәннәре төтенне дә бик матур итеп, һавада шактый вакыт әйләнә-әйләнә эленеп торырлык божра рәвешендә итеп чыгара. Болары инде синен чын егет булып житүеннен дәлиле...

Ул заманнарда бик зурлап үткәрелә торган Октябрь бәйрәме алдыннан

була бу хәл. Өлкән абыем Рәхимҗан яшьтәшләре белән (алар инде егетләр) төрелгән тәмәке кабып урамның уртасыннан бәйрәмчә шат күңел белән сөйләшеп-көлешеп киләләр. Араларында абыйның яшьтәше күрше егете Мөнир дә бар. Мөнирнең әтисе Сабир абзыйны кинәт каршыларына килеп чыккач кына күреп алалар болар. Бүтән чара калмый—тәмәкеләрне тиз генә учлап кесәләренә тыгалар. Өлкән кеше сәламнәрен алыр да, узар да китәр, янәсе, яшьләр янына тукталып тормас. Хәйләкәр Сабир абзый исәнләшә дә, бәйрәм хәлләрен сораша башлый. Егетләр берәм-берәм өздереп пешә башлаган кулларын кесәдән тартып алалар. Күп тә үтми кесәләрдән бормаланып-бормаланып төтен чыга башлый—яна башлаган кесәләрне сүндерү чарасын күрергә туры килә.

Бу кичне егетләрнең өйләрендә әтиләр шул чорларга хас булган кырыс тәрбия чаралары үткәрәләр. Бездәгесен мин үзем дә яхшы ук хәтерлим. Тик менә абый тәмәке тартуны гомеренең ахырына кадәр диярлек ташламады. Әмма аны һичбервакыт, инде олыгаеп җиткәч тә, әти-әнигә күрсәтмәде. Мин генә менә бу «мәртәбәле һөнәр»не тәки үзләштерә алмадым.

Тәмәке дигәннән, тагын бер гыйбрәтле вакыйганы хәтердә яңартып китим әле.

Безнең авыл егетләренең кичләрен кинога яки уен кичәсенә керер алдыннан клуб артына җыелышып гәпләшә, уен-көлке сөйләшә торган гадәте бар иде ул чорларда. Билгеле инде, монда тәмәке дә кабызыла. Ә без гадәттәгечә алардан читтәрәк кайнашабыз, көнләшеп аларның сүзләренә колак салабыз. Малай чакта кемнең соң тизрәк егет булып җитешәсе килми!

Түбән оч Хәбирнең бер начар гадәте бар—аның бер генә вакытта да үзенең тәмәкесе булмый. Берәр тәмәке суыручы егеткә мөрәҗәгать итә бу:

—Кая, калдыр әле!—дип төпчек сорап ала. Тегеләре, билгеле, каршы килми. Ни дисәң дә дуслар бит.

Беркөнне егетләрнең үтә чаясы Зиннәтулла акылга утыртырга була моны. Хәбир, гадәттәгечә төпчек сорагач, төпчекнең башын борып тиз генә Хәбиргә суза. Тегесе исә гәзит кәгазенә мул итеп «мәхрә» салып төрелгән тәмәкене кабып та куя. Шундук Хәбирнең буылып йөткергән тавышы ишетелә һәм ул яшен тизлеге белән төпчекне төкереп тә ташлый.

Ул көнне кичке уенга керми Хәбир. Алдагы өч-дүрт көндә дә клуб тирәсендә күренми. Кабат чыга башлаганда аның теге ямьсез гадәте онытылган була инде, ул тәмәкене үз кесәсеннән алып кабыза. Егетләрнең ара-тирә «Хәбирнең авызы пешкән!» дип көлешкәннәрен генә ишеткәли идек без.

## Сарык кыйссасы

Сугыштан соңгы иләмсез авыр елларда авылда сарык белән кәҗәне күп асрыйлар иде. Сыер асраучылар бик аз—озын кыш дәвамында ашатырга азык күп кирәк булгангадыр инде. Ничек тә булса җан сакларга кирәк ич.

Бер елны безнең, ни сәбәпледер инде, сарыклар бөтенләй калмады. Әти белән әнинең җәйгә чыгу белән сарыклар алу турында үзара сөйләшеп-киңәшеп йөргәннәре бүгенгедәй хәтеремдә.

Апрель җитү белән авылда терлек санын исәпкә алу башлана. Бу эшне үтә зур җаваплылык һәм җентеклелек белән уздыралар, чөнки терлек санына карап налог салына. Ни генә сорамый иде дәүләт ул вакытларда тормышның очын-очка ялгый алмый интеккән, болай да ярым ач авыл кешесеннән—маен, итен, йонын, йомыркасын, бәрәңгесен... Өйдәге җиде бала, ач күзләребезне мөлдерәтеп, әнә шуларны алып чыгып киткәннәрен карап калуларыбыз гомергә онытыласы түгел.

Терлек исәбен алуны авыл Советы секретаре, налог агенты, авыл

активистларыннан бер пунәтәй составындагы бик кырыс комиссия башкара. Хәтерлим, налог агенты Шәрифә апа бик тә усал һәм рәхимсез кеше иде. Анын теленнән ул чорлардагы түрәләр авызында бик тә модный булган «буржуй», «халык дошманы», «саботажник», тагын әллә нинди сүзләр коелып кына тора.

Менә алар безгә килеп життеләр. Сыерны, әле күптән түгел генә туган, өйнең ишеге янынарак бәйләп куелган юеш авызлы, мөлаем карашлы бозауны яздылар. Әтидән сарыклар санын сорыйлар. Әти сарыклар юклыгын әйтә. Шундук бәхәс башлана.

—Юкны сөйләмә, синдә биш-алты сарык бар да бар инде анысы,—ди кырыс тавыш белән Шәрифә апа. Шулай итеп бәхәс куера.

Шәрифә апа аяк арасында буталган мина таба борыла:

—Наныем, әйт әле, сезнең сарыкларыгыз бар бит, иеме!—ди.

—Юк,—дим кыюсыз гына.

—Буржуй калдыгы!—ди Шәрифә апа утлы усал күзләрен уйнатып.

Алар тиз генә кузгалып абзар, мунча, каралты эчләрен, су буена төшеп тал-тирәк арасын, яр асларын актарып чыгалар. Әмма сарыклар табылмый.

Әти шаянлыкка да маһир иде. Болар капкадан чыгып китү белән әнигә күз кысып:

—Кызык итим әле мин боларны!—диде һәм жәһәт кенә өй астына сикерде. Өй астынын кечкенә жил тәрәзәсеннән нечкә генә тавыш белән сарык бәрәне булып мәәлдәгәне ишетелде. Ул сикереп торып өстәлдәге чәй артына утырганда тегеләр капкадан йөгереп кире кереп тә життеләр.

—Әйттем сарыкларың бар, дип. Мине алдый алмассың. Әле генә кычкырды сарыгың. Кайда яшердең, әйт!—ди Шәрифә апа тыны кысылып.

Болар кабат барысын актарып чыктылар. Өй астына, базга төштеләр, хәтта без таралышып йоклый торган сәке астын да барладылар. Әмма сарыклар табылмады.

—Кычкырды бит сарыгың!—ди Шәрифә апа.

—Күршенеке кычкыргандыр ул, Шәрифә,—ди әти тыныч кына.

—Барыбер эләктерәм әле мин сине, кунтра!—ди Шәрифә апа бармак янап.

Алар чыгып китте. Без түгәрәкләнеп чәй эчәргә утырдык. Әти белән әни әле алардан озак көлештеләр. Әтинең сәер елмаюы чәйдән кузгалганчы йөзеннән китмәде. Канәгать иде ул үзенең усал шаяртуыннан. Мин дә анын кәефен бозмас өчен «кунтра»нын кем булуын әлегә сорарга базмадым.

## Тәэминатчы

Хәер, гел балачак димәгән. Бераз балачактан тайпылып алыйм әле. Тик бу хикәям дә шул ерак балачактагы дусларым-чордашларым белән бәйле.

Әлеге дә баягы инде телгә алынган Навил, озак еллар буе иксез-чиксез Советлар иле буйлап бәхет эстәп йөреп олыгая төшкәч, кабат туган авылга кайтып төпләнде, әтисе нигезенә яна йорт житкерде.

Малай чактан анын үткенлеген белгән колхоз рәисе Навилне тәэминатчы итеп эшкә ала. Узган гасырнын туксанынчы еллары авылны, колхозларны тарату хәрәкәтенен кин колач алган чоры. Дәүләт тәэминаты системасы юкка чыккан. Колхознын көндәлек мен төрле проблемасын хәл итү өчен кирәк булганнын барысын үзенә эзлисе, үзенә табасы. Тапканын сатып алу өчен акча да юк—житештергәнен дәүләткә кирәк түгел. Кирәк дигәненен дә бәясе ташка үлчим. Кыскасы, хужалыкка үткен тәэминатчы кирәк.

Рәиснен ышанычын аклый Навил—нинди генә йомыш белән, кая гына жибәрсәләр дә буш кайтмый, кушкан йомышны үтәп, кирәк әйберне эзләп таба.

Беркөнне нәрәт алдыннан идарә янына жыйналгач моннан:

—Навил, ничек син шулай бөтен йомышны үти, бөтен нәрсәне таба аласың соң? Заманы да бик буталчык бит,—дип сорыйлар.

—Егетләр, мин йомыш белән кая гына барсам да бик кәттә киенеп, галстук тагып барам. Кая гына керсәм дә ишекне киң ачып, корсакны киеребрәк, дәрәҗәле итеп керәм. Сразы кабинет хуҗасы каршына килӛм дә бодрый итеп:

—Исәнмесез, Фәлән Фәләнеч, Сезгә Илсур Бакиевичтан күп сәлам!—дим. Башта битараф кына булган теге абзый сагаеп кала.

—Кем әле ул Илсур Бакиевич?—ди бу кыюсыз гына, ниндидер бер атаклы кешене белмичә унайсыз хәлгә төшмәгәем, дип.

Мин исә бик гаҗәпләнгән булам:

—Разве Сез бөтен Союзга знаменитый «Ударник» колхозы рәисе депутат Илсур Бакиевич белән таныш түгел?—дигән булам. Теге сразы шиңеп кала. Аннан:

—А-а-а, извините. Мин онытып җибәргәнмен,—ди һәм аягүрә басып, минем кулымны кысып, каршындагы йомшак кәнәфигә утырта. Аннан соң инде йомышны үтәү чепуха. Кирәк әйбер үзендә булмаса, «Минем бик влиятелни дустым өчен шуны эшлә әле!» дип ишләренә шалтырата. Кайсылары үз кәнәфие артындагы затлы бүлмәгә алып кереп сыйлап та җибәрә әле. Һичьюгында, ишеккә кадәр озатып калмаганы бик сирәк, кәнишне,—дип үзенең уңышының серләре белән уртаклаша Навил.

Анын хикәясендәге хәлләрнең күпмесе дөрес булгандыр, әйтүе кыен. Әмма балачактагы җорлыгы, алдарлыгы гомере ахырына кадәр югалмады.

---

## *Кайда күпме мөселман яши?*[1]

| Урын | Илләр | Халык саны (млн.кеше) | Мөселманнар саны (млн.) |
|---|---|---|---|
| 1 | Индонезия | 228,4 | 201,0(88%) |
| 2 | Һиндстан | 1030,0 | 144,2 (14 %) |
| 3 | Пакьстан | 144,6 | 140,3 (97 %) |
| 4 | Бангладеш | 131,3 | 109,0 (83 %) |
| 5 | Нигерия | 126,6 | 95,0 (75 %) |
| 6 | Кытай | 1273,1 | 76,4 (6 %) |
| 7 | Төркия | 66,5 | 66,5(100%) |
| 8 | Иран | 66,1 | 65,4 (99 %) |
| 9 | Мисыр | 69,5 | 65,4 (94 %) |
| 10 | Эфиопия | 57,2 | 37,2 (65 %) |
| 11 | Алжир | 31,7 | 31,4(99%) |
| 12 | Марокко | 29,8 | 29,4 (99 %) |
| 13 | Судан | 31,5 | 26,8 (85 %) |
| 14 | Әфганстан | 26,8 | 26,5 (99 %) |
| 15 | Гыйрак | 21,4 | 20,8 (97 %) |
| 16 | Үзбәкстан | 23,4 | 20,6 (88 %) |
| 17 | Согуд Гарәбстаны | 19,4 | 19,4(100%) |
| 18 | Танзания | 29,0 | 18,9(65%) |
| 19 | Сурия | 15,6 | 14,0 (90 %) |
| 20 | Йәмән | 13,5 | 13,3(99%) |
| 21 | Россия | 143,2 | 13,1 (9%) |

[1] БМОның Халыклар фонды мәгълүматы (www.unfpa.org). 2005 ел.



Әмир
Мәхмүдов

# ДИМ БУЕНЫҢ ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

## Иркәләнеп кенә

Иркәләнеп кенә туганмын мин…
Иркәләнеп кенә яшәдем.
Иркәләнеп кенә яшьнәдем мин…
Иркәләнеп кенә яшәрдем.

Сизмәгәнмен…
Иркәләнеп кенә
Тормыш юлымны да үткәнмен.
Беркем сизмәс…
Иркәләнеп кенә
Якты дөньялардан китәрмен.

## Китеп бара Дим буеның шагыйрьләре…

Китеп бара Дим буеның шагыйрьләре,
Мәңгелеккә торып кала
Үлем белмәс шигырьләре.

Сизеп була җан тибешен
Димгә койган елгаларның,
Шагыйрьләрнең җырын җырлап,
Дим дә ага боргаланып.

Димгә таба талгын ага
Әбдрәшит чишмәләре…
Шагыйрьләрнең сүзе бетми,
Наэлый китап киштәләрен.

Әмир МӘХМҮДОВ (1947) — *шагыйрь, әдәбият галиме; «Матурлык тантанасы», «Мәңгелек моң» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Аек күз белән карамый,
Сакламыйдыр сау ирләрне.
Үз янына ала Әҗәл
Чишмә түмен ак кәгазьгә
Күчерәлгән шагыйрьләрне...
Китеп бара Дим буеның шагыйрьләре—
Данлылары, ярсулары, сак ирләре...
Җирне тукмап ага сыман «Тукмак чишмә»:
«Афәтләрдән коткарыгыз шагыйрьләрне!»

Котылу юк шагыйрьләргә,
Ялварса да бөтерелеп су ташлары...
Китеп бара Дим буеның шагыйрьләре—
Кудашлары, Вахитлары, Кәримнәре, Шамилләре...

Мең сер алып, могҗизадай,
Китә Димнең шагыйрьләре.
Бу шигырьне язган Кеше—
Әлегә исән Әмир әле...

## Ак сихергә төреп...

Сихерләрнең
Җирдә төрлесе бар...
Бардыр, диләр,
Хәтта ак сихер.
Яшел урманнардай
Җаным сизгер:
Ак кулмәкле,
Шомырт күзле,
Кара чәчле кызый,
Ак сихергә төреп
Сөю бураннарын
Язгы таңнарымнан
Син китер!

## Без күршеләр идек...

Без күршеләр идек,
Вафирәкәй,
Сыкрап куя
Газиз йөрәккәй:
Нинди көчкә генә,
Нинди көчкә генә
Аерырга безне кирәккән?

Без күршеләр идек...
Хәйдәр, Фаил,
Рәхилә һәм Рафаэль—
Без күршеләр идек...
Кыска юлдан
Китте Фаил күрше.
Празат абый
Бардымы озак?
Без күршеләр идек...
Бату абый,
Яхин Рөстәм.
Җыр өзелде...—
«Кем кушты өстән»?
Иманыңа тугры калдың,
Вафирәкәй.

---

Вафирә Гыйззәтуллина, Хәйдәр Бегичев, Фаил Шәфигуллин, Рәхилә Мифтахова, Рафаэль Билаловлар. Автор.

Йөрәкләрдә—моңлы җырың,
Яңгырый «Ком бураны»:
«Илдә көрәш барган чакта
Өйдә ятып буламы?»

Без күршеләр идек, моңлы Вафирәкәй,
Сезне сагынып сызлый йөрәккәй.

## Мин—чын татар!

Чал Уралның гади баласы мин,
Мин—чын татар!
Бүген миңа кара җаннар
Уклар атар.
Дим буенда туып-үстем.
Мин—чын татар!
Татарларны сөймәгән зат
Мең ут атар.
Талдай бөгелмим.
Имән мин,
Мин—чын татар.
Чаганнар да «бүләк» өчен
Телен сатар.
Имәннәр һич тә сатылмый.
Атса,
Аны
Яшен атар!
Мин—чын татар!

## Бәхетегез сезнең йомгакланыр...

Искән җилләр канатында йөртә
Далаларның моңсу сагышларын,
Ярсу аргамаклар кайдан килә?—
Зур өметнең чыңлавыдай
Тоякларның тавышлары...

Еллар гына талгын аккан,
Алыштырган
Төннәр—көнне, көннәр—төнне.
Далаларда сүнми калган учаклар да...
Бәхет йомгагы да милләтемнең
Тәгәрәгән...—
Бетмәс сүтелеп.

Аргамаклар чаба далаларда.
Тояк тавышлары сагышлы.
Адашып йөргән
Ялгыз бүреләрдәй
Далаларда бүген табыштык...

Азаматлар куа юргаларны.
Кайтканмы әллә Нугай урдалары?—
Өмет канатының кодрәте киң,
Егылмагыз, Гобәй балалары!
Сезнең Бәхет әле йомгакланыр,
Тавыш килә иңләп далаларны...

## Нокта

**Гел янмыйлар сүнмәс утта,**
**Ял да кирәк шагыйрьләргә куәт барда!**
**Шигърият дәрьяларын иңләп,**
**Елгыр дулкыннардан көнләп,**
**Ниһаять,**
**Мин дә чыгып киттем уң як ярга.**
**Чоңгылларда шагыйрь батмас, утта—**
**Янмас, бозда—туңмас...**
**Елгалары тыныч ага, төптә—чоңгыл.**
**Атым тынмас,**
**Мәшәкатьләр тынып калды**
**Сул як ярда.**
**Утларында**
**Бу тормышның.**
**Янганмындыр**
**Йөз мең тапкыр.**
**Кол түгел мин...**
**Тынмас җаным**
**Мәңгелек учакларында**
**Күмер булып**
**Көйрәп ятыр.**
**Хәзер мина**
**Һәрбер нәрсә гүзәл инде,**
**Гүзәл—һәр кыз!**
**Чоңгылларны үткән кеше**
**Әллә тиле?**
**Иксез-чиксез**
**Җәйрәп ята Әмир ИЛЕ.**
**Ага Бәхет чишмәләре...**
**Моң, Җыр иле...**
**Яшь-җилкенчәк янсын бүген сүнмәс утта!**
**Дөнья белән юктыр минем алыш-биреш.**
**Үткән юлым минем—матур,**
**Киләчәгем—гүзәлрәк,**
**Яшәешкә баш иям мин, туктап,**
**Һәм сүземә куям нокта.**

**Редакциядән:**
*Бу айда шагыйрьгә 60 яшь тулды. Аңа яңа иҗат уңышлары, исәнлек теләп калабыз.*

Лилия
Газизова



# ТАТАРЧАМЫ, УРЫСЧАМЫ—ГАМЕМ...

* * *

**Озын күлмәкләр мин кия идем,**
**Муенсалар астым тезгә тикле...**
**Ил биләмәк идем шигырь белән,**
**Дөнья мине үзе әсир итте.**

**Чәч кырдырдым бер яз, җүләрләнеп.**
**«Ай-яй, кыю!»—кычкырдылар арттан.**
**Хәзер миңа җылы кыйммәтрәк,**
**Үземдә дә инде җылы арткан.**

**Кешеләргә ышанарак төшәм,**
**Һәм кочасым килә бу дөньяны.**
**Тормыш бераз рәнҗетсә дә кайчак,**
**Үпкәләмим, аңлыйм бит мин аны.**

**Тик төшенмим бары яшәешне—**
**Күзләремә карамасаң, дәшеп...**
**Син күрмисең—түя су тамчысы—**
**Керфегемдә дерелдәгән яшьне.**

## Байбичә

**Артык «буржуаз» мин шагыйрь өчен—**
**Һәрчак ыспай тышкы күренешем.**
**Кирәк иде, бәлки, гасабилек...**
**Шәхси тормышта да бераз кимлек.**

**Шагыйрьлектә күп шул йомшак ягым—**
**Җайлы тормыш сөям һәм мул табын.**
**Көтәләрдер юкса мескен кызны,**
**Бер бичара мокыт, ялгызны...**

*Лилия ГАЗИЗОВА—рус телендә иҗат итүче шагыйрә, тәрҗемәче; «Черный жемчуг», «Поэма о беременности», «Зимние арабески» һ. б. шигырь китаплары авторы. Г. Державин исемендәге премия лауреаты. Казанда яши.*

* * *

Куе томан—телем-телем,
Өстәлгә куйсаң кисеп,
Тормышның гади икәнен
Аңларлар иде кискен.

Томан таралыр анысы,
Шәүләсе җанга сеңәр.
Сагышлар йоктыра инде
Шушы томанлы көннәр.

Буш бүлмәдә бер ялгызым,
Яктысында бу шәмнең,
Юка җилкәләрем белән
Тотам сыман түшәмне...

* * *

Акрын вакыт агышы.
Мин—бер йокысыз кеше.

Тыныч төннәр ялгана.
Карлар ява Казанда.

Урамнар буйлап йөрим.
Төшләр очышын күзлим.

Онытып әр-ызгышны,
Йөрим ялгыз... сагышлы.

Кар булса идем әгәр,
Явар идем тын гына

Учларга, керфекләргә,
Һәм кошлар канатына.

Бәхетле булсам әгәр,
Кар булыр идем мәгәр...

* * *

Яңгыр ява әсир яугирләрдәй—
Абына ул, сафы буталган.
Ә мин сизмим әле югалтуны,
Өметсезлек җебе югалган.

Яңгыр ява, күлләвекләр кайный,
Сагыш өстәп килер елларга.
Ә мин агым уңаена йөзәм
Йокымсырап яткан елгада.

Ник оета мине бу яңгырлар?
Мин бер агач... куак... түзәрмен.
Эт кояшы күз салса да шул чак
Өзелеп китәр кебек үзәгем.

* * *

Урыс сүзләре төшсә дә
Шигыремнең юлына,
Әбием төшә исемә,
Дисбе тотып кулына.

Әбием дога кылганда
Янында тордым түзеп.
Исемдә, әби, исемдә,
Төз гәүдәң, уйчан йөзең.

Татарчамы, урысчамы—
Гамем дөньяви гелән.
Тик беркайчан ярым аем
Кавышмас тәре белән.

Нишлим—урысча язам мин,
Сыймасам да юлларга...
Хәтеремдә—гел шул дисбе,
Дисбе—газиз кулларда.

* * *

Куыктай шартлады көн,
Тимгелләр җанда яна.
Сөрсегән тәгам каптым,
Ул гүяки өр-яңа.

Кыш көне яшәүләре!—
Сагышы да сап-салкын.

Көзгедәге сурәтем
Күзәтә мине тып-тын.

Кала түгел, даладыр
Тәрәзнең теге ягы.
Ямщикның берәр җырын
Көйлимме әллә тагы...

* * *

Саңагын алып бу яшәешнең,
Сөенәсе килә кабат: мин—кеше!

Үлчә идең йолдызларның яктысын
Вәзеннәрдә... Яшен белән «син»гә—«син».

Җир шарын сыйдырган тамчы кебек дим,
Бер куакта дер-дер килер идем мин.

Карыйсым килә күзенә үлемнең,—
Үлемсезлекме, сагышмы телим мин?

## Марина Цветаевага

И яшисе килә мәхәббәттән
Мәс килеп бер, бик-бик аз гына,
Серле бакчадагы хур кызыдай,
Егерменче гасыр башында.

Ник яшәргә юкса җир йөзендә,
(Ә йөрәк бит шундый ялангач...)
Килер буыннарга дәрт шәрабын
Авыз иттерә дә алмагач...

...Тик түзәрмен микән сөргенлектә
Сагыш кыскан язмыш ташына?
Белмим, шөбһәләнәм... үземнең дә
Ыгы-зыгы ашкан башымнан.

Түзәрменме көзге Чулман әгәр
Үзәгемне өзсә бу төштә?
Белмим, шөбһәләнәм... андый язмыш
Тимәсен дим минем өлешкә.

Талант биреп, Тәңрем, шагыйрьләрне
Чөясең син тәмуг катына...
Узмам сыман мондый сынауларны...
Лаекмы мин шагыйрь атына?

*Ркаил ЗӘЙДУЛЛА тәрҗемәләре.*

# АТЫЛГАН ЙОЛДЫЗ КЕБИ...

*Быелның февралендә Тәбриз Мөбарәковка 75 яшь туласы иде... Аңардан «Хәтер аланы» һәм ул тудырган сокланулы гаҗәпләнү калды.*

Тәбриз Мөбарәков татар прозасында, яшендәй атылган йолдыз кебек, тиз арада якты эз калдырып киткән шәхес.



1995 елны «Казан утлары» журналының 4 нче санында дөнья күргән «Хәтер аланы» исемле повесть-кыйсса әдәби мөхитебездә күптән күрелмәгән, гаҗәеп матур жанлану тудырды. Исән вакытларында ук классик язучыларга әйләнгән аксакалларыбызны әсәрнең XX гасыр ахырында татарча уйлап, татарның гореф-гадәтләрен саклап, искитмәле матур саф татар телендә язылган булуы гаҗәпләндерде.

1996 елның 16 мартында Язучылар берлеге исеменнән Ә. Еники, А. Гыйләжев, Г. Ахуновларның чакыруы буенча, Тәбриз, бәлки әле шул вакытта «Хәтер аланы»н китап итеп чыгару хәстәрен дә күреп булмасмы дип өметләнеп, Казанга кайтты. Шунда ук язучылар: А. Гыйләжев, Г. Ахунов, Ш. Галиев, И. Юзеев, Ә Еникиләр дә жыйнаулашып безгә килеп керделәр. Әдәбият әһелләренең үзен шулай көтеп алулары һәм үзенә зур игътибар вә хөрмәт күрсәтүләре аның өчен һич көтелмәгән сюрприз булды. И-и, ул көнге очрашуның чын мәгънәсендә гаҗәеп матур әдәби кичәгә әйләнеп, төн уртасына кадәр сөйләшеп утырулар күңелләрдә мәңге онытылмаслык хатирәләр калдырды. Ә икенче көнне Арчалыларның Казан циркында узачак зур бәйрәмнәренә, хакимият башлыгының «Талантлы язучы, якташыбыз Тәбриз Мөбарәковка» дип махсус чакыру билеты җибәрүе, зурлап каршы алулары аның өчен шатлык өстенә шатлык булды.

Әмма, ни аяныч, 18 март көнне иртән, соңгы «Космоста булмасак та...» исемле хикәясен язып утырганда, кинәт аның йөрәге тибүдән туктады.

Ни гаҗәп, кичтән әллә сизенде инде... шулай тыныч кына сөйләшеп утырганда (күңеле көр, кәефе дә әйбәт шикелле иде): «Апакаем, (шулай әйтергә ярата иде) бу дөньяда минем өч теләгем бар: беренчесе—Уфада, чит туфракта ятып калмасам иде. Туган авылыма, әнием янына кайтыр идем. Икенчесе—«Хәтер аланы»ның китап булып чыгуын бик тә күрәсем килә. Өченчесе—китабымны мөмкин кадәр күбрәк кеше укысын иде!»—димәсенме.

Үзен югалткач, аның бу өч теләген миңа ышанып әйтеп калдырган васыяте дип кабул иттем. Беренче теләген үтәү, Уфадан шатланып кайтып кергән якын туганының тиз арада үз өеннән җеназасын алып чыгып китү коточкыч авыр булса да, язучыларның ихлас озатып калулары, яныбызда һәрвакыт туганнарыбызның булуы, Арчадан район житәкчеләренең безгә кушылуы, Мөрәлегә килеп житкәч, авыл халкының, мәктәп балалары һәм укытучыларның каршы алулары, ниһаять, Тәбризнең зур хөрмәт белән якыннары янында гүргә иңдерелүе—үкенечләребезне аз булса да жиңеләйткәндәй булды... Икенче теләген тормышка ашыру өчен тугыз ел вакыт кирәк булды. 1993 елны китап нәшриятына тапшырылган кульязмасының икенче нөсхәсен Уфадан алып кайтып, аны булачак китапның макетына әйләндерү эшл-

ərен үз өстемə алдым. Үлеме артыннан ук Т. Мөбарəковны Язучылар берлегенə кабул итəр өчен кабул итү комиссиясе рəисе Ш. Галиев, проза остаханəсе житəкчесе Г. Ахунов, аларга кушылып Ф. Яруллин, А. Гыйлəжев, Ə. Еникилəр бөтен көчлəрен куйдылар. Барлык кирəкле документларны туплап проза остаханəсенə тапшыруны мина йөклəделəр. Шулай итеп, 1997 елны Т. Мөбарəков, үлеменнəн сон (бердəнбер очрак) Язучылар берлегенə, бер каршылыксыз кабул ителде. Ниhаять, 2005 елны икенче телəге дə тормышка ашты. Гəрчə, автор үзе həм мин телəгəнчə үк булмаса да, китабы да дөнья күрде. Ни өчендер китапка минем кереш сүзем кертелмəгəн. Авторның туган авылы күрсəтелмəгəн. Инде 9 ел элек мəрхүм булуы турында мəгълүмат бирелмəгəн. Жəмəгатьчелек тарафыннан танылган гажəеп талантлы авторның беренче вə соңгы китабы бит югыйсə... Шунысы куанычлы, авторның өченче телəге дə тормышка ашты. Китап нəшриятында укылмыйча тузан жыеп яткан бер генə китабы да калмаган.



*Тəбриз Мөбарəков якын туганнары белəн. 1988 ел.*

Ни аяныч, Т. Мөбарəков үзенең зур ижат планнарын тормышка ашыра алмыйча арабыздан китеп барды. Ана быел 75 яшь тулган булыр иде. Шул уңайдан мин аның турында күренекле əдиплəребезнең фикерлəрен həм «Гөл əби» исемле хикəясен «Казан утлары» укучыларына тəкъдим итəргə булдым.

**Гөлчəчəк ГАЛИЕВА**

*«Аның теле гажəеп матур, сыгылмалы, стиле əллə нинди сүз осталарын да көнлəштерерлек, жөмлəлəр төзек, жыйнак. Əсəр башыннан ахырына кадəр зур кызыксыну белəн укыла. Мин «Хəтер аланы» романының (мин аны роман дип кабул иттем) укучы кулына китап булып керүен телəр идем».*

***Əмирхан Еники***

*«XX гасыр тəмамланып килгəндə татарча уйлый торган язучы килде. Ул татар дөньясын яхшы белə. Чуар дөнья бөтен каршылыклары белəн аның тынгысыз күңеленə сыя. Əдəби теле бай, уй-фикерлəре камил. Тетрəнлерде мине бу əсəр. Туктама, Тəбриз, яз!».*

***Аяз Гыйлəжев***

*«Хəтер аланы» мине тау елгасы кебек үз чөгермəклəренə алып кереп китə həм зур елга-дəрья тамагына китереп чыгара. Мин аны бер йотым су кебек эчəм həм тагын эчəсем килə... Дөресен əйтим, соңгы 30-40 елда мин хəзерге татар əдəбиятында телне, стильне, вəзен-ритмны бу кадəр нечкə тойган чəчмə əсəр язучыны күргəн булмады. Əлбəттə, мондый тирəн тоюда ясалмалык, көчəнүнен кəтрəсен дə күрмисең. Ана бу, беренчедəн Ходай тарафыннан бирелсə, икенчедəн, авторның тормышны искиткеч тирəн белүе нəтиҗəсе... Шулай үтемле, үткер həм тормыш талəп иткəн бердəнбер тел белəн язылган əсəр бу».*

***Айдар Халим***

*«Быел безнең әдәбиятка чишмә кебек бәреп бер яңа исем килеп керде—Тәбриз Мөбарәков. Бу кеше мона кадәр кайда булды икән? Тетрәндергеч «Хәтер аланы»н үзе повесть-кыйсса дип язса да, мин аны роман дип кабул иттем.»*

***Фәнис Яруллин***

*«Тәбриз Мөбарәковның әдәбиятка килү юлы да ифрат үзенчәлекле дә, гыйбрәтле дә. Гаҗәп хәл: гомере буе югары уку йортларында рус телендә төгәл фәннәр укыткан һәм зур фәнни хезмәтләр язган галимнең күңелендә, ком-таш эчендәге алтын кисәге шикелле, саф туган телебез стихиясендә кристаллашкан олуг хәзинә—зур әдәби талант яткан. Шунысы кызганыч—бу хәзинә галим-әдип гомеренең соңгы елларында гына халыкка ачыла алды... Тормыш чынлыгы ягыннан булсын, тел җәһәтеннән булчын, әсәр гаять үзенчәлекле, һәм ул хаклы рәвештә җәмәгатьчелек тарафыннан үзенә лаеклы олуг бәһане алды да. Соңрак журналыбызда басылган, дусты М. Мәһдиев турындагы истәлекләре дә укучылар тарафыннан шулай ук бик җылы кабул ителде».*

***Равил Фәйзуллин***

---

Тәбриз
Мөбарәков

# ГӨЛ ӘБИ

ХИКӘЯ

Жиде-сигез йортлы, бер генә яклы Аргыяк урамы көнгә карап аккан инешнең уң ярында, Артышлытау итәгенә сыенып утыра. Ошбу урам фәрештәләр канаты астында: җәен еш кына була торган өермә-давыллардан аны Инеш буенда үскән, ябалдашлары күккә тиеп торган йөзьеллык талтирәкләр саклаcа, кышын котып җилләреннән Артышлытау ышыклап тора.

Җәй көннәрендә Аргыяк яшеллеккә күмелә. Май урталарында, июнь башларында йорт-каралтылар тирәли үскән алма, шомырт агачлары чәчәк ташкынында була. Алардан соң Инешкә таба сузылган бәрәңге кишәрлекләре, буразналардагы көнбагышлар чәчәккә бөреләнә.

Читән белән уратып алынган, канәфер, балан куакларына чумып утырган Шәрифелҗамал түти йорты Аргыяк урамның уртабер җирендә. Тәрәзәләрендәге шау яраннары, ишек алды тулы бакча гөлләре белән бу йорт чәчәкләр әрҗәсен хәтерләтә. Хуҗабикәнең гөлләргә хирыслыгы бөтен авылга билгеле. Ала яздан кара көзгәчә куш йодрык кадәрле чәчәк аткан ал, кызыл, ак яраннары бөтен авылда, хәтта тирә-юньдә дан тота.

Шәрифелҗамал карчык гөлләрен үзе генә инанган ырым белән үстерә: аларны Кипкәнкүл инкүеннән алган балчыкка утырта, сибәр суын таң тишегеннән

торып, Инешнен ана гына мәгълүм булган тугаеннан китереп куя. Кояш жылысында бер тәүлек жылынгач кына, һәр чүмеч суына авыз эченнән ниндидер әфсен укып, каз канаты очыннан гөл төбенә саркыта: «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим!.. Шифалы су булсын, дәү үс, мул, матур чәчәкле бул!..»

Әбидән гөл сорап килүчеләр өзелеп тормый. Аларга дигән гөлләрен ул карты ясап калдырган эреле-ваклы тырысларга күчереп куя, ин матур чәчәк ата торган яраннарының яшәргә, үсәргә ашкынып торган бәбәкләрен генә сайлап утырта. Шәрифелжамал түти гөлләрен бигрәк тә яшь киленнәргә өләшергә ярата. Чәчәкләр сөйгән кеше йомшак бәгырьле, киң күңелле, сизгер жанлы була торгандыр шул. Гөл үсентеләрен биреп чыгарганда, яшь киленчәкләргә үзенең изге теләкләрен дә әйтми калмас: «Яна нигездә яран гөлдәй тирән тамыр жәй, гөлең дә, үзең дә пардан бөреләнеп жибәрегез, тигез яшәгез, тормышыгыз шау чәчәктә булсын!..»

Авыл кешеләре киң күңелле, тәмле телле Шәрифелжамал түтине яратып, Гөл әби, Чәчкә әби дип йөртәләр. Менә шушы мөхтәрәмә карчык бер көздә үләргә жыенды. Үзенең данлыклы яраннарын кышларга идән астына гына төшермичә, үз аягы-кулы белән күрше-күләнгә, дус карчыкларына өләшеп чыкты,—төсем булып калсыннар, кешеләрнең күңелен яктыртып, гөрләп чәчәк атып утырсыннар...

Гөлләр белән мәшәкатен бетергәч, карчык үлемтекләрен барлап-хәстәрләп куйды, ахирәте Хәернисаны чакырып, ана үзенең васыятен әйтте. Мәетемне Гыйльмениса абыстай юсын, анын кулы жылы, йомшак; тастар башын канкүршем Минлениса тотар... Узган ел гына бәйләткән мамык шәлемне килендәшем Шәмсекамәр бөркәнсен... Чәмчәле читегемне Күпер төбе Гайникамалга багышлыйм. И-и, гомерләр диген!.. Без анын белән бер авыл кызлары бит, Мираска да килен булып бер үк жәйдә, бер үк жыенда төшкәниек... Плүш бишмәтемне үзең киеп йөрерсен, әни мәрхүмәдән калган тәсбихымны да син тартырсын...

—Һай, ахирәткәем, юкка гына тәшвишләнмисен микән, ашыкмыйк әле бу якты дөньядан китәргә, бер киткәч, аннан кире кайту әмәлләре юк ласа, тиктомалга түгелме бу әсәрләнүләрен, хәстәр-гамәлләрен?!—ди Хәерниса кортка.

—Юк, юк, Хәерниса ахирәтем, гәүдәләрем дә бик авырайды бит, жаным да жегәрсезләнде. Күңелем дә бик сүрән бу көздә, сизәм, сизәм—Алла хозурына барыр вакыт житте мина. Нуруллам янына барып ятырга...

Шәрифелжамал карчыкны тагы моннан өч ел элек үлгән карты Нурулла төшенә кереп йөдәтте: өйләнешкән елларындагы шикелле яшь, чибәр Нурулласы зират очыннан килә дә ишек алдында йорт эшләре белән мәшгуль Шәрифелжамалына читән аркылы сүзсез генә карап тора, имеш. Тора-тора да, нәүмизләнеп, дәшмичә генә янә зиратка таба китеп бара. Чатка житкәч, кулын изәп кенә хәләле белән хушлаша да, күккә ингәндәй, күздән гаип була. Атна саен шулай, жәй буе шулай... Тикмәгә генә йөрми инде анын Нурулласы, тикмәгә генә түгел анын шулай йөрүләре...

Ир белән хатынның туган бер баласы сабый чагыннан ук үлә барды. Изгеләр рухына нәзер-ниаз кыла торгач, бер Ходайдан ялвара торгач, гомер жәйләре узып барганда гына Хак Тәгалә аларга тагы бер бала бирде. Төпчекләре гомерле булды. Ата-ананың куанычы Нургали терчә малай булып үсте, биш-алты яшеннән әтисе алып биргән гармунда өздереп уйный башлады. Вакыты житкәч, мәктәпкә китте, яхшы гына укып, күрше авылда жиде класс тәмамлады. Укымышлы уллары сәвиттәме, калхуздамы, берәр язу-сызулы урында эшли башлар, кул арасына керер дип өметләнде инде олыгая барган ата-ана. Аннан сон Ходай теләсә...

Нургали укуын тәмамлаган жәйдә аларга кунакка шәһәрдә яшәүче кардәшләре кайтып төште. Кайтты да, гөнаһ шомлыгына каршы, малайның күңелен азындыра башлады:

«Сина, энекәш, ничу авылда мужик булып калырга. Мин синнән гаратскуй егет ясыйм, бер дигән һөнәргә өйрәтәм!—диде сәгать төзәтүче Мансур абзыйсы.— Синең кулларында көрәк, сәнәк түгел, ә менә нинди нәрсәләр булыр!»—Ул жилет кесәсеннән алтын чылбырлы швисәрски алтын сәгать чыгарып күрсәткәч, тәмам тәкате калмады хәерсез малайның.

Нинди ата-ана күз карасы булган баласының теләгенә, аның бәхетенә каршы килер икән! Тәки газизләре Нургали Мансур абзыйсына ияреп шәһәргә китте шул, китте дә шәһәр кешесе булып яши башлады.

Мирасның Нурулла малае инде күптән базар читендәге алачыкта үзбаш, кала кешеләре китергән ватык сәгатьләргә җан кертеп утыра. Авылга да сирәк кенә кайткалады Нургали. Үзе исән вакытта улы янына әтисе баргалап йөрде. И-и, күп итеп күчтәнәчләр биреп җибәрер иде игелекле улы әнисенә, яулык-мазар, кәвеш-каталар дисеңме...

... Инде чынлап торып, урынга ятып авырый башлагач, Шәрифелҗамал түти Минлениса кызы Нурияны чакыртып, каладагы улына хат яздырды. Бердәнбере, йөрәк парәсенә чук-чук сәламнәрен күндергәч, сырхау ана Нургалиенә үзенең соңгы гозерен юллады: «Атаң янына барып ятыр вакытым җитте, балам... Кайтып күзләремне йомдырып китсәң икән...»

Әнисенең хатын алуга Нургали кайтып та җитте! Улы алып кайткан сәйлүн чәен кара яндырып ясап, күчтәнәч әлүн кагы салып, эчеп җибәргәч, әфлисун капкалагач, Ходайның рәхмәте! Әҗәл түшәгендә яткан ана сихәтләнеп китте, аркасын ястыгына терәп утырып тора башлады.

«Кил әле, улым, утыр әле яныма!—диде бер көнне Шәрифелҗамал түти.— Сина әйтер сүзем бар: әллә авылда гына торып каласыңмы, балакаем?.. Йортжиребез дә әйбәт кенә, урыныбыз да бик матур җирдә... Шәһәрдәге һөнәрең авылда да ярап куярые әле... Өйләнеп җибәрерсең, Ходай теләсә...»

Кире авылга әйләнеп кайту фикере Нургалинең үз башына да килгәли иде. Юк, иялнә алмады егет шәһәр тормышына, аның сасы һавасына, кысынкы фатирларына, таш урамнарына. Җәй көннәрендә авылда иртән торып, яланаяк ишек алдына чыгып, чыклы чирәмнәргә басуы үзе ни тора! Кичләрен Инеш буендагы таллыкта исәрләнеп сайраган сандугачлар, яшенләп-күкрәп явып узган җылы яңгырдан соң бер башы Инешкә, бер башы урман артына төшкән салават күпере! Шәһәр җирендә боларның берсе дә юк бит! Аннан соң, һәм иң мөһиме— бер ялгызы гына яшәп яткан, инде көчен-кодрәтен җуя барган карт ана көтә... Барсын да уйлады Нургали хаста янында утырганда.

—Кайтам синең яныңа, бөтенләйгә кайтам, әни!—диде Нургали.—Тик бер шарт белән: син иртәгә үк тереләсең, урыныңнан торып йөгереп йөри башлыйсың, бүтәнчә авыруның нәрсә икәнен дә белмичә, әле тагы егерме биш-утыз ел яшисең, килештекме?!

—Һай, рәхмәт, балам, килештек, бик килештек... Иртәгә үк терелəм, урынымнан торам, Алла боерса...

Улының бу өметле сүзләрен ишеткәч, авыру карчыкның чырае ачылып китте, авызына тәм керде:

—Самавыр куеп җибәр әле, балам, тагын әлүн кагы салып чәй эчик әле икәүләп, тәмләп кенә...

Гөләбинең хәл-әхвәлен белешеп торган хатын-кыз кавеме, Нургалинең бөтенләйгә әнисе янына кайтасын ишеткәч, карчык өчен бик куанды: «И-и, үз балаң үз балаң шул инде!..»

Шәһәр белән тиз генә алыш-бирешен өзеп, андагы бөтен житиясен, бер әрҗә коралларын күтәреп, сәгать төзәтүче Нургали янә туган йортының бусагасын атлап керде.

Улы кайтып яши башлагач, Шәрифелҗамал түти күзгә күренеп савыкты, урыныннан торып, акрын гына кыймылдап йөри башлады.

Эшлекле Нургали икенче көнне үк кулына балта-пычкы, чүкеч алып, күптән ир-ат кулы тимәгән йорт-жир, каралты-куранын авыш-түеш урыннарын төзәтергә керешге, киртә-казыкларны рәтләде, түбәгә менеп, моржа башын акшарлап төште.

Рәхмәтле ана чәй янында тагы улынын башлы-күзле булуы турында сүз кузгатты:

—Хәзер инде, балам, өйләнәсеҥ генә калды...

Әйе, сазая барган Нургалигә өйләнергә бик вакыт инде, әмма егетнен бер моны бар: әллә куәс төбе балага камыр житенкерәмәде, әллә бүтән сәбәпләр булды инде,—буйга чыкмады ул. Авылга кайтып, бераз кызлар тирәсендә чуалгач, сәгать төзәтүче егет үзе белән бергә мәктәптә укыган, буе белән дә кулайрак булган Тәслимәгә сүз кушып караган иде—кая ул! Колхоз кәнсәләрендә чут тартып утыручы кыз борынын чөйгә элде! Шәһәрдә яшәп кайткан егет тәбәнәк булса да дәрәжәсен югары тотты, Тәслимә тирәсендә бүтән буталып йөрмәде, әмма үз авылы кызларына өйләнмәскә ант итте—тәбәнәк ир заты гарьчән була.

Бер көнне ахирәтенен хәлен белергә Хәерниса карчык килеп керде. Ул узган атнада гына туган авылы Масрада кунакта булып кайткан икән. Хәерниса Шәрифелжамал ахирәтенен улына шуннан кыз димләде. Үтерепләр дә мактады инде кызны: үзе яшь, үзе чибәр, буйга-сынга да жыйнак кына, эшкә дә бик уңган, һөнәре дә менә дигән—әртиллә тегү тегә, чигү чигә...

Ниндидер бер сәбәп табып, Нургали Масрадагы кардәшләренә чыгып китте. Атна да узмагандыр, кулына кечкенә генә төенчек тоткан уналты-унжиде яшьлек кыз баланы ияртеп кайтып та керде егет....

Шәрифелжамал түти килене булачак баланы беренче көнендә үк ошатты, аны үз итеп, яратып «кызым» дип дәшә торган булды. Килене Санияга да кайнанасы «әни» булды. Сабый чагыннан үк ятим калган, балалар йортында үскән кызга «әни» сүзе тансык һәм изге иде.

Кайнана киленен йомшак тел белән ипләп кенә йорт эшләренә өйрәтте. Тумыштан черкәм, игелекле Сания да кайнанасы өчен үлеп торды—өрмәгән жиргә утыртмады. Комганында һәрчак жылы су торды, инендәге тастымалы пакь, ятар урыны йомшак булды Шәрифелжамал түтинен.

Сания матур итеп тел очы белән генә сөйләшә иде. Кәнсәләрдә утырган Тәслимә авылда: «Нургалинен хатыны сакау икән»,—дип гайбәт тараткан. Нишләп сакау булсын ул?! Кошлар теле, сандугач теле белән сөйләшә Шәрифелжамалнын килене!..

Нургалигә төзәтергә стена, кул, кесә сәгатьләре китерә башладылар. Көзге, кышкы озын кичләрдә гаилә әгъзалары үзләренә муафикъ эш белән мәшгуль була. Ян өстәлгә коралларын таратып салып, Нургали нәүбәттәге ватык сәгать эчендә казына башлый. Ястү намазын укыгач, Шәрифелжамал түти мич артыннан кабасын алып йон эрләргә керешә—улына, килененә бәрән йоныннан гына оекбашлар бәйләп бирер, Алла боерса. Өйдәге вак-төяк эшләрен бетергәч, Сания да ире каршына килеп утыра һәм, карап торырга менә дигән сәгатьне пыр туздырып сүтеп ташлаганын күреп, хафалана башлый: «И холаем, кире жыя алырмы икән?..»

Эшләгәндә Нургали бик житди, аз сүзле була. Күзенә монокль кыстырып, нәп-нәзек эскәкләр белән сәгать эчен актарып утырган ире бу минутларда Саниясына буй житмәслек югары, әллә нинди могжизаларга, тылсымнарга сәләтле кеше булып күренә.

—Бу нәмәстәкәй нәрсә була инде?—дип сораган була Сания, чынлап та әлеге кеше—Жир кешесе, анын ире икәненә ышанасы килә яшь хатынның.

—Шестеренка,—дип жаваплый тегесе, башын күтәрмичә генә.

—Ә бусы?

—Рычажок...

—Ә менә хәзер генә эскәгенә эләктергәне? Анысы ничек атала?

—Келтрифүн, келтрифүн дип атала!—ди сабырлыгын җуя башлаган Нургали.

—Ә бусы?

—Анысы да келтрифүн!..

—Келтрифүн, келтрифүн... Барысы да келтрифүн булмас инде...—Сания үпкәләп, авызын турсайта.

Нургали шаркылдап көлеп җибәрә, өстәл артыннан чыгып хатынының иңнәреннән кочып ала:

—Их син, минем келтрифүнем!..

Бәхетле Сания да көлә, каба төбендә утырган әниләре дә елмаеп куя...

Сүткән сәгатен җыеп, борып җибәргәч, Нургали аны хатынының колагына куеп тыңлата.

—Йөри! Келт-келт итә, йөри!—ди Сания, шатланып кулларын чәбәкәйли.— Йөри!..

Нургали коралларын җыеп әрҗәгә салгач, шкаф башында торган гармунын ала:

—Эш беткәч уйнарга ярый, дигән Тукай абый. Йә, әни, бүген дә концертыбызны син яраткан җырдан башлыйбызмы?—Урындыгын идән уртасына куеп утырып, яшь хуҗа гармунын сузып җибәрә. Аның уң ягына баскан Сания артистларча кулларын күкрәгенә кушырып, җыр башлый:

> Сәмдәлләрдә генә утлар яна, Гөлзамал,
> Зиткән кызлар киндер зеп эрлиләр...

Йомшак күнелле кайнана балавыз сыга: Һай балакаем, бигрәк тә майлы инде тавышың, бигрәк тә үзәкне өзәсең инде, кызым...

Шулай тату, күркәм генә яшәп, көз, кыш узып китте. Җылы, матур яз килде. Табигатьтәге янару шаукымы узган көздә үк фани дөнья белән хушлашырга җыенган Шәрифелҗамал карчыкны да читләтеп үтмәде, гөлләре яшәргән чакта ул да яшәреп китте, сүрелә башлаган күзләрендә янә тормыш, яшәү гаме уянды.

Менә Май бәйрәме дә килеп җитте. Нургали белән Сания, ике-өч көнгә генә, Масрага кунакка киттеләр.

Үзе генә калгач, Шәрифелҗамал түти иң беренче чиратта күршеләренә тараткан яраннарын җыеп алып кайтып, тәрәзә төпләренә тезде. «Һай, Алла! Ничек ямьләнеп китте өй эчләре! «Син нишләп бик кәй күренәсең әле? Салкын җирдә кышлаттылармы әллә?—ди Гөләби, Мөхлисә карчыктан алып чыккан яранына.—Мин синең балчыгыңны алыштырырмын, бәлки сихәтләнеп китәрсең».

Әби чиләк-коянтәләп Инештән су алып кайтып кояш яктысына куйды. Җылына торсыннар...

—Өзлегә күрмә, Гөләби!—ди Минлениса, көне буе ишек алдында чуалган карчыкка.—Өзлегә күрмә!

—Иншалла, өзлекмәм, рәхмәт гамең өчен, күршекәем!

Өзлекмәс, өзлекмәс Алла боерса!.. Хәер, өзлексә дә, өзелеп китсә дә, әлхәмделиллаһи, шөкер, кызганырга кызы бар, күзен йомдырырга улы янында... Инде ашыйсын ашаган, яшисен яшәгән, дигән шикелле... Шулай да бер дә китәсе килми шул бу якты дөньядан, бер дә китәсе килми!.. Ирештем дигәч кенә ишеләсе, життем дигәч кенә җимереләсе килми шу-ул!..

Икенче көнне дә Шәрифелҗамал түти яраннары белән мәш килде: кәй күренгәннәрен яңа туфракка күчерде, кайберләренең зәгыйфь тармакларын күтәрде, кичке якта мул итеп су сипте. Сөбханалла! Әнә ничек дәррәү, барысы да бертигез булып чәчәккә бөреләнгәннәр! Шатлык өстенә шатлык—аның Сания-

се дә бик матур гына түгәрәкләнеп килә, исән-саулар гына булсыннар, яман күздән Ходай сакласын!

Кайнана туачак оныгына инде исем дә табып куйды: Алла биреп, исән-сау гына кыз бала туса—исеме Галимәбану булыр. Бигрәк тә ошый инде ана шушы исем! Соңгы мәртәбә авырга узгач: «Кызым булса—исемен Галимәбану куярмын»,—дип аларынган иде Шәрифелжамал, әмма Нургалиен китерде. Әгәр Саниясе малай тапса, аты Нуриәхмәт булыр, бөтен нәселләре белән нурлы булсыннар, амин!..

Балалары кайтасы көнне дә әни карчык көнозын аяк өстендә булды: бер табак кер чайкап элде, комлап өй, өйалды идәннәрен, чолан баскычларын сары гәрәбә төсле итеп юып чыгарды, самавырын агартып кояшка куйды. Майтарган эшләреннән бик канәгать калды карчык. Аллага мең шөкер, арыды-аруын, әмма күнелендә торганнарны башкарып чыкты. Кара эшләрен бетергән генә иде, аны Минлениса үзе янына мунчага чакырып керде.

Шәрифелжамал түти бүген көне буе күнел төбендә ниндидер җан шатлыгы тоеп йөргән иде. Көтмәгәндә генә ул моның сәбәбен аңышты—оланнары кунактан кайтачак бит бүген, шуна аның күнеле җилкенә! Мунчадан соң бөтен тәне, барча әгъзалары мәлҗерәп китсә дә, улы белән киленe кайтышка төче коймак пешереп куярмын дип, коштабакта камыр тугларга, аннан соң самавырын чыжлатып җибәрергә дә хәле житте әле карчыкның.

Икенде вакыты җитеп килә икән. Шәрифелжамал түти пакь тәненә Саниясе тегеп биргән, әле бер дә киелмәгән чуар бизәкле күлмәген киде, башына чытыр ак яулык бәйләде дә, сәкегә яшел постау намазлыгын җәеп, намазына басты: «Әгүүзе-билләәһи-минәш-шәйтаанир-ражиим... бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим!..» Әбинең башы әйләнеп, күз аллары караңгыланып китте. Инде ул намазын тезләнеп кенә укый башлады: «Ходай кабул итәр әле, хәлемә керер, иншалла...»

Әбинең күзе ян тәрәзәгә төште. Анда, еракта-еракта,офыкта, юлсыз-нисез яшел уҗым басуы өстеннән, җитәкләшеп аның Нургалие белән Саниясе кайтып килә иде. «Нишләп соң алар ул яктан кайталар? Масра бөтенләй икенче унайда лабаса?..» Икенче мәртәбә караганда аның балакайлары инде юкка чыкканнар иде. Гөләби әсәрләнде: «Тәүбә, әстәгъфирулла, саташа башладым, ахрысы... Әгүүзе-билләәһи-минәш-шәйтаанир-ражиим, тьфу, тьфу!..»

Чуалган намазының рәтенә чыгып, Шәрифелжамал түти беренче сәҗдәсенә бөгелде. Менә хикмәт—аның колакларына Саниясенең саңгырау гына җырлаган авазы ишетелде: «Сәмдәлләрдә генә утлар яна, Гөлзамал...» Әби тагы самавыр капкачы ләпелдәгәнен ишетте: «Самаварым да кайнап чыкты бугай... Дөньяви үй намаз бозар, дигән... И Ходаем, ярлыка инде бу гөнаһлы бәндәңне!..» Хәлсезләнгән, инде тәмам бутала башлаган карчык намаз укуын аңышмыйча гына дәвам итте вә янә сәҗдәгә иелде. Бу юлы аның колагына Минлениса тавышы килде: «Өзлегә күрмә, Гөләби!..» Аннары ул Нургалие белән Саниясенең: «Әни, җаным, үлмә! Тагы бер генә ел тор, тагы бер генә ай яшә, әни, бәгырем!»—дип өзгәләнеп елаганнарын ишеткәндәй булды... һәм... сәҗдәгә түңкәйгән изге җан, ике учын намазлыгына, яшькә чыланган йөзкәен кул аркаларына куеп, чәчәккә кунган күбәләккә охшап, тынып калды...

Икенче көнне төштән соң, авылның могтәбәр картлары Гөләбине иннәренә күтәреп, йөз адым саен тәкъбир әйтеп, Нурулласы янына илтеп куйдылар...

# 2006 ЕЛ НӘТИҖӘЛӘРЕ

*Инде күп еллар элек урнашкан матур традициягә дәвам итеп Татарстан язучылары үткән әдәби ел йомгакларына багышланган гомуми җыелышларын уздырдылар. Журналыбызның бу санында укучыларга анда тыңланган докладларны бераз кыскартылган рәвештә тәкъдим итәбез.*

**Илфак ИБРАҺИМОВ,**
*Татарстан Язучылар берлеге рәисе*

## ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЕЛЫ



Узган елның республикабыз тормышында никадәр әһәмиятле булуын, ә иҗат оешмалары һәм аерым иҗат әһелләре өчен икеләтә әһәмиятле булуын без барыбыз да аңлыйбыз.

Республикабызда узган әдәбият һәм сәнгать елы—әдәби, мәдәни чараларның кайчандагыга караганда да күп оештырылуы белән тарихка кереп калачак. Габдулла Тукайның тууына 120, Муса Җәлилнең тууына 100 ел тулу, башка күренекле шәхесләребезнең төрледән-төрле истәлекле көннәренә мөнәсәбәтле дистәләрчә, йөзләрчә чаралар ел дәвамында Татарстанда, Мәскәүдә, С.-Петербургта, Россиянең бик күп төбәкләрендә, чит илләрдә үткәрелде. Халкыбызны тагын да берләштерү, аның милли үзаңын үстерүгә әйтеп бетергесез тәэсирле йогынты ясалды...

Бу чараларны үткәрүдә Татарстан хөкүмәте, Мәдәният министрлыгы белән бергә киң җәмәгатьчелек, шул исәптән Татарстан Язучылар берлеге, башка иҗат берлекләре дә актив катнаштылар.

Узган елда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе Пермь өлкәсендә, аның 7 районында һәм шәһәрендә, Татарстан республикасының 8 районында Татар әдәбияты көннәрен үткәрде.

Моннан тыш, язучыларыбыз җәйге чорда авыл хезмәтчәннәре белән очрашу өчен 12 районга чыктылар. Көз көне Республикада балалар әдәбияты айлыгы үткәрелеп, әдипләребез тагын 6 районда мәктәп балалары белән очрашты.

Әдәбият һәм сәнгать елы—зур иҗади ел булды. Язучыларыбыз, шагыйрьләребез, галимнәребезнең әсәрләре нәшриятларда йөздән артык китап булып басылып чыкты... Әдәби басмаларда гына түгел, ә республикабызда һәм республикабыздан читтә дә, газета-журналларда каләмдәшләребезнең әдәби-публицистик әсәрләре еш дөнья күрде.

Әдәбият һәм сәнгать елында "Йосыф" балетын сәхнәләштергән композитор Леонид Любовский, биюче Нурлан Канетов, шагыйрь Ренат Харис Россиянең Дәүләт премиясенә, язучыларыбыз, шагыйрьләребез: Рабит Батулла, Равил Бохараев, Марсель Галиев, Рафаэль Мостафиннар Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләренә, шагыйрьләребез Газинур Морат һәм Ләбиб Лерон Республиканың Муса Җәлил исемендәге премияләренә лаек булдылар. Дистәдән артык каләмдәшебез Язучылар берлегенең әдәби премияләре белән бүләкләнде. Балалар

язучысы Рафаэль Газизов Халыкара Андерсен исемендәге дипломга лаек булды.

Әдәбият һәм сәнгать елында телевидение, радио, барлык массакүләм матбугат чараларында әдәбиятыбыз, сәнгатебезне пропагандалау буенча эшләр башкарылды. Ниһаять «Яна гасыр» телевидениесендә айга бер мәртәбә чыга торган "Әдәбият дөньясында" исемле даими рубрика булдырылды. Бер сүз белән әйткәндә, Әдәбият һәм сәнгать елы, ул безнең иҗат берлегенең һәм иҗади, һәм социаль-иҗтимагый активлыгын сизелерлек арттырды.

Әмма шунысы да бәхәссез: әдәбиятыбыз һәм сәнгатебез—аның сакланышы, үсеше мәсьәләләрен хәл итү ул бер ел кысаларына гына сыеша алмый... Һәм без бергәләп үткәргән, хезмәт куйган әдәбият һәм сәнгать елы бәйрәмнәр елы гына түгел, ә киләчәк өчен житди уйланулар, эзләнүләр елы да булды... Узган елда дистәләрчә мәдәни чараларны уздырганда, әдәби-мәдәни мирасыбызны барлаганда, Ана телебезне саклап калу һәм үстерү—гомумән, халкыбызның милли йөзен саклап калу һәм туар буыннарга лаеклы тапшыру өчен, һәрбарчабызның үтә дә җаваплы икәнлегебезне тагын да ныграк тойдык...

"Казан утлары" журналында басылып чыккан Республика Президенты М.Ш. Шәймиев белән әңгәмә дә, безнең уйлавыбызча, нәкъ шундый җаваплылыкка нигезләнгән иде... Әлеге күләмле язманы, без һичшиксез, бүгенге көндә Республикабызның рухи потенциалын көчәйтүдә Дәүләт һәм иҗади җәмгатьчелек мөнәсәбәтләренең, хезмәттәшлегенең яңа формаларын, ысулларын билгеләүгә омтылыш дип кабул иттек. Илбашы безне, Әдәбият һәм сәнгать елында ук, дистә елларга алга карап әдәбиятыбыз һәм сәнгатебезне саклап калу һәм үстерү, дөньякүләм әдәби-мәдәни мохитка ныклап үз урынын таба алырлык дәрәҗәгә ирешүне максат иткән Программа төзүгә ачыктан-ачык чакыра лабаса! Бу Программа Дәүләтнең сәяси-икътисади мөмкинлекләренә генә түгел, ә чын мәгънәсендә Алтын хәзинә булган Милли интеллектуаль һәм иҗади потенциалыбызны активлаштыру, күркәм традицияләребезне яңарту һәм киң куллануга нигезләнергә тиеш...

Язучылар берлеге идарәсе шундый Программа төзүне кичектергесез рәвештә кирәк дип саный һәм аны төзүдә без турыдан-туры катнашырга әзер булуыбызны белдерәбез.

Хөрмәтле каләмдәшләр!

Узган елның әдәби иҗат буенча төп йомгаклары турында махсус докладлар әзерләнүен һәм Сезнең кулларга таратылуын искә алып, мин үз чыгышымны берничә мөһим проблемага һәм аларны хәл итү чараларына багышларга уйлыйм.

Беренчесе: ул—яшь әдәбиятчылар тәрбияләү.

Әдәбият һәм сәнгать—ул, ниндидер катып калган статистик халәт түгел, ә җанлы, хәрәкәттәге, табигый үсештәге процесс... Әдәбиятта һәм сәнгатьтә буыннар алмашы да чор-дәверләргә, җәмгыятьтәге иҗтимагый мөнәсәбәтләргә бәйле хәлдә табигый рәвештә булып тора... Әдәбиятыбызга Тукай, Әмирхан, Исхакый, Галимҗан Ибраһимовлардан соң, Такташ, Җәлил, Кутуй, Туфаннар, Исәнбәтләр килгән...

Еникилар, Бәшировлар, Сибгат Хәкимнәрдән соң, Юзеевлар, Гыйләҗевлар, Ахуновлар, Мәһдиевләр...

Инде Фәйзуллиннар, Әгъләмнәр, Ркаил Зәйдуллалардан соң исемле буыннар булмасмы?—дигән шик-шөбһәләр урынсыз түгел иде... Соңгы 15-20 елдагы буталчыклардан соң, шөкер, әдәбиятыбыз мәйданына талантлы, өметле яшьләрнең өр-яңа буыны чыгып килә... Дистәгә якын яшь шагыйрьләребез, прозаикларыбыз: Гөлнур Корбанова, Марат Кәбиров, Ленар Шәех, Гөлнара Җәлилова, Айдар Җамалиев, Лилия Гыйбадуллина, Йолдыз Миннуллина, Рифат Сәлахов, Илгиз Зәйниев, Алина Бикмуллина һәм башкалар "Иделем акчарлагы" буенча чыныгуларын алып, әдәби басмаларда беренче камил әсәрләрен бастырып, Язучылар берлегенең секцияләре утырышларында беренче имтиханнарын тотып, һәм, ниһаять, Татарстан китап нәшриятында һәм "Мәгариф" нәшриятында үзләренең беренче китапларын бастырып чыгардылар, драма әсәрләрен Республикабызның театрларында сәхнәләштерделәр.

Әдәбият-сәнгать елында Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең "Татнефть" ачык акционерлык җәмгыяте белән берлектә гамәлгә куйган Сажидә Сөләйманова исемендәге стипендияләрне иң беренче чиратта аларга билгеләвебез һәм ниһаять

24 яшьлек Ленар Шәехне Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алуыбыз бу яшьләргә ышаныч күрсәтүебез һәм жаваплылык йөкләвебез булып тора. 2008 елның маена кадәр, ягъни, XVI съездга кадәр алар безнең иҗат оешмасының лаеклы әгъзалары булыр,—диган өметтә калабыз.

Әмма, яшь әдәбиятчылар тәрбияләү дигән җөмләдән без яшь язучылар, шагыйрьләр, драматургларны гына күздә тотмыйбыз, ә тирән профессиональ белемле—текстологларны, рус теленнән һәм рус теленә тәрҗемәчеләрне, татар-рус-инглиз теленә тәрҗемәчеләрне, әдәбият һәм сәнгатьнең аерым жанрлары һәм төрләре буенча белгечләр әзерләүне дә күздә тотабыз... Бүген нәшриятларда һәм әдәби басмаларда бердәм кабул ителгән сүзлекләр җитешми... Заман, әдәби хезмәткәр—әдәбиятчы дигән профессия кешесен—иҗат кешесен әзерләү—Дәүләти югарылыкта хәл итүне көтә.

Бүгенге көндә Татарстан Язучылар берлегендәге 321 каләм иясенең 52%ы пенсия яшендә булуы һәм 30 яшьтән 50 яшькә кадәрге язучыларның нибары 23% ны тәшкил итүе безне уйландырырга тиеш... Без бу мәсьәләне шушы елның 16 январендә Республикабыз Президенты М. Ш. Шәймиев белән очрашканда да күтәрдек. Яшь әдәбиятчыларны әзерләүдә агымдагы елда ук Казан дәүләт университеты яки Татар дәүләт гуманитар педагогия университетының татар теле һәм әдәбияты факультетында 10-15 кешелек махсус язучылар әзерләү бүлеген ачуны тәкъдим иттек. Моның өчен бөтен мөмкинлекләр: кадрларыбыз—галимнәребез, талантлы язучыларыбыз бар...

Бүгенге көндә Республикабыз әдәбиятының төп терәк-таянычлары булган, яшьләре 60 тан узган язучыларыбыз, кайчандыр Мәскәүдә, М. Горький исемендәге әдәбият институтында, яки югары әдәби курсларда белем алганнар иде... Әйтергә кирәк, төпле белем һәм тәҗрибә!.. Хәзер дә андый курслар эшли, ләкин алар түләүле. Берьеллык курсларда уку мең ярым евро тора... Башкортстан һәм Чувашстан Республикалары хөкүмәтләре үзләренең таланты яшьләрен анда укыталар. Безгә дә быел ук бу мөмкинлекне табу зарур...

Мин, яшь язучыларның профессиональ әзерлегенә кагылышлы мәсьәләгә генә туктадым... Ә иҗат берлегендә аларны даими барлап тору, һәр яшь иҗатчыга остазлык итү, республикабыздагы әдәби берләшмәләр белән эшләүгә әлегәчә игътибарыбыз җитми. Мин бу максатта бигрәк тә Язучылар берлегенең Яр Чаллы һәм Әлмәт бүлекчәләрендә эшне активлаштыруны сорар идем...

Яшь язучыларның беренче китапларын бастырып чыгару, әдәби басмаларда аларга мәйдан бирү буенча соңгы 2 елда сизелерлек алгарыш булды. Киләчәктә Татарстан Язучылар берлеге идарәсе һәм Татарстан китап нәшрияты, "Мәгариф" нәшрияты, "Рухият", Янарыш фонды нәшриятларының килешенгән бердәм планнарын төзү кирәк булачак.

Икенче төп мәсьәлә. Ул—язучы хезмәтенең рухи яшәешебездәге урыны... Ягъни китапларыбызның язмышы мәсьәләсе... Әйткәнебезчә, без әдәбият һәм сәнгать елында, күзен республикабыз авылларында булып, анда игенчеләребезнең көн-төн эшләп мул ашлык җыйнап алуын, тулы ындыр табакларын, тулы амбарларны күреп куандык... Сонрак, шул икмәкләрнең илдә бик очсыз торуын, сатылмыйча амбарларда ятуын ишетеп бик борчылдык. Баксаң, безнең хезмәтебез дә авыл игенчесенеке кебек икән бит... Тирән эстетик эчтәлекле, зәвыклы итеп бастырылган китапларыбыз, дәүләт акчасына бастырылган китапларыбыз, нәшрият складларында—димәк, дәүләт складларында ята... Шул ук вакытта, китапларның сатылмавында дәүләт оешмалары язучыларны гаепли, янәсе китапларны алучы юк... Яки, бүген шәһәр, район, авыл китапханәләрендә, уку йортлары, мәктәп китапханәләрендә матур әдәбият фонды 60-70% тузганлыгын бөтен җитәкчеләр белә... Без узган ел булган Мамадыш, Әлки, Биектау, Арча, Яна Чишмә, Спас, Лаеш, Питрәч, Әгерҗе районнарында моның шулай икәнен инде ничәнче кат күреп кайттык... Бүгенге көндә дә мәктәпләрдә, җыр дәресләрендә балаларга:

*Мин Чапаев абыемны*
*Кинодан күреп белəм,*

—дигән җырлар өйрәтәләр...

Китапларнын язмышында Мәгариф һәм Мәдәният министрлыклары зур роль уйный һәм уйнарга тиеш. Аеруча Мәгариф министрлыгына мөрәҗәгать итәбез. Бүген бер язучынын бер китабы, ин күп дигәндә, 2000 тираж белән чыга. Бер китапханәгә бер китап та туры килми... Министрлыклар дәүләт заказы тәртибендә китапларны бастыру һәм сатып алуга һәрчак алынсалар иде. Ә без һәм безнен депутатларыбыз, бу министрлыкларнын бюджетларын арттыру өчен үзебезнен сүзне ныклап һәм гел әйтеп торырга тиешбез.

Җыйнап әйткәндә—китап уку культурасын тәрбияләү—анын озак елларга исәпләнгән матди һәм башка нигезләрен формалаштыру бүген ин беренче дәрәҗәдәге бурыч булып торадыр. Без Республикабызнын рухи үсешенен Программасын төзибез икән, анда ин беренче урында "Китап уку—чтение" Программасы торырга тиеш.

Өченче мәсьәлә: Ул матур әдәбиятыбызнын, милли сәнгатебезнен бөтен дөнья әдәби пространствосына чыгуы өчен беренче алшарт булган әдәби тәрҗемә мәсьәләсе.

Сегодня актуальным остается проблема литературного перевода. Данный вопрос настолько актуален и проблематичен...

В этом направлении нами уже предприняты первые шаги, и что отрадно, имеются первые результаты. Как вам известно, после XV Съезда писателей была создана секция художественного перевода. Возглавил ее известный поэт-переводчик Сергей Малышев.

За короткое время Сергей Владимирович сумел сплотить вокруг себя около десятка молодых литераторов, занимающихся переводческой деятельностью. За один год им удалось представить прекрасные образцы переводов на русский язык произведении татарских авторов. Это стало возможным еще и потому, что Кабинетом Министров было выделено целевое финансирование в сумме 140 тысяч рублей в рамках Государственной Программы Республики Татарстан по развитию языков.

Кроме того, удалось наладить сотрудничество с Академией поэзии России. Были приглашены специалисты из Москвы во главе с известным поэтом-переводчиком Валентином Устиновым, которые в июле прошлого года в течение недели вели семинар для наших переводчиков. Московские коллеги высоко оценили работу «команды» Сергея Малышева. Работа действительно была проделана большая. Произведения более девяноста татарских прозаиков и поэтов, переведенные на русский язык в объеме 50-ти печатных листов, подготовлены к изданию и приняты Таткнигоиздатом.

Как я уже говорил, это лишь первые шаги. А какова же перспектива? Мы уверены, что перспектива есть.

Во-первых: У нас имеются кадры. В основном, это профессионалы, владеющие двумя государственными языками.

Во-вторых: Наша поэзия, проза и публицистика—достойны эстетических запросов русскоязычных читателей, как в республике, так и за ее пределами.

Однако литературный перевод не может существовать лишь за счет энтузиазма переводчиков. Требуется достойная оплата их деятельности. Необходимо установить определенную квоту по изданию переводной литературы в издательствах республики, включив ее в бюджетное финансирование. При этом нужно предусмотреть включение в штат государственных издательств профессиональных переводчиков.

Перевод татарской литературы на русский язык дает нам большие возможности выхода на читателей всей России через московские литературные издания.

В 2006 году, в связи со 100-летием со дня рождения Мусы Джалиля, нам удалось представить современную татарскую поэзию на страницах «Литературной газеты» в 4-х полосном вкладыше.

В этом году уже достигнута договоренность с журналом «Дружба народов» о выпуске номера журнала, освещающего литературный процесс в Татарстане.

При содействии Кабинета Министров РТ и Министерства культуры РТ, совместно с журналом «Дружба народов», Международным сообществом писательских союзов,

Академией поэзии России в конце апреля планируется провести в Казани «Форум писателей и переводчиков Поволжья в рамках Года русского языка в России» с участием делегаций из Башкортостана, Чувашии, Удмуртии, Мордовии, Марий Эл. На форум приглашены также видные московские литераторы.

Говоря о перспективах переводческой деятельности, стоит сказать, что мы не собираемся ограничиваться лишь переводами с татарского на русский язык. Сегодняшние требования времени таковы, что необходимо развивать переводческую деятельность шире: на английский, турецкий и другие языки. Это естественное движение в направлении дальнейшей популяризации татарской литературы во всем мире.

Но сегодня мы должны прежде всего закрепиться на тех позициях, которые нами уже достигнуты по решению безотлагательных проблем в вопросах организации переводческой деятельности. Уверен, мы сегодня готовы к решению и более сложных задач в этой области.

Четвертый вопрос: Он тоже напрямую связан с социальным статусом писателя в обществе.

Творческий союз—это союз людей труда одной профессии—писательской. И заработную плату, и трудовой стаж, и пенсионное обеспечение—все это писатель имеет за свой писательский труд!

В течение последних пяти лет в стране производилась индексация заработной платы тружеников всех профессий в зависимости от инфляции, но только не писателей!

Последний раз в республике вопрос повышения оплаты писательского труда, т.е. размера гонораров, рассматривался в 2002 году—ровно 5 лет назад. Здесь мы имеем в виду оплату государством профессиональной деятельности писателя—гонорар за изданную книгу.

Разумеется, такое положение дел характерно не только для Татарстана. Неслучайно, на недавней встрече Президента России Владимира Путина с молодыми писателями было выражено недовольство создавшейся ситуацией и выдвинуты предложения по налаживанию отношений: государство—писатель.

Есть некоторые положительные примеры в отдельных субъектах России: Губернатор Орловской области Егор Строев установил ежемесячную стипендию в сумме 5 тысяч рублей 22-м писателям.

В соседнем Башкортостане размеры гонораров за изданные книги превышают татарстанские в 2,5—3 раза.

Справедливости ради нужно сказать, что в прошлом году был наведен порядок по своевременной выплате гонораров в Таткнигоиздате, но в то же время за книги, изданные в 2006-м году сумма не выплаченных гонораров на сегодняшний день составляет 30 %.

Да и гонорары за публикации в журналах и газетах (кроме «Казан утлары») оставляют желать лучшего.

Также довожу до Вас: бюджет СП Башкортостана составляет 6,5 млн. рублей, что в 3 раза больше, чем бюджет нашего Союза. У нас в аппарате работают 18 человек, у них—33 сотрудника.

Мы вынуждены сегодня обратиться за помощью к Правительству, и к Вам, уважаемая Зиля Рахимьяновна, чтобы со всей ответственностью потребовать от агентства «Татмедиа» наладить гарантированную систему оплаты труда писателей за свои публикации в средствах массовой информации и предусмотреть в дальнейшем повышение объема финансирования нашего Союза.

...Социаль статуска кагылышлы пенсия белән тәэмин ителеш турында бер җөмлә сүз. Без бу хакта Президентыбызга да житкердек...

Бүген Татарстан Язучылар берлегендә әгъза булып торган профессиональ язучының "язып яшәгән" еллары Россия законы буенча хезмәт стажы саналмый... Гәрчә, ул гонорарыннан барлык налогларны һәм шул исәптән пенсия фондына тиешле әҗерен салып барса да... Бу мәсьәлә буенча Президентыбыз Дәүләт Советына ачыклык кертү, кирәкле чараларны күрү кирәклеген күрсәтте.

Хөрмәтле каләмдәшләр!

Әдәбият һәм сәнгать елында без үзебезнең иҗат оешмасының социаль паспортын төзедек... Бу язучыларыбызга, мөмкин булганча, адреслы социаль ярдәм күрсәтү максатыннан чыгып эшләнде...

Бүгенге көндә язучыларыбызның яшәү-торак шартларын яхшырту, аларга медицина хезмәтен күрсәтү, өлкәннәребезнең гаиләләрендә әхлакый-психологик мохит мәсьәләләре калкып чыкты:

—49 язучыбыз инвалидлар, аларның 38-е беренче-икенче группа инвалидлары;

—32 язучыбызның торак шартлары иҗат белән шөгыльләнү өчен яраклы түгел;

—26 язучының квартирларына кичекмәстән капиталь ремонт үткәрү кирәк;

—Һәр 5 язучының берсе авыру һәм олы яшьтә булу сәбәпле даими ярдәмгә мохтаж.

Ел дәвамында санап үткән ихтыяжлар һәм мохтаҗлыклар буенча билгеле күләмдә эш башкарылды. 12 язучыбызны больницага урнаштырып дәвалау, 93 язучыга Татарстан Республикасы Президентының мәдәниятне үстерүгә ярдәме фондыннан 154 мең сумлык, Язучылар берлегенең үзенең хәйрия юлы белән торткан акчаларыннан 26 инвалид һәм авыру язучыларыбызга 53 мең сумлык ярдәм күрсәтелде. 39 язучыбыз санаторийда дәваланып, иҗат итте...

Төп хәл итәсе проблема булып, торак-яшәү шартларын яхшырту мәсьәләсе кала... Ел дәвамында язучыларыбыздан Мәдәният министрлыгына, Президентка дистәләрчә тапкыр мөрәҗәгать итүләр булды...

Республикабызда һәм бөтен илдә торак белән тәэмин ителешнең принципиаль яна тәртибе урнашып килә... Һәр граждан үзенең торагын яхшырту мәсьәләсен, турыдан-туры үзенең яшәгән районындагы "Торак агентствосы" белән хәл итә... Торак шартларын көйләү буенча без язучыларыбызны Республика торак фонды агентлыгы белгечләре белән очраштырып, анлатуны да оештырдык. Шуна да карамастан, язучыларыбыз—өлкәннәр генә түгел, хезмәт яшендәгеләр дә—бу мәсьәләдә Язучылар берлеге рәисенә мөрәҗәгать итүне хуп күрәләр.

Өлкән язучыларыбызның үзләренең һәм балаларының торак шартларын яхшыртуга омтылуын мин һич тә гаепкә алырга җыенмыйм. Бу мәсьәләдә дә безнең сорауларны яшәү урынындагы "Торак фондлары" хәл итә. Яна тәртиптә, яна шартларда... Хәтта без көткәндәгедән тизрәк һәм отышлырак та...

Инде «мәңгелек торак-йорт» турында берничә сүз. 16 нчы январь көнне булган очрашуыбызда Президентыбыз, вафат булган зыялыларыбызны җирләү буенча без алдагы җыелышларда күтәрелгән мәсьәләнең якындагы айларда тулысынча хәл ителәчәген, аның күрсәтмәсе буенча шәһәр җитәкчеләреннән күренекле шәхесләрне җирләү буенча Казанда яна урын әзерләвен әйтте...

Хөрмәтле каләмдәшләр!

2007 ел республикабыз Президенты тарафыннан "Хәйрия елы" дип игълан ителде... Хәйриячелек—асылы белән безнең халкыбызга бик тә таныш күренеш. Халкыбызның мәгърифәтчелек тарихы тулысы белән хәйриячелеккә корылган... Бу күркәм традиция, шөкер, бүген дә яши һәм быел ул тагы да колачлы булыр, яшь буынны, бигрәк тә бай яшьләребезне, миһербанлы эшләргә этәрер дигән ышанычта торабыз.

Хәйрия елы—иҗатчыларыбыз, язучыларыбыз өчен дә эзсез узмаска тиеш. Без идарәдә, һәр язучының Республикабыз мәктәпләренә барып укучылар, укытучылар белән очрашуны, анда үзенең китапларын, кульязмаларны бүләк итеп бирүен—ин савaплы хәйрия дип, шулай ук Республикабыздагы балалар йортларына, өлкәннәр йортларына шефлык итүне мәхкүл гамәл дип билгелибез.

Узган ел, алдагы елларда вафат булган каләмдәшләребезнең каберлекләрен барлау, аларны төзекләндерү буенча башлаган эшләребезне дәвам итәргә уйлыйбыз.

Халкыбызда булган шушы игелекле гамәлләрне үзебезнең иҗатыбызда яктырту, игелекле кешеләрнең образын тудыру ихтыяҗлары да каләм ияләрендә уяныр дип уйлыйбыз!

Әлбәттә, Язучылар берлеге башкарган һәм башкара алмаган мәсьәләләр турында күпләп сөйләп булыр иде, хәл итәсе мәсьәләләр дә шактый... Барысын да күрергә,

игътибар итәргә тырышырга кирәк! Шуңа да карамастан, узган иҗат елы, әйткәнемчә, чын мәгънәсендә актив иҗат елы булды. Мин, махсус рәвештә, чыгышымда бер генә язучының исемен дә атамадым һәм иҗат үрнәкләренә тукталмадым. Алар хакында бүген жанрлар буенча әзерләнгән докладларда тәфсилле анализ бар. Шулардан чыгып, без Әдәби ел йомгаклары турында эшлекле рәвештә фикер алышырбыз, киңәшербез дигән ышанычта калам.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

---

**Ләбиб ЛЕРОН**

## ХӘЛЕҢ НИЧЕК, ТАТАР ПРОЗАСЫ?



Сүземне күпләргә мәгълүм бер мәзәкне искә төшерүдән башлыйм әле.

Мәскәүдәге Горький исемен йөрткән Әдәби институтка, укырга керергә дип, бер чукча килгән имеш.

—Толстойның «Война и мир» романын укыдыңмы? Пушкин нәрсәләр язган? Гогольнең кайсы әсәрләрен укыдың?—дип кызыксынганнар моннан имтихан алучылар. Чукча үзенә сорау бирүчеләргә бераз сәерсенеп карап торгач:

—Чукча—не читатэл, чукча—писатэл!—дип әйтеп салган имеш...

Яшерен-батырын түгел, безнең күбебез әлеге мәзәктәге чукча кебек: әдәби әсәрләрне, бигрәк тә каләмдәшләребез язганны, укырга әллә ни атлыгып тормыйбыз. Үземнән чыгып әйтәм, әгәр проза остаханәсе җитәкчесе Марсель Гали: «2006 ел өчен Фатих Хөсни премиясен алган кеше буларак, мартта буласы әдәби ел йомгакларында проза буенча чыгыш ясарга әзерлән! Идарә шулай хәл итте!» димәсә, мин ошбу көнгәчә әле һаман да «писатэл» булып кына йөрисе кеше идем.

Менә ике ай буе инде мин—укучы: дөрес, укуымда үзгә бер эзлеклелек юк—әле «Казан утлары»н кулыма алам, әле «Идел» журналына тотынам дигәндәй, әле генә хикәя укыган булсам, шул арада повесть йә роман дөньясына күчәм...

2006 ел, шөкер, чәчмә әсәрләргә мул булган икән—укып бетерә торган түгел! «Казан утлары» белән «Идел»дә һәм «Мәйдан»да, әдәби газетебез «Мәдәни җомга»да гына басылганнарны күз уңында тотып әйтәм әле мин.

Шушы ике ай эчендә җәмгысы 45 хикәя (шулардан унысы—шаян вә каһкаһәле әсәрләр), 5 роман һәм кайберләре күләм ягыннан романга көндәш булырлык 12 повесть күздән кичелде.

Инде килеп, сүз-үгезнең мөгезеннән эләктереп алсак та ярый: узган ел дөнья күргән чәчмә әсәрләр арасында чын мәгънәсендә Әдәби Табыш, Әдәби Ачыш, Әдәби Вакыйга булырдайлары, атаклы Исхакыйлары, олпат Әмирханнары белән мең кәррә кодрәтле, саллы Татар Прозасына Яңа Куәт өстәрдәйләре... бармы? Әгәр бар булса, ул Татар романы, Татар бәяне (ягъни повесте), Татар хикәясе дигән өрфия канатлы Иҗат Кошларыбыз нинди Уй-Гамьнәр Яссылыгында, кайсы Биеклекләр Югарылыгында торып, безнең Күңелләр Иленә юл саба икән? Кыскасы, бүген синең хәлең ничек, Татар Прозасы?

«Тормыш—тормыш инде ул, мин аны ничек бар шулай кабул итәм»,—дигән мәшһүр Бернард Шоу. Тормышны бар көенчә, үзең күргәнчә генә кабул итү—әле

бер нәрсә, әгәр син гавамга Яңа Сүз әйтәм дип, әһле каләм иясе булырга җыенгансың икән, күргәнеңне матур тел белән сурәтләп, мәгънәви төсмерләргә төреп, гап-гади укучыга да аңлашылырлык югары-әдәби кимәлдә яза да белергә тиешсең! Бу урында янә бер даһи язучының сүзләрен китерү бик мәслихәт булыр: «Мина калса, киләчәктә әдәби әсәрләрне уйлап чыгарып язудан туктарлар. Язучылар, әгәр алар ул вакытта булсалар, уйлап чыгарып мәшәкатьләнмәсләр, бары тик тормышта үзләре күргән аеруча мөһим һәм мавыктыргыч хәлләрне генә тасвирларлар», һәр нәрсәгә нечкә тоемлы, сизгер күңелле әдибебез Мөхәммәт Мәһдиев тә Лев Толстойның әлеге сүзләренә игътибар иткән булган икән—ул аларны көндәлегенә теркәп куюны кирәк тапкан.

Мәһдиевнең шәкерте, якташы Вакыйф Нуриевның «Җиденче палата» дигән повестен укый башлауга ук әнә шул фикерләр келт итеп исемә килде. Автобиографик алым кулланып, мөһим бер мәсьәләне күз офыгында тотып язу—әдәби-вакыйгаи әсәр тудыру—галиҗәнап Әдәбиятта монарчы да бар иде. Автобиографик алым кулланып, дип кабатлап әйтәм, биредә сүз һич тә без күнеккән-гадәтләнгән мемуар әсәрләр хакында бармый. Рус әдәбиятында мондый алым белән язып, гаять кызык вә үзенчәлекле әсәрләр тудырган бер әдип бар—Сергей Довлатов. Мин биредә Сергей Довлатов язганнар белән Вакыйф Нуриев повестен чагыштырырга җыенмыйм. Бу кирәк тә түгел. «Туп-турыдан юл пашул» дигәндәй, мин сүз сөрешемне әлегә фәкать Вакыйф Нуриев иҗат иткән әсәрләргә таба турылыйм. Әсәрләр, дидем—ялгыш әйтмәдем. Шаккаткыч хәл: монарчы балалар өчен «Бүре кадәр бүрек» дигән бердәнбер шаян китапчык чыгарган Вакыйф Нуриевның узган ел матбугатта берьюлы өч повесте дөнья күрде! «Әбиемә—әфлисун», «Җиденче палата» һәм «Карга карагы» дип атала алар. Исемнәре белән үк үзләренә җәлеп итеп торган ошбу әсәрләрнең каһарманнары—безнең арабыздагы гади-гадәти кешеләр, әдәбият дәреслекләре теле белән әйтсәк, «кечкенә» кешеләр. Вакыйф алар турында яратып яза. Үзе күреп белгән каһарманнарын, аларның холык-халәтләрен укучыны ышандырырлык итеп сурәтли. Әсәрләрендә вакыт-вакыт Ибраһим Гази белән Мирсәй Әмир, остазы Мөхәммәт Мәһдиев белән Фатих Хөсни аһәннәре «яңгырап» ала. Бу—табигый. Уйлап карасаң, без барыбыз да—классик әдәбияттан яралган язучылар ич! Кайвакыт эксцентрик, ягъни табигый булмаган образ кертеп сөйләштертүләр (мәсәлән, «Карга карагы» повестенда андый образ—кырык ел элек сугышта һәлак булган Сәхап өрәге), гадәттән тыш сәер-мәзәк хәлләрне укучы күңелендә шик-шөбһәгә урын калдырмаслык итеп сурәтләүләр Вакыйфка хас. «Форма—үзе үк әсәр. Стильдән гайре нәрсә юк»,—дигән Густав Флобер. Вакыйф Нуриев әсәрләре форма ягыннан да, инде әйткәнемчә, язу алымы-стиле белән дә гаять үзенчәлекле һәм кызыклы. Кыскасы, узган елдагы Әдәби ачышларыбызның берсе—берәгәйлесе, нәкъ менә Вакыйф Нуриев булды, дисәм, һич тә арттыру булмастыр. Вакыйф Нуриевны өлкән каләмдәше Вакыйф Нуруллин белән монарчы бик еш бутыйлар иде. Инде мондый шәп повестьлар язганнан соң бүтән буташтыру-саташтырулар булмастыр, шәт..

Мин тагын өч каләмдәшемнең исемнәрен атыйм: Мирсәй Гариф, Искәндәр Сиражи һәм Илдус Хуҗин. Алар да узган әдәби елыбызның Яңа исемнәре—Әдәби ачышлары булып саналырга бик тә хаклы, минемчә.

Мирсәй Гариф. Чагыштырмача яшь язучының «Тукай һәм Зәйтүнә» дигән күләмле бәянен «Идел» журналы үз битләрендә урын биреп һич тә ялгышмаган. Без Тукайны беләбез, дип уйлыйбыз. Ләкин Мирсәй Гарифның, шагыйрь яшәгән чорны тирәнтен өйрәнеп, Тукай белән Зәйтүнә мөнәсәбәтен документаль нигезләп, әдәби телдә шәрехләп биргән бу әсәрен укыгач, Тукайның яңача рухта ачылганын аңлыйсың. Безгә мондый Мәхәббәт Тәфсилләмәсе укыткан автордан Фатих Әмирхан, Шәехзадә Бабич кебек әдип-шагыйрьләрнең дә могъшукаларына карата булган самими мәхәббәт кичерешләре сурәтләнгән чираттагы яңа кыйссаларны түземсезлек белән көтәргә генә кала.

Искәндәр Сиражи. Соңгы вакытта бу автор матур мәгънәдә «азды»: узган ел ул «Идел» һәм «Казан утлары» журналында дүрт хикәя бастырды. «Ватаным Татарстан» газитендә бер повесте дөнья күрде. Повесть белән тулаем танышып

чыгалмавым сәбәпле, хикәяләр турында гына бер-ике кәлимә сүз: дүрт хикәянең дүртесе дә дини рух белән өретелгән, ике хикәянең, «Тәреле мулла» белән «Күкләр никаһы»ның, исемнәреннән үк сизелгәнчә, үзәгендә мулла образы ята. Әйтергә кирәк, автор ни язасын белеп яза, геройларының эчке кичерешләрен, аларның уй-гамьнәрен, эш-гамәлләрен укучы күңелендә тәэссоратлы эз калдырырлык итеп сурәтли. «Гыйсметдин тәүбәсе» дә, «Тауларда яз иде» хикәясе дә талантлы кул белән язылган. Алга табан тәнкыйтьчеләребез, Искәндәр Сиражи иҗатын да аерым бер игътибарга алырлар, дип уйлыйм.

Инде Илдус Хужинга тукталыйк. Дөресен әйтим, монарчы мин бу автор иҗаты белән бөтенләй таныш түгел идем. Баксаң, ул инде «Казан утлары» һәм « Идел» журналлары белән күптән тыгыз элемтәдә тора икән. Свердлов өлкәсендә яшәп иҗат итүче Илдус Хужинның узган ел «Идел»дә—«Днепр буендагы фаҗига», «Казан утлары»нда «Кызыл тәнлеләр юлбашчысы» дигән күләмле генә хикәя-бәяннәре басылган. Минем күңелемә, шәхсән, «Кызыл тәнлеләр юлбашчысы» әсәре аеруча хуш килде. Кулымнан килсә, мин бүген үк бу әсәр нигезендә татарча кинофильм төшерә башлар идем. Әйе, маҗаралы, хыялый бәян. Әйе, укырга бик җиңел әсәр. Марк Твенның «Том Сойер»ын, Гаррнет Бичер-Стоуның «Том агай алачыгы»н, Джеймс Фенимор Куперның «Соңгы могикан»ын, суга сусагандай, йотлыгып укыганым исемә төште. Алар да, миңа калса, укырга җиңел әсәрләрдән иде. Илдус Хужин үз әсәренең кереш өлешендә болай дип искәртеп куюны кирәк тапкан: «Әбрар Кәримуллинның казанышлары хакында белмәгән кеше сирәктер. Әдипнең киң тармаклы эшчәнлегенең бер юнәлеше, ул да булса, Америка континентында төп халыклар белән безнең ата-бабаларыбызның кан һәм тел кардәшлеге турындагы гипотезасы шушы бәянне язарга этәргеч булды». Җөмләдәге «төп халыклар»ны индеецлар (авторча әйтсәк, һиндеецлар) дип аңларга кирәк. Унсигезенче гасыр урталарында, төрле маҗаралар кичә-кичә, чукындырылган татарымыз «Сабуров Максим Николай улы», ягъни мушкетер-солдат-матрос Мәргән, аяусыз язмышына ирексездән буйсынган хәлдә, нәкъ менә шул индеецлар мохитына килеп эләгә, аларның курку белмәс юлбашчысына әверелеп, шунда төпләнеп калырга мәҗбүр була. Русиянең талап баю максаты белән кечкенә халыкларны үзенә буйсындырырга омтылуы, канлы сәясәт алып баруы күренешләре дә әсәрдә гыйбрәтле деталь-картиналар аша укучы күңеленә житкерелә. Ошбу кыйсса башына «Хыялый бәян» дигән мөһер сугылса да, әсәр миндә чынбарлыктан алып язылгандай тәэсир калдырды.

Узган ел дөнья күргән биш романны укып чыгуым турында алдарак әйтеп үткән идем инде. Болар—Заһид Мәхмүдинең «Һәркемнең үз юлы», Зиннур Хөсниярның «Козгыннар йолдыз чүпли», Фоат Садриевның «Бәхетсезләр бәхете», Рәфкать Кәраминең «Олы юл да сикәлтәле» һәм Рауль Мирхәйдәровның «Үзем хөкем итәм» дигән романнары.

Заһид Мәхмүдинең роман тиклем роман язарга алынуына гаҗәпләнмәдем. Ул моңа иртәме-соңмы бер тотынырга тиеш иде. Әүвәлге повестьлары шикелле үк бу романы да шактый кызыклы гына. Игътибар иткәнегез бардыр, Зөлфәт Хәким пьесаларында еш кына бер персонаж—участковый милиционер очрый. Заһидның да үзе яраткан шундый бер образы бар. Ул—иблис. Әлбәттә, Иблис катнашкан җирдә юньле тормыш була алмый. Заһид Мәхмүдинең «Ахырзаман шаукымы» дигән яңа бәянендә сурәтләнгән вакыйга—Иблиснең турыдан-туры коткысы белән кешеләрнең барлы-юклы намусларын закладка салулары турындагы вакыйга шуны ачык раслый. Авторның «Һәркемнең үз юлы» романын укыганда исә, хикмәти Хода, ни Иблис үзе, ни аның кеше кыяфәтендәге образы ялгыш та күзгә чалынмады. Аның каравы, көтмәгәндә, Понтий Пилатка юлыктым. Әйе, әйе, урыс әдәбияты классигы Михаил Булгаковның «Мастер һәм Маргарита» әсәреннән безгә бигрәк тә таныш булган прокуратор Понтий Пилатның нәкъ үзенә! Татар романында төп геройны—элекке милиционер, чарасызлыктан контракт белән Чечняга барып, аннан акылына зыян салып кайткан Әхәтне Понтий Пилат белән саташтырып мәрәкәләндерү идеясе бүгенге көндә бары тик Заһид Мәхмүди башына гына килә ала, минемчә. Ә болай, әйткәнемчә, Заһидның романы укырга кызык.

Тәнкыйтьчеләр теле белән әйтсәк, житди әсәр дип саналырга лаек.

Зиннур Хөснияр, бәхәссез, әдәбиятта үзен «Кичү» һәм «Трагедиягә ике билет» дигән хикәяләре белән танытты. Байтак кына ипле-төпле повестьлар, «Терсәк сугышы» һәм «Эттән туган» дигән тирән эчтәлекле роман-дилогия язып, үзе шикелле күләмле әсәрләр тудырырга сәләтле күп кенә авторлар янәшәсендә бер баш өстен урын алып торса да, мин Зиннурны, барыбер, менә шул хикәя жанрының бер остасы дип саныйм. Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Ибраһим Гази, Фатих Хөсни, Мәгъсүм Хужин кебек әдәби остазларының лаеклы дәвамчысы итеп күрәм. Инде «Козгыннар йолдыз чүпли»гә тукталып алыйк. Романның эченә үк кереп тормыйм. Керсәм, чыгалмам дип куркам. Бары шуны гына әйтүне үземә фарыз күрәм: дөньяның атаклы фәйләсүфләре язып калдырган бихисап бөек тәгълиматларны жентекләп, тирәнтен өйрәнеп, шуларга нигезләнеп салды роман язарга алынуын, аны татар дөньясына бәйле рәвештә унышлы гына тәмам итеп чыгып, зәвыклары төрле булган укучылар хөкеменә тапшыруын—язучы тарафыннан кылынган әдәби батырлык дими ни дисен инде!

Бу роман хакында тиешле-әтрафлы фикер әйтер өчен үзеннен дә бик житди әзерлекле булуын зарур. Мондый жаваплы миссиягә алынучылар тәнкыйди каләм тибрәтүчеләребез арасында табылмый калмастыр, дип уйлыйм.

Кайнап торган Казаннан, ыгы-зыгылы Әдәби Мохиттән читтә, беренче карашка тын, әмма чынлыкта тынгысыз авыл жирлегендә—«Их, Мөслим, инде нишлим?!» дип жырга кергән Мөслим төбәгендә яшәп, әледән-әле катлаулы язмышларга бәйсаллы әсәрләр язып, үзенен барлыгын даими искәртеп торучы бер мөхтәрәм каләмдәшебез бар безнен: ул—Фоат Садриев.

Китап сөюче күпсанлы укучыларыбыз тарафыннан яратып кабул ителгән «Тан жиле» романы өчен генә дә үзенә күптән Тукай премиясе бирерлек менә шул язучыбыз узган ел «Казан утлары» аша «Бәхетсезләр бәхете» дигән роман-трилогиясенен өченче кисәген әдәби жәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим итте. Язучылар даирәсендә, әлеге әсәрнен алдагы өлешләре дөнья күргәч, шундыйрак сүз булды шикелле: автор заманнан артта калып бара, үз вакытында язып бастырган булса, романнын тәэсир итү көче, куәте, кыйммәте тагы да югары булыр иде имеш! Жәмәгать, әгәр әсәрдә күтәрелгән мәсьәләләр киң янгыраш ала икән, алар еллар узып та актуальлеген югалтмый икән, ул әсәр берничек тә искерә алмый. Хис белән, Тойгы белән күнелне кузгатырлык итеп язылган әсәрдән талымлы укучы беркайчан да бизми, киресенчә, ул аны кайта-кайта укый, алгысак жанына тынгы бирмәгән дистәләрчә сорауларга жавапны барыбер табасына ышанып укый. Нишли дә алмый Вакыт—Фоат Садриевнын «Бәхетсезләр бәхете» трилогиясе күпләр кызыккан шундый Бәхетле язмышка дучар!

Рәфкать Кәрами ижаты турында сүз алып барганда әүвәл анын «Очар кошлар белән янәшә» һәм «Каргышлы этаплар» дигән әсәрләрен искә төшерәбез. Кәрами ашыгып-кабаланып яза торган әдипләрдән түгел. Анын үз укучыларыннан гына торган аудиториясе бар. "Казан утлары»нда бүленеп-бүленеп өч сан рәттән басылган «Олы юл да сикәлтәле» романын да ул, минем уемча, ин элек менә шул тугрылыклы укучыларын күз унында тотып ижат иткән, һәм ялгышмаган. Әсәр герое Габделнурнын күргән-кичкәннәре, һичшиксез, аларнын самими-садә күңелләренә галибанә хуш килгәндер.

Бездә, төгәлрәк әйтсәк, әдәбият дөньясында, элек-электән килгән бер кызык хәл күзәтелә. Берәр түгәрәк датасы якынлашкан автор, бигрәк тә үзен прозаик дип санаганы, ашыгып-каударланып, күләмле әсәр язарга тотына. Тырыша торгач, ул аны повесть, хәтта роман дәрәҗәсенә үк житкерә дә. Мондый «стимул» белән язылган әсәрләрнен байтагы, әлбәттә, пышыйк килеп чыга. Бу сүзләр сонгы елларда аеруча продуктив-актив каләм чарлаучы, күптән түгел генә илле яшен тутырган Галимҗан Гыйльмановка турыдан-туры кагылмый да сыман. Чөнки ул юбилей шаукымы белән генә түгел, болай да ин күп ижат итүче авторларыбыздан берсе! Әсәрләре белән матбугатта ин күп күренүче ул, телевизор экраннары аша телебез турында даими кайгыртып торучы да—ул, һәммәсенә житешә, өлгерә Галимҗан, кыскасы, кермәгән-чыкмаган тишеге юк анын. Безгә, язучынын шулай өлгер

булуына сокланып, сөенергә генә кала. Анысы шулай шулаен да. Тик менә... артык активлыкның иҗатка шактый гына тискәре йогынты ясавы ихтималы барлыгын да онытмау лаземдер ошбу авторга. Шул исәптән безләргә дә.

Узган ел Галимҗан Гыйльмановның «Идел»дә һәм «Казан утлары»нда ике повесте басылды. «Идел»дәгесе—«Эт елы», «Казан утлары»ндагысы «Соңгы сугыш» дип атала. Мәгълүм ки, әдәбиятта мәңгелек тема—«мәхәббәт өчлеге» темасы: икәү яратыша, берәү мишәйт итә. Галиябану белән Хәлил һәм Исмәгыйль, кыскасы! «Эт елы»нда сүз-вакыйга, аңлашылганча, менә шундыйрак «мәхәббәт өчлеге» тирәсендә бара. Янә ярдәмче ике образ бар: берсе—Гадел исемле малай, икенчесе—сөйләшә белүче Акколак дигән эт. Галимҗан Гыйльмановның әлеге әсәрен укып чыккан берәү, Мәһдиев әйтмешли, «бер иптәш» болай дигән иде : «Кичә генә телевизордан кино карадым—анда да эт сөйләшә, кино белән повесть арасында охшашлыклар шактый!» Киноны үзем карамагач, артык сүз куертып, өстемә гөнаһ аласым килми, бары шуны гына әйтәм: эт сөйләштерү идеясе яңалык түгел, безнең әдәбиятта моңарчы кәҗә хәтле кәҗәне сөйләштерүчеләр дә булды хәтта! Инде авторның «Соңгы сугыш» дигән әсәренә килсәк, монысында, чыннан да бер «эский» бар: урысның «Ворошиловский стрелок» дигән, яисә, үзебезчә әйтсәк, «Ворошилов мәргәне»дигән мәгълүм киносы белән әлеге повесть арасында җитди генә уртаклыкны күрергә була. Кинода Михаил Ульянов герое мәсхәрә ителгән оныгы өчен үч алса, Галимҗан әсәрендә исә Зәкәрия карт, шулай ук, мәсхәрә ителгән оныгын яклап, шулай ук, кулына корал тотып, явызлыкка каршы чыга. Ә калганы инде, кем әйтмешли, техника эше...

Бәян. Ягъни повесть. Бу жанрны үз итүче авторларыбыз шактый икән безнең. Берничәсе хакында сүз булды инде. Тагын кайбер язучыларыбызны телгә алып үтәсем килә. Марат Әмирханов. Соңгы елларда бик актив яза. Иҗади маяны күп туплаганлыгы күренеп тора. Аның «И, кылган догам минем» повестен укучылар яратып укыганнардыр дип уйлыйм. Әсәр герое Хисам Сабирның әсирлектә интеккәннәре икенче бер язучыбыз Нәби Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» дигән повестенда сурәтләнгәннәр белән беркадәр аваздаш шикеллерәк тәэсир калдыра калдыруын. Ә болай әсәр яхшы кабул ителә. Повестьта сугыш вакыты белән бүгенге заман вакыйгаларының бергә матур гына үрелеп, ике яссылыкта баруы әсәрне тагын да отышлы, бербөтен иткән, дигән уңай фикер калды миндә.

Нәбирә Гыйматдинова. Повесть жанрына да, «Идел» журналына да бердәй тугрылыклы автор. «Идел»дә елга бер мәртәбә повесть бастырмаса, Нәбирә—Нәбирә Гыйматдинова булмас иде. Узган ел ул «Күкчәчәк» дигән бәянен журнал укучылары хөкеменә тапшырды. Безгә ул әсәрне озаклямый телевизор экраныннан кино рәвешендә яисә Тинчурин театры сәхнәсеннән спектакль сыйфатында күрергә туры килмәгәе. Галәттә, шулай була торган иде.

Хәбир Ибраһим. Пьесалар язмаган чагында—повестьлар, повестьлар язмаган вакытында күңеленә ни хуш килсә, шуны язып тәм табарга яратучы бу авторның узган ел «Төнге шаяру» дигән бәяне «Идел» өстендә балкыды. Әсәр абсурдка корылган. Күәстәге измәдән яралып, гомер буе бала өмет итеп яшәгән ирле-хатынлы Борһан-Сафура гаиләсендә пәйда булган Камыр малай турында бу әсәр. Таныш әкиятне хәтерләтә, шулай бит?! Әмма ашыкмагыз, бу беренче карашка гына шулай тоела. Вундеркинд Камыр малай, тумышы белән дөресен генә сөйли торган бала булып чыгып, тиз арада «ата-ана»ны хафага сала. Ахыр чиктә, Хәбирнең турыдан-туры булышлыгы белән, «ата-ана» дигәннәребез Камыр малайны киредән күәскә ябып-томалап куя.Кыскача эчтәлек шулайрак. Туры әйткән—туганына ярамаган, диләрме әле? Вәйт, бу әсәрнең морале шул.

Тагын ике повесть турында. Икесе дә «Казан утлары»нда басылган. Берсе—Локман Бадыйкшанныкы. «Тәкъдирем» дип атала. Истәлек-повесть. Кем ничектер, мин үзем мондый әсәрләрне укырга яратам. Бигрәк тә әсәрдә таныш исемнәр очраса. Бадыйкшан агайның әсәрендә андый таныш исемнәр күп: мәсәлән, Нәкый Исәнбәт, Шәрәф Мөдәррис, Гази Кашшаф, Ләбиб Гыйльми...

Икенче повесть та—автобиографик әсәр. « Җәнбәт юруы» дип аталган ул әсәрнең авторы—Альберт Хәсәнов. Бу язучының байтак әсәре миңа яхшы таныш. Кайчандыр

бер повестен редакцияләргә дә туры килгән иде шикелле. Аның язганнары арасында бар әйбәте, бар уртачасы дигәндәй... Бу әсәре кай ягы, нәрсәсе беләндер үзенә аеруча җәлеп итте мине. «Әлеге дә баягы—башыма уклау таягы» дигән сыман, хикмәт—истәлек формасында язылуындадыр мөгаен. Әсәрдән бер өземтә китереп үтәм: «Ибраһим абый (биредә сүз Ибраһим Гази турында бара—Л.Лерон искәрмәсе.) безгә фронтта дивизия газетасында эшләвен, сугышта күргәннәрен сөйләде. «Полуторка машинасында алгы сызыктан штабка тораташ булып каткан мәетләр төшәлгән юлдан кайтабыз. Бер урында кар көртенә чумдык. Буксовайт итә башладык. Зыр килеп бер урында әйләнеп утырган арт көпчәкләргә дә, кар астыннан гына өстерәп чыгарып, мәетләр тыгабыз»,—дип сөйләде.

—Кемнәрнеңдер газизләре, бердәнберләренең гәүдәләре бит инде болар!—дидек без әсәрләнеп.

—Сугыш! Фронт! Алар турында уйлап торырга вакыт бармы?—диегез. Приказ үтәргә ашык. Үтәмәсән—трибунал! Анда күп сөйләшеп тормыйлар. Алып чыгалар да, шалт мангаена берне! Синең дә үле гәүдәңнең юл төшәргә китүе ихтимал,—дип куйды агабыз...»

Вакыт-вакыт җанны сулкылдатып алган менә шундый детальләр еш очрый «Җәнбәт ыруы»нда. Әсәрнең җылы, мавыктыргыч итеп язылуында да шул детальләр зур роль уйнамады микән әле?!

Сизгәнсездер, шәт, әсәрләрнең теле хакында мин бер дә сүз кузгатмадым. Сүз кузгатмыйча дөрес эшләдем дип уйлыйм. Нигәме? Чөнки беләм: күпчелек язучыларның әсәрләре әле журналга тәкъдим ителгәнче үк бу мәсьәләдә шактый тәҗрибә туплаган, сизгер редакторларның иләге аша әллә ничә мәртәбә иләнә, төзәтелә, кайвакыт матур-матур җөмләләр белән баетыла да хәтта. Мин монда берәр авторның әсәреннән, шәп җөмлә, дип өзек китерермен, күкләргә чөеп мактармын, ә ул җөмлә исә, бөтенләй авторның үзенеке булмыйча, әйтик, «Идел» журналханәсендә үз язма-хикәяләре белән әвәрә килүе өстенә, эш-вазыйфасы буенча читләрнеке белән дә чиләнергә « мәҗбүр ителгән» мөхәррир Ркаил Зәйдулланыкы, яисә «Казан утлары»нда проза бүлеген җигелеп тартучы Камил Кәрим белән Марат Закирныкы булып чыкса!? Шул-шул, анладыгызмы җилнең кай тарафтан искәнен?

Инде, ниһаять, хикәяләргә дә чират житте бугай. Хикәя—гәзит-журналларда иң күп, иң еш басыла торган жанр. Бу шулай булырга тиеш тә. Сүзне яшьрәк авторлардан башлыйм: Халисә Ширмән, Хак Шәйхи, Ләйсән Низамова, Лира Ибраһим-Вәлиди, Гөлсинә Галимуллина, Гөлназ Нигъмәтуллина, Айсылу Имамиева... Кара, кызык—хикәячеләрнең барысы да нәфис затлар булып чыкты түгелме соң?—дисәм, Ленар Шәех белән Фәнис Мотыйгуллин бар икән! Кызык парадокс: өлкәнрәк каләм ияләре яшьлекләрен сагынып язсалар, яшьләр картлык турында, аерым алганда, әбиләр, бабайлар хакында язарга яраталар. Шунысы янә кызыклы: яшьләр үз әсәрләрендә карт-карчыклар образын хәйран матур гына ачалар да. Мин болай дигәндә, бигрәк тә Ленар Шәех белән Лира Ибраһим-Вәлидинең «Бал бабай» белән «Гаделҗан бабай» хикәяләрен күздә тотам.

Эльмира Шәрифуллинаның мәхәббәт, гаилә хакындагы бик җылы ике хикәясе игътибарга лаек. Роза Мулланурова белән Рифә Рахман хикәяләре дә ир-егетләр язганнан бер дә калтыш түгел. Киресенчә, кайберәүләрнекенә караганда бераз шәбрәк тә түгел микән әле. Дөрес, Рифә Рахманның «Сөннәтче әби»ен укыганда азрак «буксовайть иткәләп» алырга туры килде килүен: хикәядә исемнәре бер хәрефтән башланган Мәфруза, Мәлихә, Мәүлиха, Маһибикә, Маһикамал, Мөхәммәтгали, Мотыйклар башны исәңгерәттеме шунда...

Узган ел шулай ук хикәяләре басылган Ркаил Зәйдулла, Туфан Миннуллин, Зәки Зәйнуллин,Радик Фәизов, Әнәс Хәсәнов, Рафис Гыйззәтуллин, Нәгыйм Шаһи, Фердинант Бигашев, шулай ук юмор осталары Камил Кәрим, Фәнзаман Баттал, Аманулла, Рәдиф Сәгъди, Тәлгат Нәҗмиев исемнәрен атап үтмәсәм, Әхәт Гаффар әйткәндәй, халык мине дөрес анламас, һәр авторның да хикәясе, һич кенә дә купайтып-күпертеп әйтүем түгел, бик оста язылган, хәтта әйтер идем ки, арада «иң-иң» дип әйтерлекләре дә бар. Шундыйлардан берничәсен, әйтик, Туфан Миннуллинның «Житлегү» исемле кино-хикәясен, Фәнзаман Батталның «Җәза»

һәм «Крутой әби» дигән хикәяләрен, Ркаил Зәйдулланың «Яшел чирәмдә сары келиндир» хикәясен аерым билгеләп үтәр идем.

«Әгәр китапны ике тапкыр укып чыгып булмый икән, аны бер тапкыр да укып торырга кирәкми»,—дигән бер акыл иясе. Мин бүген телгә алынган әсәрләрнең һәммәсен дә бер мәртәбә укып чыктым. Икенче тапкыр укырга вакыт кына житмәде. Бигайбә!

---

**Әхмәт РӘШИТ**

## ШИГЪРИ ХӘЗИНӘДӘ НИЛӘР БАР?



Нинди заманда яшәвебезне шәрехләп торуның хажәте юктыр. Матди байлыклар елдан-ел рухи хәзинәләрне кысрыклап чыгара бара. Кешенең эчке дөньясы инде Янарыш чоры һәм аннан соңгы дәверләр тудырган рәссамнарның, композиторларның, әдип - шагыйрьләрнең классик әсәрләрен бөтенләй кирәксенми диярлек. Икътисад атына менеп атланган һәртөрле мененджерлар, алыпсатарлар, нуворишлар теге яки бу иҗат кешесенең шәхсән нәкъ менә аңа тугры булуын, аның фикерләрен үткәрүен һәм һичьюгы теге яки бу күләмдә туган, дус һәм якташ булуын гына күздә тотып эш итә. Район газеталарының гына түгел, республиканың кайбер нәшрият органнарының да түләүле китапларны күпләп чыгаруы шуның белән бәйләнгәндер. Матбугат турында кануннар йомшаргач, «цензура» дигән элекке буки алып ташлангач, хәзерге басмачылар теләсә кемнең теләсә нинди әсәрен дөньяга чыгарырга керештеләр. Искәндәр Сиражи әйтмешли, ул «чидивырлар» китап киштәләрендәге классик әсәрләрне инде кысрыклый ук башладылар. Китап киштәләре түренә ярымнадан, ярымдетектив, ярымәкияти әсәрләр менеп кунаклады. Европа һәм Американың иң түбән сортлы шул «чидивырлары»на үрнәк буларак язылган, художество кыйммәте ягыннан рухи азык булудан бигрәк, юлда барганда жинелчә «чтиво» (гафу итәсез, бу сүзнең татарчасы, Ходайга шөкер, юк шикелле әле!) итеп укыр өчен алынган китаплар тормыш сабагы да бирми, берәр гыйбрәтле вакыйга турында да сөйләми. Маринина һәм Донцова кебек әдәбиятка килеп сырышкан эшкуарлар элек китапларга ябырылып ташланган укучының ориентирларын буташтырдылар, начардан яхшыны аеру иммунитетын какшаттылар. Әллә никадәр, инде бөтен гавамга билгеле язучылар, артистлар, фән эшлеклеләре тормышта очын-очка чак-чак ялгап барган бер чорда, алар миллионнарча тиражлар белән эш итәләр, миллионнарча долларлык байлык туплыйлар. Ил күләмендә чын әдәбиятның, чын сәнгатьнең бу кадәр девальвациягә дучар булуы, әлбәттә инде, безнең милли мәдәнияттәге вәзгыятькә дә тәэсир итми калмый. Мин татар халкы язмышына шундый куркыныч яный, дип расларга җыенмыйм. Ләкин балык башыннан чери башлаган икән, тора-бара ул чир аның койрыгына да барып житәргә мөмкин. Шөкер, безнең бик күп халыкларны көнләштерерлек язма әдәбиятыбыз бар, шөкер, безнең Колгали, Сәйф Сараи, Котб кебек борынгы остазларыбыз бар, тотрыклы традицияләребез бар, адаша башлаганда юл күрсәтердәй Тукайларыбыз, Исхакыйларыбыз, Такташларыбыз, Жәлилләребез, Исәнбәтләребез бар. Алар эшен дәвам итәрдәй замандашларыбыз бар. Юлларга маяклар тезелгән, иншалла, магистраль юлдан читкә тайпылмабыз.

Узган 2006 елның Президентыбыз тарафыннан Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан ителүе, минемчә, нәкъ менә шул ышанычка, нәкъ менә шул иманга да

нигезләнгән булгандыр. Тукайның тууына 120, Муса Җәлилнең 100, Татар театрының 100 еллыклары, Фатих Әмирхан, Натан Рахлин, Сара Садыйкова, Александр Ключарев, Нәҗип Җиһанов, Рөстәм Яхин, Габдулла Кариев, Хәлил Әбҗәлилов, Николай Фешин, Гали Ильясов, Нинель Юлтыева, Софья Гобәйдуллина кебек күренекле шәхесләребезнең юбилейлары безнең бөтен рухи тормышыбызга матур төсмер биргән вакыйгалар булдылар. Бу мөһим даталарга бүген исән булган язучылардан Әдип Маликовның 85, Хисам Камаловның 80, Флера Гыйззәтуллинаның һәм Роза Хәлиуллинаның 75, Клара Булатова, Фаяз Дунай һәм Әхмәт Рәшитнең 70 еллыклары, инде житмешенче дистәнең икенче өлешен ваклаган Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Гәрәй Рәхим, Гарифҗан Мөхәммәтшинның туган көннәре, 60 дигән рубиконны уза алган Мөдәррис Әгъләм, Харрас Әюпов, Нур Әхмәдиев, Марсель Галиев, Илдус Гыйлаҗев, Рәшит Ягъфәр юбилейлары килеп тоташты.

Әдәбиятыбызның тагын бер тантанасы «Казан утлары» журналының меңенче саны чыгу белән бәйләнгән иде. Шунысын да әйтик, бу—шактый шартлы сан. Бу басманың элгәрләрен, Президентыбыз котлавында әйтелгәнчә, XX гасыр башында нәшер ителгән «Әлгасрел-җәдид», «Шура» һәм «Аң» журналларыннан да башларга мөмкин булыр иде. Шунысы сөенечле, бәйрәм тантаналары вакытында без журналның әллә кайчангы сәхифәләренә, күнелдә горурлык хисе уята торган саннарына да күз сала алдык. Аның бай һәм гыйбрәтле тарихын безгә шул уңайдан сиксән сигез ярым (кабатлап әйтәм—сиксән сигез ярым!) басма табаклык «Сүнмәс утлар балкышы» дигән китап-хроника да сөйли. Чынлап та, аны могтәбәр журналыбызның озын һәм шактый каршылыклы юлын яктырткан энциклопедиягә тиңләп булыр иде. Мәгълүм булганча, бу уникаль басмага багышлап Мәскәү хәтле Мәскәүдә зур тантана үткәрелде. Редакция коллективының, баш мөхәррир Равил Фәйзуллинның, китапны төзүче Рафикъ Юнысның, «Идел-Пресс» нәшриятының бу титаник хезмәтен без дә, һичшиксез, зурлап билгеләп үтәргә тиешбездер. Бер уңайдан, шундый авыр елларда, халык әдәбияттан бер кадәр читләшеп, зур матди кыенлыклар һәм мәшәкатьләр кичергән бу чорда укучыларыбызга даими рәвештә рухи азык өләшеп торган иҗат коллективына рәхмәтләр генә әйтәсе килә. Мәскәүнең кайчандыр миллионнарча тираж белән чыккан журналлары соңгы елларда хәтта дистә меңгә дә тулмаган вакытта «Казан утлары»ның чагыштырмача тотрыклы калуы язучыларыбызның фидакарьлегенә дә, баш мөхәррир Равил Фәйзуллинның тынгысызлыгына да бәйләнгән. Шуңа күрә шагыйребезнең һәртөрле мактауларга, регалияләргә саран бер заманда «Дуслык» ордены белән бүләкләнүе, аның татар шигъриятендә тоткан мәртәбәле урынын тану булса, икенче яктан Равил Фәйзуллинның зур оештыру сәләтенә дә бәйләнгән иде.

Бу яктан аның «Ватаным Татарстан» газетасында туган телебез язмышы өчен борчылып язган шигъри тупланмасы аеруча гыйбрәтле:

*Илләр күп ул, җырлар күп ул, телләр күп ул,*
*Ә гомерләр—һәркемнең дә берәү генә!*
*Җырым әйтсен: халык өчен җан аямый*
*Яшәүчеләр ирешсеннәр теләгенә,*

—ди ул «Ышаныч» дигән әсәрендә. Яки:

*Мәгълүм: дөнья көтү заман өчен*
*Файдалырак телләр бары да...*
*Тик шунысы хак: фәкать туган телдә*
*Иман иңә кеше җанына,*

—дип гомумиләштереп нәтиҗә ясый.

Былтыргы июнь аенда Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында куелган «Йосыф кыйссасы» балеты өчен композитор Леонид Любовскийга, биюче Нурлан Канетовка һәм либретто авторы шагыйрь Ренат

Хариска 2005 елда әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Россия Федерациясе Дәүләт бүләкләре бирелде. Аннан композитор Резеда Ахиярованың Ренат Харис либреттосына иҗат ителгән «Шагыйрь мәхәббәте» дигән операсы сәхнәләштерелде. Уйландырырлык фал бу! «Алтынчәч»ләрдән, «Шүрәле»ләрдән, «Самат»лардан, «Су анасы»ннан, «Каһәрләнгән мәхәббәт»тән, «Кәккүк моңы»ннан соң татар авторлары әсәрләреннән аерылып торган опера һәм балет театры, ниһаять, милли репертуарга мөрәҗәгать итте.

Сүз уңаенда Ренат Харисның нәшриятта жиде томлыгы чыгуын, мәшһүр якташыбыз Державин шигырьләрен тәрҗемә итүен, «Казан утлары» журналында сонетлары, композитор Мирсәет Яруллинга, шагыйрь Шамил Анакка, исемнәре Ренат булган иҗат әһелләренә багышланган шигырьләре чыгуын да әйтеп китәргә кирәктер. Әлеге сонетлар мәсьәләсендә шагыйрьгә минем бер дәгъвам да бар. Әдәбият теориясен яшь чактан ук иҗатның төп кануны итеп алган, хәтта күпмедер дәрәҗәдә консерватив карашлы кеше буларак, мин шигырьнең бу ныклы, тотрыклы формасының төп кагыйдәләрен үтәргә кирәк дип саныйм. 14 юлдан торган—француз, итальян, инглиз шигъри кагыйдәләрендә кайбер үзгәлекләр булса да, форма мәсьәләсендә даимилек сакланган—мондый әсәрләрнең исемнәре тәгәл әйтелми, алар фәкать цифр белән билгеләнә, ә әсәрнең төп идеясе соңгы ике яки өч юлга салына. Бу жанр татар шигърияте өчен бераз ятрак булса да, Шәрәф Мөдәррис, Мәхмүт Хөсәен кебек шагыйрьләребез аны гамәлгә керткәннәр иде. Минем үземнең дә берничә сонет язганым бар, башка каләмдәшләрем дә ана сирәк-мирәк мөрәҗәгать итәләр бугай. Сәбәбе гади: бу жанр иҗатчыны катгый кысаларда тота, борынгыдан килгән таләпләрнең тәгәл үтәлүен сорый.

Ренат Харис үз иҗатында нигездә поэмаларга мөрәҗәгать итә. Хәтерем ялгышмаса, аларның саны утызга җитте бугай инде. Алар арасында, әлбәттә, уңышлылары да, уңышсызлары да бардыр. Әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышларда бу хакта үз вакытында әйтелгән иде инде. Бу фикерләр белән килешергә яки килешмәскә мөмкин. Ләкин мин аның соңгы елларда аеруча актив эшләвен әйтергә тиешмен. Шагыйрьнең «Ватаным Татарстан» газетасында басылган «Жилсез дә алма коела», «Шәһри Казан»дагы «Без әле һаман узаман» дигән шәлкемнәре дә матур тәэсир калдырды.

Узган ел иң актив эшләүчеләрнең тагын берсе, мөгаен, Фәнис Яруллин булгандыр. «Казан утлары» журналында да, «Мәдәни җомга» атналыгында да, башка басмаларда да аның исеме гел күзгә чалынып торды. Аның «Без—табигать балалары» дигән тупланмасы ихласлылыгы белән укучы күңелен җәлеп итсә, дөнья хәлләре турында уйландырса, сискәндерсә, «Нурсөя» дигән поэмасы бөтен күңелләрне биләп ала. Менә без бер-беребез белән дан-дәрәҗәләр турында бәхәсләшәбез, үзара тарткалашабыз, нәрсәдер даулыйбыз. Ә менә янәшәбездә генә шундый олы йөрәкле, фидакарь җанлы бер ханым бар. Без аның бу каһарманлыгын сизмибез дә. Ә без аны дөньяның иң бөек хатын-кызлары рәтенә бастырыр, әллә нинди дөньякүләм олуг дәрәҗәләр бирергә тиеш идек. Рәхмәт Фәнисебезгә—ул аны, әнә шундый дулкынландыргыч әсәр язып, олылый белде, ирләрчә зур ихтирамын җиткерде.

Мин бу чыгышымда шагыйрьләрне касталарга, төркемнәргә бүлүне максат итеп куймадым. Күпмедер дәрәҗәдә субъектив булса булыр, ләкин бәһаләрне зиһенең, акылың, тәҗрибәң күрсәткәнчә куярга кирәктер. Узган ел «Ватаным Татарстан» газетасында да, «Казан утлары» журналында да, «Мәдәни җомга» атналыгында да Гарифҗан Мөхәммәтшинның камиллеккә дәгъва итәрдәй шигъри шәлкемнәре, шулай ук дүртьюллыклары—робагыйлары дөнья күрде.

*Ярларына кайта инеш, ташый да,*
*Идел булам, дип ярларны ашый да...*
*Язгы инеш хыяллары ничә кат*
*Әйләндерде безнең исәр башны да.*

Шигъриятебезнең робагый кебек борынгы төренә Мөхәммәт Мирза да еш мөрәҗәгать итә. «Казан утлары» журналының өченче санында аның да робагыйлары

басылып чыккан иде. Һәр шигырьне, бигрәк тә аның дүрт юлдан торганын шәрехләве кыен. Аның камил кимәлдә булуын әйтү белән бергә, шигырьнен үзен мисал итеп китерү дә житә торгандыр. Шуңа күрә ул робагыйның үзен генә бергәләп укыйк:

*Әйтерең хаклыгын әүвәл ачыкла:*
*Кылчыклы булмасын бәян, ашыкма...*
*Даһи иҗат түгел тарих боткасы,*
*Кабып йотып булмый салып кашыкка...*

Яки

*Бу дөньяның бердәнбер «Мин»нәре күп...*
*Һәрберсенең бәхетле «Миң»нәре күп...*
*«Миң»ле «Мин»нәр арасында тагын да*
*Мин—миңлеге азганга тиңнәре күп...*

Мөхәммәт Мирзаның «Мәдәни җомга» газетасында чыккан шигъри тупланмасы да укучы игътибарын җәлеп итәрлек. Зур-зур мисаллар китермичә, шагыйрьнең кайбер табышларын гына телгә алып үтим. «Җинеп жинсез кайткан җил егетләр...», «Җан һәм вөждан—вакыт мыскалында...», «Өлкән туган өчен эшләп, гомеркәйләр киселгән...» һ. б., һ. б. шагыйранә хакыйкатьләр укучы күңеленә сеңеп кала.

Былтыр 60 яшен бәйрәм иткән Илдус Гыйлаҗев үз бәйрәмен Татарстан китап нәшриятында басылган «Яратканга күрә» җыентыгы, «Мәдәни җомга» атналыгында һәм «Ватаным Татарстан» газетасындагы шигъри шәлкемнәре белән каршылады. Дөресен әйтергә кирәк, шагыйрь бөтен вөжүде белән җир кешесе. Аның язганнары да «җиде кат күк фәлсәфәсе» түгел, реаль чынбарлык. Шул ук вакытта аның җиргә, җир кешеләренә булган мөнәсәбәте утилитар түгел—ул тормышның, яшәешнең асыл мәгънәләрен таба, үзенең житди нәтиҗәләрен чыгара. Бу аның озак елларга сузылган төп һәм җаваплы хезмәте белән дә бәйләнгәндер.

Узган ел татар әдәбияты зур югалту ачысы кичерде—яшәү рәвеше белән үк шигърияттән аерылгысыз Мөдәррис Әгъләм якты дөньядан китте. Ул үзенең 60 еллыгын үткәрергә, «Халык шагыйре» дигән мәртәбәле исемгә лаек булырга гына өлгерде. Мәрхүмнең моңа шатланырга юньләп вакыты да булмагандыр. Чөнки теге дөньяга күчәргә санаулы гына көннәр калган иде аңа. Туган көне—13 октябрь, Президент Указы—24 октябрь, вафаты—26 ноябрь... Безнең күңелләрне ул калдырган шигъри мирас кына юата хәзер. Ул котылгысыз көн аның каләмдәшләренә күпмедер дәрәҗәдә, әйе, алдан ук билгеле иде инде. Ләкин безне аның һәрвакыт оптимистик рухлы булуы гына алдап торгандыр. Аның республика матбугатында дөнья күргән соңгы шигырьләре безгә—исәннәргә—изге аманәт булып яңгырый.

Арабыздан вакытсыз киткән тагын бер каләмдәшебезне искә төшерик. «Рухият» нәшрияты былтыр Наис Гамбәрнең «Ачык калган тәрәзәм» дигән шигырь китабын бастырып чыгарды. Моңарчы без аның «Баш очымда—кояш» (1991), аннары «Күзләрем яфрак коя» (2001) дигән җыентыкларына игътибар иткән идек. Бер үк вакытта әдәбият белгече дә, тәнкыйтьче дә, шагыйрь дә булган иҗатчылар бармак белән генә санарлык. Наис, каләмдәшләренең иҗатын чын ихлас күңелдән анализлый белү белән берррәттән, башкаларга өлге-үрнәк булырлык әсәрләр дә тудырды.. Иренең иҗатына шулкадәр игътибарлы булган Гөлфирә ханымга да, каләмдәшенең язганнарын дөньяга чыгару өчен күп көч куйган, кереш сүз язган шагыйрь Рәдиф Гаташка да чын күңелдән рәхмәт әйтәсе килә. Тагын шунысы сөенечле, Наисның шигъриятенә битараф булмаган, якын якташы Зөлфәт каләмдәшенең вафатыннан соң аны күздән яшьләр чыгарырлык сүзләре белән олылады:

*Кайтыйк әле, дидем, Мөслимгә бер,*
*Безнең бәхет бары Мөслимдәдер...*

*Әйттем... никләр генә бу сүзем?-*
*Кайтып киттең, Наис, бер үзең...*
*Киттең... Казан сәер, буш инде...*
*Нәрсә дисең: «Наис, хуш инде».*
*Гел сокландым синең талантка,*
*Ыргып менгән сыман син атка*
*Шигырь дөньясында җилдердең.*

Зөлфәтнең бу шигъри тупланмасы беркемне дә битараф калдырмагандыр. Аның «Каны кызган кыргый ат», «Аунадынмы чын чирәмдә», «Аңлашылыр», «Асрама», әдәбиятыбыз классигы Әмирхан Еникига багышланган «Ифрат кадерле хатирә» шигырьләре дә үзенең яшьлегенә хас көчле накал белән язылган. Зөлфәт үзе үк күп кенә әсәрләрендә бүген дә ат тота—шигырьләрендә ат образы әледән-әле кабатлануы тикмәгә генә түгел.

Кайчандыр Зөлфәткә беренче шигъри сабаклар биргән Рәдиф Гаташ та әле ат уйнатырдай ир-егет. 65 ен тутырса да, анда шигъри дәрт ташып тора. Аның «Казан утлары»нда чыккан «Гомер сәхифәләре», гәрчә кайберләре инде электән таныш булсалар да, «Ватаным Татарстан» газетасындагы тупланмалары, «Шәһри Казан»дагы гарәп мотивлары һ. б. бүгенге иң таләпчән укучының да игътибарын җәлеп итәрлек. Без бу шагыйрьне элек-электән «мәхәббәт җырчысы» буларак беләбез. Ләкин еш кына ул дөньяның олуг илһамчыларына—һөнәрдәшләренә дә мөрәҗәгать итә. Бик табигый гомумиләштерүләр дә ясый. Мәсәлән, «Былбылга эндәшү» шигырендә ул:

*Югалтмаслармы соң моңны?*
*Сез—Бөек Былбыл иле,*
*Моң—гомумдәүләт байлыгы,*
*Ул милли дәүләт теле,—*

дигән нәтиҗәгә килә.

Узган ел иң актив иҗат иткән шагыйрьләрнең тагын берсе, мөгаен, ул—Роберт Әхмәтҗанов булгандыр. Аның «Казан утлары »ның 12 санында басылган «Кечке тәрәзәләр» циклы аеруча дулкынландыра. Ул укучыны фикеренең кыюлыгы, гамәлләренең сафлыгы, риясызлыгы белән җәлеп итә.

*Эт күңеле сөяк кенәмени—*
*Кем сөт бирсен нәни үксезгә?*
*Өрегез сез, бу бит Чечня түгел,*
*Фәләстин дә түгел бу сезгә!*

Автор бу шигырен:

*Ачык йөз бит бездә тәрегә дә!—*
*Толерантлык безнең фиркадә...*
*Этләр бәйле булып торсынмыни,*
*Бездәй бәйсез,*
*Демократик республикада?!*

Мин аның «Әле ярый...», «Теләү» һәм башка шигырьләреннән дә шундый ук уңышлы, ут чәчрәп торган юллар китерә алыр идем. «Ватаным Татарстан» газетасындагы ике әйбәт тупланмасын да телгә алыр идем.

Шулай да гаять үзенчәлекле шагыйребез Рөстәм Мингалим турында берничә сүз әйтмичә мөмкин түгел. Күпмедер күләмдә язмыш тарафыннан кыерсытылып, каләмдәшләре белән еш аралаша алмаса да, кулыннан каләмен төшергәне юк аның. «Казан утлары» Рөстәмнең «Минем белән яши хатирәләр» дигән гомер истәлекләрен һәм «Мәдәни җомга» аның тагын бер шигъри бәйләмен бастырып чыгарды. Аның шигъри планкасын һаман да шулай югары тотуы сокландыра.

Инде әйткәнемчә, узган ел юбилейларга аеруча бай булды. Шагыйрьләребез аерым китаплары белән дә, газета-журналларда басылып чыккан тупланмалары белән дә хисап тоттылар.

Татарстан китап нәшриятында Клара Булатованың «Каурый каләм—жил атым», Нур Әхмәдиевнең «Абага чәчәге», Шәмсия Жиһангированың «Ак күлмәгем», Рәшит Ягъфәровның «Тулпар моңы» дигән шигъри басмалары дөнья күрде. Бу китаплар хакында көндәлек матбугат, радио һәм телевидение күпмедер дәрәҗәдә мәгълүмат бирде инде. Мин алардагы бәяләр белән нигездә килешәм. Юбилейларга хас мактаулар күп булса да, ул материалларны хупларга кирәктер.

Болардан тыш нәшриятның үз планы тәртибендә Разил Вәлиевнең дүрт томлыгын тәшкил иткән басманың шигырьләрдән тупланган .китабын, Гөлшат Зәйнашеваның шигырьләрен, жыр текстларын, сәхнә әсәрләрен эченә алган «Сайланмалар»ын, Салисә Гәрәеваның «Йолдыз яңгырлары», Фирая Зыятдинованың «Безнең гомер», Рифә Рахманның «Айлы күлдәвекләр», Рифкать Закировның «Жан жылысы», Гакыйль Сәгыйровның «Йөрәк сере», Шәүкәт Гаделшаның «Чоңгыл» китапларын да узган елгы шигъри уңышлар рәтендә атар идем.

Яшь каләмнәргә дә лаеклы урын бирелгән. Айрат Суфияров, Рәис Абдулла, Гөлнур Корбанова шигырь сөючеләр алдында беренче чирканчык алганнар. Иншалла, киләчәкләре матур булыр дип фаразлыйк. Өлкәннәрдән инде әллә кайчан азау теш чыгарган Басыйр Рафиков, Хатип Касыймов, Чыңгыз Мусин булдыра алганча үз шигъри авазларын укучыга житкерергә тырышканнар. Түмән татарларыннан унлап автор әсәрләрен туплаган «Мин—Себер татары» дип исемләнгән китап та төрле төбәкләргә таралып яшәүче милләтебезнең яшәешенә бер шифалы импульс булыр дип уйлыйм.

Узган елгы әдәби продукция арасыннан мин тагын Равил Рахманиның «Мең чакрымга—мең чакрым» китабын һәм «Казан утлары» журналында чыккан шигырьләрен аерып алыр идем. Мин радиода эшләгән чагымда аның житди галим һәм таләпчән тәнкыйтьче булуына бер сокланган идем инде. Бу юлы ул мине камил шигырьләре һәм аларга салынган мәгънәле фикерләре белән гажәпләндерде. Аның бу әсәрләре халкыбызга булган ихлас мәхәббәт һәм тугърылык хисләре белән сугарылган.

*И Тәңребез, аң бир безгә -*
*Жәмгыбызга!*
*Еллар өзек... юллар төзик*
*Мәңгебезгә!*

Тагын бер шагыйребез ижатына игътибарны юнәлтмәсәм, тел очында тирбәлеп торган фикергә хилафлык китерермен шикелле. Татарстан китап нәшрияты Нур Әхмәдиевнең шактый калын ( 14 басма табак чамасы) «Абага чәчәге» дигән китабын, «Мәдәни жомга» атналыгы шигырьләр циклын бастырып чыгарды. Мин бу шагыйребезнең ижатын күптәннән бирле күзәтеп киләм. Заманында эчке рецензия дә язганым булды. Аның ижади үсеше һәркайсыбызның күз алдында—алар каләмдәшебезнең фикер тирәнлегенә, шигъри табышларына игътибар иткәннәрдер. Аларда авторның карашлары киңлеге дә, шигъри табышлары да бар. Бу шигырь сөючеләрне, һичшиксез, сөендерә.

Ә менә аның «Казан утлары»нда чыккан «Дәрдмәнд» поэмасы мине канәгатьләндерә алмады. Югыйсә, бөтенесе дөрес—жөмләләр төзек, рифмалар телтеш тидерерлек түгел. Ләкин поэма кебек катлаулы жанр өчен нәрсәдер уйлап житкерелмәгән шикелле. Укучыны киеренкелектә тота торган эчке пружинасы юк бугай әсәрнең. Чорлар чатында бераз аптырабрак калган, ләкин, һичшиксез, ак намуслы Дәрдмәнднең шәхси фажигасен да күрәсе килә. Әсәрдә тыпрап торган шундыйрак «ботаклар» да булса, шагыйрь теманы тулырак ачар иде. Хрестоматия хакыйкатьләре белән генә тормышның бар катлаулыкларын ачып бетереп булмый.

Татар шигърияте борынгы да, бай да, гыйбрәтле дә. Узган ел матбугатта йөздән артык авторның әсәре дөнья күргән. Безгә алмашка килүче яшь буын да бик сөендерде. Мин инде Луиза Янсуар, Рәзинә Мөхияр, Фәүзия Солтан кебекләрне үзенең

гыйбрәтле сүзен әйтердәй, өлгергән авторлар рәтендә саныйм. Иң сөендергәне: авылдашым Рифат Сәлахов булды. Аның иҗатын шагыйрьләр секциясендә тикшергәндә, һәммә кешенең фикере бер иде—оригиналь фикер йөртә, табышлары үзенчәлекле, перспективасы зурдан. Университетның юридик факультетында укыса да, аның дөньяны шигъри күзаллавы тирән—шигырь әлифбасын, әдәбият тарихын филологлардан бер дә ким белми. Аның «Иделем акчарлагы» бәйгесендә «Гран-при»га лаек булуы күп нәрсә турында сөйли. Рифатның тагын бер яшь каләмдәше Ленар Шәех та күңелдә зур өметләр уята. Һәрхәлдә аның көндәлек матбугатта дөнья күргән шигырьләре әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан һәрвакыт әйбәт каршылана.

Узган ел шигъриятнең поэма жанры беркадәр торгынлык кичерде шикелле. Инде телгә алынганнарыннан тыш, уңышлылар рәтендә Лена Шагыйрьҗанның «Галәм кисәтүе» дигән фәлсәфи пландагы поэмасын, Рәниф Шәриповның «Миннән бер өлеш» исемле лирик әсәрен генә атарга мөмкиндер. Алар, һичшиксез, жанрның кырыс таләпләренә туры килә. Шулай да Рөстәм Зариповның «Фоторәсем», Заһит Фәйзинең «Янам-сызланам», Фирдәвес Әһлиянең Бакый Урманчега багышланган «Мизгел балкышы», Хәнәфи Бәдигыйнең «Дала бөркете», Резеда Вәлиеваның «Муса Җәлил» поэмасыннан өзекләр минем күңел кылларына кагыла алмады.

Тагын бер өлгергән мәсьәлә—ул «Татар поэзиясе антологиясе»нең яңа басмасы кирәклеге. Моннан 50 ел элек чыгарганы искерде дә искерде инде. Соңгы ике томлыгы да бүгенге таләпләргә җавап бирми. Чөнки аның борынгы чорны яктыртканы да, бүгенге заманга караганы да тулы түгел—бу хакта Рәдиф Гаташ матбугатта җентекләп язып чыкты инде.Ул басмага безнең үткән гасырлардагы бик күп шагыйрьләребез кермәгән. Совет чорына караганы да Ленин һәм партия турындагы шалтыравыклы әсәрләр белән тулы. Өченчедән, антологияләр төзү принцибы сакланмыйча, авторлар туган еллары буенча түгел, язучылар берлегенә керү вакытына карап урнаштырылганнар. Андый акылсыз фикер кем башына килгәндер—цивилизацияле халыклар беркайчан да болай кыланмый.

Менә ничә еллар инде без язучыларның белешмә китабы турында сүз алып барабыз. Аны көтә-көтә тәмам көтек булганбыздыр. Ул редакцияләргә дә, иҗат оешмаларына да, җитәкче даирәләргә дә һава кебек кирәк! Энциклопедиядәге кыска-кыска мәгълүматлар белән генә булмый.

Алдагы бурычлар—мөһим, иҗат көчләре—әзерлекле. Заман кыенлыкларына карамыйча, фидакарьләрчә иҗат итәсе бар—нишлисең, язмышыбыз шундый инде безнең. Гел болай гына бармас әле бу дөнья. Иртәгә чыгасы кояшны шатланып каршыларга язсын!

---

## Гали АРСЛАНОВ

# ЕЛЛЫК ДРАМАТУРГИЯ



Татар драматургиясенең еллык үсеше үткән белән киләчәк арасында бара. Шуна күрә бу туктаусыз процесстагы үсеш-үзгәреш тенденцияләре, проблемалары кичә яки бүген генә ачыкланган-билгеләнгән нәрсәләр түгел. Аларнын кайберләре (мәсәлән, миллилек яки татар идеясе, милләтпәрвәрлек) йөз егерме еллык тарихы булган зур драматургиябызнын ин беренче әсәрләрендә үк билгеләнеп, бүгенге көнгә янарып, күптөрле сыйфатлар белән баеп, янадан әйләнеп кайтса, икенчеләре исә чагыштырмача күптән түгел, ягъни сиксәненче-туксанынчы еллар чигендә формалашты, үсеш алды. Андыйлар да аз түгел. Чөнки кинәт үзгәргән вәзгыять, ил, халык тормышындагы көтелмәгән борылышлар, әлбәттә, тормышның үзенчәлекле көзгесе булган театр сәнгатендә,яна азык бирә

килгән драматургиядә чагылыш табарга тиеш иде. Һәм бу шулай булды да.

Гасырның соңгы дистә ярым елында илдә «үзгәртеп кору» игълан ителеп, азмы-күпме демократия җилләре исә башлагач, милли автономик республикаларда сәнгать үсеше өчен элеккегә караганда да тискәрерәк шартлар барлыкка килде. Дәүләт дотацияләре күпкә кимеде. Тотрыклы булмаган икътисад, халыкның бай һәм ярлы катламнарга бүленүе иң элек матди яктан бер яклаусыз калган иҗат зыялыларына «сукты». Көтелмәгәндә кыргый базарның болганчык мөнәсәбәтләре уртасында калган сәнгать әһелләре, шул исәптән драматурглар да, яшәү өчен кирәк булган көндәлек минимумнан да мәхрүм калдылар. Дәүләт тарафыннан бирелә торган азмы-күпме ярдәм, иҗат оешмаларына бүленгән торак-фатирлар күпкә кимеде. Әмма, матди яктан драматургия үсеше өчен шартлар авырлашса да, базар икътисадының кайбер унай яклары да булды. Әйтик, демократияләштерү процессы иҗат әһелләре иреген әлегәчә буып килгән тоталитар режимның тоташ идеологик контроленнән азат итте. Дөресрәге, идеологик ориентирлар бөтенләй юкка чыкты. Бу исә үз чиратында мона кадәр әдәбият-сәнгать хезмәт иткән аерым сыйныф мәнфәгатьләрен читкә этәреп, гомумкешелек кыйммәтләрен, кеше гомере кадере, шәхес иреге проблемаларын алга куярга, милли үзаңны үстерү, тәрбияләү эшенә керешергә булышты. Башланып киткән бу процесс драматургияда иң элек иҗтимагый-сәяси драма жанрында чагылыш тапты. Нәтиҗәдә тоталитар режимны, бюрократик система функционерларын фаш итә торган Т. Миңнуллинның «Бажа мал түгел, кәҗә туган түгел», З. Хәкимнең «Телсез күке», «Легионер», Р. Батулланың «Җимерелгән бәхет'' кебек әсәрләр язылды. Аларда тоталитар система машинасына эләгеп җимерелгән, сытылган кеше язмышлары, гаилә бәхете, Сталин ГУЛАГ-лары корбаннары трагедиясе һәм бүгенге көндә демократия исеме астына поскан, ләкин кеше шәхесен изә, таптый, җир белән тигезли торган бюрократик система идарәчеләре турында сүз бара. Бу әсәрләрдә авторлар күп очракта кеше шәхесенә каршы юнәлтелгән, аларның җаннарын гарипләткән, җинаятьләрне, куркыту алымнарын, террорны сәнгать чаралары ярдәмендә ышандырырлык итеп ачуга, кире кагуга ирешәләр.

Тоталитар режимның аяусыз сәясәте нәтиҗәсендә аерым шәхесләр генә түгел, хәтта Кырым татарлары, карачәй, ингуш һ. б. кебек бөтен бер төркем халыклар да гаепсездән гаепләнеп, үз туган илләреннән яшәү өчен бөтенләй шартлар булмаган чит җирләргә сөрелделәр. Быел язылып, «Яңа татар пьесасы» конкурсына җибәрелгән пьесалар арасында депортацияләнгән Кырым татарлары кичергән коточкыч афәт, вәхшилекләр, гаилә бәхетсезлекләренә багышланган «Бакчасарай гөлләре» исемле мелодрама да бар. Үзен «№77» дип билгеләгән автор әле милли драматургиябызда бөтенләй чагылмаган өр-яңа темага мөрәҗәгать итеп, мона кадәр аерым шәхес язмышы кысаларында гына яңгыраган бу зур теманы, бөтен бер халык язмышы, ил трагедиясе масштабына күтәргән. Сәнгатьчә эшләнеш ягыннан кайбер кимчелекләр булуга да карамастан (әйтик, сюжет линиясенең беркадәр схема буенча үсүе, милли гореф-гадәтләр бирелеше), гомумән алганда әсәр театрларыбызның игътибарына лаек.

Демократия җилләре тәэсирендә татар халкында үз милләтенең чын тарихына, әдәбият, сәнгатенә карата көчле кызыксыну уянды. Мәдәниятебезнең ертып ташланган, яндырылган, яки башкача юкка чыгарылган битләрен яңадан барлау, тергезү эше башланды. Октябрь инкыйлабыннан соң чит илләрдә яшәгән Г. Исхакый, С. Максуди, Ф. Туктаров, Й. Акчура кебек бөек шәхесләребезнең иҗади мирасын, саф исемен халыкка кире кайтару эше ул шулай ук демократиянең зур казанышы, милләтнең мәдәни тормышында зур вакыйга булып бәяләнергә хаклы. Шуларга аваздаш буларак драматургларыбыз Октябрьгә кадәрге чорда ук Г. Камал, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, К. Тинчурин кебек олуг әдипләребез башлап җибәргән бик кирәкле эшне—татар халкының милли үзаңын уяту, тәрбияләү эшен—яңадан тергезеп җибәрделәр. Шунысын да әйтик, бу адым бик вакытлы һәм кирәкле иде. Чөнки сәнгать үсеше беркайчан да идеологик бушлыкны күтәрми. Коммунистик идеалларның бәясе төшкәч, алар урынын милли идея, гомумкешелек кыйммәтләре алу бик табигый, урынлы булды.

Соңгы елларда драматургларыбыз, театрлар татар халкының менталитетын билгеләү, милли үзаңын үстерү буенча берничә юнәлештә эш алып бардылар.

Шуларның иң беренчесе—сәхнә әсәрләре ярдәмендә халкыбызның данлы тарихын, бөек шәхесләрен гәүдәләндерү һәм шулар аша тамашачыларда, укучыда милли горурлык хисе тәрбияләү. Үзгәртеп кору елларында сәхнәдән гәүдәләндерелгән бөек шәхесләребез рәтенә Ю. Сафиуллин әсәрендәге «Идегәй», Р. Хәмиднең «Хан кызы», М. Маликованың «Сөембикә» пьесаларындагы Сөембикә образларын да кертеп була. Ә Р. Батулланың татар, башкорт, казакъ халыкларының уртак шагыйре Акмуллага багышланган «Юл газабы» шигъри трагедиясе үзенчәлекле формасы, аерым актер-башкаручыга тәгаенләнгән булуы белән игътибарны җәлеп итте.

Шул ук авторның «Җимерелгән бәхет» пьесасы да Заһидә һәм Кәрим Тинчуриннар, Гаяз Исхакый, Габдулла Кариев, Фатыйма Ильская кебек бөек сәнгатькәрләребезнең бөтен бер образлар галереясын тәкъдим итүе, аларның тормыш һәм иҗат биографияләренә өр-яңа фактлар өстәве белән кызыклы.

Быелгы сезонда да драматурглар һәм театрларыбыз бу өлкәдә шактый үзенчәлекле эш башкардылар. Югарыда аталган «Яңа татар пьесасы» конкурсына килгән әсәрләр арасында үзен «Гөлназ» дип атаган авторның «Гәүһәршад» пьесасы, Ф. Галиев һәм Р. Әюповның Казан яшь тамашачы театрында куелган «Җырларым», « Печән базары» спектакль-композицияләре әнә шундыйлардан. Борынгы тарихыбызда тирән эз калдырган Мөхәммәдәмин хан кызы Гәүһәршад тормышының аерым бер чорын күрсәткән һәм М. Җәлил, Г. Тукай кебек бөек шагыйрьләребезнең иҗатларын популярлаштыру максаты куйган бу әсәрләр бәлки зур драматургия таләпләренә җавап биреп тә бетермиләрдер. Әмма мондый омтылыш-эзләнүләр драматургиядә дә, театрларыбыз репертуарында да сакланырга тиеш. Чөнки югары сыйфатлы әсәрләр буш урында, йомшартылмаган туфракта барлыкка килә алмыйлар.

Татар халкының менталитетын, гореф-гадәтләрен, бай, үткен телен, фольклор хәзинәсен, акылын, зирәклеген, юмор үзенчәлекләрен, көлү культурасын чагылдырган әсәрләр дә элек-электән халкыбызның милли үзаңын тәрбияләүгә хезмәт итеп киләләр. Хәтергә төшерик, КПСС Үзәк Комитетының мәдәниятебез үсешенә шактый зыян китергән 1944 елгы мәгълүм карары нигезендә Н. Исәнбәтнең «Идегәй» трагедиясе белән бер рәттән шушы ук авторның «Җирән Чичән белән Карачәч сылу», «Хуҗа Насретдин» әсәрләре юкка гына репертуардан алынмады. Мондый пьесаларның милли аң тәрбияләүдәге ролен тоталитар режим функционерлары ул вакытта ук бик яхшы аңлаганнар. Бүгенге көндә, кызганычка каршы, мондый пландагы югары сыйфатлы әсәрләр сирәк языла. Быел язылган пьесалар арасында Сәйф Сараи поэмасына нигезләнгән «Сөһәйл вә Гөлдерсен», Гөлкәйнең «Йөзен яшерүче хан кызы», Нижнекамск театры, Казан яшь тамашачы театрында уйнала торган, фольклор мотивлары файдаланылган Р. Кожевникованың «Шаян мәче», М. Закированың «Серле балдак маҗаралары» кебек әсәрләр бар. Ләкин аларга фәлсәфи тирәнлек, халкыбызның үткен юморы житенкерәми. Шуңа күрә дә кай очракта режиссерлар билгеле авторларның элеккерәк елларда язылган әсәрләренә мөрәҗәгать итәләр. К. Тинчурин исемендәге театрда куелган М. Әмирнең «Гөлшаян», Д. Салиховның «Танышу, кавышу театры», Ю. Әминовның «Өти балак Гөлүзә» пьесалары әнә шундыйлардан.

Халкыбызда милли үзаң тәрбияләүдә шулай ук драматургия, театрлар тарафыннан тәкъдим ителә торган милли эстетик идеал, эстетик нормалар да житди әһәмияткә ия. Бу турыдан-туры халыкның бүгенге көндәлек тормышын чагылдыру, өлге алырлык шәхесләрен табу һәм сәхнәгә күтәрү, милләт алдында торган бурыч-проблемаларны билгеләү һәм сәнгать чаралары ярдәмендә аларны чишүнең үрнәк юлларын күрсәтү белән бәйләнгән. Бүген языла торган пьесаларның зур күпчелеге, әлбәттә, халкыбызның хәзерге тормышын, яшәү рәвешен, проблемаларын чагылдыруга багышланган. Әмма мин аларны милләтебез яшәешен төрле яктан да иңли, үзләштерә, чагылдыра дия алмыйм. Менә кайбер саннар һәм фактлар. 2006 ел дәвамында, конкурска килгән һәм театрларда куелган яңа әсәрләрне санасаң, якынча утыз биш пьеса язылган. Шуларның яртысыннан югарысы авыл тормышы материалы нигезендә, гаилә, ир, хатын, егет-кыз мөнәсәбәтләренә багышланган. Аларның зур күпчелегендә әһәмияте ягыннан ил, җәмгыять, милләт дәрәҗәсендәге масштаблы проблемалар күтәрелми. Аңлашылмаучылык, ызгыш-талаш, симпатия-

антипатия, үзара мөнәсәбәтләр ачыклау... Арада псевдонимы «Заманов» булган авторның—«Без китәбез ахыры»..., үзен «Сантый» дип атаган авторның—«Дивана», «Имән алып»ның—«Лаләләр», «Умартачы»ның—«Нигез», «Төнбоек»ның—«Адашкан юл» кебек, авылда формалашып килгән яңа бай хуҗалар һәм гади халык арасындагы кискен мөнәсәбәтләр, туып-үскән нигезнең газизлеген, изгелеген раслаган һәм уйланмыйча эшләнгән ялгышлар өчен җаваплылык кебек җитди проблемалар күтәргән әсәрләр дә күренә. Тик алар да сәнгатьчә эшләнеш ягыннан тиешле югарылыкта түгел. Кайсысы күпсүзлелек белән интегә. Ә кайбер авторлар инде драматургиядә очраган ситуацияләрне кабатлыйлар. Шулай ук кайбер персонажларның характерлары—усал, үзсүзле, мәрхәмәтсез яңа татар бае, авылның яраткан исереге, үз дигәнен булдыра алмаган җебегән ир (һ. б.)—пьесадан пьесага күчә килә. Гәрчә аларның авторлары төрле кеше булса да. Шулай ук әсәрләрдә хатын-кыз җинаятьчелеге, эчкечелек, иң борынгы профессия ярдәмендә байлык тупларга омтылу кебек, гүзәл җенес вәкилләренә замананың бик үк унай булмаган тәэсирен чагылдырган «Араш»ның «Утрау», «Әбү Бәкер»нең «Бишек җыры», Гөлназ Мәвлиева-Шәмсинең «Асыл сере» кебек әсәрләр дә бар. Проблемалар атала, күтәрелә, әмма аларның сәнгатьчә чишелеше тиешле дәрәҗәдә түгел.

Драматургларыбызның зур күпчелеге авыл җирлегеннән чыккангамы, аларга авыл тормышы, авыл тирәлеге якын. Шуңа күрә алар бүген шәһәрләрдә яшәсәләр дә, әсәрләре өчен материалны күбрәк шуннан алалар. Бу табигый хәл, аларны моның өчен гаепләп булмый. Ә бит бүгенге көндә халкыбызның шактый өлеше калаларда яши. Алар белән нишләргә? Шәһәр татарларының сәнагы эшчәнлеген белмәгәнгә, хезмәт проблемаларын ныклап торып төшенмәгәнгә күрә дә безнең бу өлкәдәге аз санлы пьесаларыбыз гаилә мөнәсәбәтләрен, төрле буыннар арасындагы уңай яки тискәре бәйләнешләрне, торак-фатир каршылыкларын, хатын-кызларның кияү сайлау процессын, ир-егетләрнең сөйгәннәре күңелен яулау тирәсендә бөтерелә. Болар да аз түгел. Болар да кирәк. Ләкин бит без халкыбызның гаилә мөнәсәбәтләре белән генә дөньякүләм масштабларга чыга алмыйбыз. Ә бит бүген без «татарны дөньяга танытырга кирәк!» дип сөйлибез. Юкмыни безнең милләтебезне күтәрә торган масштаблы, зур эшләр башкара торган шәхесләребез? Икеләнми әйтәм—бар! Бар гына түгел—күп! Бары тик драматургларыбызга алар дәрәҗәсендә фикер йөртеп, алар эшләгән эшләрнең дәрәҗәсен аңларга, яшәгән мохитне аңларга масштаблылык кирәк. Өй, гаилә мөнәсәбәтләрен даими файдаланып, вакланып китмәдекме без?

Бүгенге татар драматургиясенең үсеш шартлары, традицияләре турында сөйләгәндә, әлбәттә, сөенеп меңъеллык Ислам мәдәниятенең халкыбызга яңадан кайтуын ассызыклап әйтергә кирәк. Үзгәртеп кору башлангач ук тизләнеш алган бу—иманга кайту—процессы бүгенге көндә милләт тормышында хәлиткеч факторларның берсе вазифасын үти. Динебезнең татар халкын милләт буларак саклап калудагы әһәмиятен истә тоткан хәлдә, без аның менталитетыбызны, үзаңыбызны тәрбияләү, үстерү, саклау өлкәсендәге ролен дә билгеләп үтмичә кала алмыйбыз. Драматургия, театр сәнгате өлкәсендә дә сәнгать үсешенә бүген аеруча нык тәэсир итә торган әлеге факторны исәпкә алмыйча берничек тә мөмкин түгел. Бу җәһәттән мин иң элек Чаллы театрында Кол Гали әсәре буенча куелган «Йосыф», Минзәлә театрында Ф. Галиев инсценировкаларында «Сөннәтче бабай» һәм «Остазбикә» (режиссерлары Ринат Әюпов ) кебек спектакльләрне искә төшерәм. Бу әсәрләр Республика мәдәни тормышында чын мәгънәсендә иҗади ачыш, зур яңалык буларак кабул ителде. Әлеге уңышлы башлангыч безнең драматургиядә быел өр-яңа әсәр белән дәвам ителде. Конкурска килгән пьесалар арасында үзен «Мөәзин» дип атаган авторның «Мулла» исемле ике пәрдә һәм ун күренештән торган драмасы бар.

Соңгы еллардагы драматургиянең яшәү шартлары, тематикасы, күтәргән проблемалары, дини һәм әхлакый мотивлар, эстетик идеал турында сөйләшкәннән соң чират нәүбәтен ниһаять, язылган пьесаларның сыйфатына, алда торган кайбер хәл ителәсе мәсьәләләргә дә җиткәндер.

Иң күзгә ташланганы—авторларыбызның да драма теориясен тирәннән белмәве. Күп кенә пьесалар драма калыпларына сыймый, композиция ягыннан аксый. Кайбер авторларга вакыйгаларны, персонажларны кискен конфликт тирәсенә туплый белү

житми. Шуна күрә дә тамашачыны киеренкелектә тота торган кискен көрәшле пьеса урынына драма формалары, диалог кулланып язылган хикәя, повестьлар, соңгы вакытта хәтта романнар да дөньяга килә. Бәлки болары да кирәктер, бөтенләй үк сызып ташламыйк. Әмма сәхнә тамашасының үзәгендә бәрелеш, көрәш ятарга тиеш. Бу—кире кагылмый торган канун.

Бүгенге көндә милли драматургиябыз үсешенә тискәре тәэсир итә торган тагын бер мәсьәләгә игътибар юнәлтер идем. Ул да булса драматурглар белән театрлар арасында үзара аңлашып эшләү, татулык житмәү. Театрларыбызның репертуарына күз салсак, анда соңгы елда язылган бер-ике әсәрне генә күрербез. Калганнары йә классика, йә драматургларыбызның элеккерәк елларда язылган әсәрләре. Табигый, алары да куелырга тиешле. Ләкин бүгенге драматургия репертуарда иң беренчел урынны тотарга тиеш. Башкача заман геройларын, милләтнең көндәлек проблемаларын сәхнәдә ничек чагылдыра алабыз соң? Ул инде Республика вакытлы матбугаты битләренә дә саркып чыкты. Ике яктан да бергә җыелып, мәсьәләне уртага салып сөйләшер вакыт житмәде микән? Драматурглар театрларны гаепләп, ә театрлар авторларга канәгатьсезлек белдереп кенә унай нәтиҗә чыгар дип уйлавы кыен.

Йомгак ясап, иң элек бүгенге татар драматургиясенең үсеш-үзгәреш процессында икәнен билгеләп үтик. Таянырга аның 120 еллык бай иҗат мирасы, әле бүген дә актив эшләп килә торган Т. Миңнуллин, Р. Батулла, З. Зәйнуллин кебек аксакаллары, инде олпатлыкка йөз тоткан Р. Хәмид, Ю. Сафиуллин, З. Хәким, Д. Салихов, М. Гыйләжев, Р. Зәйдулла, Ф. Галиев, Г. Каюмов, Аманулла, Х. Ибраһим кебек көчле урта буыны, әле күптән түгел генә зур сәнгатькә килеп керсәләр дә театрлар репертуарында инде урын алырга өлгергән И. Зәйниев, З. Минһажева кебек яшь көчләре бар. Мәдәният министрлыгы, Язучылар берлеге белән Г. Камал исемендәге театр оештырган «Яңа татар пьесасы» конкурсы даими үткәрелеп килә. Димәк, бергәләп эшләгәндә милли театрларыбызны репертуар белән тәэмин итәрлек яңа пьесалар туар, алга таба да драматургиябез даими үсештә булыр дигән өмет бар.

---

**Газинур МОРАТ**

## КАРАҢГЫЛЫКНЫ СҮККӘНЧЕ, ШӘМ КАБЫЗ



Әле без яшьрәк чакларда да үз-үзен хөрмәт иткән әһле каләм арасында «публицист» дигән сүз бигүк модада түгел иде. Барча халык да партия сузган туры юлдан тәпиләгән, шул юлдан бер адым читкә тайпылу да жинаять саналган заманнарда «публицистика» дигәннәре, чыннан да, кызыл сүз сөйләү кебегрәк аңлашыла иде бугай... Матбугатта «милләт» сүзен куллану тыелган дәверләрне дә яхшы хәтерли әле безнең буын. Йә, әйтегез, шундый шартларда ничек инде публицист булып йөрмәк кирәк? Әмма әдәбиятыбызның намусы саналган әдипләр ул чакта да милләт хакын хаклап әдәби әсәрләр дә иҗат итте, публицистик мәкаләләрен дә язып, бастыра торды. Без әнә шуларны укып үстек.

Сүз дә юк, хәзерге вәзгыятьне элгәрләребез өлешенә туры килгән иҗади шартлар белән чагыштырырлык та түгел. Шунадыр, күрәсең, бүген кулына каләм алган һәркемнен—олысының да, кечесенең дә—публицист буласы килә торгандыр. Бик тә табигый теләк, билгеле. Матбугатта азмы-күпме сүз ирегә бирелгәндә—бигрәк тә.

Әйе, соңгы 20 елда публицистика заманасына күрә иң кәттә жанрга әйләнеп китте.

Хәзер укылышлы публицистик мәкаләсез чыккан газит-журналның әбүнәчесен саклап кала алуы бик икеле. Шуна күрә матбагачылар үз басмаларында публицистлар өчен махсус рубрикалар булдыра. Мәсәлән, «Ватаным Татарстан» газитендәге—«Без әле кая барабыз», «Жиденче каттан караш»; «Татарстан яшьләре» газитендәге—«Кызыл тышлы дәфтәрдән»; «Мәдәни жомга» газитендәге—«Мин әйттем», «Атнаның сәяси мизгелләре», «Идел» журналындагы—«Зәйдулла каланчасы», «Сиражи күсәге»—әнә шундыйлардан. «Казан утлары» журналы исә андый язмаларны, әлләни кыландырып тормыйча гына, «Публицистика» дигән рубрикада биреп бара.

Рубрика булдыру бер хәл, әмма аны даими рәвештә, еллар дәвамында кызыклы, укылышлы итеп алып барырдай авторлар да кирәк ич әле. Шөкер, ихтыяж булгач, бездә бу эшнең дә үз маһирлары барлыкка килде. Мина калса, Мансур Мортазин да, Туфан Миннуллин да, Фоат Уразай да, Ркаил Зәйдулла да, Искәндәр Сиражи да үз кишәрлекләрен матур гына «сөреп» бара. Әле өстәвенә, 2006 елда «Идел-Пресс» нәшриятында Мансур Мортазинның публицистик язмалары тупланган «Дөнья дилбегәсе кем кулында» дигән саллы китабы да дөнья күрде. Китап, дигәннән, нәшриятларыбызның 2006 елгы тематик планына күз салсак, анда публицистика жанрына караган мәжмугалар бармак белән генә санарлык. Һәм аның шулай булуы бик тә табигый, минемчә. Бүген көндәлек матбугатта публицистик чималга әлләни кытлык булмаса да, көндәлек ыгы-зыгылар белән артык мавыкмыйча, вакыт агышын тоеп, мөкәммәл тел белән, әдәби әсәр дәрәҗәсенә житкереп язылган публицистик хезмәтләр алай күп түгел. 2006 елда, мәсәлән, Татарстан китап нәшриятында Рашат Сафинның «Татар миссиясе», Солтан Шәмсинең «Күк капусы ачылса» дигән китаплары дөнья күрсә, «Мәгариф» нәшрияты Роберт Әхмәтжанның «Каләм жиле», Зиннур Мансуровның «Күнелдә фидаи яшәсә» дигән китапларын бастырып чыгарган. Болар янына тагын Рәфыйк Шәрәфиевнең Татарстан китап нәшриятында чыккан «Татар эзләү» дигән мәжмугасын да өстәргә буладыр. Гәрчә, анда әдәби тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр, китапларга күзәтүләр туплап бирелсә дә, автор әдәби әсәрләр нигезендә милләтебез алдында торган көнүзәк мәсьәләләр турында сүз алып бара, китапның аннотациясендә әйтелгәнчә, «заманыбызның милли героен, каһарман татар кешесен эзли, андыйларның нилектән аз булуы турында уйлана». Уйлана гына түгел, аның кайбер житди сәбәпләрен дә ачып бирә. Һәм, гомумән, Рәфыйк Шәрәфиевнең көндәлек матбугатта даими басылып килгән публицистик мәкаләләрен укыганда да, еракта чынлап та яхшырак күренә бугай, дип уйлап куясың. Балтач белән Казанның арасы да нибары йөз генә чакрым бит инде, югыйсә.

Инде янәдән югарыда телгә алынган дүрт китапка әйләнеп кайтсак, Роберт Әхмәтжанны да, Зиннур Мансуровны да, Солтан Шәмсине дә, Рашат Сафинны да без, пакусны киң алып, мәсьәләнең төбенә тоз коеп яза белүче каләм әһелләре буларак беләбез. Мина калса, аларның китаплары да һәркайсы аерым-аерым сөйләшүгә лаек, һәм матбугатта әлеге хезмәтләр турында үзләренә лаек житди сүз һичшиксез әйтелер, дип ышаныйк.

Шулай да бу урында бер нәрсәне искәртеп узу кирәктер: Рашат Сафинның «Татар миссиясе» дигән хезмәтен, ихтимал, тәгаен генә бер әдәби жанр кысасына да кертеп булмый торгандыр. Дөресен генә әйткәндә, бездә әле монарчы андый китапның күренгәне дә юк иде шикелле. Үтә дә гадиләштереп шәрехләгәндә, аның эчтәлеген өч сүз белән «геосәясәт һәм татар халкы» дип тәгаенләргә мөмкин булыр иде.

Сер түгел, без инде үзебезне ничарадан бичарага санап, бетәбез, дип сукрана-сукрана, үзара булашып яшәүгә тәмам күнеккән һәм күнектерелгән кавем. Евг. Евтушенко әйтмешли, бездән коллыкны тамчылап түгел, чиләкләп чыгарып түгәсе бар әле! Һәм менә шушы игелекле эшне башкару татар әдәбиятының, шул җөмләдән публицистикасының да, төп вазыйфаларыннан берсе булып торадыр. Каләм әһеле кыеп әйткән-язган һәр сүз-калимә, ахыр чиктә, бер нәрсәгә—адәм баласын мескенлек, кимсенгәнлек, кимлек кәсафәтеннән арындыруга хезмәт итәргә тиештер. Бертуктаусыз инкыйраз турында сүз куертып, балавыз сыгып, сукранып утырыр өчен әлләни акыл кирәкми. Караңгылыкны сүккәнче, бер нәни шәм кабызуың хәерлерәк, дигән әнә Конфуций да. Ә нәни генә бер ут шәүләсе дә төнге юлда адашып калган мосафир күңелендә яшәүгә өмет уята. Без дә шул мосафир хәлендәрәк түгелмени?

*Татар халкы! син үләргә мәхкүм инде,*
*Дару үтмәс дәрәҗәдә мәсмүм инде,*

—дип, Тукай заманында да, ана кадәр дә, аннан соң да тәкрарлаганнар. Ә нәтиҗәдә нәрсә килеп чыкты? Татар галәмен тоташ өметсезлек биләп алды. Татар үз-үзенә ышанмый башлады, денен, телен, исемен, хәтта милләтен алыштырырга керешге. Сүз дә юк, моңа, беренче чиратта, Мәскәү урнаштырган неоколониаль режим гаепле. Ләкин бер ул гына микән? Бу—безгә Ходай тарафыннан җибәрелгән бер сынау да түгелме икән? Әллә соң без: «шат яратса да җиһанга, ят яраткан Раббысы», дип хаталанабызмы? Әллә соң без, киресенчә, Раббының сөеклесеме? Үзебез үк күреп торабыз ич: ин авыр сынауларда да татар үзенең яшәүчәнлеген, тормышчанлыгын һәрдаим раслап килде. Ә инде ил-көн алдында, авыз тутырып: «Булдырабыз!»—дип әйтер өчен дә, артында сират күперләрен кичеп тә исән-аман калган, булдыклы үз халкың торуы кирәк.

Коръәни Кәримнең «Пәрдә» сүрәсендә: «Без яралткан халыклар арасында шундый бер өммәт бар: алар һич туктамыйча хакыйкатьне алга сөрүче, гаделлек урнаштыручы»,—диелә. Ни кызганыч, әлегә дөнья дилбегәсен үз кулында тотучы өммәтләр арасында хакыйкатьне алга сөреп, гаделлек урнаштырырга теләүчеләр бик күренми. Киресенчә, алар күбрәк «алтын бозау»га табынмаучы кавемнәргә зыян-зәүрәт салу белән шөгыльләнә шикелле.

Капма-каршылыкларның берлеге һәм көрәшенә нигезләнгән менә шушы глобаль сөрешләр вакытында татар нишләргә тиеш? Кул кушырып, инкыйразын көтеп утырсынмы ул, әллә геотарихи вазыйфасын аңлап, шуны башкару эшенә керешсенме? Рашат Сафинның «Татар миссиясе» дигән китабы әнә шул илаһи вазыйфаны барыбызга да аңлаешлы итеп шәрехләп бирүгә багышланган. Аны укып чыккач, Конфуцийның канатлы сүзен янә бер кабатлап куясы килә: «Карангылыкны сүккәнче, бер нәни шәм кабызуың хәерлерәк».

Үткән ел мин Марсель Галиевнең җанрын ачыклавы кыенрак булган «Рух» дигән әсәрен укыгач та, шундый ук халәт кичергән идем.

Разил Вәлиев белән Туфан Миңнуллинның парламент мөнбәреннән халкыбыз мәнфәгатьләрен яклап ясаган чыгышларын тыңлагач, укыгач та, милләттәшләребезнең билләре турая, рухлары ныгый төшәдер, дип беләм.

«Казан утлары» журналында Рафаэль Хәкимнең төрки-татар цивилизациясен шәрехләүгә багышланган күләмле хезмәте белән танышкач та, дөньяда халкыбызга карата тарихи гаделлекнең торгызылачагына ышанычым тагын да артты. Тарихны идеология белән бутамыйча, дөньякүләм икърар ителгән тарихи чыганакларга нигезләнеп язылган әлеге фәнни-популяр әсәрнең авторы Рафаэль Хәкимгә дә, аны һөнәрмәндләрчә тәрҗемә кылган Нурсөя Шәйдуллинага да, хезмәтне сигез ай дәвамында бастырып килгән «Казан утлары» журналы редакциясенә дә укучылар рәхмәтле булып калгандыр, дип уйлыйк.

Ни кызганыч: бүген дә мәктәп укучылары, югары уку йортлары студентлары «Русия тарихы» дигән фәнне җиңүчеләр язып биргән дәреслекләр буенча өйрәнә. Ә алар, аңлашылганча, тарихи дөреслекне аңлатудан шактый ерак тора. Мәгәр, Потемкин йортлары кебек, ялганга корылган псевдофәннең дә, псевдоидеологиянең дә, псевдодәүләтнең дә киләчәге була алмый. Менә шуңа күрә, бераз гына форсат килеп чыгуга, һәрбер халык үз хәсгәрен үзе күрергә, үз тарихын үзе язарга керешге дә бугай инде. Ләкин бу юлы да күпләр хәттин ашканлыктан арына алмады: берәүләр үзләрен тәгәрмәч уйлап тапкан халык итеп күрсәтергә тырышты, икенчеләре цивилизация бишеген тибрәтүчеләр кавеменнән үк булып чыкты. Һәм ул псевдоачышлар нигездә барысы да бер нәрсәгә—тарихта татар факторын тулысынча инкарь итүгә яки аны каралтып күрсәтүгә корылган иде. Әмма Аурәзия киңлекләрендәге тарихи сөрешләр турында сүз алып барганда, татар факторыннан башка берниндн җитди хезмәт язу да мөмкин түгел. Рафаэль Хәкимнең «Татар рухы» дигән әсәре бу җәһәттән тарих белән уйнаучыларга гыйбрәтле бер дәреслек, әсбап-кулланма да булып тора.

2006 елда «Казан утлары» журналы редакциясе, «Сүнмәс утлар балкышы» дигән бик тә саллы китап чыгарып, тагын бер игелекле эш башкарды. Журналның мең саны дөнья күрү уңаеннан нәшер ителгән әлеге 88,5 басма табаклы мәҗмугада әдәбиятның төрле жанрларына караган 300дән артык әсәр урын алган. Ихтимал, анда гел шаһәсәрләр генә дә тупланмагандыр (һәм мәҗмуганы төзүче авторлар андый бурыч та куймагандыр), әмма китап әдәбиятыбызның 80 елдан артыграк тарихын, аның үсеш-үзгәрешен күзаллар өчен менә дигән әдәби-гыйльми чыганак булып тора.

Фәүзия Бәйрәмованың, Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез белән якыннан аралашып, аларның халкын яклап язган әтрафлы мәкаләләре, юльязмалары да татар публицистикасының күркәм бер сәхифәсен тәшкил итә. Үз вакытында әлеге авыр да, игелекле дә эшне фидакарь әдибебез Тәүфикъ Әйди башкарып килде. Изге урын буш тормас, дигәндәй, бу вазыйфаны хәзер тагын бер фидакарь затыбыз—Фәүзия Бәйрәмова—үз өстенә алды.

Сүз дә юк, ирексезләү булган җирдә язучы лирика белән генә күңел юатып утыра алмый. Ана, ирексездән, публицистика, ягъни сәясәт белән дә шөгыльләнергә туры килә. Чөнки, бер акыллысы әйтмешли, сәясәт белән шөгыльләнмәсәң, ул синең белән шөгыльләнә башлый. Ә сәясәт, үзегез беләсез, без татарны аерата үз итте. Шунадыр, күрәсең, безнең әдәбиятта да лирика белән публицистика гомер-гомергә берегеп, бербөтен булып яшәде. Шулай да мин, һәрбер каләм әһеле публицистик мәкалә язырга тиеш, дигән фикердән ерак торам. Хәер, Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары арасында да андыйларның саны якынча утыздан артмый бугай. Ә инде Аллер Тимергалин, Мәхмүт Әхмәтҗанов, Айдар Хәлим, Зәки Зәйнуллин, Әхмәт Рәшит, Рафаэль Мостафин, Фәнис Яруллин, Фәнзаман Баттал, Асия Юнысова, Ирек Сабиров кебек каләмдәшләребез 2006 елның аерата актив публицистлары булды шикелле. Әйткәнемчә, хәзер публицистика иң укылышлы жанрга әйләнеп китте. Шуна күрә үз укучысы белән күзгә-күз карап сөйләшергә ниятләгән каләм әһеле әлеге мәйданны кемнәр беләндер шәхси мөнәсәбәтләрен ачыклау, кемнәргәдер усалрак, зәһәррәк сүз әйтеп калу өчен файдаланырга тиеш түгелдер. Каләм изгегә тартыр, дигән бөек әлгәребез. Безнең каурый каләмнәребез дә шул тарафка таба гына йөгерсен иде...

---

**Равил РАХМАНИ**

# МИЛЛӘТ ҮСЕШЕНЕҢ КӨЗГЕСЕ



Бүгенге яшь буын без үскән совет чоры баласыннан шактый гына аерыла. Тормыш авыррак булуга да карамастан, элеккеге елларда мәктәп, идеология нигездә идеаллаштырылган җәмгыять өчен яна заман кешеләре тәрбияләп килде. Бүген исә бала кече яшьтән ачык җәмгыятьтә кырыс чынбарлык белән күзгә-күз карашып үсә. Аның күнелен хыялый әкиятләр уку гына инде канәгатьләндерми, ул реаль тормыш каршылыкларына тизрәк һәм кыюрак үтеп керергә омтыла. Димәк, матбугат, радио-телевидениенең бүген әһәмияте тагын да зуррак дияче килә. Милли матбугат исә—бала күңеленең яшәеш һәм ял итү, рухи кыйбласының төп калыплашу мәйданчыгы. Шуна мин балалар әдәбияты турындагы сүземне дә нәкъ менә балалар матбугатын күзәтүдән башлап китәр идем.

Нәкъ элеккеге еллардагыча ук, татар балалар матбугатының төп әйдәп баручысы

булып «Сабантуй» кала бирә. Аның һәр битеннән балаларның укуга-эшкә, ялгаижатка булган сүнмәс дәрте тулып-ташып тора сыман. Шаулы үз тормышлары... табигать, җәмгыять, спорт, театр, кино сәнгате, рәсем, музыка дәресләре... Монда ук фән казанышлары, заман техникасы, виртуаль дөнья, машиналар күргәзмәсе, «Хәерле юл» сәхифәсе... Катлаулырак проблемаларны чишүгә абруйлы галимнәрне һәм белгечләрне чакыру язмаларны кызыклы, саллы итә, актуаль, четерекле мәсьәләләргә дә кыю үтеп керү мөмкинлеге ача. Башкортстанда әнә татар мәктәпләре ябылу дәвам итә, «165 мең татар баласының 16 меңнән артыгы гына биредә татарча уку мөмкинлегенә ия дип яза газеталар».

«Россия эчке эшләр министрлыгы белдерүенчә, соңгы биш ел эчендә наркотик кулланучылар саны өч тапкырга арткан. Татарстан хөкүмәте исә аларга каршы көрәшүгә бер елда 70 миллион сумга якын акча бүлеп биргән».

«Мәктәпне беркемгә дә бирмәячәкбез!» мәкаләсе дә игътибарыбызны үзенең исеме белән үк җәлеп итә. Анда татар музыка мәктәбенә ябылу куркынычы янавы тасвирлана.

Күп төрле темалар укучылар иҗаты—мәкалә, шигырь, хикәя белән тулыландырыла. «Сабантуй»ның интернетта ачылган үз сайты да аның заман матбугаты һәм, асылда, бөтендөнья татар балалары газетасы булуы хакында сөйли.

«Сабантуй»—йөзләгән укучыларының иҗат лабораториясе генә түгел, үзен балалар әдибе дип тойган һәрбер язучының да сыналу-иҗат мәйданы. Узган ел биредә иллеләп әдибебез мәкалә һәм әсәрләре белән катнашкан. Әмма күтәргән проблемаларының мөһимлеге белән дә, әсәрләрендәге сыйфат белән дә аларның бик күбесе, кызганычка каршы, газетаны бизәп тора дип әйтеп булмый.

Икенче балалар матбугаты органы «Ялкын» журналы да җылы сүзләргә лаектыр дип уйлыйм. Анда да балаларыбыз тормышының җанлы авазы шактый ачык ишетелеп тора. Укучыларның үз иҗатларына зур урын бирелү, узган елда бирелә утызлап әдипнең әсәре басылып чыгу—журналның әдәби мохитны да чит итмәвенә ачык мисал.

Минем үземә Тукайга багышланган апрель саны аеруча хуш килде. Журналист Халидә Әкрамованың «Апушны кем Тукай иткән?» мәкаләсе күңелдә җылы тәэсир уята. Р. Батулланың «Шүрәле гаепләме?» хикәясе дә оригинальлеге, укучыны житди һәм мөстәкыйль уйлануга этәрүе белән әһәмиятле.

2006 елгы нәниләр әдәбияты хәзинәсенә «Салават күпере» журналында басылып чыккан әсәрләр дә килеп кушыла. Үз нәни укучыларыннан тыш бирелә дә егермеләп язучыбызның әсәре урын алган. Димәк, журнал шулай ук әдипләребезгә тәҗрибәиҗат мәйданы булып хезмәт итә. Шулай да, нәниләрнең үз тормышын эзлеклесистемалы төстә чагылдыру ягыннан караганда, журнал алдагы ике басмадан күпмедер калыша төсле.

Монда укучысының яшен берникадәр олыгайтып карау да үзен сиздерми калмый. Дөрес, нәни баланың яшь үзенчәлеген исәпкә алып бетермәү ул—гомумән, безнең уртак бәлабез.

Уфада чыккан нәниләр журналы «Әллүки» турында берничә сүз. Бу басмада баланың яшь үзенчәлеге төгәл саклана. Ул мәктәпкәчә яшьтәге балалар хасиятен истә тотып яши. Казаннан читтә шундый яңа журнал чыгуы мине ифрат сөендерде. Тик аның 2004-2005 ел саннарын күзәтеп чыксам да, ни кызганыч, 2006 елда чыкканнарын мин хәтта милли китапханәдә дә таба алмадым. Монысы инде «тыгыз» бәйләнешләр һәм безнең милли басмаларга чын үзебезчә—татарча!—мөнәсәбәтебез хакында сөйли.

Тагын әле бездә нәни тыңлаучылары һәм балалар әдәбияты язмышына битараф булмаган «Татарстан» радиосы бар. Ун минутлык «Күчтәнәч» һәм «пух-пах» килгән берничә чит ил мультфильмы белән котылып калырга тырышкандай, балалар әдәбияты проблемаларына һич кенә дә кушылып кереп китә алмаган телевидениебез бар. Милләтне милләт итүдә үзләрендә күпме потенциаль мөмкинлек кулланмый ятканын алар беләме икән?!

Узган елгы балалар әдәбиятының шактый зур өлеше, билгеле, китапларда чагылыш тапкан. Татарстан китап нәшрияты һәм «Мәгариф» нәшрияты чыгарган

китапларның саны ике дистәгә якын. Һәрхәлдә, Казандагы китап кибетләрендә балалар китаплары юк дип булмый.

Шулай да мәктәпкәчә яшьтәге сабыйларга багышланган китапларның аз санда чыгарылуын әйтеп үтәргә кирәк. Һәрхәлдә, минем кулга аларның икесе генә килеп иреште. Берсе—Светлана Левандовская-Фоминаның рус телендә чыккан «Утка-пароход» китабы. Икенчесе татарча—Рафис Корбанның «Минем туган көнемдә» дип исемләнгән—авторның юбилеена төбәп чыгарылган күләмле китабы. Матур бизәлешле, затлы кәгазьдә басылган әлеге китап шагыйрьнең меңнәрчә нәни укучысына сөенечле бүләк булыр дип уйлыйм. Шунысы куанычлы, монда татар балалар шигърияте антологиясенә кертерлек үрнәкләр дә юк түгел. «Жиләктә», «Автомат» шигырьләре, минемчә, әнә шундыйлардан.

Ләбиб Леронның «Борчак шыттырам» исемле «шалтмылтфильмнар»ы—өч сериядән торган китабы—мөгаен, кече яшьтәге мәктәп балалары күңеленә хуш килер. Башлыча чуалтмышлар, мажаралар, әкиятләр рухында иҗат ителгән бу нәни әсәрләрнең һәрбер строфасы аерым рәсем белән бизәлгән һәм ул, чынлап та, мультфильм кадрларын хәтерләтә. Автор үз укучысын шигъри «Сәер ил»гә алып керә, чәчмә-комикслар, әкиятләр дөньясында йөртә. «Әкәмәт затлар»ның мажаралары нәни укучыга хыял уены аша житкерелгән житди тәрбия чарасына әверелә.

Нәни укучысына Ринат Мәннан «Ялкау өстәл» исемле шигырьләр китабын тәкъдим итә. «Тун кигән акбай» шигыре бала күзе генә тотып алалган каршылыклы тормыш деталенә һәм нәни герой кичерешләренә таянудан барлыкка килгән.

Узган елда күп кенә әкиятләр басылып чыккан. Әмиржан Моталлаповның «Бал сатучы төлке» китабы бүгенге кырыс яшәеш мөнәсәбәтләренең әкияттәге чагылышы буларак истә кала. Эльмира Шәрифуллинаның «Игезәк йолдыз» дигән тарихи әкияте безне ерак үткәннәргә алып китә. Ул Сөембикәнең фажигасе турында. Хәлим Жәләй халык әкиятләренең шигъри версиясе булган «Пәриле күл буенда» һәм «Аю белән Төлке» әкият-поэмасын тәкъдим итә.

«Мәгариф» нәшриятында дөнья күргән «Бармак малай әкияте» китабын рус халык әкиятләреннән Люция Гыйззәтуллина тәржемә итеп бастырган. Талантлы тәржемәчеләребезнең күркәм традицияләрен бүгенге көндә уңышлы дәвам иттерү омтылышы сөенечле хәл. Бу унайдан «Мәгариф»тә басылып чыккан тагын бер тәржемә мираска—ике йөзләп дөнья халкы әкияте тупланган «Алтын алма» исемле әкият китабына—тукталып үтәсе килә. Аны татарчага Разил Вәлиев тәржемә иткән. Кереш сүзне язган Рабит Батулла әлеге китапны бик хаклы төстә «Әкият энциклопедиясе» дип бәяли. Дөнья халыкларының шигъри фикерләү үзенчәлеген, туган телебезнең бай аһәнен нәни укучыларыбызга китереп житкерә алуы белән ул, һичшиксез, әдәби хәзинәбезгә өстәлгән олы бер бүләк.

Урта яшьтәге мәктәп балаларына кызыклы булырдай ике китапны атап үтәсем килә. Аларның берсе—Әнәс Хәсәновның хайваннар һәм кош-кортлар дөньясындагы хикмәтле һәм гыйбрәтле хәлләрне тасвирлаган «Табигатькә тәрәзә» китабы. Икенчесе Данил Сәфәров һәм Ләйсән Хафизованың «Мәгариф» нәшриятында «Малайларга-кызларга» сериясендә чыккан «Виртуаль дөнья» исемле китап. Монда компьютер һәм аның җиһазлары, интернет, виртуаль аралашу кебек заман күренешләре җентекләп, гади укучылар да аңларлык итеп язылган.

Узган елда үсмерләр өчен Алмаз Гыймадиев «Без андый малай түгел!» дип аталган китабын бастырып чыгарган. Биредә авторның ундүрт хикәясе һәм бер повесте урын алган. Кызыклы вакыйга-сюжет, романтик очыш, хыялый мәхәббәт, мажаралар тезмәсе, оригиналь стиль, көтелмәгән финал-чишелеш, тәрбия кысаларына сыяр-сыймас яшәгән шуклык-шаянлык, әче гыйбрәт, житди уйланулар...—мина калса, үсмерләр әдәбиятына кирәк булган бөтен сыйфатлар да монда бар. Ул иң мавыгып укыган китапларымның берсе булды. Монда әлегә бердәнбер нәрсә күрмәдем мин—ул да булса—классик әсәр! Авторга, минемчә, бу хакта ныклап торып уйланырга кирәк. Табигатьтән бирелгән талантны ярты юлда калдыру—егетлек түгел!

Игътибар иткәнсездер, укылган йөзләрчә шигырь, дистәләрчә хикәяләр

арасыннан сайлап алынганнары бармак белән санарлык кына. Сөенеп кулга алырдай китапларыбызның да яртысыннан артыгы классика һәм фольклор әсәрләренә туры килә, шуңа аларның күбесенә—әкиятләрдән башкасына мин бередә тукталып та тормадым.

Бер җөмлә белән йомгак ясап, мин узган елда балалар әдәбиятының сан ягыннан да, аннан да бигрәк, сыйфат ягыннан уңышлары һич югары димәс идем.

Иң күп әсәрләрнең тиешле югарылыкта тормавы, һичшиксез, аларның сәнгати фикерләүгә таянмауда, сурәтле фикер хасиятләрен исәпкә алып бетермәүдә. Шигырьләрдә башлыча тематик такмак ясап, тасвирны ритм-рифмага корып сөйләп чыгуда, хикәяләрдә җанлы психологик образның, детальле тормыш күренешләре аша сурәтләп, кызыклы сюжет кысаларында яктыртылмавында.

Без өлкәннәр әдәбиятына югары эстетик таләпләр куябыз. Ә бит балалар әдәбиятының сәнгати дәрәҗәсе һич кенә дә кимрәк түгел, бәлки әле ул тагын да тоемлырак, шигъри сүзе дә ачыграк яңгырарга тиештер.

Табигый ки, зур талантлар ел да туып тормый. Димәк, булганнарының кадерен белергә, әдәбиятка файда китерердәй авторларга янадан да эшләү өчен ипи-шикәрлек иң элементар шартлар тудыра белергә дә кирәк. Менә без бүген: «мәктәпкәчә яшьтәге нәниләр әдәбияты юк» дип зарланабыз. Әйдәгез, замана җитәкчеләре мантыйгына туры килерлек итеп фикер йөртик алайса: Тукайның «Гали белән Кәҗә», «Безнең гаилә» шигырьләренә түләнгән гонорар бүген якынча 40ар сум. Инде милләтнең киләчәк мәнфәгатьләреннән чыгып, шундый шигырьләрнең нык җитмәвен искә алып, җитәкчеләребезгә тагын да шундый бер дистә шигырьгә заказ бирик! Таба алырлар идеме алар (һәрберсенә 40ар миллион акча биреп булса да!) тагын шундый нәниләр шигыре?! Юк, таба алмаслар иде!

Әлеге хыялый фаразны мин бүгенге материаль һәм рухи дөньяның бер-берсенә ни дәрәҗәдә чит һәм ят торганлыгын күрсәтер өчен китереп узам. Бүгенге көндә футбол, хоккей, баскетбол командаларына—миллионнар салып, теләсә нинди талантлы уенчыны сатып алырга була. Әмма талантлы татар балалар язучысын (милли культура өчен күпкә кирәгрәк затны) дөньяның бер почмагыннан да табып алу мөмкин түгел.

Балалар әдәбиятындагы икенче зур кимчелек итеп мин балалар яше үзенчәлеген, әсәрләрдәге нәни геройларның психологик хасиятен тиешенчә файдаланмауда күрәм. «Балалар әдәбияты» дигән әдәбият юк ул. «Балалар әдәбияты» дигәч, без 2 яшьлек сабыйлар әдәбиятын да, 15 яшьлек үсмерләр әдәбиятын да бергә бутап йөртергә тиеш булабыз. Ул гына түгел, бу терминга җыелма мәгънә биреп, гомумән дә яшь үзенчәлеге билгесез яки ачыкланып бетмәгән әсәрләрне дә кертеп карарга керешәбез. Ахыр чиктә, мондый хәл балалар әдәбиятында профессионализмның җитмәве белән бәйле. Яшь үзенчәлегенә тиешле игътибар итмәүнең тискәре нәтиҗәләре, һичшиксез, бер әдәбият белән генә чикләнми. Бүгенге җәмгыятебезнең иң фаҗигале чирләре дә, башлыча, шушы элементар хакыйкатьне күз уңыннан ычкындыруга барып тоташа.

Табигать кешегә чикләнмәгән мөмкинлекләр биргән, аның даһилыгына бөтен алшартлар куйган. Гомеренең беренче елларында ук бала баш җитмәслек зур үсеш юлы уза. Бүгенге тикшерүләр күрсәткәнчә, өч яшендә балада баш мие күзәнәкләренең 80%ы формалашырга өлгерә. 2-4 яшьтә ул киләчәктә авыр бирелә торган яисә бөтенләй бирелмәгән нәрсәне дә уйнагандай бик җиңел үзләштерә.

Японияне сугыш хәрабәләреннән бүгенге көн техника казанышларына китергән кешеләрнең берсе—атаклы «Сони» фирмасын оештыручы Масару Ибука үзенең «Өч яшьтән соң инде соң...» (М., 1991) китабында баланы туганнан башлап ук ничек дөрес тәрбияләү кирәклеген күрсәтеп бирә. Теориядә генә түгел, нәкъ менә гамәлдә меңләгән япон балалары аның программасы нигезендә тәрбияләнеп, Япониянe һәръяклап дөнья лидеры рәтенә чыгардылар.

Бу даһилык чорын без ничек файдаланабыз соң? Дөресе, аннан файдаланабызмы? Кызганычка каршы, бу чорда безнең вакыт бала белән шөгыльләнеп түгел, аңа ясле, балалар бакчасы эзләп үтә. Мәктәпкәчә яшьтәге нәниләргә без юньле-башлы китап та бирә алмыйча, тамагы туйса—шул! дип, аның

бик күп сәләтләре ачылуга киртә яки тоткарлык ясыйбыз. Менә кая китә безнең милләтнең даһилары! 3-4 яшендә кулыннан тотып музыка мәктәбенә илтмәгән баладан 15 тән соң инде зур музыкант чыкмаячак. Бүгенге көндә зур композиторларыбызның булмавы, бөтен татар дөньясын авызы ни сөйләгәнне колагы ишетми торган «эстрада йолдызлары» каплап алуы әнә шуның бәласе.

Башлангыч сыйныфларда яна бер төр яшь үзенчәлеге—баланың белемгә омтылу, тел үзләштерү, фикерләү сәләтен үстерү вакыты башлана. Кызганычка каршы, бу чор да безнең милләт өчен сөйләп бетергесез зур фажига-югалтулар алып килә. Бу яшьтә милләтебез балаларының яртысыннан артыгы үзенең газиз туган телен өйрәнүдән мәхрүм ителә. Аларның ата-баба теленнән, үз милләтләреннән аерылу чоры бу. Чөнки нәкъ менә шушы этапта үзләштерелгән тел генә бөтен табигый матурлыгы, тирәнлеге белән үз булып, синеке булып, чисталыгы, камиллеге, ныклыгы белән гомерлеккә күңелеңнең яшерен почмакларына да үтеп сеңеп кала. Моннан соң үзләштерелгән тел инде ул—үзеңнеке түгел, чети-бети килгән агач протез тел генә.

Димәк, киләчәктә ничә татар баласының үз телен иҗат теле дип кабул итү ихтималын, саф татарча сөйләшү мөмкинлеге булуын бүген үк инде якынча әйтә алабыз—башлангыч сыйныфларда ничә бала үз телендә укыса, аларның саны да шул кадәр булачак!

Баланы үз ата-баба теленнән мәхрүм итү!—монардан да коточкыч зуррак җинаятьнең булуы мөмкинме? Әгәр дә кемдер моны табигый хәл дип саный икән, әйдәгез, дөньядагы бөтен милләт балаларын да шушы яшьтә берничә ел икенче телгә күчереп укытып карыйк! Бөтен милләтләр дә бертигез дибез ич! Кызык, бу идеяне күтәреп чыкканда, шовинизм вирусыннан күзләре томаланган бөек милләт вәкилләре безне нинди сүзләр белән сүгәрләр иде икән?

Быелгы хәйрия елында, мина калса, хөкүмәт җитәкчеләребез, шул исәптән барлык матбугат, иң беренче чиратта, милләтебезнең исән-сау өлеше һәм киләчәге булган, әмма хокукый изелүгә дучар ителгән, рухи ачлык, рухи геноцидтан җәфа күргән балаларына ярдәм турында күбрәк уйлансын иде! «Бездә милли проблема юк» дип, бу хакта дәшми калуны зирәк сәясәт дип санаучылар милләткә артык кыйммәткә төшә түгелме?!

Урта яшьтәге мәктәп балаларының да үз хасиятләре бар. Үзе сөйләшкән гапгади тел аны иксез-чиксез тарихи-мәдәни кинлеккә, гореф-гадәт, традиция, культура элементлары белән бизәлгән милли офыкларга алып чыга. Бу яшьтә бала милли культура мохитында тәрбияләнеп үсми икән, телне белүенә дә карамастан, милләтнең ул әчке сулышын, югалту-әрнүләрен үз җаны кебек тирән тойган шәхескә әверелми, аларга битараф кала, хәтта үз милләт менталитеты да ана ят булып тоела. Милли культурадан йөз төрле гаеп табып, үзен өстен санап, ул рухи бәхетен читләр арасында өмет итә. Үзе милли мохитта яшәп калган очракта да, бу читләшү аның балаларына бирелә. Чөнки анарда милләтне чынлап торып, әрнеп ярату юк һәм булмаячак та! Бүгенге рус телендә сөйләшкән түрәләрнең дә балалары беркайчан да татар булмаячак (аерым очракларны санамаганда). Алар инде күптән инглиз теленә өйрәтелеп куелган. Хәзер алар әти-әниләре белән берлектә, киребеткән милләтче татарларны әчтән сүгә-сүгә, дүрт күз белән бөек глобальләшү чорын көтәләр. Ой, озак тоела ул көткән нәрсә!

Ә үсмерчак ул, белүебезчә, аеруча капризлы чор. Монда бөтен галәти нәрсә кисәк җимерелеп төшә һәм аның урынында әр-яна дөнья барлыкка килә. Бу этапта да милләтебез өчен фажигаләр җитәрлек. Бу чорда тыз-быз йөгерешә башлаган министрлыклар, бушка сарыф ителгән миллион сумнар кызык та, кызганыч та. Алдагы этапларда кая караганнар? Бу өлкәдә дә мең ел элек табылган хакыйкатьне үзендә йөрткән Исламга ни дип бүген бәйләнәләр?

Әдәби әсәрләрнең сыйфатын төшергән өченче зур кимчелек—әдипнең оригиналь фикер-идеясе, философиясе булмавында, аның зур четерекле проблемалардан качуында. Хәер, монда философия дип зурдан кубып сөйләшү урынсыз да кебек. Сүз гап-гади гражданлык позициясе, кыйбла ачыклыгы булмау хакында бара.

Без үзебезне мөселман дип йөрибез. Чынлыкта үтибезме без ул таләп иткән

нәрсәләрне? Ә бит икейөзләнү, монафикълык Исламның һәм яшәешебезнең иң зур дошманы! Безнең өлкәннәребез, житәкчеләребез, тәрбиячеләребез, язучыларыбыз ни өчендер моны мөмкин эш дип саный. Ялгышалар. Үзләре качып йөргән нәрсәгә балаларны ничек өйрәтмәк кирәк?

«Милләт» дибез! Ә без ана ахыргача тугрылыклылармы? Нигә барча әдипләребезнең, сәнгать әһелләренең дә балалары татарча сөйләшми? Нигә безнең бөтен патриотлыгыбыз Чечняга каршы сугышырга солдатлар үстереп җибәрү белән чикләнә? Нигә бүгенге күренекле шәхесләребезнең балалары милләт лидерына әверелми?

Житәкчеләребез һаман әле Татарстанның чын байлыгы итеп җир асты хәзинәсен санныйлар һәм милләт үсешен баррельләрдә үлчәүне кулай күрәләр. Милләтебезнең иң зур хәзинәсе балалар һәм балалар әдәбияты икәнлегенә кайчан булса да төшенерләрме, белмим.

Иң зур кимчелегебез, шулай да, миңа калса, дәүләтнең бердәм милли программасы һәм ачык яшәеш кыйбласы булмауда. Икътисадта гына түгел, рухи тормышта да «быть или не быть» дилеммасын күптән хәл итәргә кирәк иде югыйсә! Кемнәндер игелек көтеп ятасы юк.

Милләтче булып түгел, аз гына милләтне яраткан кеше буларак күз ташласаң да, рухи тормышыбызның кайсы гына өлкәсенә барып төртелмә, һәммәсенең ярым-йорты, һәммәсенең проблемалы булуына төшенәсең.

Балалар бакчасыннан башлап, курчак театрыннан башлап (яңа бинасы булмаудан зарлануым түгел, мине репертуарында сигез татар пьесасы булып та, Казан хәтле Казанда карарга тамашачысы булмау күбрәк борчый), мәктәпләрдән башлап, радио-телевидениедән, тозсыз эстрада концертларыннан башлап, китап кибетләре, китапханәләре, язучылары, композиторлары, нәшриятлары, фәннәр академиясенә кадәр—тоташ проблема...

Киләчәктә без нинди милләт булырга тиешбез? Ничә әдибебез, ничә композиторыбыз булырга тиеш? Моңа җавапны без бүген үк эзләргә, бүген үк шуның нигезен салырга тиешбез. Сәнгать кенә түгел бит әле, четерекле мәгариф эше дә бар. Татарстанда, әйтик, бүген ничә татар баласы татарча сөйләшә белә? Ә чит төбәкләрдә, дөньяда? Белмәгәннәренә без нинди ярдәм кулы суза алабыз? Татар телен укыту һәм өйрәтү—Россиядә гаять авыр мәсьәлә. Миңа Мәскәүдә, Педагогика дәүләт университетында, укытырга туры килде. Әмма мин, ярты ел йөреп тә, Цветной бульвардагы гап-гади мәктәптә, инде бергә тупланган татар балалары сыйныфына, хәтта факультатив рәвештә генә дә, татар теле укытырга рөхсәт ала алмадым. Каршы да килмиләр төсле, кертмиләр дә. Телдән әйтелгән язылмаган закон! Аны үтү юлларын бүген кем эзләргә тиеш? Моның өчен аның дәүләт дәрәҗәсендәге бердәм теоретик һәм гамәли механизмын булдыру сорала. Бу яктан Мәскәүдә әрмәннәрнең укыту системасын оештыру осталыгына таң каласың. Хәтта алар ачкан балалар бакчасында бүтән алты милләт вәкилләре белән беррәттән, үземә дә бер ел буена татарча укыту насыйп булды. Татарча укыту—Сабантуй үткәрү генә түгел шул, бик күпләргә ул ошамый. Нишлисең, безнең милләткә, шул исәптән аның балалар мәктәбе һәм балалар әдәбиятына да, әнә шундый күп төрле каршылыкларда сыналу бирелгән...

Балалар күңеле ул бик сизгер—Тукай кебек барысын да күреп-ишетеп тора. Балалар күңеле ул бик чыдам—татар халкы кебек барысына да түзә килә. Әмма балалар күңеле ул, тарихи язмыш кебек—бик кырыс та була белә:

*Исән ич аларның үз халкы,*
*Ник үсә чит телдә мең ятим...*
*Чыгарыр хөкемен чал тарих, чын хаким:*
*Бармы ул, юкмы ул милләтең?!*

Азат ӘХМӘДУЛЛИН

## БОЗ КУЗГАЛЫРГА ИТӘ...



Әдәби тәнкыйть—бездә ин арттa калганы дип уйларга без күнеккән инде. Тәнкыйтьчеләр үзләре дә моның белән килешә кебек. Шуна күрә дә, әдәби ел йомгакларында тәнкыйть буенча чыгыш әзерләргә дигәч, мин материал артык күп булмас, өйрәнү өчен вакыт күп соралмас дип уйлаган идем. Әмма, бөтен басмаларны карый башлагач, шөкер, шактый ук хаталануымны күрдем. Сан ягыннан караганда аз чыкмый икән бит бездә тәнкыйди язмалар, һәрхәлдә, кайбер басмалар узган ел бу җәһәттән шактый ук аерылып та тора. Мәсәлән, «Казан утлары» журналында 14 мәкалә басылган (ә 2005 елда бу сан 5 әү генә булган). Алар арасындагы әдәби жанрларның аерым казанышларын яктырткан тирән эчтәлекле Илшат Вәлиулла, Тәлгат Галиуллин, Ркаил Зәйдулла, Фатих Урманче, Фәридә Хәсәнова һ.б.лар мәкаләләре дә, Сәгыйдулла Хафизовның тәнкыйди рух белән сугарылган язмасы да билгеле бер кадәр бүгенге тәнкыйтьнең дәрәҗәсен күрсәтәләр.

Яки, бүгенге әдәби процессны гел күз уңында тотарга тырышып, төрле характердагы материаллар бирә килгән «Мәдәни җомга» газетасы әдәби тәнкыйтькә игътибар бирү ягыннан үз бурычын начар ук үтәми дип әйтергә була. Ел дәвамында аның битләрендә 4 зур күләмле тәнкыйть мәкаләсе, егермегә якын рецензия, язучыларның юбилейлары уңае белән уннан артык язма, иҗатчылар белән дүрт әңгәмә-интервью, гомуми характердагы 6 язма урын алган. Шунысы куанычлы: авторлар арасында Тәлгат Галиуллин, Мансур Вәли-Барҗылы, Әлфәт Закирҗанов, Фәрит Бәшир кебек танылган тәнкыйтьчеләр белән бергә Гөлфия Гайнуллина, Алсу Шәмсутова, Ленар Шәех, Ләйсән Кәшфиева, Рәшит Калыйров кебек яшьләр дә бар. Димәк, редакция тәнкыйтьчеләр даирәсен киңәйтергә тырыша. Фоат Садриев, Ризван Хәмид, Шамил Маннапов, Фәнис Яруллин, Фирая Зиятдинова, Әхәт Гаффар, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла, Рәдиф Сәгъди, Нияз Акмал, Фәнзаман Баттал, Мәхмүт Әхмәтҗанов, Нургали Булатов, Флера Гыйззәтуллина һ.б. язучыларның, шагыйрьләрнең үзләре дә әдәби тәнкыйтькә мөрәҗәгать итүләре, язмалары белән катнашулары нур өстенә нур булып тора.

Калган матбугат органнарында исә хәл түбәндәгечә булган: «Мәйдан» журналында әдәби тәнкыйтькә игътибар шактый аз. Аның каравы редакция аерым иҗатчыларга игътибар итүнең бер формасыннан файдалана. Ел дәвамында Зиннур Хөснияр һәм Харрас Әюп турында шактый тулы һәм этрафлы шундый тупланмалар бирде. Хәниф Хәйруллин һәм Әзһәр Габидигә багышланганнары да, алай ук тулы булмаса да, урынлы иде. Әмма шунысын да әйтеп узарга кирәк: мондый материаллар, теге яки бу иҗатчының әдәбиятыбызга алып килгән яңалыкларын ачу-күрсәтү рухында язылырга тиеш булса да, тулысы белән иҗатны мактау төсен алалар. Хәер, бу хәл бер «Мәйдан» журналына гына хас түгел.

Тагын да бер басмабыз—халыкара «Мирас» журналының төп омтылышы һәм билгеләмәсе гаять изге максатка—халкыбызның үткәндәге әдәби һәм мәдәни мирасын кире кайтару һәм бүгенге укучыга җиткерүгә багышланган. Шулай була торып та журнал редакциясе бүгенге әдәби процессны да күз уңыннан ычкындырмаска тырыша, әдәби тәнкыйть мәкаләләрен дә бастыра килә. Ел дәвамында бирелә шундый рухтагы 10 мәкалә һәм рецензия урын алган. Менә тагын журналдагы «Баш редактор сүзе» дигән баш астында даими басылып килгән материаллар арасында Ф. Яруллин, Ш. Галиев, Ә. Кәримуллин, А. Гыйләҗевка

багышланганнары да булганын исәпкә алганда, бу сан 14 кә җитә. Сүз арасында әйткәндә, бу рубрика рус журналларында иркен кулланыла, ул «Мирас»ны да баета, җанландыра, хәзер мондый формага «Казан утлары» һәм «Мәйдан» журналлары да мөрәҗәгать итә башладылар.

Яшьләр журналы «Идел»дә әдәби тәнкыйть бик үк мактауда түгел икән: ел дәвамында барысы 7 генә мәкалә һәм рецензия урын алган. Шулай да журнал уздыра торган «Проблемалы мәкалә» исеме астындагы конкурсның кирәкле һәм асылда кызыклы, файдалы булуын аерым билгеләп узарга кирәк. Анда, гәрчә эстрада һәм театр сәнгатенә караган язмалар төп урынны алып торса да, әдәбиятка караган материаллар да бар. Ә менә «Татарстан» журналында әдәби тәнкыйтьнең бер генә формасына караган язма да юк; бу басма, әйтерсең лә, халыкның рухи тормышында төп урыннарның берсен биләгән матур әдәби процесска бәя бирүне тиешле санамый.

Газеталарыбызда да бу җәһәттән эшләр мактанырлык түгел. «Ватаным Татарстан»да да, «Шәһри Казан»да да әдәби тәнкыйтьнең төп билгеләмәсенә турыдан-туры караган язмалар бармак белән генә санарлык. Дөрес, редакцияләр башка формалардан файдаланалар. Болардан иң активы—язучыларның үзләре белән әңгәмә-интервьюлар. Шулай да, аларны безгә җитми торган чын мәгънәсендәге әдәби тәнкыйть дип карап булмый, гәрчә аларда билгеле бер дәрәҗәдә бүгенге иҗади барыш турында фикерләр булса да. Мондый әңгәмәләр, асылда, язучыларның юбилейлары уңае белән эшләнә һәм, күп булса, аларның әдәбиятыбызга һәм мәдәниятебезгә нәрсә биргән икәнен барлау рухында. Болар арасында «Ватаным Татарстан» битләрендә—Харрас Әюпнең 60, Әдип Маликовның 85, Рафаэль Мостафинның 75, Марсель Галиевнең 60, Разил Вәлиевнең 60 еллыгына караганнары, Роберт Миңнуллинның «Рафаэльнең батырлыгы», Разил Вәлиевнең «Гомеремнең аяз көннәре» исемле язмалары эчтәлекле һәм кызыклы булулары белән аерылып тора. «Шәһри Казан»да Гөлнара Җәлилова язмалары да нигездә Мәрзия Фәйзуллина, Рөстәм Мингалим, Рифкать Закиров, Фирая һәм Фарсил Зиятдиновлар, Харрас Әюпләрнең юбилейларына, Әхмәт Рәшит мәкаләсе Рөстәм Кутуйның 70 еллыгына багышланган. «Ватаным Татарстан»да рецензия 2 генә: Нәҗибә Сафинаның яшь шагыйрь Ленар Шәехнең «Авылдан килгән мендәр» җыентыгына һәм Мәсгут Имашевның галим-фольклорчы Рәшит Ягъфәровның «Тулпарларым» китабына. «Шәһри Казан»да да ике генә рецензия басылган: Хәнәфи Бәдигыйнең Хәләф Гарданов поэмаларына һәм Мансур Вәли-Барҗылының «Чеховны узды мәллә?» дип аталган, Вакыйф Нуриевның «Җиденче палата» исемле повестен бәяләгән, бу тәҗрибәле тәнкыйтьчегә хас булганча, югары кимәлдә язылган рецензиясе. Боларга өстәп Хәмзә Бәдретдиновның «Корычагач тыкрыгындагы Зиннәт Вәли», Шәрәф Әхмәдулланың «Үз Шекспирларыбызны үстерик» дип аталган, Фирдәвес Якупованың «Син кем улы соң?», Эльвира Мозаффарованың «Бүгенге заман хикәя таләп итә», Әхмәт Гаделнең Марсель Зарипов китабы турындагы һ. б. язмалар басылганын да әйтергә кирәк. Күрәбез, мул түгел. Бигрәк тә заманында әдәби тәнкыйтьнең торышында һәм барышында алдынгы рәттә торган «Ватаным Татарстан»ның бу яктан сүлпәнәюе эчне пошыра. Дөрес, анда чын мәгънәсендәге тәнкыйть елга бер күренеп калды. Бу—Айдар Хәлимнең «Тукай исеме белән газаплау» исемле үткен мәкаләсе. Башка юк.

«Шәһри Казан»да да чын тәнкыйть күренеп алды. Мин Зәки Зәйнуллинның бу авторга хас кискенлек белән язылган «Татар театры турында уйланулар» исемле язмасын күз алдында тотам (2006 ел, 8 сентябрь). Ләкин мәкаләнең эчтәлеген хуплау ягыннан түгел, ә тәнкыйди материал булуы, мондый характердагы язмаларның бездә гаять тә сирәк кунак булганы өчен. Зәки Зәйнуллинның бу газета битләрендә басыла торган, бигрәк тә совет чорындагы, совет армиясендәге тәртипсезлекләрне фаш иткән язмаларын мин көтеп алып укыйм. Әмма бу мәкаләсен һич тә хупламыйм, артык субъектив эчтәлекле дип саныйм. Ул театрга багышланган булса да, андагы төп тәнкыйть угы драматургиягә төбәлгән. Димәк, аны театр тәнкыйтеннән бигрәк әдәби тәнкыйть дип карарга була. Чын мәгънәсендәге тәнкыйтькә урын бирелүне хуплау тойгысын, иң әүвәл, газетаның үзара тәнкыйтьне оештыру формасы бозып тора. Ләйсән Могтәсимова «Татар театры

турында «Ай-вай»ланулар» исеме астында Зәки Зәйнуллин мәкаләсенә шактый ук урынлы төстә каршы чыкты. Бәлкем, чыннан да, мәкаләсендә яшь авторга өлкән каләмдәшенә карата тиешле хөрмәт житеп бетмидер. Әмма асылы белән ул урынлы һәм нигезле иде. Чыннан да, татар җәмәгатьчелегендә хәкем сөргән хөрлек-азатлык фикерләрен, татарның бүгенге хәлен дөрес бәяли белгән зур язучының татар театрын (дөресрәге, милли драматургияне) бәяләүдә бу кадәр тар карашлы, тар рухлы булуы гаҗәпләндерә, көендерә. Мин инде монда бүгенгенең әйдәүче драматургы, татар теле, татарның яшәү рәвеше, җәмгыятьнең бүгенге торышында татарның урыны һәм роле турында зыялыларыбызның рупоры ролен үтәгән Туфан Миңнуллинның мөһим әсәрләрен санаганда «Әниләр һәм бәбиләр», «Шәҗәрә», «Ат карагы» һ.б. дистәләгән әсәрләрен «онытып» калдыру турында әйтеп тормыйм. Күренекле драматурглар рәтенә баскан Зөлфәт Хәкимне бөтенләй дә бетереп ташлау бернинди киртәгә дә сыймый ләбаса! Нәрсә, республика күләмендә ике мәртәбә уздырылган конкурста да беренче урынны яулаган авторның пьесалары шундый бәягә лаекмыни? Бу конкурсларның мәртәбәле жюрийлары фикере шулкадәр хатамыни? Ә Мансур Гыйләҗевнең «Баскетболист» әсәрендәге яңалыкны танымыйча, аны классик реализм ноктасыннан торып кына бетереп ташлау дөрес буламыни?

Кызганыч, татар театры турындагы бу сөйләшүне газета редколлегиясе базар ярышына әйләндерде. Ни өчен редколлегия, дим? Чөнки Л. Могтәсимова мәкаләсенә каршы чыккан Гөлнара Галәвиева үз язмасын газетаның даими рубрикасы булган «Илһамият» исеменә таянып атады: «Илһамият» сүзе». Һәм ул тулысы белән дип әйтерлек яшь авторны мыскыл итү рухында. Мондый мөгамәлә белән без яшь тәнкыйтьчеләр үстерә алмабыздыр... Алга таба газетада басылган Юныс Сафиуллин мәкаләсе белән («Тәнкыйтьме, әллә театрга яла ягумы?!», 20 октябрь) хәл бераз төзәтелде кебек. Әмма фикер алышуны оештыруның рәвеш-формасы бозылу күңелсез тәэсир калдырды.

Нәшриятлар эшчәнлегенә һәм китапларга килсәк, узган елдагы әдәби тәнкыйтебезнең йөзен һәм көчен билгеләп торган җыентыклар чыкканын әйтергә кирәк. Бу яктан нәшриятларыбыз сан ягыннан түгел, ә сыйфат җәһәтеннән алга чыкты. Язмабызга «Боз кузгалырга итә...» дип исем кую да шуннан килә. Татарстан китап нәшрияты 2006 елда 3 тәнкыйть китабы бастырды: Рафаэль Мостафинның русча «Силуэты» исемендәге, Илшат Вәлиулланың «Һәр шагыйрь—бер дәрья» дип аталган, Рәфыйк Шәрәфиевнең «Татар эзләү» дигән китаплары. Болар янына Равия Зарипованың Атилла Расих турындагы хезмәтен дә кушарга мөмкин. Төп фазыйфасы дәреслекләр һәм методик кулланмалар бастыру булса да, «Мәгариф» нәшрияты әдәбиятыбызның мирасын өйрәнү, агымдагы әдәби процесска караган әдәби ярдәмлекләр хәзерләүгә нык игътибар бирә. Дания Заһидуллинаның узган елда басылган «Яңа дулкында» исемле китабы 2006 елның әдәби тәнкыйте өлкәсенә ирешелгән иң зур, иң мәгънәле казаныш булды. Ул агымдагы әдәбиятның үсеш процессын колачлап, андагы уңышларны гына түгел, аерым кимчелекләрне дә ачып салды. Дөрес, ул проза әсәрләренә генә карый, әмма гомуми фикерләр башка жанрлар өчен дә файдалы.

Китапта 17 күренекле язучының иҗаты анализлана. Автор аларның әсәрләре соңгы еллар прозасында кайсы яктан унай роль уйнаганын дәлилли. Нәтиҗәдә бүгенге прозаның шактый ук тулы картинасы тудырылган. Әлбәттә, автор соңгы еллар прозасының барлык күренекле әсәрләрен иңләп алуны максат итмәгән, бер китап кысаларында моны эшләү мөмкин дә булмас иде. Бүгенге прозага караган хезмәтләр басылгалап тора. Бигрәк тә яшь әдәбиятчылар аерым язучылар яки жанрлар буенча кызыклы күзәтүләр ясыйлар. Әмма соңгы еллар прозасын мондый киңлектә алып карап, билгеле бер проблемалар яктылыгында шулай тәфсилләп анализлау юк иде әле. Монда Дания Заһидуллина—беренче. Нәкъ менә ул бүгенге прозага кергән яки кереп баручы яңалыкларны ачыклый. Шуның белән бергә әдәби традицияләр яктылыгында язылган әсәрләргә дә тиешле бәясен биреп, аларның уңышлары нидән килгәнен җентекләп тикшерә.

Узган ел әдәби тәнкыйтенең йөзен билгеләүче тагын да бер китап: ул Илшат

Вәлиулланың «Һәр шагыйрь—бер дәрья» дип аталган мәкаләләр җыентыгы. Бусы—соңгы еллар шигъриятендә барган процесс, яңалыклар турында. Моңарчы үзенең асылда төпле язмалары белән әдәби процесска актив катнашып килгән һәм өлгергән тәнкыйтьчеләр сафына баскан бу яшь иптәшнең уңышы безне сокландырды. Равил Фәйзуллин, Мөдәррис Әгъләм, Рәдиф Гаташ, Роберт Әхмәтҗан, Лена Шагыйрьҗан, Газинур Морат кебек бүгенге поэзиянең терәкләре булган иҗатчыларның һәркайсының үзенә генә хас үзенчәлекләрен яңа яктан ачу белән бергә, тәнкыйтьче шигъриятькә ныклы адымнар белән килеп ятучы яшь авторларның казанышларын да ышандырырлык итеп күрсәтә алган. Шагыйрьләрнең иҗатларына хас үзенчәлекләрне автор мәкаләләрнең башында ук уңышлы төстә әйтеп бара. Равил Фәйзуллин шигъриятендә бу—«ир-егетлек; көрәшчелек фәлсәфәсе»; Лена Шагыйрьҗан иҗатында—«күңел түтәлләрен чүп баскан; халыклар һәм иман нуры»; Мөдәррис Әгъләмовта—«халык күңелендә ниләр бар? Милләт язмышы...»; Рәдиф Гаташта—«ике кыйтга—ике дөнья»; Газинур Моратта—«дәвер белән әңгәмә». Яшьләр иҗатында да үзләренә генә хас үзенчәлекләр күрә автор: Габделнур Сәлимдә—«мәңгелек игелеге; Алла иркендә» мотивлары; Рамис Әймәт һәм Марат Закир иҗатларындагы аваздашлыкның чагылышы—«буыннар чылбыры өзелмәс»; Луиза Янсуарда—«күк һәм җир арасындагы гармония»; Энже Афзаловада—«яктылык-яхшылык җырчысы» һ. б. Илшат Вәлиулланың шигъриятътә катлаулы фәлсәфи сорауларга җавап эзләве, кешелекнең мәңгелек мәсьәләләрен тирән итеп күтәрә белүе, шигырьләргә шул ноктадан торып бәя бирә белүе хуплау таба һәм аның әдәби тәнкыйтьтә тагын да югарырак үрләргә ирешүенә ышаныч тудыра. Инде анар бүгенге шигъриятнең казанышларын гына түгел, кимчелекләрен, алда яулаячак үрләрен билгеләүдә дә уңышлар теләргә генә кала. Әдәби тәнкыйть мажор тоннардан гына тора алмый ич.

Әлбәттә, узган елда әдәби тәнкыйть ирешкән кайбер уңышлар һәм аерым житешсезлекләр турында тагын да сөйләргә мөмкин. Гомуми фикер чыгарып әйткәндә исә: тәнкыйть әлегә басылган әдәби продукцияне инли алмый. Шулай ук аңа тәнкыйди рухның житешмәвен дә күрсәтергә кирәк. Әйе, әлегә бу җәһәттән боз кузгалырга гына итә...

---

## Авторларыбыз игътибарына

**Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кульязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.**

**Хатлар исә, җиңел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.**

# Хәтер

## *Газиз Гобәйдуллинның тууына 120 ел*

*Күренекле татар тарихчысы, әдип һәм педагог Газиз Салих улы Гобәйдуллинның (1887—1937) тууына июнь аенда 120 ел тула.*



*Газиз Гобәйдуллин Казан шәһәрендә дөньяга килгән, «Халидия» мәдрәсәсендә белем алган. Үзлегеннән рус һәм Европа телләрен өйрәнгән, дөнья әдәбияты, тарихы һәм фәлсәфәсе белән танышкан. Казан император университетының тарих-филология факультетын тәмамлаган. 1920—1930 нчы елларда Казан, Баку, Сәмәрканд, Ташкент, Мәскәү, Пятигорск шәһәрләрендәге югары уку йортларында укыткан. Татар һәм башка төрки халыклар, Шәрык илләре тарихы, әдәбият тарихы буенча күпсанлы гыйльми хезмәтләр язган, фәнни эзләнүләр алып барган. Үткен эчтәлекле хикәяләр иҗат итеп, «Г.Газиз» имзасы белән матбугатта бастырып чыгарган.*

*1937 елда кулга алынып, нахакка гаепләнеп атып үтерелгән. 1957 елда акланган.*

*Укучыларыбызга Газиз Гобәйдуллинның күп еллар элек язылган мәкаләсе тәкъдим ителә. Анда күтәрелгән мөһим мәсьәлә хәзер дә милли җәмәгатьчелегебез һәм матбугат мәйданыбызның игътибар үзәгендә.*

Г. Газиз

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘМЕ, РУС ТЕЛЕНДӘМЕ?

Әдәбиятыбызда «Ана телендә мәктәп» фикере 1905 ел революциясеннән бирле сөйләнеп килә. Октябрь революциясенә кадәр бу мәсьәләгә бары сәясәт вә милли яктан каралып килeнде һәм бу идея иске хөкүмәт белән көрәшнең бер коралы булып барды. Хәзерге көндә миллият мәсьәләсе хәл кылынып килә, хәтта Октябрь революциясе бу бабта *(мәсьәләдә)* милләтчеләр теләгәннән артык хокук биреп, милли мәсьәләдә талашырга имкян *(мөмкинлек)* калдырмады. Шуның өчен урта мәктәпләрдә вә профессиональ уку йортларында уку теленең русчамы, татарчамы булуы мәсьәләсен бөтенләй сәясәттән чыгып, бер дә сабыйланмыйча, бер хиссияткә бирелмичә, «эш» ягыннан карарга мөмкин. Ибтидаи *(башлангыч)* мәктәптә фәннәрне ана телендә уку мәсьәләсе ул бер мәгълүм хакыйкать, хәтта Ильминский шикелле консерватор педагог тарафыннан да хәл кылынган бер мәсьәлә. Шуның өчен мәсьәләнең хәл ителмәгән ягы—бары урта мәктәп.

Бу елларда татар яшьләренең урта мәктәптә ана телендә укуга каршы фикерләре күрелә башлады. Яшүсмерләр мәктәпкә керергә килгәндә, «русчамы, татарчамы

укыла?» дип сорап, татарча дәресләргә ышанмыйча карыйлар. Аталар да балаларын китергәндә «русча укыла торган мәктәпкә бирмәкче идем...» дигән шикелле фикерләр сөйлиләр. Монда бер гаҗәп эш юк; мәктәп ислахаты *(реформасы)* заманында «фән, фән» дип кычкырдык та, мәктәп вә мәдрәсәләргә «фән» керттек; ләкин кертелгән фәннәрне укытучысы юньле булмаганга, укытырга дәреслекләр булмаганга, ул «фәннәр» бик начар укытылдылар ки, гали *(югары)* мәктәпкә керергә теләсәләр, мәдрәсәдән укып чыкканга карамыйча, һәндәсәне дә, җаберне *(алгебра)* дә, җагърафияне дә, тарихны да, табигыятьне дә яңадан укырга мәҗбүр булдылар; хасыйль *(кыскасы)*, татар мәктәпләрендә фән укыган булып, аның бары ишеген генә иснәп калдылар.

Октябрь революциясе соңында да гөмбәләр шикелле үсеп чыккан икенче баскыч мәктәпләребездә, техникум вә курсларыбызда һәр фәнне дә татарча укыта башладык; ләкин аларны укытырга көчле мөгаллимнәр таба алмадык. Мөгаллимнәребез яисә «Хөсәения», «Мөхәммәдия», «Галия», «Касыймия», «Госмания»дә укыган кешеләр иделәр ки, бу мәдрәсәдә укытучылар яисә Истанбулда сухтә булып *(бик тырышып)* укып кайткан, яисә анда ярым-ярты «Мөлкия» *(хөкүмәт уку йорты)*, рөшдия *(урта мәктәп)*, игъдадияләрендә *(мәдрәсәдә югары белем алуга хәзерләү сыйныфларында)* селкенеп йөргән кешеләр; яисә Учительский школада бары ибтидаи мәктәптә рус азбукасы, дүрт гамәл «гыйльме хисап» укытырга хәзерләнгән затлар иде. Урта мәктәпләребез ачылгач та боларга без үзләре белмәгән нәрсәләрне укытырга куштык; табигый, болар укыта алмадылар; паёк алдылар, селкенделәр, йөрделәр. Аталарның да, балаларның да ана телендәге мәктәпләрдән тәмам ихласлары чыкты куйды!

Шуның өчен бу мәсьәләне тикшергәндә, маузугны *(мәсьәләне)* без болай куябыз:

—Әгәр көчле мөгаллимнәр булса, дәреслекләр мөкәммәл булса, урта мәктәпләрдә фәнне шәкертләр белми торган русчамы, әллә татарчамы укыту педагогия җәһәтеннән файдалы?

Мин бер дә өркемичә, бер дә мәсьәләгә сәясәт катыштырмыйча гына әйтәм ки:

—Татарча укыту файдалы!

Мәгълүм ки, без ысул җәдидә дәверендә ысул кадимәдән көлгәндә алар гарәп нәхү-сарыфын *(синтаксис һәм морфологиясен)* фарсый *(фарсы телендәге)* дәреслектән укыталар дип көләдер идек. «Әгәр гарәп телен татарча дәреслек вә татарча тәкърир *(аңлатып сөйләү)* белән укытылса, тизрәк белер идек» дидер идек; һәм шулай иткәч, белдек тә. Әүвәле 15-20 еллар мәдрәсәдә ятып, гыйбарә укый белми чыккан хәлфәләрдән арттырып, шул ук нәрсәне 3-4 елда белдек вә «моталәгабыз чыкты» *(мәгънәсен аңладык)*. Бу бер тәҗрибә һәм яхшы тәҗрибә. Менә рус вә татар телендә укыту мәсьәләсендә дә шулай ук, бер-бер фәнне укыганда, фәннең әсас *(төп)* мәсьәләсенә караганда, «ничек итеп әйтәсе инде» дип уйлап утыру нәкъ схоластик бер нәрсәдер. Мәсәлән, татар мөгаллиме, мина Фисагурс *(Пифагор)* теоремасын татарча сөйләде. Мин моны беренчеләй бик тиз аңлыйм, икенчеләй, аңлагач та исбат кыла алдым. Әгәр шул дәресне русча сөйләсәләр, мина мөгаллимнең нәрсә сөйли икән вә ничек фикер йөртә икән дип тыңларга тырышуым белән бергә, нинди итеп сөйли, нинди сүзләр истигъмаль кыла (куллана) вә аларның мәгънәсе ничек, алар мөәннәс *(хатын-кыз җенесен белдерә торган грамматик категория—женский род)* микән, мөзәккәр *(ир-ат җенесен белдерә торган грамматик категория—мужской род)* микән дигән шикелле, һичбер Фисагурс теоремасына бәйләнеше булмаган нәрсә хакында баш ватарга туры килә. Бу мәсьәлә гарәп сарыфын (фарсы телендәге) «Бидан» дәреслеге буенча укудан бер дә артык җире юк. Әле дә күз алдымда тора: бервакыт мин мөәмүр *(инспектор)* сыйфаты белән бер техникумда физика дәресенә кердем. Мәсьәлә «Җәзбе гомуми» *(Всеобщее тяготение)* иде бугай. Дәрес беткәч мин бер шәкерттән сорадым. Русча сорадым. Шәкерт ык-мык итте; минем күземә вә мөгаллимгә елмаеп, кызганыч сыйфат белән карады; сөйли дә башлады, булдырып чыга алмады; мина әйләнде дә: «Газиз абый, мин аны русча әйтә алмыйм, әмма татарча булдырам»,—диде. Вакыйган *(чынлап та)*, татарча сөйләп бирде. Әмма мөгаллим инде, сорап та белмәгәч, журналга «минус» галәмәтен куеп өлгергән иде. Бигрәк тә бу вакыйга сүз күп таләп кылына

торган тарих, җәгърафия, икътисад шикелле голуме мәгънәвиядә *(мәгънәви фәннәрдә)* сизелә.

«Сон бит безгә гали (югары) мәктәпкә керергә кирәк, әгәр монда ул дәресләр татарча укытылсалар, анда бит имтихан тотып булмас!»—диярләр.

Бу көчле дәлил; ләкин фәннәрне татарча укыткан чакта, бер «лябид минһу» *(котылгысыз)* булган шартны үтәргә кирәк. Ул шарт исә татар мәктәпләренең дәрес програмын ясаганда татар хосусияте белән хисаплашу. Бу мәсьәләдә исә иң күп игътибарга алына торган нәрсә—рус телен тел буларак, рус мәктәпләрендәгеләргә караганда ике өлеш күп кертергә һәм фәннәрне татарча укытканда рус истилахатын *(терминологиясен)* әйтеп узарга һәм русча дәрес укытканда коры «Кәҗә белән мәче» кыйссасын укып, язып кына уздырмыйча, ялгыз рус милләтчесенә генә кадерле булган Державин одаларын, «Бедная Лиза»ның характеристикасын тикшереп уздырмыйча, фәннәрнең төрле бабыннан *(мәсьәләсен)* тәкърирргә *(аңларга)* өйрәтү һәм шул бабларда доклад, инша вә имлялар яздырудыр. Шулай иткән вакытта шәкерт фәннәрне татарча укып та, русча сөйли беләчәктер. Менә мәсьәлә бары русча дәресне куя белүдә генә. Бу бабта минем бер тәҗрибәм дә бар. 1916 ел мин Тройскида кызлар дарелмөгаллиматында *(хатын-кыз укытучылар әзерли торган уку йорты)* укыттым, «Вазыйфа» исемле семинариядә мөдир булдым. Бер көнне мәшһүр миссионер вә Оренбург учебный округының бер түрәсе килде. Калада хәбәр чыкты: «Менә татарча укытыла торган татар семинарияләрен ревизия ясап, әгәр белмәсәләр, ябылачак икән...»

Теге мөдһиш *(куркыныч)* нәрсә килде. Бездә табигыять татарча укыла иде. Шуннан сорарга тотынды. Кызлар вә егетләр яхшы җавап бирделәр. Түрә гаҗәпләнде; мәктәпне ябарга башка сәяси нәрсәләр генә эзли башлады. Менә бу вакыйга яхшы гына бер тәҗрибә. Моннан башка да тәҗрибәләр бар. Мәсәлән, рус гимназиясен бетергән рус малае француз, немец телләрен тел буларак өйрәнү белән француз, немец университетларында, лицейләрендә дәрес укый алмыйдыр иде мени? Русиядә әллә никадәр кеше шулай укыймыйдыр идемени?

Димәк, фән русча укылсын дигән сүз бер юк, әсассыз *(нигезсез)* вәсвәсәдән башка нәрсә түгел!

Менә моннан янә бер нәтиҗә чыга:

—Татарстанда рус вә татарларны бер үк мәктәптә укыту файдалымы, әллә татарлар өчен аерым мәктәпләр ачаргамы?

Мин янә татарлар өчен аерым мәктәпләр файдалы дим, аның дәлилләре дә шулар:

—Программа ике мәктәптә ике төрле булырга кирәк. Чөнки мәйданда рус теле укытуның тәүмәле *(объемы)* һәм анарга бирелгән сәгатьләрнең саны тора.

—Безнең өчен русларга караганда рус теле сәгатьләре күбрәк кирәк булыр; икенчеләй, ул тел исемендә кергән дәресләрнең укытылуының ысулы вә максуды *(максаты)* башка, безне сөйләргә, укырга вә шул тел белән фәннәрне тәгъриф итәргә *(аңлатырга)* өйрәтергә кирәк. Әмма рус баласы өчен тагы да башка максатлар бар.

—Безгә татар теле вә әдәбияты кирәк. Дөрес, бәлки ул Татарстанда руска да кирәктер. Ләкин алар бу фәнне укуда татар баласы белән бергә бара алмыйлар. Нәкъ рус телендә татар баласы русныкы белән бара алмаганы шикелле.

Әгәр шул дәлилләр өстенә рус вә татар тарихы мәсьәләсен вә гомуми тарихны укытуда ысул мәсьәләсен вә сәяси мәгълүмат биргән чакта татарга бер якта күбрәк игътибар итәргә кирәк булып та, руска башкасына әһәмият бирүне алсак, аерым мәктәпләр дигән фикер тагын да куәтләнә.

Соңгы мәсьәләне бераз тәфсилләп китәргә кирәк. Мәсәлән, дин мәсьәләсен. Монда сәяси фән мөгаллиме динне тәнкыйть кылганда рус өчен аңларлык булган христианлыкны мисал итеп алса, татарныкында исә исламны алырга кирәк була.

*(«Безнең юл» журналы.—1923.—№ 12.—11-12 битләр).*

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ХӘМЕР*** *г.* – Шәраб, аракы, исерткеч эчемлек, шулай ук наркотик матдәләр. Мөхәммәд Пәйгамбәр: "Мән шәрабел-хәмрә хәрәҗә мән җәвуфиһи," – дигән ("Әгәр дә берәү исерткеч эчемлек эчсә, аңардан иман нуры качар"). Коръән-кәримнең "Маидә" сүрәсендә (5:90) болай диелгән: "Ий мөэминнәр! Исерткеч эчемлекләр һәммәсе дә, отыш уеннарының һәртөрлесе, санәмнәргә табыну, шулай ук уклар белән ырымлану эшләре хәрамдыр..." Дөрес, алдарак назил булган аятьләрдә әле хәмергә һәм хәмер эчүгә мөнәсәбәт болай тискәре түгел. Мәс., "Умарта кортлары" сүрәсенең (16) 67 нче аятендә: "Вә без үстергән хөрмә, йөзем җимешләреннән ләззәтле эчемлекләр вә татлы ризыклар ясыйсыз. Гакыллы кешеләр өчен бу нәрсәләрдә дә гыйбрәтләр бар," – диелгән. Мәгълүм булганча, мондый аятьләр соңрак назил булганнары белән юкка чыгарылалар.

Мөселманнарга хәмер эчү Һиҗрәттән соң өченче елда, Өхүд сугышыннан соң хәрам була. Әлеге аять Пәйгамбәргә назил булып, Мәдинә шәһәре урамнарында сөрәнче шәрабның тыелуы турында игълан иткәч, мөселман йортларындагы шәраблы кувшиннарны чыгарып түккәннәр һәм урамнарда елга булып шәраб аккан дип сөйлиләр. Эчкечелек кебек язык эшнең тамырын шушылай тиз һәм тәмам корытуның башка очрагы тарихка билгесез.

Шулай да урта гасырларда хәмер куллану шактый таралган була. Әлбәттә, бу мәсьәләдә төрле төбәкләрдә эш төрлечә торган. Мәс., 169/785 елда гарәп Хиҗазында Алид исемле берәүне хәмер эчкән өчен җәзалаганнар, шул ук вакытта Месопотамиядә мондый эштә яманлык күрмәгәннәр. Мәйханәләрнең хуҗалары һәм хезмәтчеләре гадәттә христианнардан булган. Шәрабка бай булган Мароккода эчкечелек хатын-кызлар арасында бигрәк тә нык таралган. Бай йортларда махсус пешекче белән бергә шәрабчы да булган.

Икәүләп кенә эчү гадәткә кермәгән, моны хәтта "пычкы" (миншар) дип атаганнар (чөнки пычкыны да ике кеше тарта). Антик дөньяда шешәдәшләр санын музалар (9 алиһә) яки грацияләр (3 алиһә) саны арасында сайларга киңәш итсәләр, мөселман Әбү Нувас дүртәүләп яки бишәүләп эчүне артык күргән.

Тагын кара: ***ХӘМИР, ШӘРАБ, ҖАМИ ҖАМ.***

***ХӘМИР*** *г.* – Чүпрәле камыр, әче камыр. Татарча *камыр* сүзе шушы *хәмир* сүзенә барып тоташа. Димәк, төче тәбикмәк кенә түгел, чын ипи пешерү осталыгы да безгә көнчыгыштан кергән дип әйтергә була.

*//Камыр булу, камырга әйләнү* – буыннар йомшау, хәлсезләнү (беренчел мәгънәсе – хәмерле эчемлектән). *Камыр батыр* – хәмер эчеп кенә батыраюга ишарә (дөрес, этнографлар арасында бу сүз утрак тормышка күчүгә, игенчелек белән шөгыльләнүгә һәм икмәк ашап туклануга бәйле рәвештә килеп чыккан дигән фикер өстенлек итә: ипи ашаучы – баһадир була дип ышанганнар имеш).

***ХӘММАМ*** *г.* – Җәмәгать мунчасы; ванна. Гарәпләр хәммамны римлылардан алганнар дип уйланыла. Ләкин мөселманнарда мунча үзара аралашу һәм күңел ачу чарасы да булып торган. Гомумән, "пакьлек – Иман билгесе" булып исәпләнгән. Кагыйдә

*Дәвамы. Сүзлек 2004 елның 1нче санынан басылып килә.*

буларак, ирләр һәм хатыннар өчен аерым хәммамнар булган, ә ярлырак өммәтләрдә ирләр һәм хатыннар бер үк хәммамда, ләкин төрле вакытларда юынганнар. Мунча идәннән җылытылганга, аякларга агач башмак (кубкаб) элгәннәр. Мунча эченә яктылык гөмбәзсыман түбәдәге тишекләрдән ("төннек"?) төшкән. Иске татар телендә мунча төшенчәсе шушы "хәммам" сүзе белән бирелгән. Ихтимал, хәммамнар шәһәргә хас булып, аларга параллель рәвештә гади авыл мунчалары да булгандыр. Үзбәкләрдә: "Иске хәммам, иске тас" дигән мәкаль бар ("Бөтенесе искечә, яңалык-мазар юк" мәгънәсендә), татарчада ул "Иске комган, иске тас" рәвешендә яңгырый. Бу параллельлек "комган" сүзенең этимологиясенә ачыклык кертә алмыймы икән? //*Төрек хәммамы.*

Тагын кара: ***ШӘРЫК МУНЧАЛАРЫ.***

***ХӘНДАК*** *г.* – Шәһәрне дошман һөҗүменнән саклау өчен казылган озын чокыр, траншея. Ур. 627 елда мәҗүси мәккәлеләрнең атлы гаскәрен мөселманнар Мәккә тирәсендә ур казып туктаталар (*Хәндак сугышы*). Бу чокырны казу идеясе Салман Фарсиныкы, аны казуда Мөхәммәд Пәйгамбәр дә актив катнашкан. Дөрес, мөшрикләрнең берничә кешесе атлар белән хәндак аша сикереп чыга алган. Мәс., аларның мәшһүр баһадиры Гәмр ибн Габд Вадд, хәндак аша үтеп, үзенә каршы сугышырга мөселманнардан бер баһадир таләп итә. Аңа каршы Гали ибн әбү Талиб чыга һәм мөшрик пәһлеванын үтерә. Шуннан соң мөшрикләр качып китәләр (Сөнгатулла Бикбулат буенча).

//*Шәһәрне саклаучылар яныл торган шәһәрнең утын сүндерергә ташланганнар һәм хәндактан киткәннәр.* "Бүләрне яндыру". "Риваятьләр һәм легендалар" китабыннан.

***ХӘНИФ*** *г.* – Туры күңелле кеше мәгънәсенә ия. Исламга кадәрге Гарәбстанда бер аллага табынган, ләкин билгеле бер динне тотмаган кешеләрне хәнифләр дип атаганнар. Хәнифләр йәһүдилек белән христианлыкны кире какканнар. Мәс., Пәйгамбәрнең хатыны Хәдичәнең Вәрака ибн Нәүфәл исемле агасы хәниф булган, ә Мөхәммәд Пәйгамбәр хәнифләрне Ибраһим пәйгамбәргә иярүчеләр дип санаган. Хәнифлек Исламның фикри чыганакларыннан берсе була.

Коръәндә Ибраһим пәйгамбәр *хәниф мөслим* дип аталган. Ибн Мәсъгуд Коръәненең башлангыч мәтеннәрендә *хәнифийә* термины да булган, соңыннан бу сүзне Ислам термины белән алмаштырганнар дип исәпли (мәс., 3:19/17). Ислам белгече Л.И.Климович та XI гасырның беренче яртысына кадәр мөселманнарның баштагы исеме – *хәниф* сакланган әле дигән фикердә. Чыннан да VIII-IX гасырларда ислам әдәбиятында "хәниф" сүзе "мөселман" сүзенең синонимы булып йөри, ә X гасырда суфилар үзләрен еш кына "хәниф" дип атаганнар.

***ХӘРАМ, ХӘРӘМ*** *г.* – Тыелган, тыюлы. Мондый гамәлне кылган кеше зур гөнаһлы булыр, аны хәләл дигән кеше кяфир булыр. *Хәрам гамәлләр:* җан иясен үтерү, кешене йә хайванны җәберләү, гайбәт сөйләү, угрылык кылу, исерткеч эчү кебек эшләр.

***ХӘРАМ КӘБАИР*** (зур хәрам): Аллаһка ширек катнаштыру, кеше үтерү, зиначылык, рибачылык, гайбәт йөртү, хәмер эчү, комарлы уеннар уйнау, фал, дуңгыз ите ашау, ялган, юлбасарлык, ата-анага хөрмәтсезлек һ.б.

Хәрам эшне *хәрам ләгыйнә* һәм *хәрам ләгыйрә* дип ике төргә бүлеп карау да очрый. Беренчесе – ләгънәтләнә торган эш (кеше үтерү, зина, рибачылык, ятимнәр өлешенә керү, ялганлашу, гайбәт, хөседлек һ.б. шундыйлар). Икенчесе – караклык, кеше өлешен тартып алу кебек эшләр.

*Хәрам гайре золми* – золым булмаган хәрам эшләр, ягъни башка затларга зыян һәм җәбер китермичә, кешенең үзенә генә начарлык китергән гамәлләр. Бар нәрсәдән шомлану, бөтен эшне начарга юрау да шушындый хәрам гайре золми эш булып санала. Сихерчелек, багучылык кебек эшләрне дә хәрам золми исәбенә кертәләр.

*Хәрам занный* – анык булмаган хәрам.

*Хәрам белән тәрбияләнгән тән җәннәткә кермәс.* Хәдис.

Хәрам гамәл кылганыгызны һичбер кешегә күрсәтмәгез, кылу – бер хәрам, күрсәтү – икенче хәрам. "Шәригать хөкемнәре"ннән.

***ХӘРАМ АГАЧЫ*** — Җәннәттә Адәмгә һәм аның хатыны Һәвага җимешен ашау тыелган агач. Иблис вәсвәсә кылганда Адәмгә бу агачны "мәңгелек тормыш" агачы дип атый (20:120). Библиягә караганда, бу — Яхшылык һәм Яманлык агачы булган, ләкин Коръәндә мондый атама юк.

***ХӘРАМ АЙЛАР*** — Сугыш алып бару тыелган айлар (*рәҗәб, зөлкагъдә, зөлхиҗҗә* һәм *мөхәррәм* айлары). Башкача *әшһуруль-хурум* диләр.

***ХӘРАМ ИТ*** — Мөселманга дуңгыз итенең, шулай ук күп кенә башка хайваннар (мәс., бака) итенең хәрам булуы һәркемгә билгеле. Ләкин мөселманча тәрбияләнмәгән, мөселманча суелмаган терлек ите дә хәрам санала. Билгеле булганча, фермаларда мал караучылар арасында миһырбансыз кешеләр аз түгел. Алар мал-туарны ач тоталар, вакытында эчермиләр, аларга яман сүзләр әйтәләр, сугалар һәм бичара терлекләр даими стресс халәте кичерә. Ә стресс вакытында канга адреналин һәм төрле әчелекләр бүленеп чыга, организм үзен-үзе агулый. Фаҗига ит комбинатында тәмамлана: башына суккач аңгырайган хайван әле үлеп тә җитмәгән була — аның корсагын ярып эшкәртә дә башлыйлар. Хайванның канына бүленеп чыккан агулар аның итенә күчә... Ә үзе карап, үзе тәрбия кылган малын суйганда, хуҗа кеше Аллаһының исемен әйтә, хайванны тынычландыра һәм бер ышкуда бугазлап, канын агызып бетерә. Мондый терлек ите пакь була, әлбәттә.

Коръәндә әгәр берәү ачлыктан интегеп, хәләл ризык табудан гаҗиз булса, әлеге хәрам итләрне җан саклар хәтле генә ашавы гөнаһ булмас диган фикер уткәрелә. Чөнки "Алла ярлыкаучы һәм рәхмәт кылучы" ("Маидә" сүрәсе, 5:3.).

Ризыкның хәрам яки хәләл булуына карата схоластик сүз уйнатулар да бар. Мәс., йомырка — хәрам, чөнки ул нәҗес юлыннан чыга; шул ук вакытта ул — хәләл дә, чөнки нәҗесләнүдән аны кабыгы саклый.

***ХӘРӘМ, ХӘРӘМ ЙОРТЫ, ХӘРӘМСАРАЙ*** *г.* — Хәлифә һәм шаһларның сөяркәләре — *җарияләр* яши торган сарай. Рус телендә: *гарем, сераль* (соңгысы сарай сүзеннән үзгәреп, француз теле аркылы килеп кергән).

***ХӘРӘМ АГА(СЫ)*** — Гадәттә җарияләр сараенда — *хәрәм йортында* хезмәт итүче печтерелгән ир кеше. Евнух, хаси (кастрат); хезмәтче, хадим. *Евнух* сүзе гарәп теленнән түгел, ул грекчадан "ятак сакчысы" дип тәрҗемә ителә.

Коръән дә, хәдисләр дә кешегә яки хайваннарга кастрация ясауны тыя. Ләкин миляди 800 еллар тирәсендә (Персияне яулап алганнан соң) Исламга борынгы Шәрык әхлагы үтеп керә башлый. Мәс., Һарун әр-Рәшиднең улы әл-Әмин хәлифә кастратларны туры килгән саен сатып алган, аларны көндез дә, төнлә дә үз янында тоткан, хатын-кызларны бар дип тә белмәгән дип сөйлиләр. Кастрация ясау операциясенә ул заманнарда Абиссиния шәһәре Хаджада оста булганнар. Әле XIX гасыр башларында да Югары Мисырдагы ике христиан (кобыт) монастыренда хәрәм агалары "җитештерү" эше чәчәк ата, алар бөтен Мисырны диярлек һәм өлешчә Төркияне "өченче җенесле" хезмәтчеләр белән тәэмин итеп торалар.

Ул заманнарда дүрт төрдәге хәрәм агаларны аерып йөрткәннәр: кара тәнлеләр (зәнкиләр), сәкалибләр (славяннар), греклар һәм кытайлылар. Славяннарны башта Испаниягә Алмерия провинциясенең борынгы башкаласы Печинага алып килгәннәр, шунда яшәүче йәһүдиләр аларга кастрация ясаганнар, аннары Мисырга озатканнар.

Операция бик авыр үткәнгә, хәрәм агаларның бәясе югары булган. Византиядә, мәсәлән, хәрәм ага гади колга караганда дүрт тапкыр кыйммәтрәк йөргән.

Евнухлар җенси контактка сәләтле түгел диган караш таралган. Ләкин евнухларның да төрлесе була. Аларның бер төрлесенең — *"кара"* кастратларның күкәйләре дә, пенислары да кисеп алынган, ә икенче төрлесенең — *"ак"* кастратларның күкәйләре генә алып ташланган һәм болары секска сәләтле. Ихтимал, хәрәм агаларының "кара" һәм "ак" төрләргә бүленеше заманында тән төсенә карап эшләнгәндер.

Тагы шуны әйтергә кирәк, әле XX гасырда да гуманлы Европада матур тавышлы һәм музыкага сәләтле малайларны печеп (кастрация ясап), аларның югары вокал

культурасын саклап калганнар һәм мәшһүр тенорлар арасында кастратлар еш очраган. "Тенор" дигән сүзнең дә мәгънәсе "кастрат" бит. Хәрәм агаларының исеме алдыннан "ага" сүзе өстәп әйтелгән (хәлбуки "ага" сүзе дин әһелләре һәм яубашлары исеменең ахырына ялганган), татар телендәге "*хәрәм агасы*" дигән сүз дә әнә шуннан килә.

***ХӘРЕҖ*** *г.* — **1.**Җир өчен түләнә торган салым, җир салымы (чыганакларда *хәраҗ, хираҗ* язылышлары да очрый). Баштарак буйсындырылган халыклардан җыелган ясак рәвешендә булган, соңга таба да әле хәреҗне башка диндәгеләр генә түләгәннәр (мөселманнар *гошер* түләгән), ләкин тора-бара, хак дингә чыгучылар күбәйгәч, хәреҗ мөселманнардан да җыела башлаган. Хәреҗ акчалата да, натуралата да җыелган. Гадәттә ул бөтен уңышның өчтән бер өлешенә тигез булган. Казан ханлыгы чорында авыл ясагын "*сала хәраҗы*" дип атаганнар ("Башкортостан" энциклопедиясе). Тора-бара хәраҗ салымы гамәлдән чыккан, *зәкят* белән *гошер* генә калган, ләкин кайбер мөселман илләрендә һәм төбәкләрендә "хәреҗ" гомумән "салым" мәгънәсендәге сүз булып йөри. //*Иген хәреҗе* — уңыш күләменнән алына торган җыем. *Төтен хәреҗе* — төтеннән (морҗа исәбеннән) алына торган җыем (*тар.*). **2.**Чыгым. Рус телендәге *харчи, харчевня* сүзләре дә гарәпчә хәреҗ сүзенә барып тоташалар икән. Бу сүз славян телләренә төрек һәм татар телләре аркылы кереп активлашкан дип уйларга мөмкин. Беренче тапкыр ул Афанасий Никитинның "Хожение за три моря" (1466-1472) язмасында очрый. Аның бу китабында татарча, төрки һәм гарәп сүзләре аз түгел.

Күплек саны шәкеле — *хәраҗәт.*

***ХӘСИТӘ*** *тар.* — Гарәпчә *касыйдә* сүзеннән килеп чыккан. Кызлар тагып йөргән тасмага тегеп куелган өч яки дүрт почмаклы кесә; бу кесәгә әлеге кызга атап чыгарылган шигырь (касыйдә) язылган кәгазьне салганнар. "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә: "Хәситә — хатын-кызларның алтын-көмеш акчалар, ука һәм төрле кыйммәтле ташлар белән бизәлгән, күлмәк өстеннән күкрәккә киеп куела торган бизәнү әйбере."

***ХӘТЕМ*** *г.* — **1.**Тәмамлау, бетерү; бетем. //*Окур мосхафны һәр дәм хәтем итәр.* "Кисекбаш китабы". **2.**Мөһер сугу, мөһерләү. Мөхәммәд галәйһиссәламнең эпитеты — *Хатәмен-нәбийин* — "Пәйгамбәрләр мөһере", ягъни иң соңгы, тәмамлаучы пәйгамбәр. **3.**Коръән чыгу. //*Хәтем догасы* — Коръән укып чыкканнан соң татарча укыла торган дога. "Йа Раббым Аллаһ! Безнең Коръән укуда булган хата-кимчелекләребезне Үзеңнең фазыл вә рәхмәтең белән гафу ит, гамәл-гыйбадәт кылганда күңелләребезгә ихласлык, хаклыкта һәм иманда ныклык һәм үзең теләгән һәм риза булган эшне эшләргә тәүфыйгыңны насыйп итсәң иде," — сүзләре белән башлана.

Коръәндәге билгеле бер сүрәләрдән, аятьләрдән һәм мәрасим гыйбарәләреннән торган, һәр компонентының ничә тапкыр кабатлануы билгеләнгән мини-кануни текстны да хәтем дип атыйлар. Хәтемне уку Коръәнне уку кагыйдәләренә буйсына ("Мудрость суфиев" китабына кушымта рәвешендә бирелгән сүзлекчәдән).

Себер татарларында *катым аш*, ягъни хәтем ашы — русча "поминки" кебегрәк.

***ХӘТЕМ ХУҖА*** *тар.* — **1.**XIX гасырда кайберәүләр үзләренә шәхси мөһерләр ясатып яки йөзек кашына үз исемнәрен куйдырып, язуларда шуларны басканнар. Андыйларны хәтем хуҗа, ягъни пичәт, мөһер иясе дип атаганнар. **2.**Хуҗа Баһаветдин хәзрәтләре мөридләре белән намаздан соң укыган хәтем. Чыганакларда бу хәтемнең "хисабтан тыш хасиятләре бардыр" дип күрсәтелә.

Себер якларында баланы сөннәткә утырту уңаеннан уздырылган мәҗлес һәм уеннарны да *катым хуҗа* дигәннәр.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Татар Танае

Татар Танае авылы Яшел Үзән районында, район үзәге Яшел Үзән шәһәреннән 46 чакрым ераклыкта, җирле үзидарә советы үзәге Мамадыш-Әкилдән—4, Гөбенә тимер юл станциясеннән—12, Козловка пристаненнан 45 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл атамасы тарихи чыганакларда һәм белешмәләрдә искә алына. Казан ханлыгы чоры авыллары теркәлгән исемлектә составына Мамадыш атамасы кергән авыллар Мамадыш Пять дип теркәлгән. Татар Танае авылы элек Мамадыш-Тәүгилде дип йөртелгән.

Д. А. Корсаков бастырып чыгарган белешмәдән күренгәнчә (XVIII йөз мәгълүматларын үз эченә ала), авылда ясак түли торган 33 крестьян, ясак түли торган 253 татар, 4 керәшен татары яшәгән. 1859 ел мәгълүматларын туплаган тарихи белешмәдән аңлашылганча, Гөбенә суы ярына урнашкан Мамадыш-Тәүгилде (Танай) авылындагы 136 хуҗалыкта 412 ир-ат һәм 406 хатын-кыз көн күргән, бер гыйбадәт йорты булган. 1898 елда басылып чыккан тарихи белешмә мәгълүматларына караганда, Мамадыш-Тәүгилде авылында татарлар һәм руслар яшәгән. К. П. Берстель белешмәсендә (1908) авыл Татар Мамадышы, Тавелдино Татар Танае (Татарско Мамадыш, Тавельдино Татарско Танаево) дип бирелгән һәм анда 1293 татар һәм рус кешесе яшәгәнлеге искәртелгән. К. Насыйри мәгълүматларына караганда, Татар Танае авылын элек Тәүгилде Мамадыш дип йөрткәннәр.

Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, Татар Танае авылы халкы күршедәге Мамадыш-Әкил, Карашәм, Әҗәле, Кызыл Яр авыллары белән бергәләшеп Кала ала уен җыенын үткәргәннәр. Бәйрәм июнь урталарында уздырылган. Җыенның атамасы икенче төрле Түбәтәй дип тә йөртелгән.

«Әзи баба шәҗәрәсе» Яшел Үзән районының Мамадыш-Әкил, Татар Танае, Апас районындагы Арслан, Багай, Гордеево, Салтыган авыллары белән бәйле. Хронологик чикләре XIV—XX йөзләрне колачлый. Шәҗәрә фрагментар рәвештә Риза Фәхретдин һәм Каюм Насыйри тарафыннан бастырып чыгарыла. Шәҗәрәнең тулы булмаган үзәгендә түбәндәге исемнәр билгеләнгән: Әзи баба—>Баймәт—>Мөхәммәткол—>Дәмин—>Әмин (1841 елда вафат булган)—>Мөхәммәтша—>Хәсәнҗан—>Гарифҗан—>Әшрәфҗан (1907 елда туган)—>Наил (1942 елда туган).

Шәҗәрә легендасында Әзи бабаның килеп чыгышы ягыннан болгар булуы һәм аның балалары Мамадыш-Әкил, Татар Танае, Мамадыш Арыслан, Мамадыш (Багай), Гордеево авылларын нигезләүләре әйтелә (Әхмәтҗанов).

«Биләр шәһәреннән Байсар нәселе шәҗәрәсе» тексты Татар Танае авылында табылган зур күләмле шәҗәрә китабыннан Марсель Әхмәтҗанов тарафыннан күчерелгән.

Шәҗәрәдәге материалларны XIX гасырда мәгърифәтче Каюм Насыйри да күргән һәм язып алган. Аның материаллары да Татар Танае авылы бабаларыннан Җәммәт һәм биш улының Биләрдән килгәнлеген теркәгән.

«Кыргыз шәҗәрәсе»нә язган искәрмәдә Марсель Әхмәтҗанов мондый сүзләр әйтә: «...кыргыз этнонимы татар халкы өчен ят булмаган. Кыргыз-казакъ нәселләре

*Дәвамы. Башы журналның 2006 елгы 6 санында.*

Тау ягында, Татар Танае авылында һәм Биләр шәһәрендә яшәгәннәр.

Олылар сөйләве буенча, ин элек Татар Танае оешасы авыл урынына Мамадыш Әкил авылыннан Әзи-Әжи бабай килеп утырган. Әжи бабайнын Җәммәт, Баймәт, Туймәт, Колмәт исемле дүрт улы була. Җәмматтән туган Хәмид. Хәмидтән туган: 1) Сәгыйд, 2) Хәбибулла, 3) Халид. Сәгыйдтән туган: 1) Сәйдәш, 2) Сәйфулла, 3) Сәймәт һ.б. Авылда бу кешеләрдән килгән нәселләр әле дә исән-сау гына, матур итеп яшиләр икән».

Элек авылда урыслар да яшәгән. Югарыда искә алынган тарихи белешмәдә бу турыда сүз булган иде. Татар Танае авылында гомер кичергән Дәүләтша абый һәм Мөнирә апанын сөйләвенә караганда: «Урыслар Танайда 40 төтен генә булганнар һәм 1891 елны аерылып чыкканнар һәм Рус Танаена нигез салганнар. Татар Танаенда бер урам әле дә Урыс урамы дип йөртелә.

Урыслар бик яхшы жирләр алып, бик бай яшәгәннәр, бал кортлары, хайван күп тотканнар. Алар тора-бара 60 төтенгә житкәннәр. Хәзер 14-15 төтеннән артмас. Элек Бөти тауда Мамадыш-Әкил крестьяннары белән Татар Танае һәм Рус Танае халкы икесе бер яктан шул тирәдәге бәхәсле жир өчен сугыша торган булганнар. Рус Танаеның Семен атлы кешесе Мамадыш-Әкил авылынын Вахит исемле кешесен таяк белән бәреп үтергән.

Татар Танае авылы тирә-юнендә елга-инеш-сулар, таулар, күлләр, сазлыклар, басулар, исемле урыннар күп.

Авыл үзәнлеккә урнашкан. Анын ике ягында да зур таулар тезелеп киткән. Ирексездән, борынгы заманнарда бу тирәдә бик зур елга акмадымы икән, дип уйлап куясын.

Элек бу тирәләр калын урманнар белән капланып алынган булган. Авыл янындагы ышна сүзе кергән топонимнар шул заманалардан калган тарихи истәлекләр. Менә кара урман... Анын уртасында таза һәм куәтле бабаларыбыз агач артыннан агач егып чәчүлек жирләр, йортлар салу өчен урыннар ачалар... Су һәм чишмәләр зәп-зәңгәр сулы, чиста һәм сафлар. Кешеләр күнеле дә нәкъ шулай ук чиста һәм пакь булган. Бер-берсенә ярдәм итеп, дустанә яшәгәннәр... Бергәләшеп йортлар торгызганнар, дошман килсә бергәләшеп каршы торганнар, бер-берсен бирмәгәннәр. Олылар кечеләрне, кечеләр олыларны хөрмәт иткән. Монда халык бәхетле һәм гадел тормыш белән яшәгән...

Урман арасыннан Гөбенә суы аккан. Ул Зөягә килеп тоташкан. Гөбенә суында элек алты ташлы тегермән эшләгән. Авыл басуында Гөбенәгә коя торган елга-чокырлар байтак (Тау ягында елгаларны чокыр дип әйтәләр). Тоба елгасы, Уктачыл чокыры, Канны (канлы) күл чокыры, Ышланлы суы, Кабык күпер чокыры суы, Иске Гөбенә, Чат чокыры, Нәүрәп чокыры, Мөнәш чокыры, Ышналы чокыры, Елга чокыры, Нәжметдин малае чокыры, Минһажетдин чокыры, Акшарлык чокыры, Урта алан чокыры, Кыр ышланлы чокыры һ.б. Авылнын көньягында кечкенә генә инеш ага. Аны халык, югарыда искә алып кителгәнчә, Ышланлы дип атый. Анын тирәсендәге басуларны һәм көтүлекләрне дә халык Ышланлы буе дип йөртә.

Күлләрнен табигыйлары да, казып ясалганнары да бар. Авыл уртасындарак урнашкан күлне халык Көя күле дип атый. Авылнын икенче башында жәй көннәрендә кибә торган Пилмән күле жәелеп ята. Бу күлне авыл халкы казып ясаган. Күлнең ике ягында тау-калкулыклар урнашкан; бу калкулыклар күл казыганда чыккан балчык. Аны Пилмән таулары дип йөртәләр. Пилмән исеме күл янында яшәгән кешеләрнең кушаматыннан килеп чыккан. Авыл янында тагын Каен күле, Кумыл күле, Сәрби күле, Мансур күле, Мунчала күле, Чыршы очы күле, Камә күле һ. б. исемдәге күлләр бар.

Чишмә-кизләүләр: Кизләү, Уктачыл кизләве, Маржа кизләве һ. б. Авыл янында сазлык һәм буа да әлегә исән.

Татар Танае авылы тауларга да бай. Анда Мичкә тау, Бөти тавы, Морат тавы, Багай тавы, Панау тавы, Ышна тавы, Чыбалан тавы исеме алган тауларны искә алып китү кирәк. Авыл янында тагын Алып бабай чабатасын каккан тау игътибарга лаек. Кайбыч районынын Шуширмә авылында да Алып бабай чабата каккан тау бар. Татар Танае авылы халкы сөйләвенчә, Алып бабайнын бер аягы Шуширмә авылында, икенчесе Татар Танае авылында булган. Менә бит, халык фантазиясе нинди ул!

Авыл янында чалу-печәнлекләр һәм болыннар да аһәнле исем алганнар. Уба чаты чалуы, Маматыш болыны, Таш кичү чалуы (чалу янында коесы да бар, халык аны кое дип атый), Уба сырты, Вөлкә болыны, Арык арты һ. б. печәнлек-болыннар әле дә халыкка хезмәт күрсәтә.

Басулардан Урман басуын, Ышна басуын, Вагай басуын һәм Марат басуын атарга мөмкин.

Авыл халкы Кумыл юлы, Ходайбирде юлы, Күпер юлы дигән юлларны әле дә хәтерендә саклый.

Авыл янындагы исемле урыннарны да әйтеп китик. Гөбенә күпере, Кабык күпер, Питрәй тирмәне, Туйралык, Күпер ягы, Хәмиди култыгы, Кабык күпер, Гатау яры, Мансур аланы, Туералык, Җиләклек кашы һ. б.

Халык хәтерендә Керәшен зираты атамасы сакланып калган. Зират урыны хәзер сөрелгән, басуга әйләнгән. Ә чукындырылган халык янадан исламга әйләнеп кайткан. Авыл халкы арасында керәшеннәр булуы югарыда искә алынган тарихи белешмәләрдә дә күрсәтелгән иде.

Авылда элек ике мәчет эшләгән. Берсе урынында хәзер су суырта торган җайланма (водокачка) тора. Ул урынны халык хәзер дә мәчет яны дип йөртә. 1992 елда авылдагы башлангыч мәктәп бинасын ремонтлап, манара куеп мәчет ачылган. Хәзер иртән авыл өстенә азан тавышы агыла. Авылга, халыкка иман кире кайта...

1990 елда авылда яңа, ике катлы урта мәктәп торгызылган. Аңа Афзал Шамов исеме бирелгән. Татар язучыларының олы буын вәкиле Афзал Шамов Татар Танае авылында хәлле крестьян гаиләсендә үскән. Кайбер әсәрләрен (күбесенчә фельетоннарын) ул Тәүгилде псевдонимы белән бастыра.

Авылда культура йорты бик матур һәм зур. Кибет, медпункт эшли.

Авылда иске зират урыны бар. Анда зур кабер ташы сакланган. Зират ташларында Акдәүләт, Имхуҗди улы Имхизди исемнәрен укырга була. Бу таш кебек үк рәвештәге ташлар Шөгәле зиратында да күзәтелә.

Хәзер мәетләр күмелә торган зиратны авыл халкы карап, тазартып һәм тәрбияләп тора. Тирә-юне тотып алынган, чүп-чардан чистартылган.

Авылның борынгы һәм күптән килә торган традицияләре бар. Бәби туйлары, никах мәҗлесләре, сабантуйлары үткәрүне халык чын күнеленнән эшли. Авыл олылары дога кылганда шәһре Болгар газизләрен, су газизләрен искә алалар. Халык үткәннәргә ихтирам белән карый, ата-ананы, олыларны ихтирам итә торган алмаш үстерә.

Авыл халкы үзәкләштерелгән газ яга, юлларга асфальт түшәлгән.

Авыл урамнары халык телендә Урта урам (Олы урам), Ындырчы урамы дип йөртелә.

Яшьләр хәзер авылда калып тормыш корырга тырыша. Бәхетләрен алар туган нигез һәм туган туфрак белән бәйләп табарга уйлыйлар.

Халыкның тормышы әйбәт һәм нык. Каралты-куралар таза, халык эшчән һәм тырыш. Авылда яшь гаиләләр күбәя. Авылның киләчәге матур һәм өметле.

## Үзи

Аксубай районында Иске Үзи һәм Яңа Үзи авыллары бар. Яңа Үзидә татарлар яши. Ул район үзәге Аксубайдан 19 чакрым ераклыкта урнашкан. Иске Үзи авылында чуашлар яши. Район үзәге белән ике арасы 19 чакрым.

Үзи атамасы тарихи чыганакларда һәм фольклор әсәрләрендә очрый.

Иске Үзи һәм Яңа Үзи авыллары янында археологлар бура, Имәнкискә, болгар, борынгы болгар, Алтын-Урда чорларына мөнәсәбәтле авыл хәрабәләре, зират, торак урыннары тапканнар.

XVIII гасырда Иске Үзидә 150 чукынган чуаш яшәгәнлеге мәгълүм. А. Артемьев белешмәсендә (1866) күрсәтелгәнчә, Иске Үзи авылындагы 71 хуҗалыкта 232 ир-ат һәм 222 хатын-кыз, Яңа Үзидәге 115 йортта 372 ир-ат һәм 365 хатын-кыз көн иткән. 1898 елгы китапта бирелгән мәгълүматларга караганда, Иске Үзи авылында руслар һәм чуашлар, ә Яңа Үзидә татарлар һәм чуашлар яшәгән. К. П. Берстель белешмәсендәге (1908) мәгълүматлар буенча, Яңа Үзи авылында 1502 татар һәм чуаш, Иске Үзидә 826 чуаш көн иткән.

XX йөз башында Яңа Үзидә ике мәхәллә була.

Беренче жамигъ мәчетенең бүгенге көнгә кадәр сакланмаган бинасы мәхаллә кешеләре тарафыннан 1906 елда төзелгән. 1909 елда мәхәлләдә ир-ат затыннан 308 жан исәпләнгән. Бу мәхәллә крестьяннары үзләренең имамнары итеп Сиражетдин Габделхәким улы Курамшинны (1862 елның 15 маенда туган) сайлаганнар. Беренче мәхәллә мәдрәсәсендә 83 ир бала һәм 60 кыз укыган.

Хәзерге вакытта сакланган бер катлы агач мәчет 1906 елда Н. Фошдеребрюген тарафыннан эшләнгән проект белән тәңгәл килә. Яна мәхәллә 1906 елның февралендә теркәлгән. Шул ук вакытта Казан губерна идарәсе икенче мәчетне төзергә рөхсәт биргән, әмма проектның расланувы (төзелеш уставына каршы килү сәбәпле) тоткарланган. Чөнки, устав буенча, мәчет тирә-ягындагы мәйдан 20 сажиннан да ким булырга тиеш түгел. Шушы шартны үтәгәннән соң, 1908 елның 7 июлендә, ниһаять, мәсьәлә унай хәл ителгән. Мәхәлләдә ир-ат затыннан 273 кеше исәпләнгән.

Үзи авыллары утырган жирләр элек тоташ урман булган һәм халык урман арасына килеп урнашкан. Беренче килеп утырган кешене халык Үзи баба дип йөртә.

Авыл аксакаллары сөйләвенә караганда, Яна Үзи авылында төрле урыннардан жыелган халык яши. Бу авыл Иске Үзидән аерылып чыккан. Шуның өчен ана исемне Яна Үзи дип кушканнар. Берәүләр хәзерге Алексеевский районындагы Тигәнәледән, икенчеләре Яна Чишмә төбәгендәге Тубылгы Тау авылыннан килгәннәр. Авылда чукынмаган чуашлар да яшәгән. Күбесе ислам кабул итеп татарлашканнар. Авыл халкы чукындыру сәясәтен үз жилкәсендә татыган. Халыкның яртысы чукындырылган. Чукынмый калган кешеләр авылда төп ара, ягъни төп мөселманнар, ә керәшен татарлары кече ара дип йөртелгәннәр. Тирә-юньдәге татар авыллары халкы бу авыл егетләренә кызларын бирмәгән. Кече аралар исламга чыгу ягын караганнар. Тикшерергә килгән попларны куып жибәреп, ислам диненә күчкәннәр.

Авылда көчле мөселман төпләре Мөхәммәтнекеләр була. Алар үзләренә бер зират ясыйлар. Керәшен татарларының һәм чуашларның да аерым каберлекләре була.

Авыл янында Хужалар тавы дигән тау бар. Халык бу тау янына барып нәзер әйтә. Тау янына дога укырга халык чәршәмбе көнне килә. Хужалар тавы янында борынгыдан калган кирпечләр, чүлмәк ватыклары, көбә күлмәкләр һәм камчылар чыга. Авыл янында Кызлар зираты дип аталган изге урын билгеле.

Хужалар тавы турындагы легенда татар халык ижаты жыелмасының «Риваятьләр һәм легендалар» томына урнаштырылган. Яна Үзи авылында язып алынган «Мәржән каласы һәм унике кыз хикәяте» дигән тарихи риваятьтә болай сөйләнә: «Яна Үзи авылы янындагы кырда, урман эчендә Хужалар тавы дигән тау бар. Шул тауда борынгы заманнарда Мәржән исемле болгар шәһәре булган. Мәржән шәһәрендә Тырышмал Хужа хөкем сөргән.

Тырышмал Хужаның берсеннән-берсе сылу, берсеннән-берсе акыллы унике кызы булган. Хужа аларны, яшьләре житкәч, Бүләр шәһәренә Рабига остабикә мәдрәсәсенә укырга жибәргән. Алар арасында Мәржән иленең батыры Иштирәк баһадирның сөйгәне Нәркәс сылу да бар икән.

Рабига остабикә мәдрәсәсе Бүләрдәге Хужалар тавы[1] итәгендә бик зур чишмә буена урнашкан була. Рабига көн саен Шәһри Болгардан жир асты юлы буена 66 шәкертен ияртеп укытырга килгән.

Бер вакыт Болгар илен яу баскан. Ул Бүләргә кадәр килеп житкән һәм шәһәрне камап алган. Бүләрне якларга Кызылтаудан, Кызлардан[2], Нократтан[3] h.б. шәһәрләрдән батырлар килгән. Иштирәк баһадир да үзенең иптәшләре белән дошманга каршы чыккан. Сугыш бик каты булган, бик күп батырлар башларын салганнар. Иштирәк баһадир белән өч батыр сугыша-сугыша Хужалар тавына менгәннәр. Батырлар тау башында туган илләре өчен соң тамчы каннары калганчы көрәшергә сүз биргәннәр һәм дошманнар өстенә ыргылып, тигезсез сугышта шәһит

---

[1] Бу тау турында Ф. Тәржеманов «Жирле халык анда болгар изгеләре күмелгән дип исәпли. Төрле жирләрдән, хәтта Казаннан да зиярәт кылырга бик күп кешеләр килә», – дип яза.

[2] Легендар болгар шәһәрләре.

[3] Хәзерге вакытта Татарстанның Әлки районы Иске Нократ авылы янында Болгар чорыннан калган шәһәрлек бар.

булганнар. Аларны тау башында җирләгәннәр. Тырышмал Хуҗаның кызлары, Бүләр өчен сугыш барганда, яу артыннан каргап торганнар, шуның белән баскынчыларның көчләрен какшатканнар. Моны күреп ачулары чыккан илбасарлар кызларны куа башлаганнар. Нәркәс сылу, мәдрәсәдә алган гыйлеме белән, куа килүчеләргә каршы ау корган. Үзе курка икән, бу ауга киекләр генә эләкмәсә ярар иде дип, һәм, җиргә ятып тынлап, туганнарыннан сорый икән:

*Корып куйдым ау ишкән,*
*Шаулап килә, яу микән?*—дип.

Кызлар куркытып: «Яу, яу!!!»—дигәннәр. Шуннан унике кыз Мәрҗәнгә таба йөгерек атларын куганнар. Ә яу алар артыннан калмаган, урман, алмагачлар эчендә утырган гүзәл Мәрҗәнгә хәтле җиткән һәм шәһәрне көл иткән.

Ә Тырышмал Хуҗаны, аның унике кызын тотып алып Хуҗалар тавы кырына китергәннәр. Монда алар дошман кушуы буенча, яланаяк килеш көне-төне туфрак ташып, яна бер тау өйгәннәр. Дошманнар, биек тау өелеп беткәч, Хуҗаны һәм аның кызларын шул тау башына терелэй җиргә күммәкче булганнар. Шулчак кызлар унике йолдыз булып күккә күтәрелгәннәр, ә Тырышмал Хуҗа таудан сикереп елга суына әйләнеп, агып киткән. Халык хәзер дә шул елга башланган чишмәне изге санап, аңа адарына, ә кызлар өйгән тауны «Кыз тавы» дип атый.

1996 елның җәендә изге чишмәне төзекләндерү, матурайту һәм чистарту эшләре алып барылды. Бу саваплы эшкә Татарстан нефть берләшмәсе генераль директоры Ринат Галиев алына. Бер ай дигәндә чишмә тирәсен кечкенә шәһәрчеккә әйләндергәннәр дә куйганнар. Шәһәр паркларының бер якта торсын. Чишмә яры буена асфальт аллеялар түшәлгән, кырыйларын кирпеч белән уратып алганнар. Фонтан эшләп тора, ял итү урындыклары, ашау өстәлләре, намаз уку, ашарга пешерү бүлмәләре ясаганнар. Кыскасы, бу җирнең матурлыгын һәм гүзәллеген язып бетереп булмый, үзең барып күрергә кирәк. Халык бу урынны Изгеләр чишмәсе дип йөртә. Ринат Галиев һәм аның җитәкчелегендә эшләгән алтын куллы нефтьчеләргә саулык-сәламәтлек, ак бәхетләр тели халык.

Авыл янынннан Олы Сөлчә суы агып уза. Аңа Мөнәҗәп, Чиктермә, Мулла, Иске Үзи, Озын күпер сызасы, Гантәй күпер сызасы, Коры елга, Бикчабар, Чик, Яңа авыл арты, Калыйр, Кисә, Кәҗинкә елгалары килеп кушыла. Авыл янында чишмә-кизләүләр дә күп. Кайберләрен генә әйтеп китик: Кәҗинкә, Кызыл Яр, Камышлык, Болын, Коры елга һ. б.

Элек басуларда да чишмә-коелар казылган, аларны карап, чистартып торганнар.

Бүгенге Яңа Үзи авылы гөрләтеп яши. Йортлар саны 200 дән артыграк. Колхоз идарәсе шушында урнашкан. Авылда урта мәктәп, мәдәният йорты, кунакханә, медпункт, балалар бакчасы, мәчет бар. Халык үзәкләштерелгән газдан файдалана, юллар асфальтланган.

Халык әби-баба ята торган зиратны тәртиптә тота.

Авыл халкы ялгыз яши торган өлкәннәрне дә онытмый.

Халыкның тормышы әйбәт, йортлары да таза, матур. Авыл үсүгә, янаруга һәм зураюга йөз тота.

Яңа Үзи авылында язучы Газиз Кашапов (Газизҗан Салих улы Кашапов, 1942—1991) туган. 1992 елда авылда Г. Кашаповка багышланган музей ачылган, аның бер бүлмәсендә тарих-этнография музее эшли. Авылда шулай ук журналист, җәмәгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык депутаты булып сайланган Роза Рәхмәтулла кызы Туфитуллова (1945) туып-үскән.

АККОШ КҮЛЕ–ИЛҺАМ АЛАНЫ

*«Мәгариф» нәшриятында «Аккош күле—илһам аланы» исемле китап әзерләнде. Татарстан язучыларының «Аккош күле» иҗат йорты тарихы һәм бүгенге хәле тасвирлана анда. Китапта утыздан артык авторның «Аккош күле»нә багышланган хатирә-язмалары, шигырьләре тупланган. Без шул китапка кергән берничә истәлек язмасы белән укучыларыбызны да таныштырырга булдык.*

Мөдәррис Вәлиев

## «Аккош күле»ндә әдипләр чуагы

Анда янган учакларның төтене дә үзгә, башларны әйләндерерлек хуш исле. Анда үскән урман үләннәре дә купшы гөл-чәчкәләрдән затлырак.

Анда үткән гомернең һәр минуты сәгатькә тиң.




Әйе, татар әдипләренең атаклы җәйләве — «Аккош күле»нең хәтер аланына әйләнә барган дәвере бүген. Кулыгызга алган китапта ул шул рәвешләрәк чагылыр да. Чөнки авторларыбыз — шактый озын гомер юлы үтеп, хатирәләр урманы аша тирән уйланулар күленә таба салмак кына атлаучы юлчылар. Алар һәр агачны, һәр үләнне танып, исемнәре белән эндәшәләр. Ике якка рәт-рәт булып тезелгән чыршы-наратлар аларны аягүрә сәламли. Баш очыннан гына вакыт утраулары төсле уйдык-уйдык болытлар ага... Ул болытлар «Аккош күле» дигән утар өстеннән инде ярты гасыр буе агалар... Бирегә, әйтик, безнең гаилә килгәнгә дә егерме елдан артык гомер үткән икән. Сибгат ага Хәким, Нәби ага Дәүлиләр белән ут күрше булып яши башлаган ул көннәрнең һәркайсы әйтерсең лә бал тулы кәрәз күзләре.

«Аккош күле» — илһам аланы. Сибгат аганың Хәсән Туфан тәрәзәсендә янган иҗат уты, гамь уты турындагы сүзләре әле дә булса язылып бетмәгән шигырь сыман яңгырый. Без килгән чорда да ул иҗат рухы сау иде әле. Күрше-күләннең «кич утырып», яңа гына каләм очыннан тамган әсәрләрен уку бәйрәмнәрен күрергә насыйп булгалады. Олыларны олылаган тәкъдирдә, җаннарның «бер яшьтә» икәнлеге шул чакларда бик ачык күренә иде. Холкыма күрә, ишеген шакып, бусагасын таптамасам да, бездән бераз гына арырак яшәгән Гомәр аганың үзе килеп, ихлас гәпләшеп утырган чаклары сагындыра. Кайберләре инде бакыйлыкка күчкән якты исемнәр...

Әдәби мохиттә генә түгел, «Аккош күле»ндә дә ызандаш булган язучыларның, холык-фигыль ягыннан һәм иҗат дәрәҗәсе белән нык аерылган тәкъдирдә дә, бер-берсен ныграк аңлавы, үз-якын итешүләре гаҗәпмени! Бу — мәгълүм иҗат

союзларыннан ныграк, абруйлырак бергәлек иде. Кешелеклерәк дип тә өстәргә кирәктер.

«Аккош күле»ндәге әдипләр чуагы — татар рухи тормышындагы иң матур фасылларның берсе.

Шул ук вакытта «Аккош күле» — киләчәк аланы. Бу китаптагы истәлек-уйланулар, мәгълүм сәбәпләргә бәйле рәвештә, беркадәр моңсулык белән өртелгән булсалар да, һәр язмадан әдәбиятыбызның дәвамлы язмышына өмет-ышаныч һәм аның якты шәхесләре белән горурлану хисләре бөркелә. Тарих тузаны күтәрелергә торган юл булып ятасы килми бу сәхифәләрнең. Алар, үткәнгә генә бәйләп тотмакчы хәтер-хатирә «камыт-тышау»ларыннан тугарылып, киләчәк үрләренә таба чаба.

Моннан бер ел элек укучыга тәкъдим ителгән Матбугат йорты турындагы китап-һәйкәл кебек үк, «Аккош күле» иҗат йортына багышланганы да — Татар Йортының әлегә күпләр өчен изгелеген җуймаган нигезен янә бер барлау, ныгыту омтылышы. Булыр әле, аның чын бәһасен аңлап, Милли рух аланы икәнлеген танучылар да булыр!

...Анда янган учакларның төтене дә башларны әйләндерерлек хуш исле. Андагы кәккүкләр сезгә һәм безгә озын гомер телиләр.

---

## Зөфәр Бәширов

### Сурәтләрдә тарих «күзе»

Аккош күле... Бу шигъри географик исем безнең гаиләдә бик күп еллар көндәлек тормышта телдән төшмәде. Әдип Гомәр Бәширов тормышында Татарстан язучыларының Аккош күлендәге иҗат йорты аеруча зур әһәмиятле урын алып тора иде. Чөнки язучылар өчен махсус иҗат йорты булдыру идеясе, дәүләтнең рәсми оешмаларыннан рөхсәт һәм җир урыны алу, проектларын эшләтү, финанс чыганакларын табу һәм, ниһаять, практик яктан төзелешен тәэмин итү —болар барысы да Гомәр Бәширов эшчәнлеге белән аерылгысыз рәвештә бәйләнгән.

1950 еллар башында Гомәр Бәширов, СССР Дәүләт премиясе лауреаты, СССРның Югары Советы депутаты һәм ТАССР Язучылар союзының рәисе буларак, бөтенсоюз аренасына чыга. Ул Мәскәү һәм Союзның бик күп республикалары язучылары белән аралаша, аларның тормыш һәм иҗат итү шартлары белән якыннан таныша. Мәскәү янындагы СССР Язучылар союзы Әдәби фондының Переделкино һәм Малеевка иҗат йортларында торып, эшләп кайта. Күрәсең, шул йөрүләр, күзәтүләр нәтиҗәсендә ул Татарстанда да язучылар өчен иҗат йорты булдырырга кирәк дигән фикергә килә һәм аны тормышка ашыру чараларын да күрә башлый.

Әтинең ул планнары турында мин беренче тапкыр 1953 елда гаиләдә иртәнге чәй вакытында ишеттем. Күрәсең, ул мәсьәлә принципта инде хәл ителгән булгандыр, чөнки сүз иҗат йортын кай тирәдә салу турында барды. Сөйләшкәндә Васильево, Займище, Моркваши дигән исемнәр чыкты. Мин дә, ул чагында 16 яшьлек яшүсмер, сүзгә кушылырга булдым.

Хикмәт шунда ки, без, Казанның Иске бистәсендәге Акком асты урамында үскән малайлар, табигатькә җәен-кышын ике җиргә йөри идек. Берсе — Иске бистәдән ерак түгел Иделнең Бакалтай дигән җире, икенчесе — Казанның Ягодный бистәсеннән көнбатыш яктагы Аккош күле урманы, күлләре. Җәйләрен Бакалтайга балык тотарга, ә кышларын Ослан тавына, Аккош күле урманына чаңгы шуарга йөргәли идек. Әлеге иртәнге чәйдә мин шул Аккош күле тирәсенең матурлыгын мактап сөйләдем. Минем сөйләгәннәрем әтигә ничек тәэсир иткәнен хәзер әйтүе

кыен, ихтимал, ул тирәләрне әти миннән башка да бик яхшы белгәндер. Ул житди мәсьәлә, әлбәттә, Язучылар союзында да, югары оешмаларда да бик жентекләп каралган булырга тиеш. Ничек булса булды, шул елның август аенда әти якын иптәше, Казан дәүләт университетының проректоры профессор Александр (Искәндәр) Гаврилович Шәфигуллин белән мине Аккош күленә алып китте. «Победа» автомобиле «Аккош күле» тукталышына килеп житкәч, шоссedан сулга борылып, урман юлы белән бераз барды да күл янындагы нарат урманы эчендә утырган дачалар поселогында туктады. Безне ул йортларның берсендә ял иткән шагыйрь Сибгат Хәким һәм аның җәмәгате Мөршидә ханым каршы алдылар. Күрәсен, Риза Ишморат гаиләсе дә шунда ял иткәндер, чөнки бераздан ул да җәмәгате Рәисә ханым белән безгә кушылды. Сибгат Хәкимнәрдә чәй эчкәч, барыбыз да Аккош күле тирәсен әйләнеп чыктык. Шул вакытта минем үтенечне тыңлап, язучылар урманның бер матур жирендә туктап тордылар, ә мин аларны фоторәсемгә төшердем.

Аккош күле тирәсе белән танышкач, безнең төркем, кире шоссега чыгып, урман юлы белән төньякка таба китте. Бер-ике чакрым узгач, Кече Тирән күл янында туктап, шул тирәләрне карап чыктык. Ул көнне төшергән рәсемнәрдә Кече һәм Зур Тирән күл күренешләре бар. Күрәсен, булачак иҗат йорты урыны шушы тирәләрдән сайланган булса кирәк.

Соныннан ул шулай булып чыкты да. Язучыларга иҗат йорты өчен урынны Кече Тирән күлдән үргә менгәч каен урманы эчендәге бер аланнан бирделәр. Ул вакытта анда шул тирәдәге 4—5 хужалыкның бәрәңге бакчалары иде. Шул бәрәңге бакчасында язучыларга иҗат йорты булдыру өчен әтигә бик зур көч куярга туры килде. Ул мәсьәлә Казанда гына түгел, күбесенчә Мәскәүдә хәл ителә иде. Чөнки төзелеш СССР Язучылар союзының Әдәби фонды акчасына алып барылды һәм соныннан, ялгышмасам, аның балансында булды. Күрәсен, иҗат йортын салырга Татарстанның Совмины да ярдәм иткәндер, чөнки әтинең, «Аккош күле» нефть акчасына салынды, дигәне исемдә. Шактый зур киртәләрне узып, кыенлыкларны жиңгәч, 1955 елны дүрт жыелма фин йорты кайтарылды. Иҗат йорты өчен бүлеп бирелгән шактый зур мәйданда ул дүрт йортны бик тиз арада торгыздылар. Төзелеш барышы турында әти Мәскәүдәге СССР Әдәби фонды алдында даими рәвештә хисап бирep тора иде. Шулай беркөнне әти мине, тагын дусты профессор А. Г. Шәфигуллин белән машинага утыртып, Аккош күленә алып китте. Мин яңа салынган фин йортларын, төзелеш мәйданын фоторәсемнәргә төшерергә тиеш идем. Үземә йөкләнгән бурычны мин кулдан килгән кадәр тырышып үтәдем, һәм ул фотографияләр Мәскәүгә хисапка кушымта булып киттеләр.



*Аккош күле. 1953 ел.*

Татарстан язучыларының «Аккош күле» исеменнән йөрткән иҗат йортының тарихы (гәрчә ул Аккош күле буенда түгел, ә Кече Тирән күл янында булса да) 1955 елда менә шушы дүрт фин йортыннан башланып китте.

Әтинең сөйләүләре буенча, иҗат йорты СССР Язучылар союзының Мәскәү янындагы Переделкино иҗат йорты шикелләрәк итеп планлаштырылган булган. Анда ашханә, клуб, медпункт һәм башка шундый тәэмин итү оешмалары да булдыру күздә тотылган. Әмма төрле сәбәпләр буенча ул планнар тормышка ашмады.

«Аккош күле» иҗат йорты икенчерәк, үзенчәлекле бер формада эшли башлады. Язучылар иҗат йортыннан бүлмәләрне бер елга арендага ала торган булдылар. Ул арендага йорт янынннан яшелчә-җимеш бакчасы өчен җир дә бүленеп бирелде. Билгеле, шәһәрдән читтә урман эчендә утырган йортта язучы берүзе генә яши дә, иҗат та итә алмый. Шунлыктан ул йортларда язучылар гаиләләре белән тора башладылар.

Иҗат йортына бәйләнешле истәлекләр минем хәтердә өзек-өзек фрагментлар рәвешендә сакланган. Чөнки алар күбесенчә анда төрле вакытта төшерелгән фоторәсемнәр белән бәйләнгән. Архивтагы иске негативларны, рәсемнәрне актарып карaганда ул фотографияләр гүя җанланалар, шул вакыттагы кешеләр, вакыйгалар, күренешләр әйтерсең кичә генә булган шикелле хәтер түреннән чыгып күз алдына килеп басалар. Ул истәлекләрнең фрагментар булуларының икенче сәбәбе дә бар. Мина бер вакытта да «Аккош күле»ндә даими рәвештә озаклап торырга туры килмәде. Гадәттә, мин анда әтигә бетмәс-төкәнмәс хуҗалык эшләрендә ярдәм итәргә генә йөри идем. Инде барган юлы Аккош күле тирәсендәге урманнарда йөрү, елның төрле фасылларында табигатьнең өрөзлексез үзгәрешен күзәтү, аларны фоторәсемгә төшерү минем өчен бик зур бәхет иде.



*Кече тирән күл. 1953 ел.*

Шуна күрә мөмкинлек булганда мин Аккош күленә бик теләп бара идем. 1955 елның кышында барганда яна салынган йортлар әле буш иделәр, берничә кеше генә тора иде. Шуларның берсе — язучы Нәби Дәүли. Нәби абзый инде шул еллардан ук анда даими яши иде һәм, ялгышмасам, иҗат йортының беренче коменданты да булды. Ул көннәрдә мин иртәдән караңгы төшкәнче Аккош күле урманында, фотоаппарат күтәреп, чаңгыда йөри идем. Бер баруымда каршыга шагыйрь Зәки Нури очрады. Ул шоссе янындагы кибеттән азык-төлек алып кайтып килә иде. Тонык кына көн, ябалак-ябалак кар ява. Зәки абзый, туктап ниндидер мәзәк сөйләп, күнелне күтәреп җибәрде. Мин аны шунда рәсемгә төшердем. Бер иптәш мине дә Зәки абзый белән бергә рәсемгә төшерде. Ул фотография миңа бүген дә Зәки абзыйның көләч йөзен, оптимизм һәм юмор белән сөйләшүен искә төшерә.

Шулай итеп, «Аккош күле» 1955 еллардан язучылар өчен чын мәгънәсендә иҗат йорты булып китте. Ул вакытта әлеге дүрт йортта 15 язучы торган, чөнки әтинең көндәлек дәфтәрендә 400 мең сумга 15 язучы өчен дачалар салынуы турында язылган (Г. Бәширов. Күңел дәфтәре. Икенче дәфтәр.— 8 декабрь, 1956 ел. Кульязма). Шуны да истә тотарга кирәк: ул вакыт өчен 400 мең сум бик зур сумма булып санала иде.

Әмма, күрәсең, ул дүрт йорт язучыларга җитми башлагандыр. Чөнки әти тагын яна йортлар салдыру эшләре белән йөри башлады. Бу юлы инде йортларны шәп юан нарат бүрәнәләреннән салдылар. 1957 елның сентябрь аенда мина тагын Аккош күленә барып, яна салынган йортларны отчет өчен фоторәсемгә төшерергә туры килде. Иҗат йорты утарының урта җирендә зур, дүрт гаилә иркенләп торырлык йорт салынган иде. Ул йортның ике якта да иркен верандалары да бар, һәр гаилә өчен аерым ишек эшләнгән иде.

Утарның көньяк-көнбатыш почмагында тагын бер кечкенә генә агач йорт

салынган иде. Анысы булачак комендант өчен салынды дип әйттеләр. Әмма комендант гаиләсе өчен ул кечерәк булды шикелле, аның гаиләсенә соңрак шул ук тирәдә икенче йорт салдылар. Ә бу кечкенә йортта озак еллар минем әти яшәде һәм иҗат итте.

Тора-бара йортлар артканнан-арта барды. С. Хәким һәм И. Гази бу утарда үз йортларын салып куйдылар. Утарның төньяк-көнбатыш почмагында 40 метр тирәнлектә скважина казылды һәм һәр йортка яхшы артезиан суы килә башлады, мунча салынды. Һәр йортның бакчасы булды, алмагачлар, җиләк-җимеш утыртылды, яшелчә түтәлләре күренә башлады, һәрбер өй алды чәчәкләр белән бизәлде. Шулай итеп яздан кара көзгә кадәр «Аккош күле» иҗат йорты үз тормышы белән яши башлады.

Аккош күлендә төрле елларда халыкка танылган бик күп язучылар, шагыйрьләр, әдәбият галимнәре яшәделәр, иҗат иттеләр. Мин күреп белгәннәре генә дә шактый: Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Абдулла Әхмәт, Риза Ишморат, Зәки Нури, Нәби Дәүли, Афзал Шамов, Хәсән Хәйри, Мария Елизарова, Галимҗан Латыйп, Нил Юзиев, Рафаэль Мостафин һәм башка бик күпләр. Аларның һәрберсенең тормышында, иҗатында «Аккош күле» һичшиксез тирән эз калдырган булырга тиеш.

Гомәр Бәшировның тормышына һәм иҗатына килсәк, Аккош күленең әһәмияте ифрат зур булды дип ихлас күңелдән ышанып әйтә алам. Юкка гына автор «Туган ягым —яшел бишек» повесте ахырында язылу урынын «Аккош күле — Казан. 1965—1968», ә «Җидегән чишмә»дә «Аккош күле, 1978—1981» дип куймаган бит. Аккош күленең матур табигате, андагы тынычлык, тынлык язучы кешегә иҗат эшенә тулысынча бирелеп, илһамланып эшләргә ярдәм иткән. Ә инде шәһәрдә ыгы-зыгылы тормыш белән яшәгән чакларда иҗат йорты әнә шул яклары белән сагындырган. Ул хисләр әтинең көндәлек язмаларында да чагылганнар. Мәсәлән:



*Иҗат аланының беренче йортлары. 1955 ел.*

«Бу көннәрдә хуҗалык эшләре белән баш катырдым. Их, минем җәй көне Аккош күлендә верандада берүзем ямь-яшел урманга күз салгалап язып утырган чакларым! Кая китте ул рәхәт көннәр, кая минем хөрлегем?! 30 октябрь, 1980». (Тормыш дәфтәре. Сайланма әсәрләр. V том.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2005, 386 б.).

Яздан алып көзгә кадәр әти белән әни «Аккош күле»ндә даими диярлек яшәсә дә, елның калган вакытларында да анда юл өзелми иде. Дөрес, кышларын көнендә генә барып кайтыла иде. Әти 1959 елдан башлап кышын Аккош күленә барып чаңгы шуа башлады. Чаңгы сукмакларында язучылардан Зәки Нури очраштыргалый иде.

Әти һәр язны бик сагынып көтеп ала иде. Март аенда ук без Аккош күленә барып, бакчада язгы эшләргә тотына идек. Алмагач ботакларын кисү, аларның кәүсәләрен ак известь белән буяу, карлыган куакларына корткычларга каршы агу сиптерү, түбәдән кар төшерү, алмагач төпләренә кар өеп таптау һәм башка бик күп шундый эшләр. Гадәттә, кыш буе яшәгән шәһәр тормышыннан туеп ул вакытларда анда язучылардан Сибгат Хәким, Хәсән Туфан да күренгәли башлыйлар иде.



*Иҗат йорты салу өчен урын сайларга килгән бер төркем язучылар Аккош күле урманында. Сулдан уңга: Габдрахман Әпсәләмов, Риза Ишморат, Мөршидә ханым (С. Хәким хатыны), Александр Гаврилович Шәфигуллин (Казан дәүләт университетының проректоры), Гомәр Бәширов, Рәисә Ишморатова, Сибгат Хәким. 1953, август.*

Ә инде апрель аенда безнең анда барулар ешая. Табигатьнең уянган чагы. Ничәмә-ничә мәртәбәләр Аккош күле өстеннән күктә каңгылдашып кыр казлары узганын сокланып карап калдык без! Урман артындагы кырлардан карлар эреп, ерганаклар буйлап шаулап, язгы ташулар ага. Утардан ерак түгел Шайтан ерганагыннан аккан язгы ташу тавышы хәтта төннәрен дә ишетелә иде. Кече һәм Зур Тирән күлләр арасындагы үзәнне су баса, юл өзелә. Шул вакытларда Аккош күленә Хәсән абзый Туфан да йөри башлый иде. Бер баруда мин аны әнә шул үзәндә карлы суны ерып барганын күреп хәйран калган идем.

Язның ничек килүенә карап, үзәндәге юл кипшерү белән әти белән әни «Аккош күле»нә торырга күчәләр иде. Дөрес, әтине төрле эшләр шәһәрдән бөтенләй үк җибәрми, әмма күп вакыты шунда уза иде. Җәй җиткәч, алар янына безнең балалар да торырга киләләр иде.



*Балалар концертын карарга җыелган тамашачылар. 1974, август.*

Бүтән язучы гаиләләрендә дә шундыйрак хәлләр иде. Дөрес, иҗат йортына көндез барсаң, бакчаларда хатын-кыз һәм балалардан башкалар күренми әле, чөнки язучылар һәрберсе үз бүлмәсендә, язу өстәле янында. Бервакыт хәтта баганаларга «Тынычлыкны саклагыз!» дигән өндәү дә язып эленгән иде.

Иҗат йортының, Г.Тукай әйтмешли, «һәр ягы урман иде». Элегрәк елларда табигать анда шактый бай, саф, чиста иде әле. Кайвакытларда утар тирәсенә хәтта пошилар да килгәлиләр иде. Ә инде кошларның күплегенә, төрлелегенә хәйран каласың. Әти белән Хәсән абый Туфан ул кошлар белән аеруча мавыгып киттеләр. Әти Мәскәүдән Чехословакиядә басылган «Кошлар дөньясында» исемле рәсемле китап алып кайтты, ә Хәсән абыйның шактый калын, махсус белгечләр өчен чыгарылган «Определитель птиц СССР» китабы бар иде. Шул китаплар буенча алар шактый кошларны танып, күзәтеп тордылар. Мин дә аларны сурәткә төшерү белән мавыгып алдым. Архивтан бу китапка рәсемнәр сайлаган вакытта бер кошның рәсемен күргәч, «кылт» итеп исемә төште. Бу кошның оясын мина бит Хәсән абый Туфан үзе күрсәткән иде! Аккош күленә бер килүемдә минем янга Хәсән абый килде. «Зөфәр, әйдә, мин сина бер яна кош күрсәтәм»,— дип, урманга алып китте.

Урманда яздан алып җәй урталарына кадәр кошлар сайраган тавыш өзелми иде. Сыерчык, сандугач, күке, шәүләгән, уткойрык һәм башка бик күп кошларны якыннан күрү гадәти хәл. Әтинең бакчасына терәлеп үскән биек каенга куелган сыерчык оясы бер елны да буш калмый иде. Дөрес, миләш чыпчыклары җиләкләр өлгергәч шактый зыян китерәләр иде китерүен.

Әмма 60 нчы еллар урталарыннан бу идиллия шактый ук ямьсез булып бозылды. Сәбәбе — иҗат йортыннан төньякта ике-өч чакрым ераклыкта «Оргсинтез» заводлары эшли башлады. Кайвакыт җил шул яктан кара сөрем алып килә, ерганаклар буйлап Тирән күлгә әллә нинди сасы, сары төстәге сулар агып төшә башлады, агачлар корыды. Аккош күленең һавасы бозылды, кошлар да елдан-елга кими башладылар. Бу хәл язучыларга шактый борчу салды. Әти шул унайдан Оргсинтез җитәкчеләренә дә, югары оешмаларга да йөреп карады. Ул проблема буенча химик, академик Б.Е. Арбузов белән дә кинәште. Соңрак, заводларның технологиясе камилләштеме, ничекме, күзгә күренгән зыян кимеде. Әмма табигать ул тирәдә шактый зәгыйфьләнде, кошларның саны да, төре дә бик кимеде.



*Концертта Наилә (Г. Бәширов оныгы) һәм Ләйлә (Х. Хәйри оныгы) татар биюен башкаралар. 1974, август.*

Еллар узу белән иҗат йорты Татарстан Язучылар союзының җәйге резиденциясе булып китте. Тугандаш республикалардан килгән язучыларны да шунда алып барып кунак итә торган булдылар. 1966 елның җәендә Урта Азия һәм Кавказ республикаларыннан килгән язучыларның бер төркемен әти Аккош күлендә кунак иткән иде. Исемдә калганнардан Гафур Голәм, Кайсын Кулиев, Сабит Муканов әтинең шул кечкенә генә йортының верандасында бик күңелле итеп табын артында гәпләшеп утырганнар иде. Кызганыч, мин аларны рәсемгә төшерә алмый калдым, чөнки кунакларга хезмәт итүдән бушамадым. Шул ук җәйне, 26 июньдә, Аккош күлендә әти икенче кадерле кунакны кабул итте. Ул Уфадан килгән язучы Сәйфи Кудаш иде. Чәйдән соң Сәйфи Кудаш, Хәсән Туфан, Мөхәммәт Мәһдиев һәм әти бакчада каен күләгәсендә өстәл янында шактый вакыт сөйләшеп утырдылар. Соңыннан Аккош күле урманнары буйлап йөреп тә кайттылар. Ул көнне төшергән фоторәсемнәр кадерле истәлекләр булып калдылар.

Тора-бара «Аккош күле»ндә үзенең традицияләре туа-оеша башлады. Шундыйларның берсе — «әдәби җомга». Утарның урта бер җирендә күпкырлы формадагы беседка (чатыр) бар иде. «Әдәби җомга» көнне «Аккош күле»ндә яшәгән язучылар, шул беседкада җыелып, берәр авторның яңа әсәрен тыңлыйлар. Соңыннан фикер алышулар, бәхәсләр башлана. Миңа фәкать ике «әдәби җомга»ны күрергә туры килде. 1969 елның 18 июлендә шагыйрь Хәсән Туфан «әдәби җомгада» шактый озын яңа бер әсәрен укыды. Икенчесендә, 1969 елның 9 августында Сибгат Хәкимнең яңа поэмасын тыңладылар. Кызганыч, укылган әсәрләрнең исемнәре вакытында язылмаган, ә хәтернең ялгышуы мөмкин. Әмма ул көннәрне төшергән фотографияләр «әдәби җомга»ларның ничегрәк узуларын күзалларга ярдәм итә алалар.



*Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Гомәр Бәширов иҗат йортыннан автобус тукталышына баралар. 1969, апрель.*

Тагын бер матур традиция бар иде. Җәй ахырында, яшелчә, җиләк-җимешләр өлгергәч, уңыш бәйрәме уздырыла башлады. Мин 1969 елның 9 август көнендә уздырылган уңыш бәйрәме мәҗлесендә булган идем. Утар кырыенда зур гына бер сарайда (ул клуб хезмәтен дә үти иде шикелле) озын өстәлдә табын әзерләнде. Һәрбер кунак үзенең бакчасында үстергән җиләк-җимешләрне алып килде, башка нигъмәтләр дә шактый мул иде. Мәҗлесне бик күңелле итеп тамада булып Зәки Нури алып барды. Шагыйрьләр шигырь укыдылар, үзара күңелле итеп сөйләшүләрдән мәҗлес гөр итеп торды. Нәби Дәүли, ниндидер юмористик шигырь укып, халыкны көлдереп алды. Ә Хәсән абый Туфан үзенең мәшһүр «...Ә җир барыбер әйләнә!» шигырен бик ялкынланып укыды. Ул мәҗлестә төшерелгән Хәсән абый фоторәсемнәре (гәрчә яктылык бик начар булса да) минем архивта иң кадерле кадрлар булып саклана ал. Белмим, булдымы икән соңыннан тагын шундый матур, күңелгә сеңеп кала торган мәҗлесләр.

Җәй көннәрендә Аккош күлендә шактый бала-чага җыела иде. Алар үзара бик тиз дуслашып, бергә уйнап, урманга җиләк, гөмбә җыярга йөреп мәш киләләр, үз тормышлары белән яшиләр, кыскасы, рәхәт чигәләр иде.

Алай гына да түгел, ел саен диярлек җәй урталарында шунда торган балалар язучылар, ата-аналары, килгән кунаклар алдында концерт та куялар иде әле. Берзаман башлана концертка әзерләнүләр, репетицияләр, әниләренең күлмәкләреннән концерт костюмнары әзерләүләр һәм башка шундый ыгы-зыгылар. Концертны оештыручы, балаларны җитәкләүче энтузиаст кешесе дә бар — ул әдәбият галиме Хәсән Хәйринең җәмәгате Рауза ханым. Менә беркөнне әлеге «әдәби җомга» уздырыла торган беседкада сәхнә оештырыла, чаршаудан пәрдә тартыла. Сәхнәдә, пәрдә артында төрле яшьтәге бала-чага, җыелып, чырык-чырык көлешә, шаяра. Ә беседка алдында тамашачылар, һәрберсе үз эскәмиясе белән килеп, рәт-рәт тезелеп утыралар. Концертны, гадәттә, иң кечкенә бала башлап җибәрә. Китә шуннан шигырь укулар, бергәләп тә, аерым да җырлаулар, биюләр. Соңыннан һәр артистны, яшенә карап, әзерләп куйган бүләкләр дә көтә әле.

Инде тамашачыларның шатлану-сөенүләре, көлүләре, кул чабулары әйтеп бетергесез ихлас була, чөнки һәрберсенең диярлек йә оныгы, йә баласы катнаша бит! Әмма ләкин алар арасында да Хәсән абый Туфан һәр чыгышка үзенең эмо-

циональ реакциясе белән аерылып тора иде.

Бүген ул сәхнәдә җырлаган, биегән балалар инде урта яшьләрдәге дәрәҗәле ирләр, ханымнар — үзләре ата-аналар.

Аккош күлендәге шул тарихи, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким шигырьләрен укыган беседка бүген дә бармы икән? Йөриләрме икән ул бакчаларда, чәчәкләр арасында ерактан күбәләккә охшаган нәни балалар? Күптән инде минем Аккош күленә барганым юк һәм барырга аягым да тартмый. Чөнки күп еллар буена әти гомер иткән, үзенең мәшһүр әсәрләрен иҗат иткән кечкенә, сөйкемле агач йорт безнең гаиләдән китте инде. Минем хәтердә Аккош күле гомеремнең ахырына кадәр, әнә шул әти белән язучы дуслары бергә яшәгән вакытлардагы сурәттә, бер хыялый гүзәл дөнья кебек кенә сакланыр инде.

*2006*

---

## Ләбибә Ихсанова

### Истәлекле җәй

Язучыларның иҗат мөмкинлекләрен үстерү униеннан илленче еллар башында республикабыз хөкүмәте иҗат йорты төзү өчен җир бүлеп биргән иде. Биек агачлар әйләндереп алган яшел аланны бер күрүдә яраттылар каләм ияләре. Бер якта, кояш нурларында ялтырап, Аккош күле җәелеп ята, икенче якта — Кече Тирән күл. Яр буендагы каеннарның күләгәсе су өстенә төшеп, күлне тагын да тирәнрәк, тагын да серлерәк итеп күрсәтә.

Ачык төсләргә буялган фин йортлары бер-берсенә терәлеп, тыгызланып утырмыйлар. Төрле җирләргә сибелеп урнашканнар. Бу йортларда күбрәк роман-повестьлар язучы өлкән әдипләр һәм сугыш нәтиҗәсендә иҗатлары бүленеп торган фронтовиклар яшәп иҗат итә иде. Ул елларда ирем Шәрәф Мөдәррис «Полк намусы» дигән поэма язган иде. Беркөнне Язучылар союзыннан канатланып кайтып керде. Безнең гаиләгә дә иҗат йортына путевка биргәннәр икән.



*Иҗат йортының көньяк-көнчыгыш почмагындагы аерым фин йорты. 1956 елның җәе.*

Гаҗәеп бер җәй булды ул минем өчен. Бик күп язучыларны, аларның гаиләләрен, балаларын якыннан белдем. Дачалар биләмәсенең кыл уртасында, зәңгәр чәчәкле үрмәле гөлләр чолганышында агач беседка бар. Кич життеме, язучылар шунда җыела. Көне буе язу өстәле янында утырып, оеган буыннарын язып, тәлләрен чарлап алырлык шушы кечке сәгатьләрне көтеп алалар кебек. Тыныч, тымызык җәйге кич, урман ягыннан юкә балы, түтәлләрдән җиләк, чәчәк исләре бөркелә. Түшәмдәге электр лампасы тирәли, болыт булып, озынборыннар өерелә. Бик йөдәтә башласалар:

— Мөдәррис, бер төтәтеп ал булмаса,— дип, Фатих Хөсни кеткелдәп куя.

Ибраһим Гази тәмәке төтенен яратмый, яшьтән үк тартмаган, сугышларда йөреп

тә өйрәнмәгән. Бу яктан фикердәше һәм дусты Афзал Шамов белән бер алар. Ибраһим ага фронттан алып кайткан «трофей» халатына төренеп, беседка баганасына аркасын терәп, читтәрәк басып тора. Ул күбрәк кеше сөйләгәнне тыңларга ярата. Кайчагында берәр җор сүз дә кыстыргалап куя. Фикердәшләр арасында үпкәләшү юк... Әй ул онытылмас кадерле кичләр!.. Күпме истәлекләр тыңладым да мин анда, никадәр акыллы сүзләр ишеттем мин анда. Еллары да нинди иде бит аның...

Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» дөньяны шаулаткан чак. Җәлилчеләр баш очындагы куе кара болыт таралган вакыт. Хәсән ага Туфанның озын-озак сәфәрдән әйләнеп кайткан еллары. Әлегә кадәр исемнәрен дә әйтүдә тыелган Галимҗан Ибраһимов, Галимҗан Нигъмәти, Фәтхи Бурнаш кебек классикларның әсәрләре әдәбиятыбызны бизәгән көннәр.



*Әхмәт Юныс, Гали Хуҗи, Фатих Хөсни гаиләләре белән.*

Ул җәйне Хәсән ага белән бер йортта яшәү дә зур куаныч булды безнең өчен. Күл ягындагы капкадан кергәч тә уң кул якта беренче йорт иде ул. Кояш чыгышына караган бер бүлмәдә Хәсән абый яши. Урман ягындагы ике бүлмәгә безнең гаилә урнашты. Ничек шулай туры килгәндер, бу легендар шагыйрь белән берничә ел күршеләр булып яшәгән кешеләр без. Казанның Иске дип аталган урамына, шулай да иске һәм бернинди уңайлыклары булмаган, хатыны актриса Луизаның соңгы сәгатьләре узган хәсрәтле йортка кайтып төшкән иде ул. Шуннан ерак түгел, Нестеров чокырында тактадан үзебез салып кергән кечкенә өебез. Еллар арулана башлагач, язучыларның да фатир хәлләре яхшыра төшеп, Хәсән абыйга да, безгә дә Эрмитаж бакчасына караган зур йорттан фатир бирделәр. Бер ун елдан соң шәһәрнең Ленин районындагы фатирларыбыз да бер үк ишегалдында булып чыкты. Инде менә Аккош күле буендагы иҗат йортында да өйдәш булырга язган.

Хәсән абый бүлмәсендә төне буе ут сүнми. Ә иртән, ишек- тәрәзәләрне ачык калдырып, урманга чыгып киткән була. Кайчан ятып ял иткәнен дә белмәссең. Урыны пөхтәләп җыелган, өстәл өстендә — яшел кара белән энҗе кебек вак хәрефләрдән тезеп язылган кәгазь битләре. Бер читтә тәмәке төпчекләре белән тулы көл савыты. Сулы стаканга куелган урман чәчәге дә өстәл өстендә. Бергә тора башлаганнан бирле, Хәсән абыйның зәңгәр кыңгырау чәчкә алып кайтуына игътибар итә идем. Беркөнне сеңлем Венера хәл белергә килгәч, күләгәдә сөйләшеп утырабыз шулай. Хәсән абый кайтып керде. Кулында әлеге дә баягы кыңгырау чәчәк.

—Нинди чәчәк ул, Хәсән абый? — дип сорады Венера.

—Исемен белмим әле. Тургайлар килгәч чәчәк ата ул.

—Тургай чәчәге дип әйтик без аңар.

Бу исем шагыйрьгә бик ошады. Хәер, бу турыда Илдар Юзеев та әйткән икән аңар. Соныннан Илдарның «Тургай чәчәге» дигән китабыннан укып белдем.

Язучыларның кайберләре төнге сәгатьләрдә эшләргә яраталар. Тирә-якта тавышлар тынгач, хәтта кошлар да очудан туктагач, мөгаен, тургай чәчәге дә күзен йомгач, илаһи минутлар, сәгатьләр иркенә биреләләрдер. Көндезләрен күбрәк ял итәләр, шәһәргә барып, Язучылар союзындагы хәлләрне белеп кайталар. Хатларны,

газета-журналларның яңа саннарын алып кайталар, Әхмәт абыйның хәлен белешеп торалар.

Ул елны олы шагыйрь Әхмәт Фәйзи бик каты авырып киткәннән соң, Мәскәү табиблары да хәлен җиңеләйтә алмагач, туган якның саф һавасы килешмәсме дип, бирегә алып кайтканнар иде. Сеңлесе Зәйнәп апа белән икесенә көяшлы яктан иркен бүлмә бирделәр. Әхмәт абый күбрәк ачык веранданың челтәрле рәшәткаләре аша дөньяга карап ята. Каләмдәшләре кергәч, күңеле күтәрелеп китә, сөйләшү бик җиңел булмаса да, күп хәлләр турында белешә.

Әхмәт абыйны мин студент чагымнан ук беләм. Гаиләсе белән күбрәк Мәскәүдә яшәсә дә, кыш айларында Казанга кайтып, озак-озак торып китә иде. Международная (хәзерге Кави Нәҗми урамы) һәм Бауман урамнары кисешкән чаттагы актерлар тулай торагында аның да бүлмәсе бар иде. Белүемчә, бу бүлмә яшь язучыларның өлкән шагыйрь белән очрашу урыны да була иде. Университетның татар бүлегендә укучы яшь каләмнәр бирегә әдәби түгәрәккә еш килә, язучы аларны исемнәре белән белә, үз күреп сөйләшә, иҗатлары турында газета-журналларга яза. Бервакыт ул минем дә «Зәңгәр чәчәк» дигән шигырем турында язган иде. Дөресен әйтим, тәнкыйть мәкаләсен укуы авыр булса да, шундый зур шагыйрьнең игътибары сөендергән иде.

Бирегә кайткач, Әхмәт абыйның янына кереп, борчып йөрергә уңайсызлана идем. Беркөнне аның верандасы буеннан үтәргә туры килде. Шулвакыт аның:

— Ник кермисең? — дигән хәлсез тавышын ишеттем.

Бик уңайсыз, хәтта оят булып китте. Янына кергәч:

— Балаларны эзләп чыккан идем,— дип акланган булып маташтым.

—Син андый эшне Мөдәррискә куш. Малайлар артыннан йөрү — аталар эше ул, — диде шагыйрь, бераз тын алып торгач.— Әйбәт малайлар алар,— дип өстәде. Тумбочка өстендәге гөмбәләргә карап алуымны күргәч:



*Учак янында Хәсән Туфан. 1966, август.*

—Чага дигән гөмбә ул. Малайлар урманнан җыеп керткән. Әхмәт абыйларын савыктырасылары килә,— дип өстәде.

Карт каен кәүсәсенә ябышып үскән коры гөмбәне чага дип әйтүләрен белә идем. Беркөнне хатын-кызлар белән Әхмәт абыйның авыруына шул чага файдалы икән дип әйткәннәрен сөйләшеп торган идек. Ничек ишетеп алганнар да, ничек тиз генә җыеп кайтканнар аны бу тынгысыз җаннар.

Әмма Әхмәт абыйга әллә нинди көчле дарулар да файда итмәде. Аның хәле авырайганнан-авырая барды. Көннәрдән бер көнне шагыйрьне шәһәрнең онкология больницасына алып киттеләр.

Беседкада кич утырулар азайды ул көннәрдә. Язучылар Әхмәт абыйның авыр язмышы турында сөйләшүдән качалар кебек иде. Хәсән абый да күп вакытларын бүлмәсендә эшләп, укып утыра башлады. Кичке чәй вакытында нинди генә истәлекләр сөйләми иде бит ул Шәрәф белән мина...

Күргәннәре, кичергәннәре турында мавыктыргыч итеп сөйли белә иде. Ә үткәне аның — укып туймаслык бер китап. Кайсы гына битен ачсаң да, бәйләп бетергесез кыйммәтле сәхифәгә юлыгасың. Ул еш кына яшьлек дусты Такташ турында искә ала иде. Туфанның Бишбалтадагы фатирына Такташ күп килгән. Кичләр буе сүзләре бетмәгән шагыйрьләрнең. Туфан аны озата чыккан, сөйләшә-сөйләшә, Такташ фатирына барып җиткәннәр. Шулай таң атканын да сизми калган бу ялкынлы ике яшь йөрәк.

Туфан иҗатында эчкерсез бу дуслык турында шундый юлларны укырга мөмкин:

*Беренче кат күрешү минутында*
*Сиздек микән үзебез, юк микән, —*
*Кулларны без мәңге аерылмаска,*
*Ташлашмаска биргәнбез икән.*

Алар ташлашмаган. Бу икәүне мәрхәмәтсез үлем генә бер-берсеннән аерган. Бик иртә, рәхәтләнеп яшәр чагында, янып-ялкынланып иҗат итәр вакытларда аерган. Такташның соңгы сулышында да баш очында Туфан булган. Аккош күле буендагы тын һәм тыныч кичләрнең берсендә Хәсән абый бу хәсрәтле вакыйга турында болай дип сөйләгән иде:


*Уңнан сулга: Риза Ишморат, Әхмәт Фәйзи, Нури Арсланов, Мансур Мозаффаров һ. б. Ә. Фәйзинең вафатына дүрт ай кала төшкән фото. 1958 ел.*

— Такташ авырып киткәч, көн саен хәлен белергә бара идем. Яшь идем ул чагында, авырып китүнең ни икәнен дә белмәгән вакыт. Үз башыңа төшмәгәч, каян беләсең аны, —дип үкенеп сөйләгәне бар иде Хәсән абыйның. — Тора-бара дустымның хәле бик авыраеп китте. Саташа башлады. Трибунадан шигырь укыган кебек итенә, Бухарин, Раковларны сүгә, алар белән бәхәсләшә. Аннан тагын аңына килә. Үләр минутында да аңында иде. Күз карашы мәгънәле, иреннәре кыймылдый, ә сүзе ишетелми. Гөлчирә дә, мин дә йөзенә иелеп тынлыйбыз, авызына колагыбызны куеп карыйбыз. Сүзен аңлый алмадык... Соңгы сулышы өзелде Һадиның. Ниләр әйтергә теләде икән ул, нинди васыятьләрен ирештерә алмый калды икән?

Бу сөйләшүләр үзләре кыйммәтле бер сәхифә булып калыр дип кем уйлаган?


*«Аккош күле» иҗат йортында Гомәр Бәшировта кунакта Сәйфи Кудаш, Мөхәммәт Мәһдиев, Хәсән Туфан. 1966, июнь*

Инде җәй үтеп бара. Кояш элеккечә кыздырса да, төннәрен салкынча. Язучылар беседкага калынрак киенеп чыга башладылар. Әкренләп юкәләргә сары төс инә. Көз якынлашу, гомумән, күнелләргә сагыш сала. Табигать хозурында яшәү рәхәтенең, ял вакытларында гына була торган борчусыз һәм ваемсыз кәефкә бирелеп көн үткәрүнең тәмамланып килүен күреп тору кешене басынкыландыра. Шулай беркөнне: «Кичке чәй янына Хәсән абыйны да чакырыйк әле»,— дидем. Шәрәф барып, шагыйрьнең ишеген какты. Ул кыстатмады, озак көттермәде, яна гына язып тәмамлаган шигырен алып керде. Үзе бик дулкынланган иде. Ин

элек нинди хисләр бу шигырьне язарга мәҗбүр итүен сөйләде. Аннан соң, һәр юлына аңлатма бирә-бирә, «Әйткән иден...» дигән шигырьне укып күрсәтте. Еллар буе көтеп тә, күрешергә санаулы айлар гына калгач, якты дөньядан китеп барган хатыны артистка Луизага багышланган иде ул.

Гомерендә зур тетрәнүләр кичергән олы шагыйрьнең рухи ныклыгы, нинди генә авырлыклар күрсә дә сынмавы, сыгылмавы, мәхәббәткә хыянәт итмичә, гомере буена саклавы сокландырды безне. Озак та үтмәде, композитор Әнвәр Бакиров шигырьне көйгә салып, җыр сөючеләргә бүләк итте, һәм ул күпләрнең күңелен яулап алды.

Ә көз?.. Ел фасылының гадәти бер мизгеле ул. Үз матурлыгы, үз моңы, үз сагышы белән үтә дә китә, тагын әйләнеп килергә китә. Янадан яз килер, тургайлар кайтыр, дөньны ямьләндереп, тургай гөлләре чәчәк атар... Әдипләр җыелып, гәпләшеп, шигырьләр укып утырган беседканы үрмәле гөлләр чорнап алыр... Язучыларның Аккош күлендәге иҗат йорты тагын җанланып китәр.

*2007*

## Равил Фәйзуллин

### Әдипләрнең гамь бишеге

Дөресен әйтим, язучылар яши торган «Аккош күле» дачалары турында иркенләбрәк, тәфсиллерәк, күләмлерәк итеп язарга ниятем бар иде. Ул теләкнең хәзер дә кимегәне юк. Фотосурәтче Рифхәт Якупов белән без аны альбом-китап итеп күзаллаган идек. Бу җәһәттән беркадәр эш башкарылган да иде. Дөньяның көтелмәгән яна мәшәкатьләре көн саен диярлек туа торып, ниятләгәннәр һаман чигерелә торды. Без шулай сузып-тарткалап йөргән арада хөрмәтле «Мәгариф» нәшрияты «Аккош күле» турында күмәк китап әзерләп өлгергән дә икән! Афәрин! Көнләшеп сокланырга гына кала. «Мәгариф» белән санлашмыйча булмый. Әле күптән түгел генә безләр өчен бик тә кадерле булган Казанның мәшһүр Матбугат йорты турында менә дигән китап чыгарып куйдылар. Ихтимал, татар өчен тарихи әһәмияткә ия ул бина һәм аның кешеләре хакында да безнең кебек берәр хезмәт язарга хыялланып йөрүчеләр булгандыр. Инде китапның әлегесендә (дөрес, «Матбугат йорты — гомер китабы» дигәнендә дә бәләкәй генә язмам бар иде) —«Аккош күле — илһам аланы»нда мина да катнашырга тәкъдим булгач, бик теләп ризалаштым.




*Иҗат йортлары янәшәсендәге Кече Тирән күл. 1969 ел.*

Татар әдәбиятының соңгы ярты гасырын «Аккош күле»ннән башка күз алдына китерү кыен. Чөнки бу җирдә заманның күренекле шәхесләре — зур әдипләр яшәгән.

Йортлар саны ике дистәгә дә тулмаган шушы бәләкәй «авылда» әдәбиятыбыз тарихында калырлык күп әсәрләр язылган. Әнә бу йортта мәшһүр поэмалар туган, тегесендә атаклы роман язылган, өченчесендә, әйтик, пьесалар, гыйльми хезмәтләр әзерләнгән, кемнәрдер дөнья халыкларының әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү белән шөгыльләнгән...

Кызганыч, «Аккош күле»нең иҗади гөрләп яшәгән «егет» чагына туры килә алмадым мин. «Язучылар оясы»на күченеп килгәндә, бу җирнең аксакал хуҗалары — Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Ибраһим Гази, Хәсән Хәйри, Нәби Дәүлиләр биредә юк иде инде. Килүем 1989 елда булды. Фин йорты дип йөртелгән өйнең мина дигән өлешендә элегрәк Мәҗит Рәфыйков, Гәрәй Рәхимнәр яшәгән булган. Баштагы бер-ике елда нигәдер сирәк киленде, мич ягып жылытырлык йорт булса да, кышларын бөтенләй йөрелмәде. Идел буендагы элек яшәгән Займище сагындырдымы, әллә бүтән сәбәпме, кисәк кенә үзләшә алмадым. Ә менә соңгы унбиш елда шулкадәр берәктем бу җиргә, аерыла алмас дәрәҗәгә килдем бугай инде. Шушы елларда биредә байтак шигырьләр, публицистик мәкаләләр, эссе-уйланулар рәвешендәге күп хезмәтләр язылды. Китапларга кергән кайбер шигырьләрем ахырына «Аккош күле, фәлән елда язылган» дигән искәрмәне күргәч, шул елларга караган күп истәлекләр яңара. Шулай да «Аккош күле»нә ун ел, кимендә биш-алты ел алданрак килмәгәнемә үкенәм. Теләсәм, мөмкинлекләр бар иде.

Совет чорындагы СССР территориясендә язучыларның иҗат йортлары дистәләгән иде. Переделкино, Ялта, Күктүбә, Дубулты, Гагра, Пицунда, Малеевка, Дүрмән... Союздаш саналган республикаларның һәрберсендә диярлек язучыларның иҗат йортлары, ял итү базалары бар иде. Үз вакытында Татарстанда да бөтенсоюз статусындагы иҗат йорты булдыру юнәлешендә талпынышлар булып алды. Барып чыкмады. Хәер, ул вакытта оешкан булса да, бу заманның байлык жыю осталары — елгыр егетләре, мөгаен, аны үз кулларына төшергән булырлар иде... Алда саналганнарга бик үк охшамаса да, «Аккош күле» үзенчә бер иҗат йорты инде. Үзенчәлеге шунда: биредә путевка-юллама биреп яшәтү тәртибе булмаган диярлек. Гадәттә, бер килеп урнашкан кеше, гомерлеккә төпләнеп калган. Берәүләр үзләре йорт җиткергән, икенчеләр, казна йортын үз итеп, хуҗаларча яшәп ятканнар. Йортлар Әдәби фонд карамагында булган. Теге яки бу нәрсәне төзергә яки төзәтергә кирәк булса, Язучылар оешмасына буйсынган әнә шул Әдәби фонд вәкилләренә мөрәҗәгать иткәннәр. Хөкүмәтнең язучы хезмәтенә хөрмәт белән карауның гаҗәеп формалары булган ул заманда! «Аккош күле» Россиядәге иҗат йортларының Переделкино дигәненә күбрәк туры килә бугай. Анда да бер төркем язучылар үзләренә билгеләнгән йортларда гомер буена торып иҗат иткәннәр.



*Хәсән Туфан, Сәйфи Кудаш, Гомәр Бәширов Аккош күле урманында. 1966 ел.*

«Аккош күле»нең оешуына иң күп өлеш керткән кеше —Гомәр Бәширов. Ул — үткән гасырның 50 нче елларында республиканың иң абруйлы шәхесләреннең берсе. СССР Верховный Советы депутаты, Сталин премиясе лауреаты, Татарстан Язучылар союзы рәисе. Югары даирәләрдә сүзе үтә торган чагы. Ул заманда, хәзерге «Аккош күле»ннән ерак түгел генә җирдә — аралары күп булса бер чакрым булыр —Татарстан өлкә комитетының ял итү базасы булган. Халык аны обком дача-

лары дип йөрткән. Ул вакытта Беренче секретарь — Моратов Зиннәт Ибәтович. Татар мохитен, тарихын һәм рухын яхшы белгән кеше буларак Салих Гыйлемханович Батыев та ул заманда республика житәкчелегендә зур түрә кеше. Г. Бәширов шул кешеләр аша язучыларга жир алуга ирешкән. «Язучылар — партия булышчылары, алар белән якын булу комачау итмәс», дигәннәрдер инде. (Дачаларның оешуында, материаль базасы ныгуында тагын бер кешенең — элеккеге фронтовик офицер Бәдретдинов Шәмсетдиннең дә өлеше зур булган.) Әмма янәшәлек гомере озакка бармый: 50 нче еллар ахырында «Оргсинтез» заводы төзелә башлагач, обкомчылар бу жирдән Идел буена — Боровое Матюшинога (бу сүзнең татарчасын ишеткән юк, бәлки, ул тирәләрдә безнең тел, гомумән, гамәлдә дә түгелдер) күчеп киталәр. Житәкчеләр сәяси мәсьәләләрдә генә түгел, экологик тоемга да бик сизгер. «Аккош күле»нең оешу тарихы шулайрак. Гомәр агага рәхмәт, урыны жәннәттә булсын. Моннан өч ел элек кенә Бәшировлар йорты (анда берара М. Мәһдиев тә яшәп алды) исән иде. Бүрәнәдән салынган жыйнак кына бу йорт шактый нык, таза иде әле. Һәрхәлдә, мемориаль йорт итеп сакларлык иде. Бетерделәр. Ул урында яна кешеләр яна пулат-сарай салдылар. Ә бетмәскә тиеш иде Гомәр Бәширов нигезе! Варислары да рухи дөнья кешеләре юкса: улы Зөфәр — күренекле фоторәссам, кызы Лилия — педагог, М. Мәһдиевнең хатыны, оныгы Гәүһәрия — редактор-язучы. Нидә хикмәт: ваемсызлыктамы, әллә вак меркантиль исәп-хисаптамы? Бу жәһәттән күренекле журналист, шагыйрә Асия Юнысова «Ватаным Татарстан» газетасында (2006, 2 июнь) кайчандыр Х. Туфан, С. Хәкимнәр яшәгән йортларның аяныч хәлдә икәнлеге турында әрнеп язып чыкты. Чарасызлыктан ул әрнүләргә кушылырга гына кала.




*Гомәр Бәширов хатыны Кәримә ханым. 1961 ел.*

Сөйләүләренә караганда, 60—70 нче еллар «Аккош күле»нең гажәеп матур чоры булган. Табигать хозурлыгы, сафлык һәм тынычлык (машиналар юк диярлек, дөрес, ул вакытта юньле юлы да булмаган) — ижат өчен идиллик шартлар. Яши торган йортлар да бер чамарак: хәзерге кебек бер-берсен уздырып салган таш яки агач пулатлар юк. Чагыштырмача социаль тигезлек. Кешеләр ижат иткән, киртәсезнисез ачык түтәлләрдә чәчәкләр, гөлләр үстергәннәр. Унган хужаларның яшелчәләре дә муллдан булган. Күзләрен уныш бәйрәмнәре уздырганнар. Атаклы беседкада (ул кайбер фоторәсемнәрдә сакланып калган) язучылар жыелышып яңа язылган әсәрләрен укыганнар, фикер алышканнар. Бердәнбер уртак мунчага (хәзер һәр йорт янәшәсендә шәхси мунча!), чиратлашып ягып, бер-берсен дәшкәннәр. Ул чәйгә йөрешүләр, кунак бүлешүләр... Зур сарайны клуб сыман итеп яше-карты бергә телевизор караулар... Күмәклек, бердәмлек, кешелеклелек хисләре көчле булган. Йортларның хужалары — күбесе сугыш кичкән асыл ир-атлар. Тыныч тормышның, гаилә иминлегенең, табигать күркәмлегенең кадерен яхшы белгәннәрдер.

Кемнәр яшәгән дә, кемнәр ижат итеп яткан бу жирләрдә? Үткән ел Фарук ага Сабиров (язучылар дачалары салына башлаганнан соң утыз еллап биредә бу жирнең «хужасы» —коменданты булган кеше 2007 елның апрелендә вафат булды. Истәлеккә ул утырткан чыршылар аллеясы калды) белән шушы илле елдан артык вакыт эчендә «Аккош»та яшәгән (кайберләре биредә озак яшәгән, кайберләре берәр ел яки берәр жәй генә торып киткән) кешеләрне барлап, искә төшереп утырдык. Әдәбият тарихын

өйрәнүчеләр өчен, бәлки, кирәге чыгуы бар дип, исемлек китереп узыйм (тулы булмавы да мөмкин). Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Нәби Дәүли, Хәсән Туфан, Афзал Шамов, Нәкый Исәнбәт, Ибраһим Гази, Әхмәт Фәйзи, Фатих Хөсни, Габдрахман Әпсәләмов, Хәсән Хәйри, Гариф Гобәй, Зәки Нури, Абдулла Әхмәт, Рувим Моран, Сафа Сабиров, Гали Хужи, Салих Баттал, Шәүкәт Галиев, Мария Елизарова, Шәрәф Мөдәррис, Ләбибә Ихсанова, Нил Юзиев, Фәнил Мансуров, Алексей Талвир, Габделхәй Сабитов, Мәҗит Рәфыйков, Рафаэль Мостафин, Рөстәм Кутуй, Галимҗан Латыйп, Мөдәррис Әгъләм, Фаил Шәфигуллин, Фәннур Сафин, Ризван Хәмид, Рәдиф Гатауллин, Габдулла Шәрәфи, Мәгъсүм Насыйбуллин, Гәрәй Рәхим, Ринат Мөхәммәдиев, Роберт Миннуллин, Сафуан Муллагалиев, Камил Кәримов, Рифкат Закиров, Рөстәм Мингалимов, Наис Гамбәр... Бүген яшәп ятучы язучыларны һәм төрле елларда җәйләрен дуслары хозурында айлап-айлап яшәп



*«Аккош күле»ндә яшәгән язучылардан бер төркем. Сулдан уңга: Фатих Хөсни, Риза Ишморат, Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Нәби Дәүли һәм Зәки Нури (улы белән). 60 нчы еллар.*

алган Мөхәррәм Каюмов, Эдуард Мостафин, Марат Закиров кебекләрне дә бергә исәпләсәң, алтмышлап исем килеп чыга. Нибары ике гектар чамасы гына булган алан өчен зур сан бу.

Казан язучыларының бакча-дачалар рәвешендә күмәк яши торган җирләре берничә: Займище, 774 км дип йөртелгән Идел буендагы һәм Биектау-Киндерле җирләре, тагын Васильеводан ерак булмаган, элек «чегән хуторы» дип аталган урын. Займище дигән җиргә журналист-язучы халкы 60 нчы еллар уртасында килеп урнашты. Анда — Аяз Гыйләҗев, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Газиз Мөхәммәтшин, Әхсән Баян, Вакыйф Нуруллин, Рәис Даутов, Диас Вәлиев, Ибраһим Нуруллин, Яхъя Халитов, Аллер Тимергалин, Әхәт Мушинский... Үземнең дә уночь елга якын яшьлек гомерем шунда узды. 774 км дип йөртелгән җир — Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Нури Арсланов, Гөлшат Зәйнашева, Хисам Камал, Ләбибә Ихсанова, Марс Шабаев, Лирон Хәмидуллин, Фәрваз Миннуллин...; Васильево — Мөхәммәт Мәһдиев, Фәнис Яруллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рәфкат Кәрами, Җәүдәт Дәрзаман, Рәшит Әхмәтҗанов, Зәет Мәҗитов, Әхмәт Рәшитов, Кояш Тимбикова, Шамил Маннапов, Роза Мулланурова, Рөстәм Фәйзуллин (Акъегет), Мансур Шиһаповлар; ә Биектау-Киндерле җире, белүемчә, Зөлфәт, Роберт Миннуллин, Рафис Корбан, Рашат Низами, Газинур Морат, Рәфикъ Юныс, Камил Кәримов, Ләбиб Лерон исемнәре белән бәйле. Бу җирләрдә дә язучылар яшәгәннәр, иҗат иткәннәр, җәйләрен гомер кичергәннәр һәм кичерәләр. Әмма күпләр өчен язу-

чыларның төп иҗат урыны дип барыбер «Аккош күле» санала. Тарихи үткәне белән дә, язучыларның ишлелеге белән дә, җырларга кереп калган исеме белән дә. Бүтән дачалардан аерып куярлык өстенлекләре дә бар шул: Казанга якын. Каены-чыршысы, юкәсе-имәне үсә торган урман. Якында гына ике матур күл — Тирән күл, Кече Тирән күл… Шуна өстәп, җиләге, гөмбәсе дигәндәй. Килеп, беренче күргән кешеләр: «Җәннәт урыны икән бу җир!» — дип сокланалар. Язучыларның кишәрлек җирләре алай күп түгел түгелен: уртача 5-6 сотый чыга торгандыр. Алай да сер бирмибез, кайчак, бераз мактанып, бу кишәрлек җир—өй салыр өчен генә бирелгәне, ә безнең төп биләмәләр әнә ничаклы дип урман-күл якларын күрсәтәбез. Бу сүзләрдә хаклык та бар: капканны ачып чык та урман сукмаклары буйлап кит. Кинәнеп йөр, табигать белән хозурлан, хыяллан, яна әсәрең өчен хикмәтле сүзләр уйлап йөр… Һәм шулай йөргәннәр дә әдипләребез. «Туган ягым — яшел бишек», «Кырыгынчы булмә», «Яшәү белән үлем арасында», «Гүзәл гамь», «Онытылмас еллар», «Тукайга хатлар» кебек әсәрләр шулай йөреп-уйланып язылганнар дип уйлыйм.


*Кайчандыр пошилар да йөргән бу җирләрдә. 1974*

Территориясе бәләкәй генә булса да, язучылар «авылы»ның үз бүленешләре бар: Югары оч, Түбән оч… Кесә телефоныннан яхшырак ишетелсен өчен, Түбән очтан Югары очка менәләр. Түбән оч — байлар, машиналылар ягы. Югары оч, нигездә, «җәяүле кеше сукмагы»н үз күрүчеләр. Әүвәл ничек булгандыр, белмим, хәзер шулайрак. Мин үзем дә Югары очта яшим — кайчак «Түбәндәге»ләргә шаяртып әйтеп куям: «Сез кирмәннең бистәсендә, капка төбендә яшисез. Посад-бистә нык булырга тиеш! Сез нык булсагыз, Югары оч — Үзәк яхшырак сакланыр!» Көлемсерәп куялар, каршы әйтмиләр тагын үзләре… Әйтергә кирәк, Түбән очны язучы булмаган, әмма халле кешеләр белән ныгытуда Ренат Харисның өлеше зур. Гомумән, соңгы елларда урнашу-төзү мәсьәләләрендә, бу заманга хас башбаштак үзешчәнлек, дөресрәге үзбашлык нык сиздерә.

Вакыт — һәрнәрсәне үзгәртүче бөек көч. Яшәгән саен шуна инана барасын. Кешеләр үзгәрә, буыннар алышына, авыллар, шәһәрләр еш кына танымаслык хәлгә килә. «Аккош күле» авылы да бик нык үзгәрде. Хәсән Туфан, Әхмәт Фәйзи, Мостай Кәрим, Сәйфи Кудашлар торып басса, тел шартлатып танымый торырлар иде. 50 нче елларда салынган йортлардан хәзер фәкать өчесе генә калды. Алары да ташландык хәлдә. Хәзергечә әйтсәк, «тузган торак» истәлекләре. Якындагы елларда алардан берни дә калмастыр инде… Ә татар җаны өчен бик кадерле йортлар югыйсә.

Берсендә Х. Туфан, А. Шамов яшәгән, икенчесендә — С. Хәким, И. Гази, өченчесендә — Н. Дәүли… Нигә шундый хәлгә калганнар соң алар дигәнгә, кистереп җавап бирү, кемнедер гаепләү кыен. Иң әүвәл, бу җирнең әлегә төгәл статусы билгеләнмәгән: дәүләтнекеме, әллә хосуси кешеләрнекеме? Шулай да әле әйтеп үткән йортлар һәм аның тирәлеге өчен беренче чиратта варислары — балалары, туганнары кайгыртырга тиештер. Күбесе шунда үскәннәр бит. Мәсәлән, атаклы сәясәтче Рафаэль Хәкимнең, әтисе (һәм үзе дә!) яшәгән йортны карап, аны истәлекле мемориаль йорт итеп саклап калырга мөмкинлекләре юк түгел ләбаса!

«Аккош күле»нең мин дә шаһиты булган 15—18 елында да үлем-китемнәр, нигез югалтулар байтак булды, Нил Юзиев, Габдулла Шәрәфи, Фәннур Сафин, Хәсән

Хәйри, Наис Гамбәр, Мөдәррис Әгъләм гүр ияләре булдылар бу елларда. Әйткәнемчә, элеккеге йортлар урынына язучылык эшенә катнашы булмаган яңа кешеләр нигез-фундаментлар корып куйдылар, яңа пулатлар салдылар. Соңгы ике елда гына бу мохит өчен сәер күренгән, бер карасаң мәчеткә, бер карасаң клубка охшаган яңа бер галәмәт зур бина пәйда булды. Кайчандыр тынычлык хөкем сөргән табигать кочагында краннар, КамАЗлар тавышы хәзер сирәк тынып тора. Ярый, дөнья гел бер урында тормый, төзесеннәр, корсыннар да ди, яңару — яхшы гамәл. Шулай да тарихи традицияләрне онытырга ярамый. Әйтик, бульдозерлар, краннар белән шактый ук имгәтелгән төп керү капкасын үзеннән соң рәтләп калдырырга була бит инде! Авылча гади, матур гына капка өстендә «Аккош күле» дигән язу да бар иде. Күпләр өчен истәлекле (фотога төшәр өчен генә булса да) урын. Аның каравы җир кишәрлекләрен тотып алган яңа шәхси капкалар, җил үтмәслек тоташ коймалар калыкты. Яңа заман, яңа кешеләр, яңа әхлак, яңа тәртипләр...



*Сибгат Хәким һәм Ибраһим Гази яшәгән уртак йорт. 2003 ел.*

Әйе, тормыш алга бара... Куанычы да, хәсрәте дә җитәрлек. Иң кыены — якын кешеләрне югалту. «Аккош күле»ннән Мәңгелек Йортка беренче озатылган кеше 1958 елда Әхмәт Фәйзи булган... Табигый, ярты гасыр эчендә кемнәр килеп китмәгән бу дөньяда! Шул исәптән «Аккош күле»ндә дә. Соңгы елларда минем өчен иң авыр югалтулар — Мөдәррис Әгъләм һәм Наис Гамбәр вафатлары булды. Соңгысы биредә әллә ни озак яшәмәде, ә инде Мөдәррисне чын мәгънәсендә «Аккош күле» иясенен берсе диярга була. Кеше буларак та, шагыйрь буларак та ул бу җирдән аерылгысыз: алтмыш ел гомеренең төгәл яртысы биредә узган. Мөдәррриснең яшәү рәвешенә төрле кеше төрлечә караса да, ул бу җирнең бизәге булган икән. Һәрхәлдә, минем өчен шулай. Күршеләр идек без. Иң аралашкан кешем дә ул булды. Иртән торып ишекне ачуга, Мөдәррис яки Наис торган йортларга төбәләсен: торганнармы, ишекләре ачыкмы? Кичләрен дә шулай: кайттылар микән, утлары бармы? Төрлечә яшәде Мөдәррис, «җен алыштырган» чаклары да булмады түгел. Ләкин беркайчан да, беркем алдында да шагыйрь икәнен, татар баласы икәнен онытмады.



*Мөдәррис Әгъләм Равил Фәйзуллинның этисе Габдрахман ага белән. 1997 ел.*

Мөдәррис катлаулы кеше иде, кайчагында сүзенең чынмы, ялганмы икәнен аңлап бетереп тә булмаган кебек, аны бер яклап кына аңлап яки аңлатып та булмый. Әйтик, аның соңгы еллардагы «Аккош күле»нә, йорт-җиренә мөнәсәбәтен кабул итү кыен. Гөл кебек тотасы урында, торган йортын карамады, ташландык хәлгә җиткерде. Ә бит бу җир аны олы иҗатчы иткән. Гүзәл табигатьнең дә үз рәнҗүе булырга мөмкин бит әле... Үләренә берничә ел кала ул «Аккош күле»ннән китте, яки китәргә мәҗбүр булды. Сонрак өен җимереп ташладылар, кишәрлек җире

күршеләр җирләренә кушылып «эреде»... Хәзер ул төштә Мөдәррис истәлеге булып ике карт алмагач калды. Берсенең алмалары бигрәк тә тәмле, сусыл. Исән булсак, киләсе җәйләрдә авыз да итәрбез. Әмма ул алмалардан өстәмә бер тәм, ачы сагыш тәме дә килер инде...

Наис Гамбәр мина үзенчә якын иде. «Казан утлары»нда хезмәттәш булып байтак еллар бергә эшләдек. Шагыйрь һәм гыйлемле редактор буларак, ул әдәбиятны, бигрәк тә шигъриятне бик нечкә тоя, аңлый иде. Үземә бәйле рәвештә дә моны раслый алам: иҗатым турында язылган йөзләгән мәкаләләр арасында Н. Гамбәрнең хезмәте төплелеге, тирәнлеге белән бүтәннәрнекеннән бер башка аерылып тора. Еш искә төшәсез, сагындырасыз, дусларым!.. «Аккош күле» ул Агачлар, Кешеләр, Күлләр Иле генә түгел, Сагыш, Гамьнәр җире дә...

Без һәм бездән элгәре буыннар өчен «Әдәбият — халыклар дуслыгы» дигән шигар бар иде һәм ул изге төшенчә иде. Хәзер дә бу шигарне бөек саналырлык шигар дип



*Равил Фәйзуллинда кунакта. Беренче рәттә сулдан: Николай Шамшурин (Түбән Новгород), Валерий Тургай (Чувашия); икенче рәттә сулдан: Мөдәррис Вәлиев, Илфак Ибраһимов, Туфан Миңнуллин, Зиннур Хөснияр, Равил Фәйзуллин, Станислав Куняев, Рауль Мирхәйдәров, Фәкил Сафин. 2005, 30 август.*

исәплим. «Аккош күле»ндәге тормыш рәвеше бу девизга гел тугрылыклы булып килде. Нинди генә халыкның нинди генә асыл кешеләрен кабул итмәгән ул! Биредәге һәр йортта диярлек күренекле затлар кунак булган, «тел вә лөгать алмашып» сайрашкан! Һәр очрашу һәркем өчен бәйрәм дә, тормыш дәресләре дә булгандыр дип уйлыйм. Әйтик, Гомәр Бәшировларда, Хәсән Туфан яки Сибгат Хәкимнәрдә кемнәр генә булмаган да, нинди генә сүзләр сөйләнмәгәндер! Бу җәһәттән әллә ни мактана алмасам да, минем йортта да күңелемә якын кешеләр байтак булды. Кайчак искә төшереп утырам, туган-тумачадан, хезмәттәш коллегалардан тыш, халкыбызның әдәбият-сәнгатьтәге атаклы кешеләре — рәссамнар Әхсән Фәтхетдинов, Эрнест Мулдашев, Абрек Абзгильдин; җырчылар Илһам Шакиров, Вафирә Гыйззәтуллина, Рафаэл Сәхәбиев; композиторлар Алмаз Монасыйпов, Шамил Тимербулатов; галимнәр Вил Мирзаянов, Әбрар Кәримуллин... Үзебезнең күренекле язучылар турында әйткән дә юк инде! Кунак булган җирдә бәрәкәт арта, диләр. Бәлки, ул, чыннан да, шулайдыр...

Халыкларның рухи дуслыгы турында совет чорындагы кебек сөйләнмәсә дә, әдәби әсәрләрне тәрҗемәләү эше бүгенге көндә дә бик актуаль. Яхшы тәрҗемәчеләр булдыру өчен рәсми оештыру чаралары гына җитми; бу эшкә сәләте булган һәрбер шәхесне әдәбиятка җәлеп итә белү, алар белән туганнарча аралашып яши белү дә

кирәк. «Аккош күле»нең бу җәһәттән дә бәрәкәтле җир икәнен искәртеп үтү кирәк. Мәсәлән, заманында Мәскәү тәрҗемәчесе Рувим Моран биредә җәйләр буе яшәп, С. Хәким, Х. Туфан шигырьләрен тәрҗемә иткән. Моннан нәкъ 50 ел элек 1957 елда чыккан «Татар совет антологиясе»н (рус телендәгесе) төзүдә катнашкан байтак рус язучылары кунак булганнар биредә.



*Чаңгы юлларын кар баскан.*

Бүгенге көндә «Аккош күле»ндә унлап язучы яшәп ята. Кемнәр дигәндә, санап китәм. Түбән очтан башлыйк: Ренат Харис, Җәүдәт Сөләйман, Зиннур Хөснияр, Флүс Латыйфи... Югары очтагылар — Зиннур Мансуров, Мөдәррис Вәлиев, Равил Фәйзуллин, ягъни мин, Мансур Вәлиев, Ркаил Зәйдулла, Фоат Галимуллин. Төрле төбәкләрдә туып үсеп биредә тамыр җибәргән төрле яшьтәге, төрле холыктагы кешеләр. Әмма кайсын алсаң да, татар әдәбияты елъязмасында, сәяси, мәдәни, гыйльми дөньяда үз урыннары бар шәхесләр.

Бүгенгесе шулай. Моңа кадәр әдәбият учагы булып килгән бу «Язучылар аланы»ның киләчәге нindирәк булыр? Табигый сорау. Мин дә уйланам бу хакта. Уйланам да мондый нәтиҗәгә киләм: ул, мөгаен, ун-унбиш еллап узгач, элеккеге язучылык данын йөртерлек җир була алмастыр. Чөнки бүген яшәп иҗат итүчеләр — олы яшьтә. Яшьләре уртача алганда алтмышлар тирәсе. Яшәеш үсеше өчен буыннар гармониясе кирәк. Әйтик, моннан утыз еллар элек биредә Гомәр Бәширов кебек өлкәннәре дә, Рафаэль Мостафин, Нил Юзиев кебек урта яшьтәгеләре дә, Ренат Харис, Мөдәррис Әгъләм кебек яшьрәкләре дә булган. Әйткәнемчә, хәзер хәл бүтән. Хәзерге язучыларның балалары гел генә язучы яки рухи дөнья хезмәткәрләре булып китмәс. (Мәрхүм әтиләре китапханәсендәге кул тамгалы китапларны чүплеккә чыгарып ташлаган «варислар»ны да күрергә туры килде.) Бу йортларда башка буын яшәр. Телләре, көй-моннары инде бүтән булыр. Нишлисең, кыйтгалар да үзгәрә, империяләр җимерелә, халыклар юкка чыга... «Аккош күле» генә үзгәрми торып кала алмас шул. Шунысына разый булыйк: ул Вакыт дәрьясының аерым чорында татар әдәбиятының бишеге, милли рухның үзенә күрә бер үзәге булып кала алган.

«Аккош күле» Табигатьнең һәр фасылында үзенчә матур, үзенчә гүзәл. Хәер, Табигать илаһи матурлыкның үзе бит инде. Аннан аерылмаганда, үзенне аның белән бербөтен хис иткәндә, кеше күнелендә дә ямьсезлеккә урын калмыйдыр. Җәй башында алмагачлар, чияләр чәчәк аткач, алар агач-куак түгел, күбекләнеп торган ак болытлар гүя. Көчлерәк җил исеп куяр да зәңгәр күккә ашарлар кебек. Таңнарын сандугачлар берсен-берсе уздырып өздереп сайраганда уянып китәсен дә исәрләнеп татлы уйларга таласың, яшь чакларның сәгадәтле сәгатьләре искә төшә... Кышларын үзенчә әкияти дөнья. Тоташ аклык дәрьясында ак каеннарның төз, сылу гәүдәләре янына янә бер аклык өсти. Бәсле куакларга кунган кызылтүш — миләш чыпчыклары үзе бер могҗиза! Рәссам бул да кәгазьгә төшер дә куй. Кай көннәрне иртәнчәк мич торбаларыннан талгын гына төтен баганалары күтәрелә. Димәк, кемнәрдер мунча яккан. Мөгаен, кемдер ләүкәдә хәл беткәнче чабынып, чөгендердәй кызарып чыгар да яна яуган карда аунар... Апрель башларында каен сулары төшкән көннәрне бәйрәм кебек көтеп алабыз. «Кемнең анда күз яшьләре

чыккан ак каеннның күкрәкләреннән!» Гаҗәеп манзара: кар әле китеп бетмәгән, җир — ала-кола, күк — жете зәңгәр, бөреләр җегәрле тулышлы, сулаган һава — тәненә бальзам. Мин үзем тәүлекнең берәр сәгатен урманда үткәрергә тырышам. Җәй айларында, гадәттә, шулай туры килә дә. Капканы ачып чыгасың да үзең белгән сукмаклардан китәсең. Монда сина һәр агач, һәр куак, үлән—иптәш, сердәш. Алар арасында уйланып йөрергә яхшы. Ниләр генә уйланылмый Табигать кочагында! Мәрхүмә дәүәнием: «Минут эчендә әллә ничә тапкыр Мәскәүләргә барып кайтам мин!»— дия торган иде (үзе Мәскәүнең кайсы якта икәнен дә белми!). Мин дә кайчак ана охшап куям. Төп уй, әлбәттә, әдәбият турында. Иҗатташ каләмдәшләр, әсәрләр турында... Күңелдән алар белән сөйләшәм, бәхәсләшәм, ниндидер фикерләргә киләм, планнар корам... «Әңгәмәдәшләрем» бүгенгеләр генә түгел, кайчак бик зур тарихи шәхесләр дә була. Кол Гали, Кандалыйлар да, Тукай, Такташлар да... Җинелгәннәре өчен борынгы бабайларга да «эләгә» кайчак. Бүгенге хаким-хөкемдарлар да кырыйда калмый... Иҗат процессы дигәннәре шул буладыр инде. Һәрхәлдә, нидер — берничә шигъри юлмы, берәр «даһи» фикерме ияреп кайтмый калмый урманнан. Үз кочагында шулай уйландырып, хисләндереп, яшәртеп һәм матур картайтып кеше итеп йөрткәнең өчен рәхмәт сина, Аккош күле!



*Чыршылы аллея хозурында. 2003 ел.*

Әйе, Аккош күле Казан үзәгеннән ерак түгел. Хәер, ул үзе дә Казан эче, шәһәрнең парк зонасы санала. Кремль тирәсеннән исәпләп Мәскәү ягына таба машина белән элдертсәң, 20—25 минутта барып та җитәсең. Матур җирләр. Самолеттан караганда Идел белән янәшә каймаланып барган урманнар еракка-еракка сузыла. Унбиш чакрымнар ары китсәң — атаклы Раифа монастыре, тагын да арырак — Зөя яклары, Идел эчендә Явыз Иван салдырган Свияжск кальгасы. Татар тарихы өчен хәтәр җирләр! Нинди гүзәл җирләрне яулап килгән баскыннар... Хәтәр җирләрдә хәтерле булу бик тә кирәк! Менә без әлегә табигатьнең җәннәтка тиң шушы җирендә басып торабыз. Үзебезчә, хуҗа булып. Бу тойгы — минем өчен дә горурлык һәм дәрәҗә. Шулай тиеш тә. Бу бит минем Туган җирем, тарихи Ватаным.

*2007, март*

## Фәрит Яруллин

(1914-1943)



Беренче татар балеты «Шүрәле» композитор Фәрит Яруллин тарафыннан 1940-41 елларда язылa. Иҗат гомере кыска гына булса да, Ф. Яруллин милли музыкабыз тарихында лаеклы рәвештә иң хөрмәтле урыннарның берсен яулаган талантлы, киң полотнолы әсәр тудырды.

Ул 1914 елның 1 гыйнварында Казанда туа. Әтисе Заһидулла Яруллин—халык музыканты, Габдулла Тукай истәлегенә багышланган популяр марш авторы. Менә шул сәбәпле, Фәрит кечкенәдән музыка һәм сәнгать кешеләре арасында үсә. 1930 елларда, Казан музыка техникумында уку белән берррәттән, үзешчән хор түгәрәкләренә җитәкчелек итә, татарча концертларда җырчыларга аккомпаниатр була, яшьләр театры спектакльләрендә музыкаль бизәлешне алып баручы триода уйный.

1933 елны Мәскәү консерваториясенә укырга җибәрелә, соңрак Татар опера студиясендә композиция буенча профессор Литинский классында дәресләр ала. 1937-39 елларда студиядә укыган чагында ук, төрле әсәрләр язып, профессиональ осталыгын үстерә. Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзи, Нәҗип Җиһанов белән очрашып киңәшкәннән соң «Шүрәле» балетын яза башлый.

Тукай яшендә Ватан сугышына китә һәм 29 яшендә Белоруссияне азат итү сугышларында хәбәрсез югала. Аның каберен 40 елдан соң гына ачыклау мөмкин булды. Боларның барысы хакында да язучы Рашат Низаминың «Ут һәм җыр» роман-хроникасында җентекләп язылган. (ТКН, Казан, 2000 ел).

«Шүрәле» балеты элекке СССРның, шулай ук Европа илләренең бик күп сәхнәләрендә зур уңыш белән барды. Балет өчен композиторга Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде.

Рәсемдәге бюсты Мамадыш шәһәренең үзәк мәйданына куелган.

## Әмирхан Еники

(1909-2000)



Күренекле әдип-прозаик Әмирхан Еники 1909 елның 2 мартында элекке Уфа губернасы Бәләбәй өязенең Яңа Каргалы авылында туа. Яшьтән үк әдәбият, иҗат эше белән кызыксынган үсмер егет 1925 елны Казанга килә һәм университет каршындагы рабфакка укырга керә. Шушы чорда көндәлек матбугат битләрендә аның әдәби парчалары һәм беренче хикәяләре күренә башлый.

Укытучы, журналист, методист, инструктор... Кыскасы, булачак язучы зур тормыш мәктәбе уза. Ватан сугышы елларында исә хәрәкәттәге армиянең хуҗалык һәм каравыл частьләрендә хезмәт итә.

Үзенчәлекле язучы-художник буларак, Ә. Еники нигездә сугыш һәм сугыштан соңгы елларда формалаша. Аның «Ана һәм кыз» (1972), «Бер генә сәгатькә» (1944), «Тауларга карап» (1948), «Кем җырлады?» (1956)

кебек хикәяләре татар психологик прозасының матур үрнәкләре булып саналырга хаклы.

Житмешенче елларга килеп житкәндә ул инде «Саз чәчәге», «Йөрәк сере», «Рәшә», «Без дә солдатлар идек», «Гөләндәм туташ хатирәсе» повестьлары, «Матурлык», «Әйтелмәгән васыять» кебек хикәяләре, заманны борчыган әхлакый-этик проблемаларны кыю рәвештә күтәрүе белән бергә, сәнгатьчә камил эшләнүләре җәһәтеннән дә игътибарга лаек.

Әмирхан Еникинең иҗтимагый тормыштагы актуаль мәсьәләләргә багышланган публицистик мәкаләләре, очерклары, әдәбият-сәнгать турындагы уйлanулары һәм истәлек язмалары көндәлек матбугатта еш күренә килде.

**Альфред ӘБДРӘШИТОВ**

---

## *Бер сорауга—бер җавап*



*—Казан дәүләт университетының журналистика һәм социология факультеты көндәлек матбугатка, әдәбиятка һәм фән өлкәсенә каләм ияләрен байтак әзерләде. Житәкче буларак, уңышларыгыз һәм Сезне борчыган мәсьәләләр хакында берничә сүз әйтсәгез иде...*

**Васил Заһит улы ГАРИФУЛЛИН, КДУның журналистика һәм социология факультеты деканы, филология фәннәре докторы, профессор:**

—Һәрбер милләтнең рухы аның матбугатында да чагылыш таба. Татар журналистикасының тарихы—менә ачык мисал. Гаяз Исхакый: «Матбугат вазыйфасының иң авыры, иң изгесе—милләт эшләре»,—дип юкка гына әйтмәгәндер. Еш кына бүгенге журналистикабыз өчен борчылып: «Кайда соң безнең Исхакый, Тукай, Фатих Әмирханнарга тиң журналистларыбыз, әдипләребез, кайда ул милләтне уятырдай үткен телле публицистларыбыз?»—дип сорау бирергә яратабыз. Ләкин чор белән чор башка, сәяси-иҗтимагый вәзгыять бүтән икәнен дә яхшы аңлыйбыз югыйсә. Һәрхәлдә, татар журналистикасы бүген үзенең мөһим вазыйфасын—милләтебезне берләштерү бурычын лаеклы үтәп килә.

Кайсы гына елларга күз салсак та, Казан Дәүләт университеты журналист кадрлар әзерләүдә зур эш башкарып килде. Безнең бүлек берничә дистә ел дәвамында Идел буе республикалары һәм өлкәләре өчен журналистлар әзерләүче бердәнбер үзәк булды. Бүген республикабыздагы матбугат чараларында эшләүчеләрнең, шул исәптән җитәкчеләрен дә, нәкъ менә бездә укып чыккан кадрлар тәшкил итә.

Бүгенге көндә безнең факультетта 800 дән артык студент укый. Быел 100 дән артык журналист әзерләп чыгардык, шуларның яртысы диярлек татар телендә яза торган кадрлар. Каләм әһелләренә ихтыяҗ зур, чөнки безнең Татарстанда рәсми теркәлү узган меңгә якын газета һәм журнал чыгып килә.

Дөресен әйтик, бүгенге гаять катлаулы чорда журналистларга мөнәсәбәтне бик уңай дип әйтеп булмый әле. Өлкән каләмдәшләребезне совет чоры идеологиясеннән арына алмауда, искечә фикер йөртүдә гаепләсәләр, яшь журналистларга карата белемсезлектә, әхлакый-кыйбласызлыкта, «сарылык»та гаепләүләр күп ишетелә.

Бу тәнкыйть күсәгенең авыр башы еш кына журналист кадрлар әзерләүче безнең факультетка да төшкәләп торды һәм хәзер дә төшкәли. Ә бит яңа гына журналистикага аяк баскан яшьләргә карата кирәгеннән артык таләпләр кую һич кенә дә дөрес түгел. Иҗатның бу өлкәсендә, теләсә кайсы тармактагы кебек үк, еллар дәвамында билгеле бер тәҗрибә-багаж туплагач, шул исәптән тормыш тәҗрибәсенә ия булгач кына зур танылу аласың бит. Без исә кичә генә мәктәп эскәмиясен калдырып килгән балалар, бүгенге студентлар иҗаты буенча

журналистикабыз дәрәҗәсе турында фикер йөрткән булабыз.

Республикада журналистлар әзерли торган факультетның татар һәм рус бүлекләренә бюджет буенча без нибары 13 әр бала кабул итәбез. Бу гадәттән тыш зур конкурс китереп тудыра. Кадрларга кытлыкның бер сәбәбе дә шул.

Әнә шул кытлык еш кына көндәлек журналистикага тиешле квалификациясе булмаган яшьләрне дә тартып китерә. Күпләр бу өлкәне, әйтик, зәңгәр экраннардан үзен күрсәтер өчен, йолдыз булу максаты белән генә сайлый. Безнең факультет студентларының да беркадәр каләме булганнары, тулаем алганда яртысынннан артыгы, икенче-өченче курстан ук редакцияләрнең тулы штатта эшләүче хезмәткәрләренә әверелә. Без моны бер яктан хуплыйбыз. Икенче яктан, бу—уку процессына зур зыян сала. Медицина өлкәсендә яңа гына белем үзләштерә башлаган студентны катлаулы операция ясарга мәҗбүр итү белән бер бу. Тиешле белеме булмаган, ярымграмоталы, эрудициясез, әле шәхес буларак өлгереп житмәгән, формалашмаган кадрлар журналистикабызда әнә шулай да пәйда була.

Инде без уйлап та куябыз: әллә соң булачак журналистларга университетта уку елларында, бигрәк тә гомуми гуманитар, классик белемнәрне алу чорында, редакциядә эшләүне бөтенләй рөхсәт итмәскәме?..

Бу ситуациядән чыгу юлы бер генәдер. Ул да булса факультетның үз гамәли базасын, шул практиканы оештыруга хезмәт итә торган матди-техник һәм технологик җиһазланышны ныгыту. Министрлык тарафыннан расланган укыту стандартлары буенча безнекедәй факультетлар заманча телевизион студия, типографик лабораторияләр белән җиһазланган булырга тиеш. Цифрлы революция чоры дип йөртелә торган үтә дә кызу темплы заманның таләпләреннән калышмый атлау мөмкин түгел. Бу мәсьәләдә соңгы елларда беркадәр алга китеш булса да, бүгенге студентны уку процессында ук газета чыгарырга, радио-телевидение тапшыруы әзерләргә өйрәтәбез дип, авыз тутырып әйтә алмыйбыз.

Хәзерге техник һәм технологик үсеш заманында бер университетның гына безнең өчен миллионнарча сумлык җиһаз алырга көче җитми. Ярый әле без хәзер контракт буенча укытудан беркадәр акча эшли алабыз. Аннары аерым редакцияләр хәлкадәри ярдәм итә. Кайбер мәсьәләләрдә «Татмедиа» агентлыгының, Журналистлар берлегенең дә теләктәшлеген тоябыз.

Күптән түгел Мәскәүдә узган киңәшмәдә без, бер төркем деканнар, Россия мәгариф һәм фән министрлыгына журналистика белгечлегенә «иҗади» дигән статус бирү тәкъдиме белән чыктык. Бу—абитуриентлар арасыннан студентларны иҗади конкурс аша сайлап алырга мөмкинлек бирер иде. Әлеге мәсьәлә унай хәл ителсә, укыту процессына практик журналистларны, тәҗрибәле каләм ияләрен укыту процессына активрак җәлеп итәргә мөмкин булыр иде.

Милли кадрлар әзерләү турында сүз алып барганда үз халкыбызның бай рухи культурасын үзләштерү проблемалары аеруча актуаль бурыч булып тора. Бу юнәлештә туксанынчы еллар башыннан шактый эшләр башкарылды (татар журналистикасы кафедрасы ачылды, белгечлек буенча күп кенә предметлар татарча укытыла башлады, дәреслекләр, уку ярдәмлекләре бастырып чыгарылды). Тик уку стандартларының «өстән», Мәскәүдән төшерелгән милли кадрлар әзерләүдә зур киртәләр тудыра. Бу стандартлар нигезендә студентлар рус, чит ил әдәбиятлары, рус теле, рус һәм чит ил журналистикасы тарихлары буенча йөзләрчә сәгать лекция тыңларга тиеш. Ә менә үзебезнең татар әдәбияты һәм журналистикасы тарихы, халкыбыз тарихы, мәдәнияты буенча өстәмә дәресләр бирү өчен мөмкинчелекләр бик аз. Мәскәү стандарты якадан тота. Хәзергә мондый дәресләрне кайсын факультатив, кайсын «региональ компонент» дигән исемнәр астында укытабыз укытуын. Ләкин бу мәсьәләдә елдан-ел «кысыла» барабыз.

Мөһим бурычыбыз—гомумкешелек кыйммәтләре һәм журналист этикасына туры килә торган әхлакый сыйфатлар тәрбияләү, журналист эшчәнлеге белән бәйле хокукый гыйлемнәрне өйрәтү. Хәзерге шартларда бу таләпләргә цифрлы технологияләрне тирән үзләштерү, базар шартларында конкурентлыкка сәләтле булу да өстәлә. Менә шундый киң планлы белгеч әзерләү өчен безнең югары уку йорты, һичшиксез, үзебезнең университетның да, хөкүмәтнең дә, массакүләм мәгълүмат чараларының да даими ярдәменә һәм теләктәшлегенә мохтаҗ.

Әңгәмәдәш—**Рашат НИЗАМИ**

Нәгыйм
Мөхибуллин

# «СӨЛЧӘ БУЕНДА» ЯЗЫЛМЫЙ КАЛДЫ...

1972 елның җәе иде. Мин Кырымга, Евпаториядәге санаторийга барырга тиеш. ТУ-124 самолеты белән төн уртасында Симферопольгә очасы. Мин иске Казан аэропортында. Ай яктылы җылы җәйге төн. Безнең рейс бераз кичектерелеп тора. Минем игътибарны бер төркем кәефле агайлар җәлеп итте. Алар базык гәүдәле бер кешене озаталар. Аны уратып алып, төрле-төрле мәзәкләр сөйлиләр. Бу чал чәчле, кысык күзле агайны кайдадыр күргәнем дә бар сыман.

Ниһаять, төн уртасында исән-имин Севастопольга килеп төштек. Ул абзыкай да чыкты, «Җәмәгать! Кемнәр Евпаториягә?» дип сөрән салды. Шул арада бер таксист та пәйда булды. Без барыбыз алты кеше җыелыштык.

«Утырыгыз, дүрт кеше алам»,—диде шофер. Теге абзый мина: «Ярар инде, ханымнар китә торсын, без икенчесен көтәрбез»,—диде. Ләкин күпме генә көтсәк тә, икенчесе күренмәде. Без троллейбус белән Ялтага килеп, иртәнгә кадәр тимер юл вокзалында поезд көтеп утырырга мәҗбүр булдык.

Икебез дә «Октябрь» санаториена барабыз икән. Яңа килүчеләрне олы яшьтәге баш врач кабул итә. Мин сәер юлдашым артына чиратка бастым. Путевка, карточка һәм паспортларны барлыйбыз. Оялып кына юлдашымның җилкәсе өстеннән үрелеп аның документларына күз төшергән идем, чак кычкырып җибәрмәдем: Шәйхи Маннур ләбаса бу!

Ул чакта без үзебезне күптәнге танышлар кебек хис итә идек инде. Шәйхи абый (мин аңа шулай дип дәшә башладым) табибка керер алдыннан мина борылып карады да:

—Сез, дускай, каршы килмәсәгез, бер палатага урнашыр идек,—диде. Каршы киләммe соң, дүрт куллап риза булдым. Табиб янына кергәч, ул миннән:

—Кто этот мужчина, который только что был у меня?—дип сорады. Мин горур гына:

—У нас в Татарии его даже все ученики знают, он—наш орденоносный поэт-писатель, автор романа «Муса» о Джалиле,—дип чатнатып җавап бирдем.

Табип: «Если так, мы еще с ним встретимся. Возможно, он согласится прочитать нам лекцию»,—дигәч, түбәм күккә тиде.

Шәйхи ага белән танышлыгыбыз әнә шулай башланып китеп, озын гомерле булып чыкты. Санаторийдан соң без гел телефоннан хәл белешеп тордык, бер-беребезгә кунакка да баргаладык.

Бер тапкыр шулай туган көнемне миндә икәү генә бәйрәм итеп утырганда, Шәйхи абый белән бабама таш куйдыру турында киңәшмәкче булдым. Дөресрәге, ташка нинди сүзләр язу турында. Әтием ягыннан бабам, волость старшинасы, япон сугышында катнашкан, анда Георгий тәресе белән бүләкләнгән. Шәйхи абый болай дип язарга киңәш итте: «Рус-япон сугышы

каһарманы, Чирмешән волосте старшинасы Мөхибулла». Аның бабам турында күбрәк беләсе килде. Шуннан мин сөйләдем инде. Көндезге 12 дән төнге 12 гә кадәр—12 сәгать рәттән! «Оят түгелме, бер-беребезне әллә кайчаннан беләбез, нигә элегрәк сөйләмәдең боларны?»—диде шагыйрь.

Шәйхи абыйганиләр сөйләдемме? Менә шуның аз гына өлешен булса да кәгазьдә кабатлап карыйм әле.

* * *

Әтием Мингалимнең әтисе Мөхибулла, ягъни минем бабам, бик ярлы гаиләдә үсә. Тумыштан таза егет сабан туйларында рәттән батыр кала. Рус-япон сугышында бер сажин[1] буйлы егетләрне гренадерлар частена алалар. Бабам да гренадер була. Ул һөҗүм вакытында японнарны берәмтекләп түгел, үзе әйтмешли, «чалгы белән печән чапкан кебек» кыра. Патша бүләге саналган «Георгий тәресе»н күкрәгенә кадый башлагач, чукындыралар, ахры, дип куркып, олуг бүләкне жиргә салып таптый. Шуннан үзен яткызып канга батканчы камчылыйлар. Өйгә кайткач, бу хакта беркемгә дә сөйләми, чөнки авылыбыз Лашманның Түбән очы ислам диненә әйләнеп кайткан керәшеннәрдән торган.



*Рәсемдә: уртада Ш. Маннур, уңда Н. Мөхибуллин, сулда М. Әмирханов (Новосибирск егете). Рәсем артына Ш. Маннур кулы белән болай дип язылган: «Нәгыйм дус, без күңелле генә ял иттек, күп нәрсәләр сөйләштек. Дуслык дәвам итсен. Бу шуның исәлеге булсын. Зур ихтирам белән, Ш. Маннур. 25. 10. 72.»*

Мөхибулла солдат сугыштан соң хуҗалык эшенә чума. Ярлы крестьянның очсыз аяк киеме чабата инде. Чабата ясарга исә юкә кайрысы кирәк. Ә юкә кайда? Патша урманында. Бер тапкыр урман каравылчысы Мөхибулланың эзеннән килә дә, юкә капчыгын эзләп өенең чормасына ук үрмәләп менә. Гренадер шунда, беткән баш беткән дип, «стрелок»ны чабуыннан сөйрәп төшерә дә, кызып китеп камчысы белән теге аның жуйганчы яра. Аны Чирмешәнгә, земский начальникка алып китәләр. Мөхибулла солдатның өйдә дүрт баласы, хатыны һәм әнкәсе елашып, «Себер китте—башы бетте» дип кайгырышып торганда, Чирмешәннән Земский белән Мөхибулла кочаклашып кайтып төшәләр. Бәхеткә каршы, түрә аның япон сугышындагы командиры булып чыга. Земский халыкны жыеп:

—Беләсезме, бу кешегә патша бүләген тапшырганнар. Кемнәр аны бүгеннән үк авыл старостасы итеп куярга риза?—дип сорый. Халык риза була. Менә сина күтмәгәндә бәхет! Әкияттә эт «Үләргә киткән кызыкай баеп кайта

[1] Сажин – 213 см.

түгелме?» дип өрә бит әле, шунын кебек инде.

Тагын ике елдан Мөхибулланы волость старшинасы итеп куялар. Менә шунда китә инде өйләнү мажаралары. Бер бай гына тол хатын элегрәк ана, зур бирнә белән, кызлыкка алган хезмәтчесен кияүгә биргән була, менә шул, бөтен мал-мөлкәтен төяп, ана яшь хатын булып килә. Ягъни кызына көндәш була. Ләкин яна старшинага болар гына да житми, ана укымышлы өченче хатын кирәк. Мөхибулла күрше авылдагы Сөнгатулла мулланын олы кызы Мәхрүзәне сорап килә. Әткәсе ризалык биргәч, кыз шул көнне үк качып китеп, яраткан егетенә ябышып чыга. Шуннан сон старшинага, өченче булып, үз ирен ташлап, авылнын ин чибәр хатыны килә. Ләкин өч хатыннын берсе дә бер кәлимә русча белми. Старшинанын эш урыны исә—урыс-мукшы авылы Чирмешән. Ул пар атын жигеп, дүртенче хатынга япь-яшь һәм бинһая чибәр Минзифаны сорап, ярым урыс, ярым татар авылына бара. Әти-әнисе риза була, ләкин чая кыз туп-туры: «Мин сина бармыйм, теләсән, малаен Мингалимгә ал»,—ди. Старшина булачак киленен шунда ук үз янына тарантаска утырта, әти-әнисен, туган-тумачаларын жыя да, үзенен Лашманына туй ясарга алып кайта. Өйдә бу хәлне малае Мингалим (сонра минем әти) белми әле. Старшина кайтып керүгә шәрран яра: «Тиз табыгыз Мингалимне, ана кәләш алып кайттым!». Малае исә елап: «Әти, мина хатын кирәк түгел»,—дип ялвара. Ул бүтәнне яраткан була. Солдат Мөхибулла—каты куллы кеше, шул көнне үк мулла чакыртып никах укыта. Ләкин бу мәжбүри ясалган туй фажига белән тәгалләнә.

Ун ел старшина булып тору дәверендә Мөхибулла юллар салдыра, күперләр төзетә. Земский аны мактап бетерә алмый. Туган авылы Лашманда өйләр кайда унай, шунда салынган була, шуна урамнар да кәкре-бөкре килеп чыга яисә бөтенләй булмый. Урамнарны турайтканда старшина бай крестьяннар рөхсәтсез үзләштергән жирләрнен бер өлешен ярлыларга бирә. Менә шул кулаклар бер ат карагын яллап, туй вакытында старшинаны атып үтертәләр. Вакыйга 1916 елны була. Казан губернаторы суд-медэкспертиза докторларын жибәрә. Мәрхүмне гүреннән чыгарып ярып карагач, күкрәгендә мышьяклы 36 ядрә табалар.

Гренадер Мөхибулла шул килеш тә өч тәүлек анын жуймый әле. Үзен атучыны кыйнап үтерүдән ул алып кала. «Закон буенча хөкем итсеннәр»,—ди. Ләкин халык старшинаны шулкадәр дә ярата ки, тегене, инде төрмәгә кергәч, барыбер кыйнап үтерәләр. Старшина үз кулы белән «Мине атучыдан башка беркемне дә хөкем итмәскә», дип язып калдыра. «Ул явызларны авыл халкы гомер-гомергә каһәрләр, халык бәддогасы ин зур жәза булыр»,—ди ул.

Әлеге фажигадән сон сиксән елдан артык вакыт узды, Лашман авылынын 150 еллык юбилеена кайткач, яшь буын вәкилләре урамда мине очратып: «Нәгыйм абый, Мөхибулла бабанны аттыручыларны беләбез»,—диделәр. Юбилей тантанасында авылнын тарихчысы: «Лашманда ике күренекле шәхес яшәде: берсе—Гаяз Исхакыйнын бабасы Исхак мулла, икенчесе—рус-япон сугышы каһарманы, Чирмешән старшинасы Мөхибулла»,—диде.

Мөхибулла бабабыз япон сугышында каһарманлык күрсәтсә, улы Мингалимгә бер-бер артлы өч сугышта катнашырга туры килә. Герман сугышына аны, улы кебек күреп, Земский үзе алып китә. Сине барыбер алачаклар, минем белән бару шәбрәк булыр, ди. Әтием атлы артиллериядә башта ездовой, аннары төзәүче була... Гражданнар сугышында исә ана бер тапкыр... үз өенә разведкага барырга туры килә.

1918 елны ак чехлар Лашманга керә. Аларнын штабы ин шәп өйдә, ягъни Мөхибулла старшина өендә урнаша. Якындагы урманда исә кызыллар отряды туплана. Командир әтине разведкага жибәрә. Старшина, үзен кәтелмәгән

хәлләрдән аралар өчен, идән астыннан өч якка өч юл казыткан була. Мингалим шуларның берсеннән идән астына үтеп кереп, өстә сөйләнгәннәрне мыегына чорнап утыра. Иртән кызыллар авылдагы отрядны тар-мар итәләр...

Бу вакытта өйдә аның хатыны Миңзифа чибәр булмый инде. Утын кискәндә пычкы сикереп, бармагын җәрәхәтли дә, каны агуланып, икенче көнне таңда ук дөнья куя ул. Ярты яшьлек кызлары Минленурны ятим калдырып. Әтием сугыштан кайтканда аңа дүрт яшь була инде.

Әти, беләсезме, кемгә өйләнә? Күрше авылның Сөнгатулла мулла кызы Мәхрүзәгә. Теге вакытта ябышып чыккан егете герман сугышыннан кайтмый. Анардан да бәләкәй кыз калган була. Шулай итеп, кичәге солдат белән аннан тугыз яшькә олы солдатка һәм ике нәни кыз бер гаилә булып берләшәләр. Аннары бер-бер артлы мин, сеңелкәш һәм ике энекәш дөньяга килгәнбез. Әни ара-тирә шаяртып: «Сүземне тыңламый кара, Мингалим, кирәгеңне бирермен, мин бит синең әниең буласы кеше идем»,—дип әйтә торган була.


Әтием Мингалим.

Төпчегебез туу белән диярлек, 1930нын гыйнварында (миңа ул чакта 6 белән 7 арасы), өйгә тиф үтеп керә. Өч ир-ат: әти, мин һәм бәби энекәш кенә бирешмәгәнбез. Калганнар бар да егылган. Әни шунда әтине Маһруй атлы карт кызга өйләндерә. «Мин балаларымның кем кулында калуын күреп җан бирергә тиеш»,—ди ул... Маһруй авыруларны бага, малларны һәм өйне карый.

Әнинең беренче ирennән булган кызы Мәснүга үлә, калганнар язга таба бар да тернәкләнә. Шунда Маһруй, шөкер, терелдегез, мин китәм инде, ди. Әни карыша. Зинһар, китә күрмә, авыр вакытта ярады да, соңыннан Мәхрүзә куып җибәрде дип әйтәчәкләр бит, ди. Маһруй исә, тиф йокты, үз өемдә чирләп ятасым килә, ди. Анда аның әнисе белән энесе генә. Тәки кайтып китә. Күпмедер вакыт үткәч, әти белән әни, бәлешләр пешереп, хәл белергә барсалар, теге ишек алдында ут чәчрәтеп утын ярып ята икән. Чирлим дию хәйлә генә булган, димәк.

—Әй, Аллага шөкер, сау икәнсең, киттек, утыр әйдә,—ди әни. Авылның ерак очы бу, ат җигеп килгән булалар. Маһруй исә тагын карыша.

—Ярар инде, рәхмәт. Алма кебек балаларыгыз бар, тигез, матур гаилә, мин артык. Сезгә бернинди үпкәм дә юк, ди ул. Кайтуын кайтмый, ләкин иң якын туганыбыз кебек булып кала. Әнием аны әтинең якын дусты гармунчы Сибгаткә димли. Өйләнешәләр.

Сибгатнең беренче хатынынннан туган улы Миндар үткән сугышта Рокоссовскийның ординарецы була. Маршал аны бик үз итә, Җиңү парадыннан соң үткәрелгән банкетка да алып керә хәтта. Ул парадка Рокоссовский командалык итте бит. Табында Сталин белән бер тирәдә утырдым, арада биш кенә кеше бар иде, дип сөйләде миңа Миндар.

Ул сугыштан япон сугышы каһарманы Мөхибулланың улы белән оныгына, ягъни әти белән миңа да өлеш чыкты. Әти Сталинград янында ятып калды. Ленинград яныннан минем турыда да кара хәбәр килергә мөмкин булган.

Полкыбыз Ленинградны саклый иде. Ул көнне андагы 3500 солдат һәм офицердан 100ләбе генә исән калган. 40 кешелек разведзводтан исә берүзем исән калдым. Без, унлап авыр яралы яткан блиндажга снаряд төшеп, блиндажның өске ягын кубарып атты. Безне берәмләп алып китә башлаганнар иде дә, бу эш кинәт тукталып калды. Коткаручыларыбызның үзләрен үтерделәр булса кирәк. Гыйнвар уртасы, чатнама суык. Башка яралылар,

озак интекмәс өчен, блиндажда булган спиртны ныгытып эчә башладылар. Мин өйдә дә, фронтта да аракы-фәлән эчеп карамаган идем, бу юлы да тыелып калдым. Иртәнгә мин берүзем генә исән идем инде. Ләкин минем дә минутларым санаулы иде. Кинәт янда ат пошкырды һәм кемдер татарча сүгенеп җибәрде. Мин дә шундук үзебезчә, «Абый, коткар мине!» дип кычкырдым һәм аңымны җуйдым.

Янә медсанбатта, тәннән мина кыйпылчыкларын алганда гына аңыма килдем. Ленинград госпиталендә гангрена дип сул аякны кисәселәр иде, теш-тырнагым белән карыштым. Чөнки култык таягы тотарлыгым юк—сул җилкәмне мина кыйпылчыгы чәрдәкләде. Хәтта, аяксыз калганчы үлүем артыграк дип, Сталин исеменә «рапорт-протест» та яздым әле... Температурам күтәрелгәннән күтәрелә барып, 40ка җитте. Тагын ничәдер тәүлектән Череповец госпиталендә смертниклар палатасында аңыма килдем. Үләргә теләгәч үлсен дигәннәрдер инде...

Бу палата чыннан да Газраилнең кабул итү бүлмәсе кебек икән: чиста ак күлмәк-ыштан киертеп алып чыгып кына торалар.

Менә соңгы кат кием алыштырырга минем дә чират җитте. Яшь, таза медсестра мине бәби тоткан кебек кенә күтәреп алып чыгып китте. Палатадан: «Татарина понесли готовить к встрече с Магомедом»,—дип озатып калдылар...

Сестра чишендереп ваннада юа башлагач, рәхәт булып китте. Кайнар су белән кайнаша торгач, тирләде булса кирәк, кызыл кофтасын салды. Шунда мин гомеремдә беренче мәртәбә шулай якыннан хатын-кыз имиен күрдем. «Теперь и умирать не жалко»,—дидем. Сестра көлеп җибәрде. «Что, татарин, до сих пор голую бабу не видел?»—ди. Ул мине нәни бала белән шаяргандай шаярып юды.

Палатага кире керткәч, кемдер миннән: «Ну как, готов к встрече с Магомедом?»—дип сорады. Готов, мин әйтәм, ведь я увидел эти... девичьи титки. Шунда мин гомеремдә бүтән беркайчан да ишетмәгәнне ишеттем: әҗәл бугазыннан алган хәлсез, зәгыйфь ирләрнең тыелалмыйча, шашынып көлүен.

Көлү тынгач, Советлар Союзы Герое, ике аягы да киселгән танкист-капитан: «Запомните, этот разведчик переживет всех нас»,—диде. «Это почему же?»—дип сорагач, болай диде: «Да потому, что перед смертью заговорил про любовь».

Иртән Герой безнең арада юк иде инде. Аны күп итеп кан салу да коткарып кала алмаган.

Мин исә тагын бер атнадан утыра башладым, аппетит та ачылды. Бүтән палатага күчерделәр.

Бераз соңрак Ленинград янында минем җизни булачак егет тә сугышып алган. Хәер, җизнидән алда апа турында сөйләргә кирәк әле.

Әтинең беренче хатыныннан булган кызы Миңленурны әбисе мин әле нәни чакта ук Свердловскига алып киткән. Шунда абыйсы гаиләсендә үсә ул, 7 классны русча укып бетерә. 1937 елны авылга да бер кайтып киткән иде. Урыс кешесенә димләүләрен әйтте, тик әтием ризалык бирмәде. Соныннан «Раз ты не слушалась нас, мы тебя не признаем» дигән хатны әти миңа әйтеп яздырды... Аннан сугыш башланды. Әти кайтмады бит инде. 1947 елны көтмәгәндә әни дә дөнья куйды.

Әнинең үлеме бигрәк аянычлы булды... Миңа Казанга телеграмма суктылар. Абый, тизрәк кайт, иртәгә кайтып җитмәсәң, әни өзелә, дип. Безнең Чирмешәнгә почта самолеты гына оча иде, хатлар өстендә утырып кайттым, кайтып өлгердем.

Бер агай сатып алган сыер сөзгәк булып чыга. Әни кәҗәне каршыларга кып-кызыл күлмәк киеп бара. Теге сыер туп-туры аның өстенә килә дә,

сөзә. Мөгезе кулмәк эченә кереп калып, ычкындыра алмый, җиргә шапшап сугып, сыер әнине урам буйлап өстерәп алып китә. Ярый әле шул тирәдәрәк яшәгән туганнан-туган сеңлесе күреп ала, көрәк белән башына сугып, сыерны ега. Ләкин әнинең бөтен арткы буыннары ватылган була инде. Фельдшер берни дә эшли алмый... Төне буе кулымда булып, иртән җан бирде әни...

700 грамм—өч көнлек ипиемне алып кайткан идем, шуның белән өчесен, җидесен үткәрдек. Күпләр белмидер, 1947 ел—ачлык ел ул. Безнең авылда да ачтан үлүчеләр күп булды.

Минленур апа турында сөйлисе идем бит. 1952 елны бик авырлык белән генә эзләп таптым мин аны. Таныш милиция хезмәткәре аша. Фамилиясен белмәгәнмен чөнки, «Мингалим» дигән исемнән «Мингалёва» дигән фамилия ясар дип кем уйлаган аны!

Свердловск вокзалында поездлан төштем. Апа белән ничек табышырга? Телеграммада вагон номерын күрсәтмәгәнмен. Мин аны соңгы тапкыр 15 ел элек, 20 яшьлек кыз килеш күргән идем бит. Ә ул мине 14 яшьлек малай итеп хәтерли... Бөтен кеше таралып бетте, мин калдым да таза, чибәр бер хатын калды торып. Менә ул «О, Нагим, это ты!» дип, үксеп мине кочаклап алды.

Апамның беренче ире инде үлгән, хәзер Василий атлы хәрби очучы белән йөри икән. Кичен ул үзе дә килде, ике фронтовик иркенләп бер сөйләшеп утырдык.

Васяларның Ленинград янында үз йортлары булган. Абыйсы, очучы истребитель, Ленинградны күктән саклаган. Вася исә истребитель булырга укып кына йөри икән. Бер тапкыр шулай абыйсы аның иңенә үз кителен сала да, кибеткә барып үзенә тиешле азык паегын алып кайтырга куша. Шулай итеп үзе дә белмичә ул энесен үлемнән коткарып кала.

Кибет бер квартал ары була. Вася күпмедер киткәч, гөрелдәп-дөбердәп бомбардировщиклар килеп чыга. Васяның күз алдында бер бомба боларның өенә килеп төшә. Өйдән, әтисеннән, әнисеннән һәм абыйсыннан зур бер чокыр гына торып кала. Хәер, тагын әле абыйсының кителе һәм аның кесәсендә абыйсының документлары була. Аның каравы үзенең бер генә документы да калмый. Вася абыйсы хезмәт иткән частька бара, шундыйшундый хәл булды дип сөйләп бирә. Абыйсының документлары белән ул булып сугышырга рөхсәт сорый. Аны абыйсының самолетына утырталар. Ул тагын әле башкалардан аерым, мөстәкыйль очыш ясарга да рөхсәт сорый. Үч аласым килә, ди. Рөхсәт итәләр. Вася күктә дошман бомбардировщиклары төркемен очрата, курыкмыйча берьялгызы һөҗүмгә ташлана һәм бер самолетны бәреп тә төшерә. (Моның өчен соныннан аңа орден бирәләр.) Ләкин аның үзен дә бәреп төшерәләр. Исән кала калуын, әмма кулын имгәтә. Свердловскига госпитальгә җибәрәләр. Аннары шунда хәрби училищеда курсантларны очарга өйрәтә башлый. Үзе исә бер куллап машина йөртергә өйрәнә. Ватык машиналарны сүтеп, үзенә машина җыя. Шунда иптәшләре әйтә аңа, Жуков янына приемга барыйк, бәлки яңа машина бирер, син чүтеки гади кеше түгел бит, диләр. (Сталин 1946 елны Г. Жуковны Одесса хәрби округы командующие итеп сөргән иде бит, аннары Урал округына күчерде.) Жуков кабул итә боларны. Аңа Васяның хәл-әхвәлен алдан аңлатып куйган булалар инде. «Барып кердек,—дип сөйләде мина Вася,—керүгә Жуков акырып җибәрде: «Ты что, сволочь, с чужими документами сел на советский самолет?!»—ди. Мин куркудан чак кына астыма җибәрмәдем. Маршал шунда елмайды да, «Не бойся! Смотрите, вот кто отстоял Ленинград!»—дип мине ике кулына күтәреп алды. Аннан, нинди йомыш белән килүемне сорагач, «Завтра же дайте!»—диде. Өр-яңа машина бирделәр».

Вася апам белән училищеда таныша, ул анда бухгалтер булып эшли иде... Апа кияүгә чыгарга ризалык сорады миннән. Әти өчен дә, әни өчен дә син калдың инде, диде. «Живите! Яшәгез!»—дидем.

Жизнәкәй аннан 7 яшькә кечерәк икән, апаны шул борчый иде. (Миннән дә бер яшькә яшьрәк булып чыга.) Әти белән әнине мисалга китердем, безнен әти дә 9 яшькә кечерәк иде бит...

* * *

Шәйхи абый мине тәмәкесен көйрәтеп, ара-тирә сораулар да биргәләп, дикъкать белән тыңлады. Соңыннан: «Нәгыйм дус, бу кызыклы тарихыңны язып бир, без аны «Казан утлары»нда бастырырбыз»,—диде. Шагыйрь журналның редколлегиясендә икән. Рәхмәт әйтеп, баш тарттым. «Мин язучы түгел бит, минем көч җитмәс»,—дидем. Бераз уйланып торгач, Шәйхи абый болай диде: «Әгәр риза булсаң, синең ярдәм белән бабаң, әтиең һәм үзең турында роман язам, өч томлык әйбер бар монда. Исеме «Сөлчә буенда» булыр». (Сөлчә—безнең авылдан өстәрәк кенә агып чыга торган елга.) Сөенеп риза булдым, әлбәттә. Мин авылга кайтып материал туплап бетерәм дип килештек. Бер мәртәбә икәүләп тә кайтып килербез дигән идек, анысына өлгерми калдык, ләкин бабайны белгән карт-карчыкларны сораштырып бик күп яңа материал җыйдым, аларның барын да Шәйхи абыйга тапшырдым. Шәйхи абый сүзендә тора торган кеше, роман һичшиксез язылачак дип уйларга була иде. Ләкин... Алла боерса, димәгәнбезме...

Көннәрдән бер көнне Шәйхи абый көтмәгәндә борчулы тавыш белән болай дип шылтыратты:

—Нәгыйм дус, нишләптер исәнлек какшап тора әле. «Сөлчә буенда» да тукталып тора. Син, зинһар, безнең хирург дустыбыз белән сөйләш әле. Бәлки, мина шунда кереп яту кулайрак булыр.

Без бит Зәки Алимовның 10 нчы шәһәр хастаханәсендә ярты ел элек кенә булган идек. Шагыйребез ул чакта ятудан баш тартты.

—Зәки дус! Саулыгымны кайгыртуың өчен рәхмәт. Ләкин минем исән-сау чагымда «Муса»мның русчага тәрҗемәсен күрәсем килә,—дигән иде ул.

Медицина фәннәре докторы, хирург Зәки Җиһанша улы Алимов аптыраган тавыш белән миңа болай диде:

—Күрәсең, обком хастаханәсе хирурглары, хәле өметсез булганга күрә, операциядән ваз кичкәндер инде. Миңа нишләргә? «Соң инде» дип әйтеп булмый бит.

Мин үзем дә Зәкидән үтенә башладым:

—Зәки дус! Әгәр дә баш тартсаң, ул шүрләр, авыруы тагын да көчәер,—дидем.

—Шулаен шулай да ул. Ләкин операция өстәлендә өзелеп китсә, Зәки генә башына җитте дияселәрен көт тә тор.

Озак кына уйлангач:

—Ярый инде, алып кил дустыбызны,—диде.

Иртәгә операция дигән көнне Шәйхи абый үтенече белән Зәки мине чакыртты. Шәйхи абыйның күңеле алай китек түгел иде. Шул хәлендә дә миңа әдәби эшемдә ярдәм итәргә тырышты, киңәшләрен бирде (шигырьләр язып маташа идем). Доктордан мине үзе янында кичке тугызларга кадәр калдыруын сорады. Аның беркайчан да шулай хискә бирелеп озак сөйләшкәнен күргәнем юк иде әле. Янында кызы Миләүшә дә утырды. Иртүк ашыгыч командировкага китәсем бар иде. Ул сабый балалар кебек:

—Дускай, тизрәк әйләнеп кайтырга тырыш,—дип калды.

Чынлап та, мин эшемне мөмкин кадәр тизрәк бетереп дүрт көннән өйгә кайтуга, хастаханәгә чаптым.

—Операция бик авыр булды,—диде Зәки.—Теге яман чир бөтен ашказанын бозып өлгергән. Ашказанын бөтенләй диярлек алырга туры килде. Практикамда андый хәлләр булгалады минем: пациентларым аннан соң әле кимендә биш-алты ел якты дөньяда яшиләр.

Шуннан, тәмәкесен озак кына суыргач, әйтә бу:

—Ләкин, Нәгыйм дус, Шәйхи абый тәртипсез бала кебек. Минем сүземне тыңламый. Инде ничә көннәр буе селкенми аркасында гына ята. Мин һәр көн аңардан өзелеп-өзелеп хәрәкәтләнүен сорасам да, файдасы юк.

—Соң ята бирсен, аның ни куркынычы бар?—дим мин.

—Беләсеңме, дустым, хәзер аңарда докторлар өчен иң хәтәре—үпкә шешү!.. Гомере буе авызыннан челемен куймаган тәмәкеченең үпкәсе болай да чак-чак кына калган бит. Без хәзергә бу чир алдында көчсез!..

Шуннан палатага кереп, Шәйхи абый койкасы янына килдек. Кәефе алай ук төшмәгән, әле бераз шаярткан да була. Мин исә керүгә шелтәләргә тотындым:

—Шәйхи абый, нигә сез докторлар сүзен тыңламый хәрәкәтсез генә ятасыз?

Ул унайсызлана төшеп:

—Егетләр, мин бит ашказанын теккән җепләр өзелеп китмәсен дип шикләнәм,—диде. Хирург шунда кырт кисеп әйтте:

—Шәйхи абый, мин теккән җепләр мәңге өзелә торган түгел—гарантияле!

Шуннан соң шагыйрь минем муеныма асылынып әкрен генә торып та утырды. Ләкин бик соң булган икән шул инде... Икенче көнне үк янә каһәр төшкән ашыгыч командировка. Без бик авыр аерылыштык.

Бу юлы да командировкадан ашыгып кайтуга хастаханәгә йөгердем. Зәки еламый гына:


—Менә, Нәгыйм дус, синең гозереңне тыңлап срогы чыккан ашказаны зәхмәте белән көрәшергә керештем. Обком врачлары юкка гына баш тартмаган инде. Операциянең үзен, билләһи дип әйтәм, бик уңышлы уздырдым. Ләкин ике яклап үпкә шешү дигән чирне җиңеп булмады. Мәрхүм гомер буе чамадан тыш тәмәке суырып ашказанын гына түгел, үпкәсен дә ашатып бетергән шул...

1980 елның 10 июнендә була бу хәл.

Шулай итеп, «Сөлчә буенда» романы да, Шәйхи ага хыялында йөрткән башка күп әсәрләр дә язылмыйча калды... «Муса» романының әдип шуны күрү хакына дәваланудан баш тарткан тәрҗемәсе генә дә чыгып өлгермәде бит хәтта...

# ТӘНКЫЙТЬ ТӘ—ТИРӘН ДӘРЬЯДЫР

Әдәбиятта яна исемнәр, яна йолдызлар ачу чагыштырмача сирәк күзәтеләдер. Әмма, вакыйгага буларак, ул әдәбият сөючеләр даирәсендә, кин катлам җәмәгатьчелек хәтерендә нык уелып кала. Берничә мисалны гына искә төшерик. 60 нчы елларда Сибгат Хәким, Хәсән Туфаннарның хәтерфатихасы белән Зөлфәт һәм Мөдәррис Әгъләмов поэзиягә әнә шундый бер ыргым белән атылып керделәр түгелмени? Вакытында Айдар Хәлим дә шигърияттә үзенең исемен ныклап янгырата алды. Хәтердә ич: берзаман шигъри мөнбәргә тагын ике яна исем—Ркаил белән Ләис күтәрелде! Инде якындагы көннәргә әйләнеп карасак, Луиза Янсуарның романтик-илаһи иҗаты күз алдына килеп баса...




Поэзиядә шулай: ул—«кавалерия» сыман җиңел сөякле, хәрәкәтчән, аерата актив. Ә менә авыр «артиллерия»—прозабызда күнелне куандырырлык яна исемнәрне атап китү кыенгарак төшә. Әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә балкып кабынган яна исемнәрне сирәк очратабыз.

Ә шулай да... Укучының игътибарын җәлеп итәр өчен, бу урында мин җөмләмне махсус өздем, күп нокталар куйдым. Чөнки әле күптән түгел генә әдәби тәнкыйть бакчасында яна ачышка, өр-яңа исемгә, яңа бер аллеяга тап булдым! «Җимешләре» исә ачы да, төче дә түгел, таманча гына. Укучының көткәне дияр идем. Сүз—Илшат Вәлиулланың «Һәр шагыйрь—бер дәрья» дигән китабы турында бара*.

Сиземләү кыен түгел: китапның исеме шигъри һәм тирән мәгънәгә ия. Һәрбер шагыйрьнең шушы бакый тормышыбызда аерым бер утрау, аерым дәүләт, кабатланмас дәрья икәнлегенә матур ишарә. Автор ике-өч битлек кенә кереш сүзендә үк укучы алдына: «Каян килә соң бу татар күнелендә шигърияткә булган сихри тартылу көче?» дигән сорауны куя һәм шунарга җентекләп, ихластан җавап эзли. Шагыйрьләрнең үзәлеген, олы серләргә үзенчә ачкыч табарга омтылышын ул аларның иҗат үрнәкләре аша сокландыргыч вә ышандыргыч рәвештә исбатлап бирә.

Сүземнең башында ук китаптагы ике үзенчәлекне ассызыклап үтәсе килә. Боларның беренчесе—язмаларда хәятыбыздагы Иман, Рух, Милләт, Моң, Сабантуй, Мәхәббәт, Көрәш, Ирек, Әрнү, Сәфәр, Намус, Вакыт, Галәм кебек мәңгелек төшенчәләр һәммәсе дә Баш хәрефтән бирелгән. Мина калса, мондый бирелеш әлеге сүзләр-төшенчәләрнең асыл мәгънәсен бер башка өскә калкытып куя, алар хәтердә ныграк уелып кала. Авторның бу гамәлендә мин Сүзне олылау, кадерләү төсмере дә күрәм.

Икенчесе—көчләп такмыйча гына, төрле гасыр, төрле вакыт аралыгында яшәгән бөек акыл ияләренең фикерләрен бик урынлы һәм отышлы итеп мәкаләләрнең тукымасына кертеп җибәрү. Илшат Вәлиулла үзенең уйлар ташкынына аларның саллы фикерләрен бик оста кушып җибәрә белә. Кайбер галимнәр, аспирантлар һәм тәнкыйтьчеләр үпкәләмәсен: аларның байтак язмалары әле дә булса марксизм-ленинизм классикларыннан яисә русның танылган галимнәреннән алынган өзекләр, арзан цитаталар белән чуарланган бу-

Илшат Вәлиулла. «Һәр шагыйрь—бер дәрья». Татарстан китап нәшрияты. 2006 ел.

лыр. Мондый «жонглерлык», игезәк мәкаләләр бирәүне дә бизәми.

Китапның «Равил Фәйзуллин шигъриятендә Моң һәм Сабантуй рухы» дигән күләмле мәкалә белән башланып китүе табигый һәм урынлы булса кирәк. Чөнки инде менә ничә еллар тормыштан хакыйкатьләр эзләүче шагыйрьнең иҗаты, колачы, тематикасы киң, ул һаман да эзләнүләр һәм ачышлар юлында. Шигърият мәйданына килүенең сәбәпләрен ул вакытында бик төгәл һәм кыска гына аңлатып биргән иде:

*...Вакытны, Хакны, Халыкны*
*танырга безнең исәп.*
(«Азмы синдә байлык...»)

Менә шундый зур, кешелекле төшенчәләрне байрак итеп алган шагыйрьнең иҗатын автор, үзе билгеләгәнчә, Моң һәм Сабантуй рухы яссылыгыннан торып, шуларның иң эчкәрге нокталарына кереп бәяли, халкымилләте өчен сызланып яшәү кичерешләрен ачып сала. Татар озак гасырлар дәвамында моң—моңлылык белән «авырган» икән! Ә чын шагыйрь үз халкының шатлык һәм сагышларыннан берничек тә читләшә алмый. Дәүләтчелеген югалткан татарның менә шушы халәтен Р. Вәлиулла бик тәфсилләп, хисси фәлсәфә белән аңлатып бирә. Әнә шулардан чыгып, шагыйрь иҗатындагы Ныклык, Көрәшчелек рухын, Хакыйкать һәм Хөрлек кебек изге кыйммәтләргә хезмәт итәргә омтылышын гамьле итеп тасвирлый.

Дөресен әйткәндә, Равил Фәйзуллин иҗаты хакында байтак язылды. Яшь тәнкыйтьче Илшат Вәлиулла исә аның шигъриятен янача аспектта анализлый, үзенең уй аргамагында сабантуй мәйданнарының уртасына кереп китә һәм шагыйрь иҗаты аша Сабантуйның татар өчен бәя биреп бетергесез мөһим, кадерле күренеш, фәлсәфә, мәңгелек бәйрәм икәнлеген раслап күрсәтә. Шунысы куанычлы—Илшат үзенә кадәрге тәнкыйтьчеләрне кабатламый, инде без «күнегеп» өлгергән шагыйрьне безгә өр-яңадан ача. Мисалга укып китик: «Сабантуй фәлсәфәсенең Милләт, Ватан, Дәүләтчелек фәлсәфәсенә барып тоташуы табигый. Чөнки батыр, каһарман, фидаи ир-ат гомер-гомергә Ил токтасы булган». Ике генә җөмлә—ә никадәрле зур мәгънәләр сыйган биредә!

Китапны укый барган саен заманыбызның чуалчык һәм болгавыр икәнлеген ничектер онытып торасың да үзеннән-үзе матурлык һәм көрәш дөньясына килеп керәсең. Еш кына ямьсез тоелган тормышыбызга, күңел халәтенә гамь, яктылык, нур өсти бу егетебез!.. Шагыйрьләр иҗатына таянып, тормыш-яшәеш-табигать турында үзенең кичерешләрен, концепциясен бәян итә. Гомумән, аның бу хезмәтендә янача уй-фикерләр Менделеев таблицасыдай «кайнап» тора шикеллерәк тәэсир калдырды миндә.

Мәкалә башына куелган, җидешәр-сигезәр сүздән торган озын атамалар баштарак «куркытып» куйган иде. Әмма, укый-таныша башлагач, аларның хаклыгы һәм урынлы булуына ирексездән ышанасың.

Яңа язмага керешкәнче, монысы нинәрсә икән дип, тагын укып китәбез. «Рәдиф Гаташ: Көнбатыштан Көнчыгышка гомер озынлыгындагы Шигъри Юл». Менә шунардан үзең теләсә ни аңла, укучы!

Әмма сүзенең башында ук И. Вәлиулла без яшәп яткан бу дөньяда Аурупа һәм Азия—ике төрле кыйтга, бер-берсенә охшамаган ике төрле дөнья, мәдәният, менталитет, фәлсәфи карашлар барлыгын искәртеп куя. «Көнчыгышмы, Көнбатышмы?» Күп кенә халыклар белән беррәттән, мондый сорау татарлар алдына да һәрвакыт куела килгән. Автор Нәҗип Думавиның Шәрыкка, ана җавап рәвешендә Җамал Вәлиди кебекләрнең татарны Гаребкә йөз белән борылырга чакыруы хакында укучыга мәгълүмат бирергә дә онытмый. Географик яктан без шундый кинлеккә урнашканбыз ки, глобализация тәэсире белән татар күңелендә Көнчыгыш та, Көнбатыш та гармониядә, үзара аңлашуда яши.

*Яраткан Хак мине шулай—бар иткән:*
*Шәрык-гарепкә бер (!)*
*гыйбрәт яр иткән.*
(«Сиңа—С. Рәмигә тәкълидән»)

Әлеге шигъри юлларын мисалга китереп, китап авторы татар шагыйре

Рәдиф Гаташны шушы ике кыйтганың улы, тугандашы дип саный, шушы уйхисләрнең иҗатында ничек чагылыш тапканын анализлый. Хәтта, бер дә икеләнеп тормыйча, аның шигъриятен «Көнбатыш чоры» һәм «Көнчыгыш чоры» дип ике өлешкә бүлеп каравын белдерә. Әйе, вакыт-вакыт Хәйям, Хафиз кебек шагыйрьләрнең исеме күренеп китсә дә, Рәдиф Гаташның «Көнбатыш чоры»нда Гете, Байрон, Гарсия Лорка һ. б. лар белән чирләп диярлек мавыкканы истә әле. Биредә, ул чаклар сәясәтенә хас булганча, Көнбатышны алгарыш-прогресс, мәдәни-фәнни казанышлар үзәге дип идеаллаштыруның йогынтысы да күпмедер роль уйнады булса кирәк... Шагыйрьнең «Парижларны күрик!» дип шигарь ташлавы, Мадрид һәм Лондон кебек борынгы-мәдәни калаларга ашкынуы бер дә юктан булмагандыр...

Ләкин, куанычка, еллар узгач, чорлар алышынгач, Р. Гаташ «Көнчыгыш»ның түренә дә кыю атлап керә алды. Экзотик газәлләр, сагындырган робагыйлар ярына әйләнеп кайтты. Мәкаләдә шушы кайту турында тәфсилләп, җентекләп язылган. Робагыйларының берсендә шагыйрь үзе дә: «Хәйям! дим; Кайтам Тукайга...» дип ачыктан-ачык белдерә. Р. Гаташ иҗатында ике дөнья, ике кыйтга бергә үрелеп китә—мактау-хуплауга лаек күренеш бу ләбаса.

Мәкаләнең бер бүлекчәсендә шагыйрь иҗатының ике канаты булган Мәхәббәт һәм Романтикага да, аларның кеше күңелен, кеше җанын саклап калудагы якты миссиясенә карата да байтак урын бирелгән.

Романтика димәктән, аның да чәчкәләрдәй төрлесе була бит. Илшат Вәлиулла әнә нәрсә ди: «...Роберт Әхмәтҗан шигырьләре башка шигъри дөньялардан аерылыбрак торган, тылсымлы тарту көченә ия үзгә романтик дөнья, үзгә романтик галәм булып күз алдына баса». Сокланырга гына кала: иҗатында берәүне дә кабатламый торган шагыйрьнең чиксез чынбарлыкны чагылдырып, үз хис-фикер дөньясын тудырып, шигърият итеп шуны безгә—укучыларга тәкъдим итә алу үзенчәлеген И. Вәлиулла бик тә сизгер тотып алган. Оптимизм белән пессимизмның тоташып торган нокталары барлыгына ишарәләп, ул аның романтикасына «оптимистик пессимизм» рухы хас дип мөһер суга.

Чынлап та шулай түгелмени:

*Бу китапның ачтым күпме битен,*
*Ничә бит бар тагын—әйтү читен.*
*Тик әлегә ачкан битләрендә*
*Ал таң иде офык читләрендә.*

(«Гомер китабы»)

Китапта Роберт Әхмәтҗан шигъриятенең метафораларга искиткеч бай булуы ассызыклап әйтелә, бу фикер шигъри юллар-мисаллар белән ныгытыла. Каләм остасының «яфраклары» гына да әллә ничә икән ләбаса—әле яшел карлыгачлар, әле алтын сандугачлар яки сары кошлар...

Р. Вәлиулла, шагыйрьнең уңыш-табышларына ихластан куанып, аны бәхетле иҗатчы дип тамгалый. Яңа заман килгәч, янача рухтагы шигырьләр язуына теләктәшлек күрсәтә. Ике гасыр (иске һәм яңа!) уртасында басып торган гражданин-шагыйрьнең «татар иртәсе»нә, милли чынбарлыкка кагылышлы романтик уй-мөнәсәбәтен унай сыйфатлар дип бәяли. Романтиканың тугры, олы, ихлас вәкиленә хөрмәт хисләрен белдерә.

«Безгә бер хәбәр кирәк» дигән мәкаләдә исә Лена Шагыйрьҗан иҗатында бүгенге кешелек җәмгыятенең кыен хәле-кризисы турындагы фикерләргә шулай ук төпле анализ ясалган.

Шагыйрә иҗатында сүзләр энергиясенең тәңгәллеге, төгәллеге һәм тылсымы космик нур сыман бәреп тора дисәк, бер дә ялгышмабыз:

*Җир сусаган Яңалыкка...*
*Кузгалырлык, бушанырлык,*
*Өр-яңадан ышанырлык*
*Изге бер Хәбәр кирәк!*

(«Безгә бер хәбәр кирәк»!)

Аның иҗатында иң мөһим, иң үзәк темаларның берсе—мәңгелек рухи кыйммәтләрнең әһәмиятлелеген искә төшерү, аларны онытккан яисә оныта төшкән җәмгыятьнең кыен хәле, кешелеккә кризислар ташкыны ябырылу... 2002 елда Лена Шагыйрьҗанның «Бөҗра вә Хөҗрә» дигән, шушы ике сүзгә күп мәгънәле тирән фәлсәфә яшерелгән ки-

табы басылып чыккан иде. Анда 200 дән артык шигырь һәм 4 поэма урын алган. И. Вәлиулла менә шундагы иҗат үрнәкләрен үзенең фикри күзәтүләренә нигез итеп алган.

«Яман илдә яхшы булу авыр»,—дип борчыла, чаң кага тынгысыз шагыйрәбез. Мәкаләдә әйтелгәнчә, аның «Дөнья базары, яхут яңа «Америка фаҗигасе» дигән лирик-публицистик поэмасы да, асылда, гаделсезлекләр, камиллектән ерак торган халыкара һәм кешеара мөнәсәбәтләр турында.

Мөдәррис Әгъләмовның шигъри фәлсәфәсенә хас кайбер үзенчәлекләр хакында сөйләгәндә дә Илшат Вәлиулла үзенең югары, фикри биеклегеннән төшми, халкы-милләте өчен җан атып яшәгән шагыйрьнең тетрәнүләрен, күңеле мөлдерәмә тулы уй-кичерешләрен фәһемле сүзләр белән укучыга җиткерә, олуг Моңның сәбәпләрен милләт язмышына бәйләп анлата. Халкы күңелендәге тирбәлешләргә үтә сизгер шагыйрь юкка гына ачыргаланып язмагандыр:

*...Кем тарафыннан киселде*
*Туган тел дигән канат?*
*Ил, Ватан дигән изгене*
*Кайсыгыз алды талап?*
(«Килде ул—кабахәт чорның...»)

Мөдәрриснең иҗаты, чыннан да—Сабантуй, Моң һәм кайнар хисләр җыелмасы, Бакыйлыкка омтылу!

Тагын шунысы куандыра: И. Вәлиулла яшьрәк буын шагыйрьләрен дә игътибарыннан читтә калдырмаган. Аның Газинур Морат, Габделнур Сәлимов, Рамис Аймәт, Марат Закир, Луиза Янсуар иҗатына карата әйтелгән фикерләре дә яңача, заманча яңгырый, фәлсәфи өслүбе белән укучыда зур кызыксыну уята. Китапның кайсы гына битләрен ачып укысаң да, авторның һәр җөмләсе моңга, нурга, фәлсәфәгә манчылган!

Безнең байтак кына талантлы әдәби тәнкыйтьчеләребез (Т. Галиуллин, Р. Мөхәммәдиев) баштанаяк прозага кереп киттеләр. Мансур Вәли дә повесть һәм новеллалар язу белән мавыгып алды. Ниһаять, офыкта яңача таланты (призвание) белән яңа йолдыз, «саф» тәнкыйтьче кабынды. Ана үзенең иҗади җегәрен, хакыйкать эзләүдәге омтылышларын төрле якка чәчмәскә-чәчелмәскә киңәш итәсе килә. Һәр шагыйрьнең бер дәрья икәнлеген исбатлап күрсәтүе безгә әнә шулай дип әйтергә тулы нигез бирә.

Җитәр, шушы урында туктап калыйк булмаса. Шигъриятебезнең серләрен, әдәби тәнкыйтьченең колачын ныграк һәм тулырак аңлар өчен бу китапны, һичшиксез, кулга тотып, җентекләп уку фарыз.

**Рашат НИЗАМИ**

## *«Татар энциклопедиясе» битләреннән*

# Г

**ГАЙНУЛЛИН** Мөхәммәт Хәйрулла улы (18.8.1903, Тәтеш өязе Коллар а., хәзерге Апас р-ны Кызыл Тау а. -24.5.1985, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1958), проф. (1967), ТАССРның, РСФСРның атказ фән эшлеклесе (1963, 1973). Шәрекъ пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1931) шунда эшкә кала. 1943-44 елларда Татар. дәүләт нәшриятын житәкли, 1944 тән СССР ФА Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1944-53, 1959-61 дә директор). Г.Тукай, К.Насрый, Ш.Камал иҗатларына багышланган беренче мәкаләләре матбугат битләрендә 1930 нчы елларда күренә башлый. 1950-60 еллардагы хезмәтләрендә Х.Һади, З.Бигиев, М.Акъегетзадә, Дәрдемәнд, С.Рәмиев, Ш.Мөхәммәдев иҗатларын анализлый. 20 йөз башы татар публицистикасын ныклап торып өйрәнә. Г. - беренче татар хатын-кыз язучыларының (Г.Сәмитева, Маһруй Мөзаффария, З.Сәгыйдә, Гыйффәт Туташ, М.Акчурина) әсәрләрен туплаган «Өмет йолдызлары» (1988) исемле җыентыкны төзүче һәм кереш сүз авторы. Төп хезмәтләре 19-20 йөз башы татар әдәбияты тарихына, иҗтимагый фикер һәм матбугат тарихына карый. Урта мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр һәм хрестоматияләр авторы.

Хезм.: Татар әдәбияты. XX йөз.: 2 кис. К., 1947; Татар әдипләре. К., 1978; Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. К., 1985 (автордаш); Татарская литература и публицистика начала XX века. К., 1966; Татарская литература XIX века. К., 1975;

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Д. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Мөхәммәт Гайнуллин (1903-1985) // Казан утлары. 1993. N 8; Мөхәммәт Гайнуллин - олуг галим һәм язучы. К., 2003.

**ГАЙСИН** Нур (Нурулла) Әхияр улы (2.11.1914, хәзерге Башкортстан Респ.-касы Чакмагыш р-ны Әхмәт а. - 1.12.1995, Казан), шагыйрь. 1936-40 елларда Казан педагогия ин-тында укый. 1941гә кадәр Ютазы р-ны мәктәпләрендә укыта. Бөек Ватан сугышында катнаша. Армиядән кайткач, бераз вакыт «Кызыл таң» (Уфа ш.) г-тасы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1946-52 дә Казан татар театр уч-щесында директор урынбасары вазифасын башкара. «Ватаным өчен» дип аталган беренче шигъри җыентыгы 1937 елда дөнья күрә. Яшьләргә багышланган «Тайгада очрашу» (1956), «Айлы кичтә» (1958), «Өмет тулы хыялым» (1983), «Таныш моң» (1984) исемле җыентыклар авторы.

Мәсәлләрендә һәм сатирик шигырьләрендә икейөзлелек, ялагайлык, комсызлык кебек кимчелекләр фаш ителә. 1981 елда Г. автобиографик характердагы «Кызыл штанлы малай» повестын бастыра. Аның әсәрләре лиризм һәм нечкә юмор б-н сугарылган. Медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Мәктәптә яз: Сайланма әсәрләр. К., 1974.

Әд.: Зөлкарнәев Ф. Балачак иленнән килгән шагыйрь // Ялкын. 1984. N11; Гаташ Р. Нур Гайсинга 80 яшь // Казан утлары. 1994. N11; Галиев Ш. Ике тапкыр ветеран // Ватаным Татарстан. 1994. 2 нояб.

**ГАЛӘУ** (Мәрҗани) Мәхмүт Галәветдин улы (сентябрь 1886, Казан губ., Казан өязе Ташкичү а. - 12.11.1938), язучы, журналист, тәрҗемәче. 1897-1903 елларда Казан мәдрәсәсендә укый. 1903-07 дә Әстерхан шәһәрендә укытучы булып эшли. Шул елларда беренче язмалары «Шаркый Рус» (Баку) һәм «Борһане тәрәккый» г-таларында күренә башлый. «Туп» ж-лын оештыручыларның берсе һәм аның чынлыкта мөхәррире була. 1907 дә Оренбург шәһәренә килә һәм анда 1914 кә кадәр «Кәримев - Хөсәеневләр» ширкәтендә эшли. 1914 тә үзенең 1918 гә кадәр эшләп килгән «Белек» исемле нәшриятен ача һәм анда «Кармак» ж-лын, фәнни-популяр брошюралар, уку-укыту әсбаплары һәм дәреслекләр («Төрки сарыфы», 1910) редакцияли һәм бастыра. «Төрки уку» (1911) хрестоматиясен төзи. Шул ук елларда татар теленә А.С.Пушкинның «Буран» («Метель») повестен, Л.Н.Толстойның «Хаҗи Морат» («Хаджи-Мурат») һәм «Крейцер сона-

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 санынан басылып килә.*

тасы» («Крейцерова соната») әсәрләрен тәрҗемә итә. Аның тарафыннан эшләнгән К.Н.Батюшков, А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов шигырьләренең тәрҗемәләре үз шигырьләре б-н беррәттән Оренбургта басылган «Ник язылганнар?» (1912) җыентыгына кертелә. 1919 да Башкортстан АССР Мәгариф халык комиссариатының кантон бүлегендә, 1920 дә Оренбург, Мәскәү шәһәрләрендә мәгариф системасында һәм нәшриятларда эшли. 1921 дә Оренбургта хәзерләү артеле оештыра, ләкин властьлар тарафыннан ул 1923 тә ябыла. 1925-26 да Мәскәүдә Үзәк нәшриятта эшли.

Актив иҗат чоры 1920 елларга туры килә. Яңаның иске б-н көрәше, авылшәһәр мөнәсәбәтләре, яңа кеше тәрбияләү темаларына багышланган очерклары һәм хикәяләре б-н матбугатта еш чыгышлар ясый. 1920 елларга хас булган яңа кыйммәтләрне мактау, искелек билгеләрен хурлау күренешләре «Каяу» (1927), «Төеннәр» (1928), «Күпнең берсе» (1931) исемле җыентыкларга кергән хикәяләрендә чагылыш таба. Мәсәлән, 1934 тә Мәскәүдә рус теленә тәрҗемә итеп басылган «Кабулсай» романында мөселман татарларының күмәкләшү чорындагы психологиясенең үзгәртү идеясен татар авылларында дуңгыз фермалары төзү, яңа кеше формалашуын Туктамыш картның диннән ваз кичүе аша күрсәтелә. Г. үзен драматургиядә дә сынап карый: «Саламторханнар» (1926), «Пугач явы» (1926) пьесаларын яза.

1920 еллар ахырында Г. «Канлы тамгалар» исемле дүрт томнан торырга тиешле эпопея өстендә эшли башлый. Анда 1877-1917 еллар вакыйгаларын, татар крестьянының милли һәм социаль азатлыкка таба үткән катлаулы юлын тасвирлау күздә тотыла. Сюжеты конкрет тарихи вакыйгаларга нигезләнә. «Ил тыныч чакта» исемле беренче китап авылдагы социаль каршылыкларның кискенләшүенә китергән 1877 дәге ачлыкны сурәтләүгә багышлана. «Ил өреккәндә» исемле икенче китабында язучы 1897 дә үткәрелгән халык санын язып алу вакыйгаларын һәм татар крестьяннарының массакүләм рәвештә 1894 тә Төркиягә күчеп китүен яктыртырга, «Сабак» дип аталачак өченче китап рус-япон сугышын һәм 1905-07 еллардагы Рев-ция вакыйгаларын, «Өермәләр» дип исемләнгән дүртенче китап Окт. рев-циясен чагылдырырга тиеш була. Ләкин бу ниятен язучы өлешчә генә тормышка ашыра ала: ике китап язылып бетеп, басылып чыга; алар татар әдәбиятында күренекле вакыйга буларак кабул ителә, яңа реалистик тарихи роман жанрына нигез салалар. «Болганчык еллар» романында заманына хас булган идеологик карашлар кысаларында Г. үз игътибарын социаль каршылыкларны сыйнфыйлык б-н аңлатуга юнәлтә. Сафа, Таҗи, Сәҗидә кебек төп уңай геройлар мисалында автор аларның сыйнфый үзаңнарының барлыкка килүенең һәм үсешенең сәбәбе итеп авыр тормышны һәм гаделсезлекне күрсәтә. «Мөһаҗирләр» романында Г. «Болганчык еллар» романы геройларының язмышларын яңа тарихи вазгыятьтә тасвирлый - татар крестьяннары Төркиягә күчә, революцион идеяләр татар авылларына үтеп керү сәбәпле, аларда сыйнфый үзаң уяна һәм үсеш кичерә. Бу әсәрләр Мәскәүдә 1930 да һәм 1934 тә рус теленә тәрҗемә ителеп басылалар, ләкин татар телендә дөнья күрмиләр. 1960 елларда гына романнар татар теленә (Р.Даутов һәм Я.Халитов тарафыннан) тәрҗемә ителәләр һәм Казанда «Болганчык еллар» (1976) һәм «Мөһаҗирләр» (1977) исемнәре б-н нәшер ителәләр. 1937 дә, милләтчелектә гаепләнеп, Г. кулга алына, романнарның кульязмалары конфискацияләнә һәм соңыннан югала. 1938 дә Г. атып үтерелә; үлгәннән соң аклана.

Әд.: Даутов Р. Әдипнең фаҗигасы / / Казан утлары. 1966. N 9.

*Ф.М.Мусин.*

**ГАЛИ (Галиев)** Габдулла Гали улы (20.6.1920, Лаеш өязе Шәдке а. - сентябрь 1941), шагыйрь. 1935 тә Казан. пед. ин-ты рабфагына укырга керә. «Яшел бөреләр» (1939), «Үсәбез» (1940) исемле җыентыклар чыгара, аерым шигырьләре «Алар сафта» (1961) исемле күмәк җыентыкка керә. Бөек Ватан сугышында катнаша, Украинадагы Каменец-Подольск шәһәре өчен барган сугышта һәлак була.

**ГАЛИ (Галиев)** Закир Халит улы (1902, Тәтеш өязе Ямбакты а. - 1941), әдәби тәнкыйтьче, тәрҗемәче. 1923-25, 1928-34 елларда «Кызыл Татарстан» г-тасы редакциясендә эшли (1928-32 дә җаваплы сәркәтип, 1932-34 тә баш мөхәррир урынбасары), 1932 дә «Атака» ж-лының, 1934-36 да «Кызылармияче» г-тасының баш мөхәррире, Татар пролетар язучылары ассоциациясенең (ТАПП) идарә әгъзасы, Татарстан совет язучылары берлеген Оештыру комитеты рәисе урынбасары була. 1920-30 елларда барган әдәби процесска багышланган (шул исәптән Сирин, Г.Газиз иҗатлары турында) мәкаләләр авторы. К.Горбунов, И.В.Сталин хезмәтләрен татарчага тәрҗемә итә. Нахакка репрес-

сиялана (1937), үлгәннән соң аклана (1958).

*Т.Ш.Гыйләҗев.*

**ГАЛИ (Галиев)** Мөхәммәт Вәли улы (24.3.1893, Лаеш өязе Олы Елга а. - 16.5.1952, Казан), язучы, журналист, әдәбият галиме. «Касыймия» (1910-12), «Хөсәения» (1912-14) мәдрәсәләрендә укый. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1917-19 елларда туган авылында укытучылык итә. 1919 дан Казанда. «Кызыл армия», «Эш», «Эшче», «Татарстан хәбәрләре» г-таларында, «Игенче» ж-лында эшли, Идел буе хәрби округының цензоры булып тора. 1922-24 тә «Безнең байрак», 1924-29 да «Крестьян газеты», 1929-31 дә «Кызыл Татарстан» г-таларында җаваплы сәркәтип. 1933 тә Казан ун-тын тәмамлый һәм 1939 га кадәр Казан пед.ин-тында, Казан берләштерелгән пед. техникумында, КПСС өлкә комитеты каршындагы Марксизм-ленинизм ин-тында укыта. Бөек Ватан сугышы елларында СССРның Әдәби фондының Татарстан буенча вәкиле булып, ш.у. Дәүләт музееның әдәбият бүлегендә эшли. 1946 дан СССР ФА Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. Әсәрләре 1914 тән башлап «Йолдыз» г-тасында, «Аң» ж-лында басыла башлый. «Сабан туенда» (1921), «Балалык көннәремдә» (1925), «Кала кешеләре булдык» (1928), «М.Гали әсәрләре» (1929-31) китапларына кергән хикәя һәм очеркларында рев-циягә кадәр һәм 1920-30 да авылда барган социаль үзгәрешләрне тасвирлый. «Теләнчеләр, яки бәхет эзләгәндә» (1936), «Имана» (1939), «Каюм Насыйри» (1945, Х.Уразиков б-н берлектә языла, һәм Татар академия театрында куела) пьесалары, Каюм Насыйри турындагы язылып бетми калган роман авторы. Хезмәтләре 19-20 йөз башы татар әдәбияты тарихына, Г.Каргалый, Г.Утыз Имәни, Г.Курсави, Акмулла, Г.Тукай, Дәрдемәнд, Г.Камал, С.Рәмиев, Ш.Камал, Г.Гафури тормыш һәм иҗатларына карый. «Газета укучылар өчен кесә сүзлеге» (1928), «Русско-татарский словарь» (1941) төзүче. Татар теленә И.С.Тургеневның «Аучы язмалары» («Записки охотника», 1936), Ж.Вернның «Су астында 20000 километр» («8000 лье под водой», 1938) әсәрләрен, Л.Н.Толстой, А.П.Чехов хикәяләрен тәрҗемә итә.

Әсәр.: Тормыш юллары. К., 1940; Г.Камал. К., 1941; Сайланма хикәяләр. К., 1952; Шагыйрь баскан эзләрдән. К., 1957; Сайланма әсәрләр. К., 1964.

Әд.: Гайнуллин М. Мөхәммәт Гали // Татар әдипләре (Иҗат портретлары). К., 1978; Әмирхан Р. Тыйнак талант // Татарстан. 1993. N 3; Рәмиев З. Талантлы язучы, күренекле галим // Казан утлары. 1993. N3.

*Р.У.Әмирханов.*

**ГАЛИ (Галиев)** Гомәр Билал улы (16.6.1900, Сембер губ., Буа өязе Иске Тинчәле а. - 6.7.1954), язучы, әдәбият тәнкыйтьчесе, җәмәгать эшлеклесе. Гражданнар сугышында катнаша. 1919 елдан актив рәвештә публицистик мәкаләләр һәм очерклар, революцион пафос б-н сугарылган, әдәби рецензияләр б-н матбугатта чыгыш ясый башлый (соңыннан алар «Пролетариат әдәбияты өчен көрәшкәндә» (1931) җыентыгына керә). 1921 дән Казанда. 1925 тә Татар коммунистлар ун-тын тәмамлый. 1923-24 тә Һ.Такташ һәм К.Нәҗми б-н берлектә татар совет язучыларының «Октябрь» исемле беренче әдәби оешмасын төзи. 1925-36 (өзеклекләр б-н) «Безнең юл» ж-лының баш редакторы. 1931 дән Татар китап нәшриятының әдәби секторын, Татар пролетар язучылары ассоциациясен (ТАПП) җитәкли, Татарстан совет язучылары союзын Оештыру комитеты рәистәшләренең берсе була. 1929-34 тә Казан медицина ин-тында татар теле һәм әдәбияты каф. мөдире. 1925 тә гамәли-кулланма сәнгать күргәзмәсенә Парижга җибәрелә. Анда алган тәэсирләре «Чит илләрдә» (1926) исемле китабында дөнья күрә. Дөнья күргән «Бикташир ничек эшче булды?» (1921), «Ат саклаганда» (1922), «Кубань буйларында» (1922), «Беренче мәхәббәт» (1924) беренче хикәяләре б-н үк Г. укучылар һәм әдәби тәнкыйть игътибарын җәлеп итә. Ләкин ул 1920-30 нчы елларда актив язып, татар әдәби процессына юнәлеш биреп торучы тәнкыйтьче буларак аеруча киң танылa. Иҗатында вульгар социалогизмның көчле тәэсире сизелә. Шуңа да карамастан, Г.Ибраһимов, К.Тинчурин, Һ.Такташ, Х.Туфан, М.Крымов иҗатларына багышланган мәкаләләренә тирән фикер йөртү, төгәл бәя бирү хас. 1937 дә советларга каршы юнәлтелгән милләтчелектә һәм троцкизмда гаепләнеп кулга алына. 1947 дә азат ителә, ләкин 1949 да кабат кулга алына, сөргенгә җибәрелә һәм анда 1954 тә фаҗигале рәвештә һәлак була. 1955 тә аклана.


Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1958. Ф+

Әд.: Ахунов Г. Нигез ташларын салганда (Гомәр Гали иҗаты) // Әдәби язмышлар. К., 1970; Гаташ Р. Гомәр Галинең тууына 100 ел // Казан утлары. 2000. N 6; Мусин М. Гомәр Гали турында истәлекләр. К., 2002.

*Р.Ә.Мостафин.*

*Дәвамы киләсе саннарда*

# ЭПИГРАММАЛАР



## Камил Кәримгә

**Язганнарың—камил бик,**
**Син үзең дә Камил бит!—**
**Сәхнәләргә мендең мәллә...**
**Сәнгатьтә дә калыйм, дип?!**



## Гәрәй Рәхимгә

**Әдәбият уфтанган ди:**
**—И бу язмыш... рәхимсез!**
**Мәңгелек йортына...**
**Тьфү-тьфү лә!..**
**Түрәләр йортына киткәч...**
**Калдым Гәрәй Рәхимсез!**




## Марат Закирга

**Өстеңдә—гимнастерка,**
**Аякта—ыштыр, итек.**
**Кеше куркытып йөрмәле,**
**Каләмне штык итеп!**

## Мансур Вәли-Барҗылыга

Эшләпәң—казански,
Чәчләрең—кызларски.
«Кызларски» дигәннән...
Матур-матур кызларга
Күзләрең кызгански!
Яңа исем-ат сиңа
Тач булыр сымански:
Мансур Вәли-Морҗалы!..
Юк ла...
...Мансур Вәли-Марҗалы!—
Шул хөрмәткә бер рүмкә
Тутырып салгански!





## Рашат Низамига

*(«Казан утлары»ннан—«Идел»гә китүенә, «Идел»дән кабат «Казан утлары»на кайтуына ишарәләп)*

Торалмыйсың бер урында—
Яшисең күчә-күчә:
«Казан утлары»на кайттың,
«Идел»ләр кичә-кичә.

## Равил Фәйзуллинга

*(«Газиз китабы»н укыгач)*

Әллә юри, әллә чынлап,
Башны бутады микән?
Үзе язган китап, дисәм...
«Газиз китабы» икән!



**Ләбиб ЛЕРОН** эпиграммалары
**Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН** шаржлары

Рөстәм
Галиуллин

# ХАФА

ШАЯН ХИКӘЯ

Атаулла соңгы көннәрдә туры гына кайтмый башлады. Бүген дә менә шуның аркасында Бибинур карчыкның күңел сызлануы иртәдән бирле кымтырыклап, борчып тора. Ул сызлану төш вакытлары житкәч тә басылмады. Киресенчә, йөрәк тирәсендә ниндидер корт-мазар, бөҗәк йөргәндәй, үзен сиздереп торды. Сәгате-минуты саен, үзенең жир төсенә кереп каралган, авылдагы бай хужалыкларның тавык кетәклегенә охшаган өеннән чыгып, үзе әйтмешли, кулга тотып, борын өстенә куймыйча берни дә күрмәгән күзен төбәп, авылның ин очында урнашкан зират буендагы юлны күзәтте. «Күренми бит, киребеткән жан! Картаеп сакалы агаргач... Акыл керергә вакыт бит инде!»—дип сукранды карчык һәр чыккан саен.

Ачуына буылган Бибинур карчык бар нәрсәне, һәркемне дошман күрде бүген: баш өстендә елмаеп торган кояшка—кыздырганга, чишмәгә су алырга төшеп барган күрше кызы Хәлимәгә—чиләкләрен «яман» чылтыратканга, унъяк күршесе Хәйдәргә—«кирәкмәгән вакытта» иске коймасын яңартырга тотынган өчен эләкте. Өй эчендә дә эшенең рәте -башы булмады. Йөрәге тынгысызлап торганлыктан, кулына нәрсә алса, шул төшеп китте. Яратып чәй эчә торган, тышына чәчәк рәсеме төшерелгән чынаягын да чәлпәрәмә китергәч, йоклап алыйм дип үзенең катлы-катлы матрас түшәлгән тимер башлы, асты пружиналы караватына барып ятты. Аны шыгырдатып, як-ягына әйләнгәләп ятса да, күзен йокы алмады, ахырдан, ничарадан-бичара дигәндәй, торып ук утырды.

Кабат юлны күзләргә дип тышка чыкса, шаккатты: кәтү тузаны әллә кайчан жиргә кунган, энгер-менгер авылның эченә үк кереп килә ләбаса! «Йә Аллам, кайларда йөри икән соң бу, ә? Бу вакытка тиклем калмый торган ие—нәрсәләр генә булды икән үзенә...»—дип, сукрана-сукрана, кинәт сызлый башлаган башын тотып, янә караватына кереп ауды. Бераздан аһ-ваһ килеп, кызыл эчле галушларын лаштыр-лоштыр өстерәп, янә урамга таба кузгалды. «Сукыр» күзе белән ерактан ук үзенә таба атлап килүче яшьтәше Сәлимәне танып алып, сүз башлады:

—Синеке генә гаепле бу хәлләргә! Гомер-гомергә өйдә тора, тәртипле ие. Синекенә ияреп кенә бозылды, харап булды, бичара, жан кисәгем, Атауллам минем!—диде ул, аның каршысына «йөрмәгән» аяклары белән очып диярлек килеп.

—Абау, нишләвең бу, Бибинур жаным? Атаулла да кайтмадымыни? Минеке дә юк, шуна борчылып килә идем.

—Бүген дә иртә белән синеке ияртеп китте бәгырь кисмәгемне үзем күреп калдым...

—Кайталар!—дип шатлыгыннан кинәт кычкырып жибәрде Сәлимә карчык.—Икәүләшеп кайтып киләләр бит, карале..—Бибинур карчык каш өстенә кулын куеп, карашын офыкка төбәде.

Чыннан да, зират буендагы юлдан әкрен генә, керт-керт атлап, көне буе урлашып тамагын туйдырган, Бибинур белән Сәлимәнең үз жаннарыннан да кадерле булган ике кәжә кайтып килә иде...

...Бибинур сөекле кәжәсенә кушаматны ферма мөдире Атауллага үч итеп кушкан иде...



Алия
Габделхакова

# ТАРТУ КӨЧЕ

ХИКӘЯ

Ничек итеп камырлык чәнечкеләренә кадала-кадала куактан төшүләрен дә, бакча артындагы биек койма аша сикереп чыгуларын да сизми калды малайлар. Иләмсез этнең куамы, юкмы икәне белән кызыксынып та тормыйча, чапканда алар үзләрен һәр көн иртән йөгерергә күнектергән Әлфиягә рәхмәт укыдылар.

—Кайда йөрдегез, чукынмыш малайлар? Борчылып беттек! Һәм нигә болай янып пештегез, артыгыздан шайтан куды мәллә?—дип өзгәләнгән әниләренә малайлар: «Шайтан гына булса икән»—дип, Ранилләрнең печәнлегенә менеп сыздылар. Куркудан йокылары качкан булса да, алжу үзенекен итте, башлары хуш исле печәнгә тию белән йоклап та киттеләр. Тик бу юлы йокы татлы булмады. Төне буе шайтан эте белән саташып чыкты малайлар. Җитмәсә, иртән әтиләре белән җитди сөйләшү көтә иде үзләрен.

—Бернәрсәгә дә ышанмый бу әти-әниләр... Без икебез берьюлы ычкына алмыйбыз бит инде. Бар иде бит ул эт,— дип сөйләнде Зөлфәт, «җитди» сөйләшүдән соң кулыннан камырлык энәсен каезлый-каезлый.

—Барын-бар иде дә—кем ышансын ди аңа.

—Хәзер үзең ышандыңмы инде мәктәп бакчасына НЛО төшкән дигәнгә? Минемчә, бу эт белән булган хәлне беркемгә дә сөйләми торырга кирәк.

—Беркемгә дә! —Ранил Зөлфәткә мыскыллы караш ташлады.—Әниләргә сөйләдек бит инде.

—Алар барыбер ышанмады бит. Искә алсалар да, күзгә генә күренгәндер, диярбез.

—Мин әниләргә алдый алмыйм.

—Ка-а-аян төшкән әүлия! Хәйләсез дөнья файдасыз ди, өйрәнерсең. Соңга да калабыз бугай инде. Сәгать ничә әле ул?

—Сигезенче ярты. Өлгерәбез. Бу вакытта бакчада Камиләападан башка берәү дә булмый.

—О, как раз. Без беркем дә юклыктан файдаланып этнең эзләрен тикшерергә тиеш.

*Дәвамы. Башы 5 нче санда.*

—Әлбәттә! Әйдә, алайса.

Авыл уянган. Уянган гына түгел, бөтен сулышына яши дә иде инде. Авыл кешесе эшкә иртә китә. Бу вакытта урамда мәктәптә практика үтүче балалар гына була. Соңгылары әлегә икәү—Ранил белән Зөлфәт кенә. Үз ихаталарында кайнаучылар исә шактый. Менә Ранилләрнең каршы күршеләрендә эш гөрли—өй салалар.

Кояшта янып каралган осталар түбә ябу белән мәшгуль. Зөлфәтләрнең күршеләрендә дә эш кайный. Гүзәл апа белән Әлфинә апа койма буйыйлар.

—Исәнмесез. Алла ярдәм бирсен!

—Исән булыгыз. Кая җыендыгыз әле болай иртүк,—диде Гүзәл апа, күк уртасына ук җитеп килүче кояшка күзен кысып карап.

—Практикага.

—Бетмәдемени әле ул практикагыз? Икәүләп тырышасыз бит инде,— диде Әлфинә апа шаян елмаеп.

—Тырышлыгыбыз җитми, күрәмсең, йә—көчебез.

—Кит әле, булмаганны. Безнең спортсменнарыбызның көче җитмиме? Мәңге ышанмыйм. Кичә кичке йөгерештән кайтканыгызны күрдем. Олимпийский рекорд куйдыгыз. Ренат абыегызны машинасында килеш узып киттегез. Мин авызымны ачтым да калдым. Гүзәл апага да әйттем әле.

—Күрми калдым шул. Мин тәрәзәгә капланганда һавада сез күтәргән тузан гына эленеп тора иде.

Малайлар: «Районда булачак ярышка әзерләнәбез»,— дип кенә җавап кайтара алдылар. Алар узып киткәч, күршеләре өзелгән сүзләрен дәвам иттеләр. Зөлфәт шунда асфальтка чүгәләде һәм кроссовка бауларын сүтеп җибәрде. Ранил берара Зөлфәтнең юклыгын сизмичә атлавын дәвам итте. Шактый ара үткәч кенә күреп, кире борылды.

—Ни булды тагын?

—Әй, бәйләп булмый.

Ранил: «Кит инде, кеше көлдермә!»— дияргә дә өлгермәде, Зөлфәт җиңеннән тартып аны үзенә таба иелдерде.

—Нәрсә сөйләүләрен тыңла әле,— диде ул пышылдап.

—Юл уртасында кеше сөйләшкәнне тыңлап утырыргамы? Әллә ычкынасың инде.

—Кычкырмале. Тыңла дим мин сиңа, аннан аңларсың.

Ранил теләмичә генә күрше хатыннарның сөйләшүенә колак салды.

—...Мәктәп бакчасыннан кишер урлаганнармы? И оятсызлар! Ничек куллары барган?

—Әйе, үзләре әйткәннәр. Аларны хәзер психбольниска җибәрәләр ди. Ниндидер утлы шар сөйлиләр дә утлы шар сөйлиләр ди. Өсләренә кием киертеп булмый ди. Барыбер янып бетә дип салып аталар ди.

—Һаман да тапкандагы кебек анадан тума йөриләр диме?

—Ие.

—Кайдан тапканнар соң аларны?

—Елга буеннан, әрәмәлектән.

—Хәзер мәктәп бакчасына кишер урларга кермәсләр инде—утлы шар «чишендергәч».

Әлфия апа белән Гүзәл апа көлешә башладылар, ә малайлар мәктәпкә ашыктылар.

—Мин бернәрсә дә аңламадым.

—Ә нәрсәсен аңламыйсың инде аның—мәктәп бакчасыннан кишер урлаучыларны елга буендагы әрәмәлектән анадан тума килеш табып алганнар.

—Кемнәр соң алар?

—Әй, ике алкаш инде шунда. Түбән очта икесе генә яшиләр бит әле.

—Фиргать белән Фәргатьме?

—Ие инде. Минемчә, монда Әсма әби күргән оча торган тәлинкәнең дә катнашы бар.

—Син НЛО ике кишер карагын урлап, чишендереп, киемнәрен ягып, үзләрен әрәмәлеккә төшереп аткандыр дип уйлыйсыңмы?

—Белмим әле. Минемчә, безгә мәктәп бакчасында тикшерү үткәрергә кирәк. Бәлки берәр нәрсә ачыклый алырбыз...

—Исәнмесез, Камилә апа.

—Нигә шулай иртә димме. Башка вакытта иң соңгылардан булып килә идегез бит.

—Башка көнне иртән йөгереп кайта идек,— диделәр малайлар җилкәләрен сикертеп.

—Ә бүген йөгермәдегез мени?

—Тизрәк йөгердек, Камилә апа.

—Бик дөрес эшләгәнсез, егетләр. Бик кирәк миңа бүген сезнең ярдәм. Бакчага кереп карасаң, котырган филләр йөргән диярсең.

«Котырган филләр» гаепле төстә башларын иеп Камилә апалары артыннан бакчага керделәр. Болай ук булыр дип көтмәгәннәр иде алар. Бакча кичәгегә караганда да куркынычрак иде. Күрәмсең, өченче «котырган фил» аеруча тырышып ташлаган.

Ранил сызгырып куйды, Зөлфәт тел шартлатты, бакчачы апалары исә дәвам итте:

—Күргәнегезчә, эш муеннан. Бүген иртәрәк эшли башларбыз. Менә бу җирне кеше рәтенә китерү белән кайтарып җибәрермен.

Кайтарып җибәрмәсә дә малайлар бик теләп эшләрләр иде, чөнки бу «сугыш манзарасында» аларның да өлеше бар бит һәм бу минутта аларны гаеп хисе кимерә иде. Ике кеше утыз сутый җирне берничек тә ярты көн эчендә тигезләп, түтәлләрен рәтләп, чүпләрен җыештырып, кыйшайган һәм казылган помидор-суганнарны төзәтеп, күмеп чыга алмыйлар. Әлсерәп йончыган малайлар тагын ике сәгатьтән куаклар күләгәсенә килеп аудылар.

—Җимерүе җиңел дә рәтләве авыр.

—Нәрсә эзләде икән соң ул эт, ә? Нәрсәдер эзләде бит инде ул.

—Эт нәрсә эзләсен инде—сөяктер.

—Гадәти эт. Тәмуг эте нәрсә эзләргә мөмкин?

—Тәмуг эте булса—җан эзли.

—Ә нәрсәгә аңа җан?

—Нәрсәгә икәнен үзе беләдер инде.

—Җан йөзек түгел ул, дус, җирдә ятарга.

—Йөзек? Йөзек, йөзек... Йөзек дисең инде. Ә беләсеңме... Ә бәлки ул чынлап та йөзек эзләгәндер?

—Нинди йөзек?

—Хәтерләсәң, Әлфиянең бармагында яшел ташлы йөзек бар иде.

—Йә, бар иде. Ләкин нишләсен ди эт Әлфиянең йөзеге белән?

—Ә бәлки, ул берәрсенең өйрәтелгән этедер, югалган әйберләрне табып бирә торган. Кемдер йөзеген югалткан да эзләргә этен җибәргәндер.

—Этен? Үзен генәме? Әйбер эзләгәндә дә, минемчә, өйрәтелгән этләрне дә ияртеп йөриләр.

—Ә бәлки, хуҗасының вакыты булмагандыр, ә эт шул дәрәҗәдә акыллыдыр...

—Ә бәлки, ә бәлки! —Зөлфәт Ранилгә җөмләсен тәмамларга ирек бирмәде. —Нәрсә дип баш катырабыз әле. Бүген мәктәп бакчасында засада оештырыйк. Әниләргә Айдарларда кунабыз диярбез, аларда аулак өй—әти-әнисе кунакка киткән.

—Димәк, бүген кич белән шушы урында очрашабыз.

Малайлар учка уч бәрештеләр.

Җәйнең сыек караңгысы төшеп җиргә, йортларга, агач ботакларына сарылгач,

ике шәүлә койманың песи сыймалы гына тишегеннән мәктәп бакчасына үтте. Алар койма буеннан гына барып куаклыкларга кереп югалдылар.

Малайлар әтне ярты төн көттеләр. Күктәге сирәк-мирәк йолдызлар да сүнә башлагач, аларның өметләре тәмам өзелде.

—Их, булмады бу.

—Бүген булмаса, иртәгә булыр әле.

—Нишләп Әлфия һаман кайтмый икән? —Ранил үзен ныграк борчыган мәсьәләгә күчте.

—Берәр мөһим эшләре килеп чыккандыр. Миннән тормый дип үзе әйтте бит.

—Ярар, килмәде бу убыр. —Ранил борчуын таратырга теләп теманы икенчегә борды.

—Нинди убыр?

—Элек менә шундый кара этләрдән убыр дип курыкканнар бит.

—Кызык әле бу,— диде Зөлфәт һәм аның күзләрендә очкыннар кабынды.

—Син нәрсә, Зөлфәт, ул этне чынлап та убырлар рәтенә кертмәкче буласың мәллә? Кит әле. Гап-гади эт ул. Юк, гадәти булмаган куркыныч эт. Эт кенә,— диде Ранил, «эт» сүзенә басым ясап.

Бакчада ниндидер хәрәкәт башлануы малайларны сагаерга мәҗбүр итте. Бүген малайлар көне буе рәтләгән түтәлләрне кичәге эт янә тар-мар итеп йөри иде.

Ранилнең йөрәген нәфрәт биләп алды. Бу нәфрәт куркыныч этнең гап-гади эт икәненә инану белән дә көчәйде. Кулына пәкесен кысып Ранил яшеренгән урыныннан ук күтәрелә башлаган иде дә, Зөлфәт аның футболка итәгеннән тотып өлгерде. Һәм нәкъ вакытында булды бу, чөнки Ранил дустын куркаклыкта гаепли-гаепли футболкасын ычкындырырга маташканда эттә сәер үзгәрешләр башланды. Аны башта ут йотты, эт шәүләсе сакланса да, ул тулысынча уттан тора башлады. Эт-ут кечерәя-кечерәя кеше башы чаклы шарга әверелде һәм җирдән аерылып күккә күтәрелде. Ул шул дәрәҗәдә тиз оча иде ки, хәттә җәядән аткан ук та аны куып тота алмас иде.

Малайлар утлы шарның җәйге күктә чак-чак сызылып калган эзен генә күреп өлгерделәр...

Инде җәйгә өченче мәртәбә түтәл ясаучы малайлар янына классташлары Гадилә килеп басты.

—Егетләр,— диде ул, гадәтенчә йөзенә мескен кыяфәт чыгарып, —минем йөзегемне күрмәдегезме? Бик матур, яшел ташлы.

Малайларга бер карашып алу җитте, алар шунда ук бер-берсенең ни уйлаганын аңлап алдылар: «Йөзекне эзләүчеләр саны артты. Әлфия үзе кая икән?»

—Йөзек яшел ташлы дисең инде. Мин аны өченче көн шушы урында тапкан идем. Синеке икәнен белмәдем бит, үзеңә биргән булыр идем.

—Таптың? Шушында? Кайда инде ул хәзер? Зинһар, бирә күрегез. Әбиемнеке иде, әбием төсе.

Гадиләнең әбисе бер атна элек гүр иясе булган иде. Оныгына васыять итеп шушы йөзекне калдырган, күрәмсең. Ранил йөзекнең Әлфиядә икәнлеген әйтергә дә өлгермәде, Әлфия үзе дә мәктәп капкасында пәйда булды. Ранил белән Зөлфәтнең йөзләре бердәй яктырып китте, иреннәренә елмаю кунды.

—Әлфия! Нишләп шулай озак?

—Борчыла башлаган идек инде.

—Әй, безнең әбиләргә барсаң, тиз генә кайтам димә. Кунак итә белә ул. Сагынып беттем үзегезне, күгәрченкәйләрем!— дигән сүзләр белән Әлфия ике дустын да муеннарыннан кочаклап алды.

Очрашу шатлыгыннан дуслар Гадиләнең караңгыланып киткән йөзен дә күрмәделәр.

—Сәлам, Әлфия. Хәлләр ничек?— диде ул, сүзләрен теш араларыннан гына кысып чыгарып.

—Ә, Гадилә. Күрми дә торам икән. Әйбәт. Ә үзеңнең ничек?— диде Әлфия, классташының ачулы тавышына игътибар итмичә. Ул Гадиләнең үзен күрәлмавының сәбәпләрен белә иде. Гадилә, әлбәттә, бер ел эчендә сыйныфта лидерга әйләнә алган яңа кыздан көнләшә иде. Әлфия нинди генә яхшы кыз булмасын, Гадилә аның начар якларын гына күрде.

—Әйбәт иде әле,— диде Гадилә.—Кунакта булдың мәллә, күренмәдең.

—Әйе. Әбиләргә барган идек. Син үзең дә берәр җирдә кунакта булдыңмы соң. Каникулның бер ае үтте бит инде.

—Кунак кайгысы юк әле. Әбине дә җирләгәч...

—О, гафу. Кайгыңны уртаклашам.

Малайлар кызларның сөйләшүләрен тыңламыйча да, ишетмичә дә тутәл ясауларын дәвам иттеләр, һәрберсе үз уйларына баткан иде. Ранил ничек итеп Гадиләнең йөзеген Әлфиядән алып бирү турында, Зөлфәт исә убыр эт турында уйлады.

—Йөзегем кайда диден син, Ранил?

Ранилга уңайсыз булып китте. Бер яктан карасаң, Гадиләнең әбисенең төсе, икенче яктан, Әлфиягә, бүләк ителгән йөзек. Ранил каушап сүз табалмый торганда Зөлфәт аңа ярдәмгә килде:

—Иртәгә алып килеп бирербез, яме. Бүген үк кирәк булмаса.

Гадиләнең йөзе ачулыдан сөйкемлегә әйләнде. Ул, шушы сүзләрне генә көткәндәй:

—Ярар, ярар. Иртәгә алып килерсез. Алай ук ашыгыч түгел,— диде, аның сөйләве гаепле кешенең аклануына охшап китте. —Ә сез бүген су керергә төшәсезме?

—Бәлкем төшәрбез дә.

—Мин дә бүген елга буена төшмәкче идем. Мине дә ияртмәссез микән? —Кызның бит очларына алсулык йөгерде.

Әлфиянең аның белән дошманлашасы килми иде. Ул аңа, күптәнге дустына эндәшкәндәй:

—Гадилә, матурым, әлбәттә, ияртәбез—диде. Ләкин Гадилә генә аның ягымлылыгына тиешенчә җавап бирмәде. «Сиңа әйтмәдем лә» диган караш ташлады да, малайлар белән хушлашып читкә китте.

—Гадилә сине яратмый,— диде Ранил.

—Бу—йомшартып әйтү,— диде Зөлфәт.

—Моның сәбәпләре бар. Гадиләне гаепләү урынсыз. Йә, ярар, миннән башка ниләр эшләдегез, сөйләп җибәрегез әле.

—Нишлик инде. Йөрдек шунда юләр сатып.

—Күп саттыгызмы?

—Җитәрлек. Ә җитди сөйләшсәк, монда бик сәер хәлләр булды бит әле.

Һәм малайлар бәйнә-бәйнә кызга ул югында булган хәлләрне сөйләп бирделәр. Алар Әлфиянең йөзендә курку, шаккату, һич югы сәерсенү күрергә өметләнгәннәр иде. Ләкин кыз тыныч калды, бары тик зөбәрҗәт күзләрендә генә сәер очкыннар кабынды.

—Һәм сез аны убыр дип уйлыйсызмы?

—Йөз процентка.

—Йөз үк димәс идем. Сиксән биш-туксан.

—Сез безнең заманда җыен җен-парилар, убырлар барлыгына ышанасызмы? Китегез әле, көлдермәгез. Сабый да түгел инде үзегез.

Әлфиянең сүзләре дусларына авыр тәэссир итте.

«Ни булган моңа? Әллә әбисеннән алмаштырып кайтарганнармы? Без бит бер-беребезгә һәрвакыт ышана идек»— дип уйладылар алар.

—Син безгә ышанмыйсыңмыни? —Зөлфәтнең йөзендә дә, тавышында да үпкә чагыла иде.

—Сезгә ышанам, ә сезнең күзләрегезгә—юк. Төнлә күзгә нәрсә күренмәс. Сезнең гап-гади этне дә убырга санавыгыз бик сәер миңа.

—Ул гап-гади эт түгел иде! —Ранил ачуын сиздермәскә тырышса да, тавышы калтырап чыкты.

—Йә, ярар, кугәрченкәйләрем. Мин бит болай гына. Мин ышанам сезгә, ышанам.

Кызның сүзләре малайларны тынычландырмады, киресенчә, үртәде генә. Ул сүзләр бу уңайсыз сөйләшүне тизрәк тәмамлар өчен генә әйтелгән кебек тоелды аларга. Әлфия белән аралашудан, аның янында булудан гына да күңел рәхәтлеге ала торган малайларга бу сөйләшүдән соң йөрәкләренә таш бастыргандай авыр булып калды.

—Әллә Әлфия берәр нәрсә белә микән? Без белми торганны дим,— дип сүз башлады Ранил Зөлфәт белән икәү өйләренә кайтып барганда. Әлфия Камилә апа белән сөйләшәсем бар дип калган иде.

—Бу безнең Әлфия түгел. Алмаштырганнар аны. Теге оча торган тәлинкәләр Әлфияне урлаганнар да, берәр спецагентларын Әлфия кыяфәтенә керткәннәр.

—Әллә нәрсә сөйләмәле, Зөлфәт. Ни дисәң дә, бу безнең Әлфия.

Балалар кайтып беткәч, Камилә апа бакчаны тагын бер урап килергә булды. Койма буенда үсүче куаклар төбендә җиргә ботак белән рәсем ясап утыручы Әлфияне күреп аптырап китте:

—Бәрәч, Әлфия! Нишләп утырасың монда, бөтенесе дә кайтып беттеләр бит инде. Ранил белән Зөлфәт тә кайтып киттеләр бугай.

—Әйе, Камилә апа, мин аларга кайта торырга куштым. Үземә генә уйланырга кирәк иде, ә безнең мәктәп бакчасыннан да тынычрак җир юк.

—Анысы дөрес. Кишер урлаучылар да булмагач, хәзер бөтенләй тынычлап калды, Ходайның рәхмәте. Йә, ярар, син утыр алайса, мин чия куакларын карап киләм әле.

Камилә апа үзе буе куаклар арасына кереп югалгач, Әлфия яңадан үз уйларына чумды. Уй йомгагы мондый фикер белән очланды:

«Минем янга киләчәк әле ул».

*Ахыры киләсе санда*

---

# Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасынын страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)




*Җырчының 70 еллык юбилей кичәсендә. Минтимер Шәймиев һәм Илһам Шакиров. 2005 ел.*



*Мирсәй Әмир һәм Сергей Михалков. 1965 ел.*



*Дуслар очрашкан җирдә — иҗат йортында. Сулдан уңга: Муса Гали, Раул Мирхәйдәров, Мостай Кәрим. Үткән гасырның 80 нче еллары.*



*Кызыклы халәт. Фатыйх Хөсни (сулда) һәм Шәукәт Галиев. 1974 ел.*



*Шагыйрь Рәниф Шәрипов. 2000 ел.*



*Әнәс Хәсәнов (сулда) һәм Галимҗан Латыйп. Үткән гасырның 80 нче еллары.*

## ЯЗ. ШИГЪРИЯТ. ТУКАЙ.

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның туган көненә һәм Туган тел бәйрәменә багышланган күптөрле чаралар республика күләмендә киң җәмәгатьчелек катнашында үткәрелә торган зур тантанага әверелде.

Ин әүвәл Г. Тукайның бакыйлыкка күчкән көнендә Казанның Яңа Татар бистәсе зиратында хәтер яңарту мәрасиме булды. Искә алу җыены алдыннан шагыйрь каберенә чәчәкләр куелды һәм аның рухына дога укылды. Биредә ул көнне Г. Тукайга багышланган шигырьләр дә, аның шәхесен зурлаган ихлас бәһаләү сүзләре дә яңгырады.

* * *

Быел Шигърият һәм Туган тел бәйрәме кысаларында беренче мәртәбә буларак, республикабызның Тукай районында «Тукай көннәре» үткәрелде. Район башлыгы Хөрмәтуллин Таһир инициативасы белән үтте ул чаралар. Очрашуларда Язучылар берлеге рәисе урынбасары Ә. Закиржанов, язучылар Р. Батулла, В. Имамов, Р. Бәшәров, Х. Җәләй һ. б. катнашты. Мәдәният йортларында һәм мәктәпләрдә оештырылган очрашулар һәр ике як—әдәбият сөючеләр өчен дә, язучылар өчен дә файдалы булды.

* * *

Менә 13 ел инде апрель аенда Балтач районының Субаш авылы клубында Г. Тукайның туган көненә багышланган әдәби-музыкаль бәйрәм үткәрелә. Быелгы тантанада Татарстан Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов, шулай ук Р. Мостафин, К. Кәримов, Балтачта яшәп иҗат итүче каләм әһелләре Г. Мөхәммәтшин һәм Р. Шәрәфиев катнашты. Очрашуга бөтен районнан укытучылар, әдәбият сөючеләр һәм иҗат белән шөгыльләнүче балалар җыелган иде. Тантанада иҗат конкурсында җиңүчеләргә һәм иң күп китап укучыларга бүләкләр тапшырылды. Аннары шигърият бәйрәмендә катнашучылар Г. Тукайның Сасна Пучинкәсе зиратында җирләнгән газиз әнисе Бибимәмдүдә абыстайның каберенә чәчәкләр салып, аның рухына дога багышладылар.

* * *

Һәрвакыттагыча, Арча районы бөек якташының туган көненә аеруча хәстәрле рәвештә әзерләнгән. Бәйрәмдә катнашу өчен башкалабыздан Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов житәкчелегендә бер төркем каләм әһелләре килде. Кунаклар быел чагыштырмача күбрәк булды, чөнки алар арасында Идел буе республикалары язучыларының һәм тәрҗемәчеләренең Казанда үткәрелгән форумында катнашучылар—Мәскәү, Башкортстан, Чуашстан, Удмуртия, Мари Иле вәкилләре дә бар иде. «Тукайның туган ягы минем өчен Ясная Поляна, Михайловское һәм башка изге урыннар кебек үк кадерле,—диде «Дружба народов» журналының баш мөхәррире А. Эбаноидзе Яңа Кырлай музей комплексында ясаган чыгышында.—Алар булган чакта күңелдә ышаныч та яши: иншалла, илебез һәм мәдәниятебез һәртөрле бозыклыктан, үз файдасы өчен генә тырышучылардан өстен калыр. Ә Габдулла Тукай музеенда алган тәэсирләрне, шагыйрьнең икенче бер бөек татар Бакый Урманче тарафыннан эшләнгән сынына соклануымны йөрәгемдә гомер буе саклармын».

Арча үзәгендәге мәйданда үткәрелгән Шигърият бәйрәмендә катнашучыларны муниципаль район башлыгы А. Назиров сәламләде. Аннары Татарстан Дәүләт Советының мәгариф, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, шагыйрь Р. Вәлиев, Россия Шигърият академиясе президенты В. Устинов, Башкортстан, Чуашстан, Удмуртия, Мари Иле язучылар оешмалары җитәкчеләре һ. б. чыгыш ясады. Бәйрәмдә яңгыраган шигырьләр җыр, музыка белән аралашып барды. Арча педагогика көллиятендәге Татар алифбасы музее белән танышу да төрле төбәкләрдән җыелган кунаклар күңелендә онытылмас тәэсир калдырды.

* * *

Сөекле шагыйребезнең туган көнендә—26 апрель иртәсендә башкалабыз үзәгендәге Г. Тукай һәйкәленә чәчәк салу мәрасимендә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Президент Аппараты җитәкчесе Ю. Камалтынов, Премьер-министр урынба-

сары—мәдәният министры З. Вәлиева, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Ратникова, халык депутатлары, әдәбият һәм сәнгать әһелләре катнашты.

***

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасы янындагы Г. Тукай һәйкәле алдында үткәрелгән Шигърият бәйрәмен кереш сүз белән Язучылар берлеге рәисе, шагыйрь И. Ибраһимов ачып җибәрде. Аннары бәйрәмгә җыелучыларны Премьер-министр урынбасары - мәдәният министры З. Валиева сәламләде һәм Президент М. Шәймиевнең 2007 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турындагы Указын игълан итте, яңа лауреатларга иҗат уңышлары һәм саулык-сәламәтлек теләде. Шуннан соң быелгы бүләк ияләре: шагыйрь Разил Вәлиев, композитор Рәшит Калимуллин, сынчы-рәссам Рада Нигъмәтуллина (кызлары Изабелла һәм Марина белән бергә), иҗатларының югары дәрәҗәдә бәяләнүе өчен, җәмәгатьчелек алдында ихлас рәхмәт сүзләрен белдерделәр.

Шигърият бәйрәмен күренекле шагыйрь Рәдиф Гаташ алып барды. Тантанада шагыйрьләр Р. Фәйзуллин, Ш. Галиев, Р. Әхмәтҗан, Р. Миңнуллин, Л. Шагыйрьҗан, С. Гәрәева, Х. Әюп, З. Мансуров, И. Гыйләҗев, Р. Газизов, Г. Морат, Р. Зәйдулла, Л. Лерон, Г. Садә, Б. Дурбелмәз (Төркия), С. Малышев, Ф. Бәйрәмова, Н. Сафина, Ш. Җиһангирова, Ф. Тарханова, Л. Газизова, Ф. Солтан, Л. Янсуар, Ч. Зариф, О. Левадная һ.б. чыгыш ясады. Шигърият бәйрәмендә Р. Сәхәби һәм аның оныгы Н. Сәхәби, И. Биктаһиров, А. Габетдинов, Б. Насыйрова башкаруында Г. Тукай сүзләренә язылган җырлар, шулай ук халык көйләре яңгырады, 5 яшьлек Ч. Хаҗиева исә бөек шагыйребезгә багышланган шигырь укыды.

***

Шул ук көнне Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасы янында Г. Тукайның туган көненә багышланган бәйрәм концерты булды. Инде байтак еллар дәвамында оештырыла торган әлеге тантана татар теленә—шагыйрьләр теленә мәдхия җырлау төсендә узды.

### БӨЕК ӘДИПНЕ ХӨРМӘТЛӘП

Республикабыз җәмәгатьчелеге, галимнәр татарлардан иң беренче булып Хезмәт Герое дигән мактаулы исемгә лаек булган классик әдибебез Галимҗан Ибраһимовның тууына 120 ел тулуны зурлап билгеләп үтте. Татарстан фәннәр академиясенең шушы бөек шәхес исемен йөрткән Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында «Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр» дигән темага фәнни-практик конференция булып узды. Аның эшендә Төркия, Әзәрбайҗан, Россия (Башкортстан, Удмуртия, Чуашстан, Мари-Иле, Мәскәү, Симферополь) һәм Татарстан галимнәре, җәмәгать эшлеклеләре, мәгариф хезмәткәрләре катнашты.

Г. Ибраһимов турында роман-трилогия язган башкорт галим-язучысы С. Поварисовның бу әсәрләре өчен ничек материал туплавы һәм трилогияне язу тарихы турындагы чыгышы конференциядә катнашучыларда аеруча зур кызыксыну тудырды. Ул «Г. Тукай татарның шигърият Пәйгамбәре булса, Г. Ибраһимов проза Пәйгамбәре»,—дип, классигыбызга бик зур бәя бирде.

Конференциядә катнашучыларга Г. Ибраһимовның әдәби эшчәнлеген, тормыш юлын чагылдырган буклетлар, секцияләрдә сөйләнгән доклад текстлары җыентыгы, язучының портреты төшерелгән календарь һ.б. бүләкләр таратылды.

***

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Г. Ибраһимов истәлегенә багышланган тантаналы кичә булды. Анда ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева һәм Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Илфак Ибраһимов чыгыш ясады. Г. Камал театры артистлары бөек әдип тормышын чагылдырган махсус спектакль күрсәтте.

### «ЯҢА ТАТАР ПЬЕСАСЫ—2006»ГА ЙОМГАК

Инде дүртенче ел рәттән татар драматургиясен үстерү, татар театр сәнгатен баету максатыннан Г. Камал исемендәге театр, ТР Мәдәният министрлыгы, ТР Язучылар берлеге, «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе, «Казан утлары» журналы, «Татарстан яшьләре» газетасы белән берлектә «Яңа татар пьесасы» конкурсын уздыра. Билгеле булганча, авторлар конкурска сәхнәдә куелмаган, матбугатта басылып чыкмаган һәм узган еллардагы конкурсларда катнашмаган пьесалар тәкъдим итәргә тиеш.

2006 елгы конкурста барысы 31 пьеса катнашып, 15е икенче турга узды. Жюри әгъзалары сынавын узганнан соң, пьесалар саны 7 гә калды. Апрель азагында барлык каләм ияләре дулкынланып көтеп алган вакыйга булды: конкурсның нәтиҗәләре игълан ителде. Туфан Миңнуллин «Мулла» һәм «Дивана» пьесалары өчен ТР Мәдәният министрлыгының махсус призы—Гран-прига һәм икенче премиягә лаек булды. Беренче премия «Суган чәчәге» пьесасы өчен Казан мәдәният һәм сәнгать академиясе студенты Илгиз Зәйниевкә бирелде. Өченче премия иясе—Мөслимдә яшәүче прозаик, драматург Фоат Садриев (пьеса «Тәрәзәгә егет килгән» дип атала). Кызыксындыру премиясенә лаек булган авторлар: Ләбиб Лерон («Күгәрчен»),

Рәдиф Сәгъди («Бакчасарай гөлләре»), Мәскәүдән Нәзифә Кәримова («Ак эрем чәчәге»).

Нәтиҗәләр билгеле булганнан соң, «Яңа татар пьесасы-2007» бәйгесе башланып китү хакында да игълан ителде. Яңа бәйге нигезләмәсендә яңалык та бар. Беренчесе—яше 35 тән артмаган авторлар өчен махсус номинация билгеләнә: җиңүчегә Туфан Миңнуллин премиясе биреләчәк.

### БАШКАЛАБЫЗ КҮРКЕ

Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концерт залының беренче түгәрәк юбилее. Моннан ун ел элек гранит белән тышланган баганалы, баскычларына ак мәрмәр таш җәелгән, утырыр урыннары затлы, ипле, дөнья музыка сәнгатенең иң күренекле иҗаткәрләре дә иркенләп, илһамланып чыгыш ясардай бина пәйда булды. Аның сәхнәсе түрендә Зур концерт залының «йөрәге» саналырлык 59 регистрлы орган тора. Биредә700 тамашачы сыярлык төп зал, 70 урынлык камера залы бар.

Бина конструктор В. Абрамов, архитекторлар В. Логинов белән Е. Прокопьев проекты нигезендә һәм «ВЕЛП» архитектура остаханәсенең иҗат төркеме катнашында төзелде. Проект авторларының шушы хезмәте 2000 елда Россия Федерациясенең әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге Дәүләт бүләге белән бәяләнде.

Бөтен Европада иң затлылардан саналган органны халыкка күрсәтүдә РФнең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисты, РФ Дәүләт премиясе лауреаты, Казан дәүләт консерваториясе ректоры дрофессор Рубин Абдуллин күп тырышлык куя. Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе, Г. Тукай исемендәге Татар Дәүләт филармониясе, Ш. Монасыйпов җитәкчелегендәге Татарстан Республикасының дәүләт кыллы квартеты, В. Спиваков җитәкчелегендәге «Мәскәү виртуозлары» оркестры, М. Плетнев җитәкчелегендәге Россия милли оркестры, В. Гергиев җитәкчелегендәге Мариин театры оркестры, О. Лундстрем җитәкчелегендәге Биг-бэнд коллективлары, Николай Петров (фортепиано), Мишель Шапюи (орган), Вадим Репин (скрипка), җырчылар Елена Образцова, Любовь Казарновская, Вахтанг Кикабидзе һәм башка бик күпләр бирредә чыгыш ясауны үзләре өчен зур мәртәбә дип саный.

Бирредә шулай ук үзебезнең атаклы язучы-шагыйребезнең, гомумән, сәнгать әһелләренең юбилей тантаналары, иҗат кичәләре еш үтә.

Зур концерт залы—концерт мәйданчыгы гына түгел әле ул, ә бәлки республикабызның мәдәни һәм сәяси үзәге дә. Аның көндәлек яшәү һәм киләчәк үсеш мәсләге җәмгыятебездәге төрледән-төрле мәнфәгатьләрнең бергә кушылуын булдыруга юнәлтелгән. Иҗтимагый әһәмиятле вакыйгалардан «Көмеш җеп» һәм «Рус силуэты» Бөтенроссия мода бәйгеләре, 1999 елда шахматта хатын-кызлар арасындагы Дөнья чемпионатының ахыргы матчы - Алисә Галлямова белән Се Цзюн уены, «Алтын мөнбәр» Халыкара мөселман киносы ачылу тантанасы, сәяси вакыйгалардан Икенче Бөтендөнья татар корылтае, Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиевнең инаугурациясе тантаналары (2001 ел, 2006 ел) бирредә үткәрелү Зур концерт залының җәмһүриятебез күрке саналуына бик саллы дәлилләр.

Зур концерт залы ачылганнан бирле аның «хуҗасы»—директоры булып шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Мансур Шиһапов эшли.

### ХӘЙРИЯ ЕЛЫНДА ИГЕЛЕКЛЕ ГАМӘЛЛӘР

С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында балалар музыка мәктәпләрендә һәм махсус урта сәнгать уку йортларында укучы иң талантлы балаларга Мәдәният министрлыгының махсус стипендияләре тапшырылды. Стипендиатларга бүләкне Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева тапшырды.

Мәдәният министрлыгы стипендиатлары саны елдан-ел арта бара, быел аларның саны 40ка житте. Стипендиянең күләме дә элеккечә түгел—ул хәзер махсус урта сәнгать уку йортлары укучыларына 1 меңәр сум, ә балалар музыка мәктәбе укучыларына 500әр сум күләмендә бирелә.

Әлеге максатта Алабугада төзелгән «Махеев» хәйрия фондының зур матди ярдәм күрсәтүен дә әйтергә кирәк. Бу фонд һәр стипендиатка 10ар мең сум акча бүлеп бирде. Моннан тыш, Казан музыка училищесының 2 нче курсында укучы Алелия Фәйзуллинага махсус стипендия билгеләде. Шушы ук фонд Казан дәүләт консерваториясе каршындагы махсус урта музыка мәктәбенең талантлы укучысы Зәринә Бикмуллинага да зур ярдәм күрсәтте. Ана дәвалану өчен 4500 доллар акча бүлеп бирелде.

Яңа стипендиатларны бүләкләү тантанасында узган еллардагы җиңүчеләр дә катнашты. Алар һәрберсе тамашачыларга үз талантын күрсәтте. Мәскәү дәүләт консерваториясе каршындагы үзәк музыка мәктәбе укучысы Руслан Сәйфи, Казан дәүләт консерваториясе каршындагы махсус урта музыка мәктәбеннән Марина һәм Максим Сабельниковлар, Мәскәү дәүләт консерваториясе студенты Рената Латыйпова һ. б.ларны тамашачы сәхнәдән алкышлап озатты.

### ИҖАТ КИЧӘСЕ

Республиканың Г. Тукай һәм М. Җәлил исемендәге дәүләт премияләре лауреаты, шагыйрь Зөлфәт үзенең укучыларын Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына җыйды. Мәдәният министры урынба-

сары Айрат Жаббаров ана Президент М. Ш. Шәймиев Указы белән бирелгән «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнүе хакында ирештерде. Шагыйрьнен каләмдәшләре анын шигырьләрен укыды. Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов Зөлфәт Маликовка анын «Гомер бер генә, сөю мәңгелек» дигән сүзләре язылган тугра бүләк итте. Юбилярны якташлары, хезмәттәшләре, театр коллективлары тәбрикләде. Шагыйрь сүзләренә язылган җырларны Татарстанның халык артистлары Шамил Әхмәтҗанов, Георгий Ибушев, Татарстаннын атказанган артисты Рөстәм Закиров һәм башка сәхнә осталары башкарды. Ул көнне тамашачы Зөлфәтнен «Ходай сулышы» дигән яна китабы белән дә танышты. Шагыйрь аларның кайберләрен үзе укып күрсәтте.

Кичәне Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Луара Шакирҗанова белән Татарстаннын халык артисты Хәлим Җалалов алып барды.

*P.S: Ни кызганыч, бу кичә анын үзе исән чактагы соңгы иҗат тантанасы булган икән.*

## РОССИЯ МИЛЛИ ОРКЕСТРЫ КОНЦЕРТЫ

Казанда РФнен халык артисты Михаил Плетнев җитәкчелегендәге Россия Милли оркестры концерты булып үтте. Концерт алдыннан уздырылган матбугат очрашуында М. Плетнев болай дигән иде: «Архангельскида тусам да, Казанны мин үземнен туган ягым дип санаим. Бу—минем балачагым шәһәре, монда мин музыка белән шөгыльләнә башладым. Казанны һәрвакыт яхшы яктан гына исемә төшерәм һәм бирегә һәрчак шатланып киләм».

С. Сайдашев исемендәге Зур концерт залындагы чыгышын оркестр татар композиторлары әсәрләреннән башлады. Н. Җиһановның «Нәфисә» увертюра-поэмасы һәм Р. Кәлимуллинның «Симфоник фрескалар»ы яңгырады. Аннан сон атаклы пианист Денис Мацуев, оркестрга кушылып, С. Рахманиновның Паганини темаларына рапсодиясен башкарды.

Икенче бүлек алдыннан сәхнәгә Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева күтәрелде һәм музыка үсешенә зур өлеш кертканә өчен М. Плетневка «Татарстан Республикасынын халык артисты» дигән мактаулы исем бирү турында Президент Минтимер Шәймиевнен Указын игълан итте.

## БАШКАЛАДА БАШ МӨГАЛЛИМ

Казан мәгариф идарәсе башлыгы итеп Илсур Гәрәй улы Һадиуллин билгеләнде. Ул 1964 елда Балык Бистәсе районынын Таулар авылында туган. Казан педагогия институтын тәмамлап, биология һәм химия укытучысы белгечлеге алган. Мона кадәр Казан шәһәренен 71 нче мәктәп директоры, мәгариф министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары, Мәгарифне үстерү институты ректоры булып эшләде.

## ИЖ БУЕНА СӘФӘР

«Казан утлары» журналынын баш мөхәррире, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин җитәкчелегендә бер төркем язучылар—журналнын баш мөхәррир урынбасары Рафикъ Юныс, бүлек мөдире Рәдиф Сәгъди һәм «Мәдәни җомга» газетасынын баш мөхәррир урынбасары Газинур Морат Ижау, Әгерҗе якларында әдәби очрашуларда булып кайтты. Алар «Казан утлары»нын мен саны чыгу уңаеннан дөнья күргән «Сүнмәс утлар балкышы» дигән китапны тәкъдир итү кичәсендә катнашты. Кичә Ижауның «Спартак» мәдәният сараенда узды. Анда Удмуртия башкаласынын татар җәмәгатьчелеге, шулай ук җирле язучылар Р. Баттал, З. Нуретдин, И. Биектаулы, Удмуртия Язучылар берлеге идарәсе рәисе Е. Волков, Удмуртиянен татар милли-мәдәни мохтәрияте рәисе И. Шәрипов, Татар иҗтимагый үзәге рәисе Ф. Мирзаянов катнашты һәм чыгыш ясады.

Шул ук көнне кичен Татарстан кунаклары Әгерҗе районы Кичке Таң авылы мәдәният йортында әдәбият сөючеләр белән очрашты. Очрашуда Әгерҗе муниципаль районы башлыгынын социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Равия Лутошкина, район мәдәният бүлеге мөдире Фәез Мусин катнашты.

## ГАЛИҖӘНАП КИТАП БӘЙРӘМЕ

Узган елнын апрель аенда Татарстан китап нәшрияте Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында «Китап бәйрәме»н зурлап үткәргән иде. Быел да ул шушы традицияне дәвам итә. Быел ул бөтен республика күләмендә уздырыла.

«Китап бәйрәме» Әлмәт, Зәй, Бөгелмә шәһәрләрендә булып үтте инде. Әлеге чараларда Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакиров һәм нәшриятнын баш мөхәррире, шагыйрь Рафис Корбан җитәкчелегендәге делегация катнашты. Делегация составында язучылар Мөсәгыйт Хәбибуллин, Резеда Вәлиева, Рабит Батулла, Марсель Галиев, Камил Кәримов, Хәбир Ибраһим, Данил Салихов, Асия Юнысова, җырчылар—Зөһрә Сәхабиева, Георгий Ибушев, Нурзадә, Фердинанд Сәлахов, баянчы Рафинат Сәлаховлар бар иде. Алар өч шәһәрнен дә татар гимназияләрендә, үзәк китапханәләрдә очрашулар үткәрде, Әлмәтнен гарип балалар интернатында, ятим балалар йортында, Бөгелмәнең техник көллиятендә, Татар иҗтимагый үзәгендә булды.

Татарстан китап нәшрияты очрашу үткән һәр оешмага 200дән артык китап бүләк итте. һәр очрашу, һәр сәфәр шәһәр мәдәният са-

районнарында гөрләп узган күнелле «Китап бәйрәме» белән тәмамланды. Анда Әлмәт театры артистлары да катнашты.

Нәшрият директоры Дамир Шакиров үз чыгышында искәртеп үткәнчә, быел беренче татар басма китабы дөнья күргәнгә 285 ел. Алда әле безне зур чаралар көтә. Сентябрь аенда Казанда Халыкара китап ярминкәсе узачак һәм Г. Камал театрында зур бәйрәм үткәреләчәк.

## ГЕРМАНИЯДӘ ТАТАР ЗИРАТЫ ТӨЗЕКЛӘНДЕРЕЛӘ

ТР Президенты Минтимер Шәймиев «Татарстан» журналы һәм Германиянең «Татарлар Дойчланд» берлегенең Беренче бөтендөнья сугышында Германиядә әсирлектә һәлак булган татар хәрбиләренең зиратын төзекләндерү буенча хәйрия акциясен хуплады.

«Татарстан» журналының баш мөхәррире Р. Фәттахов раславынча ТР Хөкүмәтеннән 5 мең евро редакциянең хәйрия хисабына күчкән инде. Ул төп мемориаль ташны торгызу, зиратны төзекләндерү эшләренең беренче этабын башкару өчен тотылачак. Бүген ташландык хәлдәге зиратта безнең берничә йөз ватандашыбыз җирләнгән.

## ПРЕЗИДЕНТНЫҢ РӘХМӘТ ХАТЛАРЫ

Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, татар әдәбиятын үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен язучы Латыйпов Кави Таһир улына (Кави Латыйп), язучы Кожевников Лев Афанасьевичка Татарстан Республика Президенты М. Шәймиевнең Рәхмәт хатлары тапшырылды.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

***

Мәдәният өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләгәне өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире **Родионов Григорий Васильевичка** (Гәрәй Рәхимгә) Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Язучылар берлеге идарәсе рәисе **Ибраһимов Илфак Мирза улына** (Мөхәммәт Мирзага) «Татарстан Республикасының атказанган сәнгатькәре» дигән мактаулы исем бирелде.

***

Матбугат өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе нәтиҗәле эшләгәне өчен «Татарстан яшьләре» газетасының баш мөхәррире **Исмәгыйль Салмән улы Шәрәфиевкә** Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

Май аенда Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, тәрҗемәче, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Фәния Гариф кызы Гайнанова** вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Туган ягым—Татарстан.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Альберт Хәсәнов**.



# ЗӨЛФӘТ

**(Дөлфәт Госман улы Маликов)**

Татар милли мәдәнияте зур югалтуга дучар булды: 2007 елның 15 маенда озакка сузылган каты авырудан соң күренекле шагыйрь, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Зөлфәт (Дөлфәт Госман улы Маликов) вафат булды.

Дөлфәт Маликов 1947 елның 3 гыйнварында Татарстан АССРның Мөслим районы Яна Сәет авылында колхозчы гаиләсендә туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, 1965-1969 елларда Казан дәүләт университетының филология факультеты татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. Ә 1969 елдан журналистлык эшендә: «Чаян» журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр, аннары Мәскәүнең М. Горький исемендәге Әдәбият институтының икееллык Югары әдәби курсларын тәмамлагач, «Яшь ленинчы» газетасы хезмәткәре. 1983 елдан гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул «Чаян» журналында эшләде.

Зөлфәтнең беренче шигырьләре студентлык елларында ук дөнья күрә. Шагыйрьнең «Язмышлар ярында» исемле беренче китабы 1971 елда Хәсән Туфанның кереш сүзе белән чыга. Әдәби тәнкыйть инде беренче басмаларыннан ук шагыйрьнең якты талантын, шигырьләренең камил формасын һәм лиризмын билгеләп үтә.

Зөлфәтнең аннан соңгы иҗаты, күпсанлы поэтик әсәрләре—гражданлык, лирик шигырьләре, поэма, балладалары «Утлы бозлар», «Адашкан болыт», «Ике урман арасы», «Йөрәгемне былбыл чакты» һәм башка җыентыкларында тупланып чыгып, киң җәмәгатьчелек тарафыннан яратып кабул ителде.

Зөлфәт күпкырлы талант иясе иде. Дөнья драматургиясенең бөек классиклары Шекспир, Лопе де Вега, Шиллер пьесалары Г. Камал исемендәге театр сәхнәсендә аның тәрҗемәсендә куелды. Ул—шулай ук курчак театры өчен пьесалар, «Мәкерле песи» исемле беренче татар балалар операсының либретто авторы да.

Зөлфәт—халык күнеленә кучкән гүзәл җырлар авторы. Ул чын-чынлап халкыбызның яраткан шагыйре иде. Татар халкының язмышы, аның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге әдип иҗатында төп урынны алып торды. Зөлфәтнең шигърияте миллионлаган укучысын тирән дулкынландырып, аларның йөрәгенә үтеп керде.

Шагыйрьнең иҗаты дәүләтебез тарафыннан югары бәяләнде. Ана «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде. «Мәкерле песи» операсына язылган либреттосы өчен Зөлфәт республиканың М. Җәлил исемендәге бүләгенә, «Ике урман арасы» һәм «Йөрәгемне былбыл чакты» китаплары өчен Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. Татар әдәбияты үсешенә керткән зур өлеше өчен 2007 елда шагыйрь Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

Талантлы шагыйрь Зөлфәтнең якты истәлеге халык күнелендә мәңге сакланыр.


**М. Шәймиев, Ф. Мөхәммәтшин, Р. Миңнеханов, Ю. Камалтынов, З. Вәлиева, И. Метшин, Р. Хәбипов, И. Ибраһимов, Р. Зәкиев.**

# Яңа китаплар




**Аяз Гыйләжев:** Истәлекләр / Төз. И. Гыйләжев.—Казан: Татар. кит. нәшр.: 2006.—271 б. Тиражы—3000 данә.

Аяз Гыйләжев кыю фикерле талантлы язучы буларак, әдәбиятның төрле өлкәләрендә—прозада, драматургиядә, публицистика һәм эпистоляр жанрда—зур ижади мирас калдырган шәхес. Тормыш юлы да бик тә гыйбрәтле: фаҗигале һәм сөенечле вакыйгаларга бай. Бу китапта биш ел элек арабыздан киткән халык язучысы А. Гыйләжев турында истәлекләр, аның иҗаты һәм сәхнәгә куелган әсәрләре хакында сөйләүче мәкаләләр (алар иллегә якын) белән бергә үзенең автобиографик язмалары һәм шигырьләр дә урын алган. Истәлекләр төрле елларны чагылдырган фоторәсемнәр белән бизәлгән. Кереш сүзне язучының улы—тарихчы-галим Искәндәр Гыйләжев язган.




**Бикә Рәхимова.** Җайдак малай.—Казан: «Мәгариф» нәшр., 2007.—103 б.: рәс. б-н. Тиражы—2000 данә.

Шигърияткә 80 нче елларда килгән Бикә Рәхимова унлап китап авторы. Ул өлкәннәр өчен дә, балалар өчен дә иҗат итә. Аның сүзләренә байтак көйләр язылган. Шагыйрә шулай ук публицистика өлкәсендә дә актив эшли, актуаль темаларга язылган мәкаләләре матбугатта еш күренә. Аның шигырьләренә һәм мәкаләләренә ватанпәрвәрлек хас. Б. Рәхимованың бу китабы балаларга адресланган; анда нәниләр өчен кызыклы, мавыгулы, мәзәк һәм гыйбрәтле шигырьләр тупланган.



Альберт Хәсәнов


КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)